КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА*

# Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рәмис АЙМӘТ. Галиҗәнап шигъри сүзнеке мин. *Шигырьләр.* ................ 3

Әлфис ГАЯЗОВ. Хат алышу. *Поэма.* ................ 41

Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ. Урда ханы Үзбәк. *Роман.* ................ 49

Вазыйх ФАТЫЙХОВ. Өметләр чишелми төйнәлә... *Шигырьләр.* ................ 155

Рахман ШӘФИГУЛЛИН. Шәп аттың, Галимулла! *Хикәя.* ................ 159

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Илгиз ЗӘЙНИЕВ. Чия тавы. *Драма, ике пәрдәдә.* ................ 8

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Ирина УЗДЕНОВА. Мин тау гөле, ташны тишеп шытам... *Шигырьләр*.
*(Рафис КОРБАН тәрҗемәләре.)* ................ 168

ЮБИЛЕЙЛАР

Әнвәр СӨЛӘЙМАНОВ. Ничекләр генә сагындыра әле үткәннәр... *(Башкортстанның халык шагыйре Әнгам Атнабаевның тууына – 95 ел)*. ................ 171

ФӘН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА, Алп ДЕМИРКАЯ. «Үткән белән бүгенге арасында күпер кормак мәсьәләсе бу...». ................ 178

ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ

Рәсимә НӘБИУЛЛИНА, Фәнүзә САБИРОВА, Рушания ГАББАСОВА, Никифор ТУКМАЧЁВ, Гөлчирә ИБӘТУЛЛИНА, Асия САФИНА, Мөнҗия ХӘЛИМОВА, Нурулла ГАПТУЛЛИН, Гөлшат СОЛТАНГУЛОВА *шигырьләре ( Рәсимә НӘБИУЛЛИНАның кереш сүзе белән)*. ................ 184

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Ирек хисләре җырчысы (*Камил Мотыйгыйның тууына – 140 ел)* ................ 188

Каһарманнарны күтәргән эзтабар (*Шаһинур Мостафинның тууына – 75 ел)
Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ................ 189

«Казан утлары» архивыннан. ................ 176

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ................ 190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 2 (1204) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.


---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.01.2023, график буенча 30.01.2023, басылып чыгу вакыты 03.02.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-0177. Тираж 6195.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Рәмис
Аймәт

# ГАЛИҖӘНАП ШИГЪРИ СҮЗНЕКЕ МИН

## Сүзгә эндәшү

*«Әүвәл Сүз булган...»*
Тәураттан

Егылма, Сүз! Түз! Сиңа дип язылган ошбу гомер.
Дәвам ит юлың, яраңны кысыплар бәйлим дә бер...
Кем шулай җәрәхәтләде сине, Раббыдан узып?
Юлдан яздырмакчылармы яңа язмышлар сызып?
Җиңел булырмы сиңа? Юк! Барасы юлың ерак,
Барасы юлың бормалы, чат саен утлы тозак.
Сыгылма, Сүз! Бул син горур, атла җиргә нык басып!
Атылган уктай туры бул, китсәң дә кайчак ярсып.
Җылыт туңган бәгырьләрне, җан өр син җансызларга,
Көчсезләргә көч-куәт бир, шәфкать бир кансызларга.
Коендыр дәрьяларыңда, сафлансын әле җаннар.
Чумып, дәрья төпләреннән эзлик энҗе-мәрҗәннәр.
Елама, Сүз! Күз яшьләрең күрсәтмә, зинһар, чыда.
Сүзсез калып сабыр ит син телсезлек дөньясында.
Тел очымда гел бер Сүрә тибри: «Әүвәл булган Сүз!..»
Булырсыңмы Ахырда да – җанга якын, изге, үз?

## «Уян!» дисең...

*...«Уян!» – дип кычкырам. Эндәшми.*
*«Мин синең йөрәгең ягында!!!»*
Луиза Янсуар

Кычкырасың җанны телеп: «Уян! – дисең. – Уян!»
Тугарылган хисләремне көч-хәл генә тыям.
Кайтты синең ярсу оран, далаларны урап.
Иңләде ул гарешләрне, озын сәфәр юрап.
«Уян! – дисең, – оч, канат җәй, сине көтә Күкләр.
Тансыклаган ак болытлар, садә биеклекләр».

---

Рәмис АЙМӘТ (1968) – *шагыйрь; «Шомырт салкыннары», «Айның аръягында», «Бозлы җилкәннәр» һ.б. татар, рус, төрек телләрендә дөнья күргән китаплар авторы. М.Җәлил исемендәге республика һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Очар идем... иңләп-буйлап җиде күк катларын.
Таба алмыйм – салдырганнар ап-ак канатларым.
Аунап ята алар җирдә... «Уян! – дисең. –Уян!..»
Канатларым бирәүгә дә килмәгән шул таман.
Мин очасы киңлекләрне никтер сарган сөрем.
Күкләр дәшми. Кемнән сорыйм шул сөремнең серен?
Качкан серләр, арткан керләр, даулый-даулый хаклык,
Соң чиккәчә җиткән килеп, һуштан язган Сафлык.
Саный монда һәр таш үзен, диеп, затлы ахак.
Чит бәхетләр тәхетендә хаким итә нахак.
Чүп эчендә ауный сүзләр, шик астында – эзләр.
Җилләрдә җилферди һаман манылмаган бүзләр[1].
Матурлык инде үзе дә кергәндә гүрләргә,
Ярдәм итә алмас кебек, сәмави җилләр дә.
Уяныргa? Бу бит бер дә түгел минем дөньям, –
Туңган җанны эретерлек йортым-куыш-оям.
Хәтер – уяу. Һәр мизгелне йөрәгемә уям.
Гүя канатлары талган горур бөркет сыман,
Яга-яга кимлекләрне, барлап яңа киңлекләрне,
Көч-куәт, хәл җыям...

## Татар теле

Синдә иркен дала киңлекләре,
Биеклеге чиксез күкләрнең.
Хөр авазы салкын кышлар белән
Саубуллашкан тәүге күкрәүнең.

Синдә Җир җаныннан тибеп чыккан
Чишмәләрнең талгын агышы.
Иделемдәй аккан чал тарихның
Мең табышы һәм мең ялгышы.

Синдә кар астыннан баш калкыткан
Умырзаяның тәү сулышы.
Алсу-кызыл миләш тәлгәшенең
Пешеп җиткән мәле, тулышып.

Синдә аһы кара еллардагы
Иңрәп ауган манараларның.
Еллар аша һаман җанны телеп,
Әрнүләре шул яраларның.

Синдә изге дога, иман нуры,
Моң-мәкаме сихри азанның.
Балкышлары – бөек Болгарымның,
Алкышлары – шәһре Казанның.

Синдә ап-ак энҗе-мәрҗәннәрдәй
Халкым күңеленең сафлыгы.
Кара төндә туры юл күрсәткән
Ак калфакның сүнмәс аклыгы.

Синдә ялкыны бар юлчыларга
Җан җылысы биргән учакның.
Бүз бүренең тиңсез тугрылыгы,
Кавышу өметләре Сак-Сокның.

Синдә туган якның тарту көче,
Җирсүләре мөһаҗирләрнең.
Шомлы кайтавазы – ирек даулап
Зынҗырланган гыйсъян җырларның.

Үлмәдең, юк, онытылмадың бер дә,
Сөрелеп тә туган иленнән.
Син калыктың кабат, яндырылган
Татар китаплары көленнән.

Яши синдә утлы яшен булып,
Һич онтылмый, һаман ул тере –
Чиркәү нигезендә сыкрап яткан
Кабер ташларының хәтере.

Синең җанда инде ничә тапкыр
Колмак батып, ташлар калыкты[2].
Купканда да мәхшәр, Туган телем,
Нух көймәсе булдың халыкның.

---

[1] Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең «Бүзләрем маналмадым» шигыренә ишарә.
[2] 985 елда Идел Болгарстаны белән Киев Русе арасында үзара дуслык турында солых төзелә. Килешүдә «колмак суга батканчы, таш су өстенә калыкканчы» тугрылыклы булырга дип ант ителә.

Туган телләр бакчасында үскән
Иң затлы һәм нәфис гөлем син.
Хәтта тылмачларсыз дөнья гизгән
Илаһи һәм бөек телем син.

Тере судай ашлап милләт җанын,
Син һаман да хаксыз орышта.
Сыймасаң да кайчак чиксезлеккә,
Сыясың син соңгы сулышка...

## Бүрелек

*Бүре мин...*
Рүзәл Мөхәммәтшин

Безнең канда инде бүрелектән,
Белмим, нәрсә генә калгандыр.
Тарих сынауларын кичә-кичә
Калганы да аның ялгандыр.

Телләр – кисек, заман җиле исеп
Кидерде шул канлы авызлык.
Бүрелектән безгә мирас булып
Калгандыр ла бары явызлык.

Инде күптән сөяк эремидер
Телсез-тешсез калган авызда.
Кисмәсен дип кылыч – баш иелгән,
Шәрә койрык каткан туң-бозга.

Бүре булып тулган айга карап,
Күпме генә ула, улама,
Безне инде күптән ишетмиләр,
Аларга без һаман алама.

Ә бүрелек түгел эрелек ул,
Тәкәбберлек яки мин-минлек.
Үз ыруын әгәр сатса Каган –
Кичерәсең икән хур, кимлек.

Каганнар да бездә инде күптән
Яратылмый кояш нурыннан[3].
Оешкан кан түгел, нәфрәт учлап
Туалардыр ана карынынн[4].

Әй, кайда ул дала кануннары –
Бер йодрыкта тоткан төрк илен?
Безнең канун хәзер – канунсызлык,
Чыгарбызмы кичеп үткелен?!

Чорлар аша безгә бага сыман
Ак бүренең зәңгәр күзләре.
Ул күзләрдә халкым өметләре,
Бабамнарның данлы эзләре.

Хакы бармы эреп югалырга
Раббы Үзе язган хаклыкның? –
Күкләр тарафыннан тудырылган,
Күкләр сайлап алган халыкның.

Дучар ителсәк тә җан асрарга
Чит-ят көтүләрдән сөрелеп,
Ә шулай да безгә кирәк әле
    Тугрылыкның тамга билгеседәй,
    Гаделлекнең асыл өлгеседәй,
    Бергәлекнең якты көзгеседәй,
    Явыз көч-рухларны өркетүче,
    Туры юлга безне күндерүче,
    Ирек тәмен канга сеңдерүче
Ак бүредәй изге Бү-ре-лек.

## Кагылу

*Мин сезнеке инде бөтенләйгә,*
*Яратсагыз, яратмасагыз да...*
Лена Шагыйрьҗан

Мин сезнеке була алмам инде,
Әлегә мин кара көзнеке,
Күкләр белән мине тоташтырган
Галиҗәнап шигъри сүзнеке.

Сабырлыкныкы мин, шытым биргән
орлыкныкы яңа Дәвамның; –
(Сабырлыкның сары алтыннары
Кыйммәтләрен җуйган заманның).

[3] Борынгы төркиләрнең ышануларына караганда, бөек каганнар кояш нурыннан яралганнар.
[4] Риваятьләр бәян иткәнчә, әгәр яңа туган балының учында оешкан кан булса, аны бөек киләчәк көткән.

Мин сезнеке була алмам инде,
Була алмам мәкер оясы.
Икейөзлелекнең тук битлеге,
Имансызлыкның буш кыйбласы.

Мин сезнеке була алмам инде...
Минме соң ул анда саташкан?!
Ачар өчен күңел капкагызны
Ачкыч яраштырып маташкан?!

Нигә кирәк миңа уты сүнгән
Күңелләрнең түрсез түрләре.
Мең йозакка бикле сандыкларның
Сөрсеп беткән серсез серләре.

Мин сезнеке була алмам инде,
Йола алмам гамьсез еллардан.
Заман тәгәрмәчен әйләндергән
Мәрхәмәтсез канлы куллардан.

Хәзер үземнән дә үзрәк мин,
Үзле балчыктан да үзлерәк.
Дини булмасам да, иманлы мин,
Бәлки диниләрдән изгерәк.

Кыек көзге түгел, турысы мин,
Хакыйкатьнең гадел, кырысы.
Башкаларның өлешенә тигән
Бәхетләрнең түгел угрысы.

Мин сезнеке була алмам инде,
Теләмим дә хәтта булырга.
Нигә әле нурсыз бакчагызда
Нәүмиз бер гөл булып сулырга?

Нигә бер тавышка җырлый торган
Хорыгызга кушылып «сайрарга»?
Күпме язмышларны кыяр өчен
Бердәм булып кылыч кайрарга?

Була алмам инде сезнеке мин,
Әлегә мин кара көзнеке,
Күкләр белән мине тоташтырган
Галиҗәнап шигъри сүзнеке.

***

Көзге бакча. Моңсу. Әрвах җәйгә
Җилләр ясин чыккан бер мәлдә,
И, талпынган була күбәләк-җан,
Кунган да ул сулган бер гөлгә.

И, талпынган, и, калкынган була,
Бары бер фасыллык гомеркәй.
Әйтерсең лә аны колач җәеп
Көтеп тора алда җылы җәй?!

Ул үзе дә узып барган җәйнең
Гүя соңгы канат кагышы.
Гүя аның соңгы елмаюы,
Соңгы назы, соңгы багышы.

Аның бәргәләнгән канат җиле,
Ярты юлда өзеп җырымны,
Мәңгелекнең чакыруы булып,
Йөзләремә килеп орынды.

Искәртте күк: гомер офыгында
Сүнеп барганда да Кояшың,
«Яшим!» диеп, кабат талпынып ал,
Күрсәтмичә генә күз яшең...

## Мәңгелек сагыш

...Аның белән мин күптәннән таныш,
Ул – Мәңгелек сагыш.

Бәлки мине әнкәм карынында ук
Ул үз күреп эзләп тапкандыр.
Эчке агым булып, тамырларда
Тыныч кына агып яткандыр.

Инде ничә еллар аның белән
Җитәкләшеп бергә атлыйбыз.
Җиңә-җиңә тиңсез сынауларны,
Тормыш кануннарын ятлыйбыз.

Кайчакларда җен ачуым чыгып
Куган булам аны үземнән.
Киреләнә кайчак ишәк кебек,
Кайвакытта чыкмый сүземнән.

Хәйләкәр лә үзе, көтмәгәндә
Югала да, җуя ул эзен.
Ташлап китеп, озак кайтмый торса,
Сагынып та куям мин үзен.

...Менә шундый сәер таныш ул,
Канга сеңгән «кансыз» сагыш ул.

## Югалтулар утравы

Югалтулар утравына күптән
Бер кораб та килеп туктамый.
Моң-сагышлар юа тын ярларын,
Әллә инде көтәр корабларым
юк тамы?

Шымчы җилләр, камчы җилләр генә
Нидер тентеп, таңны уята.
Туктатыплар дулкын кагышларын,
Эзлиләрме әллә табышларым
төн ката?

Дулкыннарның ябышып ялларына,
Ерткыч җилләр белән булышып,
Кайта, кайта... тәме бакый сөтнең –
Чияләнгән әче хакыйкатьнең
сулышы.

Монда һәрчак шомлы эңгер-меңгер,
Күләгәләр күккә сыена.
Һәрбер мәлнең кипкән иреннәре
Әйтерсең лә сусаганнар тере
суына.

Үкси монда үксез үкенечләр,
Сәҗдә кыла тыю-табулар,
Аһ оралар инде хәлдән тайган,
Тел очында әйтелмичә калган
«гафу»лар.

Үз әсирен эзәрлекли нахак,
Котын алып төнге утларның.
Сакау күке саный мәллә ялгыш
Сансыз гомеркәен япа-ялгыз
утрауның?

Югалтулар утравында хәтер
Черем итә мәллә? Ул беркөн
Уяныр да... сискәнешер таулар,
Гыйсъян рухы даулар әле даулар
үз иркен.

## Диңгез рухы

Тораташтай басып торам яр буенда,
Канлы җиргә чылбырланган аякларым.
Баш өстемдә тирән упкын – биек күкләр,
Китә алмыйм калдырып мин язмыш ярын.

Ымсындыра зәңгәрлеге чал диңгезнең,
Үрелепләр кулым сузам ал кояшка.
Төсе качкан кояшның да, әллә инде
Хакыйкать тә әверелгәнме тораташка?

Үләсе дә килми бер дә, яшисе дә,
Әвереләсе килми хәтта очар кошка.
Их, онтылып, шашып елап булса икән,
Башкаеңны бәрә-бәрә кыя ташка...

Буйсыныргга? Кан басымы дулкыннардай
Әле өскә менә, әле – түшә аска.
Ә дулкыннар... ярсый-ярсый кага ярга:
Буйсынмаска! Буйсынмаска!! Буйсынмаска!!!

Гыйсъян рухым, хөр җанымны дәваларга
Миңа диңгез җитмәгән лә, диңгез, диңгез.
Булса әгәр таяныплык терәк-кыям,
Булыр идем диңгезләрдәй мин дә тиңсез.



Илгиз
Зәйниев

# ЧИЯ ТАВЫ

ДРАМА, ИКЕ ПӘРДӘДӘ

**Катнашучылар:**
И л д а р
А л с у
М а р с е л ь
Л ә й с ә н
М ө н ә в ә р
Р а ф а э л ь

**БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ**

**Беренче күренеш**

*Кыш. Декабрьнең икенче яртысы. Шул кышкы күренеш уртасында район үзәкләрендә була торган гади дүрт бүлмәле йорт. Декорацияләр план сыман гына эшләнгән, без барлык бүлмәләрне бергә күрә алабыз. Өйдә бик күп кактуслар. Шул кактуслардан башка искитәрлек нәрсә юк.*

*А л с у ханым аш бүлмәсендә нидер пешереп йөри. Аңа кырык биш яшьләр тирәсе. Өстәлдә онга, камырга буялган бик күп савыт-саба.*

*И л д а р абзый кайтып керә. Аңа илле яшь тирәсе, ләкин ул картрак күренә. Авыр, арыган караш, күз асларында кара янган капчыклар. Ул шикәр чире белән авырый. Хәрәкәтләре җайсыз, зур корсаклы һәм нечкәреп калган беләкле. Аның аяклары авыртканы сизелә, соңгы араларда күзләре дә начарлана башлаган. Ул бик авырсынып кына чишенә. Аягыннан ботинкасын сала алмый интегә.*

И л д а р. Алсу...

А л с у. Әү... Кайттың дамы?..

И л д а р. Кил әле, аякны тарт...

А л с у. Хәзер, кулымны гына юыйм, кулым камырлы...

И л д а р. Әәәй... Сине көтеп ятарга...

Илгиз ЗӘЙНИЕВ (1987) – *драматург, режиссёр. М.Җәлил исемендәге премия лауреаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Бәби» исемле китап авторы. Казанда яши.*

*Ачу белән аягын селки-селки ботинкаларын салып ташлый. Йокы бүлмәсенә үтә. Алсу ханым кулларын юып чыга. Илдар абзыйның салып ташлаган ботинкаларын, куртка һәм бүреген җайлап урнаштырып куя. Яңадан кухняга үтә. Илдар абзый кальсон һәм ниндидер тузган футболка киеп чыга. Кухняга кереп, плитә өстендә торган кәстрүлләрне актара башлый.*

А л с у. Аш өлгермәгән әле, актарма...

И л д а р. Шул гомер нишләп утырдың соң?..

А л с у. Уйнап йөрдем, Илдар. Әллә өйдә эш беткән, дисеңме?

И л д а р. Телеңә салынма. Чәй булса да яса әле.

*Өстәл өстендәге нәрсәләрне эткәләп, чарасызлыктан утыра.*

А л с у. Хәзер... Каранымы, яшелнеме?

И л д а р. Нindие бар...

А л с у. Кофе алган идем...

И л д а р. Яса, яса, кофе... Мөнәвәр килдеме?

А л с у. Килде... Заменитель ничәне салырга?

И л д а р. Бир үземә...

А л с у. Тиресләрне түкте... Мә...

И л д а р. Карларны ник көрәттермәдең?

А л с у. Анысын әйтмәдең бит...

И л д а р. Вот ё-моё... Аны үзең белергә ярамыймы? Менә хәзер үзең чыгып көрәрсең... Минем аяк та калмады, эт булдым...

А л с у. Әйе менә, Илдар, мин эшсез торам бит...

И л д а р. Ярар, муеннан кар ерып йөрерсең алайса... Ипи булса да бир әле... Каймак бармы?

А л с у. Каймак юк...

И л д а р. Ике сыер асрап, өйдә каймак юк...

А л с у. Тавышланма әле... Җәмилә апа сорап кергән иде, сатып җибәрдем...

И л д а р. Акчасын бирдеме?

А л с у. Бирде.

И л д а р. Ярар алайса...

А л с у. Иртәнге ботка бар, ашыйсыңмы?..

И л д а р. Бир әле, әйдә, бир...

А л с у. Мөнәвәр, сугылырмын әле, диде. Күрәр. Синең нәрсә?

И л д а р. Нәрсә булсын. Җыен мудакны утыртып куйганнар. Давление да үлчи белмиләр... Рецепт язарга да кеше юк... Чират, кеше өстенә кеше...

А л с у. Бәйрәм алдыннан күренеп калыйк, диләрдер инде...

И л д а р. Ун көн ял ясап куйдылар да. Бөтен илләре белән дуңгыз урынына эчмәсәләр, күңелләре булмый...

А л с у. Бәйрәм бит инде. Мин әле уйлап торган идем, өйдә бер бәйрәм яме юк, чыршы булса да куйыйкмы әллә, дип...

И л д а р. Шул гына кирәк иде...

А л с у. Элек гел куя торган идек бит, күңелле була иде...

И л д а р. Балалар үскәндә куясың инде. Хәзер нәрсәгә, ылысларын коеп, тузып ятаргамы...

А л с у. Тузса, үзем җыяр идем әле...

И л д а р. Боларын җыеп бетер әле син башта...

А л с у. Сиңа калганы юк бит... Бәйрәм төсе кереп китәр иде... Элек тә бер пластмасс чыршы куйган булмады, гел чынны алып кайта идең...

И л д а р. Монда кирәгенә йөрергә дә рәт юк әле. Урман буйлап чыршы эзләп йөрисе генә калган иде...

А л с у. Базарда да саталар инде...

Мөнәвәргә әйтсәң, хәзер алып кайтып бирә...

И л д а р. Юк белән башымны катырма, бала-чага булдыңмы әллә?.. Син нәрсә белән кайныйсың әле? *(Өстәлдәге томаланган тәлинкәнең тастымалын ача. Анда камыр ризыклары.)*

А л с у. Бераз пешерим, дигән идем инде... Шикәрең күтәрелгәнме?

И л д а р. Күтәрелмичә...

А л с у. Төне буена йөрдең. Сөйләшеп яттың. Тагын шулмы?

И л д а р. Шул инде...

А л с у. Өйдә тыныч түгел... Хадичә астайга сәдака кертеп чыгармын әле...

И л д а р. Әле тагын шул придурокның эте төне буена улап чыкты.

А л с у. Бәйдә дә түгел, улый.

И л д а р. Хуҗасы кебек инде... Мылтыкны алып чыгып атармын, дигән идем, тынды. Ну, йокы качкан иде инде. Телевизор булса да кабызыйм дип, залга чыксам, басып тора инде...

А л с у. Аш үткәрергә кирәк... Әле төшеңә генә керә иде, инде өнеңдә дә...

И л д а р. Юк белән теңкәмә тимә әле... *(Нindидер баллы камыр ризыгына үрелә.)*

А л с у. Нишлисең инде? Шикәрем күтәрелгән, дисең үзең...

И л д а р. Нәрсә дип пешереп куйдың соң алайса? Кемгә дип? Юри мине котыртыргамы?

А л с у. Аш пешә хәзер, өлгерерсең.

И л д а р. Әллә апаңнар килергә тиешме?

А л с у. Юк, алар түгел...

И л д а р. Ә кем?

А л с у. Марсель кайтырга тиеш...

И л д а р. Марсель?

А л с у. Әллә малаеңның исемен оныттыңмы?

И л д а р. Әле бит, мин монда гомердә аяк басмыйм дип чыгып киткән иде.

А л с у. Тагын тавыш чыгарырсың инде...

И л д а р. Мин тавыш чыгарам-мы? Синең малаең аңгы-миңге булганга мин гаепләме?

А л с у. Мин аны җилдән тапмадым, Илдар. Бөтенесе дә син теләгәнчә генә яшәмәс...

И л д а р. Син менә шулай потакать итеп торганга шундый булды да инде ул.

А л с у. Илдар...

И л д а р. Синең ул малаең минем ярты башымны агартты... Аның кебекләр, әнә, җир җимертеп эшләп йөриләр, укыйлар, өйләнеп, балалар үстерәләр, ә ул...

А л с у. Кайгырма, ул да өйләнгән, хатыны белән кайта...

И л д а р. Нәрсә?

А л с у. Марсель хатыны белән кайта...

И л д а р. Нинди хатын?

А л с у. Өйләнгән Марсель...

И л д а р. Ә-ә. Әйбәт икән... Өйләнергә акылы җиткәч, гаиләсен ашатырга да җитсен инде. Мин аларны ашатып ятарга җыенмыйм.

А л с у. Илдар, җитте... Ходаем, бу йортта кайчан да бер тынычлык буламы, юкмы...

И л д а р. Шуңа кияүгә чыгарлык миңгерәве дә табыла бит әле аның... Озакка кайталармы?

А л с у. Белмим...

И л д а р. Судка кадәр каламы?

Ал с у. Судка бармыйм, диде бит инде...

И л д а р. Ул барса, моңарчы күптән җиңә идек инде...

А л с у. Булмас нәрсә белән йөрисең. Онытырга кирәк... Кая инде безгә. Шуңа тынычлана да алмыйсың... Бер ел буена... Шашасың бит инде...

И л д а р. Туктат әле такылдавыңны... Кайчан кайталар?

А л с у. Озакламаслар инде...

И л д а р *(нишләргә белмәгәч, кәстрүлләрне этеп җибәрә)*. Бу нәрсәләреңне юып куй инде ичмасам. Бер нәрсә эшли башласаң, бөтен дөньяны пычратасың... *(Чәнечке алып, кәстрүл янына килә.)* Ите булса да пешәме моның бүген, юкмы?..

А л с у. Өлгерерсең, миндә дә биш кул түгел...

И л д а р *(пар белән кулын пешереп, сыкранып куя)*. Сез дә дөньяда кеше булып йөрисез инде...

*Нишләргә белмичә таптанып торгач, авыр сулап куя, бер бөккән кебек нәрсәне эләктереп чыгып китә.*

**Икенче күренеш**

*И л д а р абзый зал бүлмәсендә кәнәфидә телевизор карап утыра. Аның каршында, артсыз урындыкта тәлинкә белән аш, аерым тәлинкәдә ипи, ит. Ул ашау арасында майлы кулы белән пультка баскалап, каналларны күчергәли. Кайвакыт туктап, игътибар биребрәк карый һәм тагын күчергәли башлый.*

*Л ә й с ә н килеп керә. Ул кыюсыз күренә. Ишек төбендә нишләргә белми басып тора. Бүлмәләргә таба карап, кемне дә булса күрергә тырыша. Аннан өс киемнәрен салып элә.*

И л д а р *(ишек төбендә тавышлар ишетеп)*. Кайттыңмы?.. Миңа чәй ясап керт әле...

*Ләйсән бераз аптырап кала. Аннан аш бүлмәсенә керә. Матуррак чынаяк сайлап, чәй ясый. Залга таба үтә.*

И л д а р. Капка төбендәге кибеткә дә бер сәгать йөрисең...

*Ләйсән баскан җирендә катып кала. Аннан чыгып китәргә дип борыла.*

И л д а р. Кая югалдың инде тагын?..

*Аркасы белән басып торган Ләйсәнне күреп, катып кала.*

И л д а р. Кызым... Регина...

Л ә й с ә н *(берни аңламый, борылып)*. Мин Регина түгел...

И л д а р. Әйе, юк... Юк... Ә кем соң син?

Л ә й с ә н. Мин Ләйсән... Марсельга шалтыратам, шалтыратам – не доступен. Заряднигы миндә киткән иде, батарейкасы утыргандыр, дип үзем килдем...

И л д а р. Тукта әле... Регина... Әй, Ләйсән... Син бит минем Регинаның иптәш кызы... Аптырап калдым...

Л ә й с ә н. Әйе, безне бөтенесе бутыйлар иде!.. Төс-кыяфәтебез, чәчләр... Дүрт ел бер аерылмагач, сөйләшүебез дә охшый башлаган иде инде... Мин сезгә чәй ясадым...

И л д а р. Ә... Мин бит Алсу апаң кайткан, дип торам... Кибеткә чыккан иде...

Л ә й с ә н. Шикәр алып керергә онытканмын, хәзер...

И л д а р. Кирәкми, кызым... Мин шикәр белән эчмим дә, ярамый... Болай да бик баллы шул мин! Телевизор бу бүлмәдә булганга монда керәм. Кеше юкта инде...

Л ә й с ә н. Минем әти дә шулай иде... Марсель кая соң?

И л д а р. Алар кайтмады әле.

Алсу гына әйткән иде, иптәше белән кайтырга тиешләр, дип... Әллә Марсельгә берәр йомышың бар идеме?

Л ә й с ә н. Алсу апа... Ул минем турыда әйткәндер инде...

И л д а р. Нәрсә?..

Л ә й с ә н. Марсельнең иптәше мин булам бит инде...

И л д а р. Ничек?..

Л ә й с ә н. Марсельгә, әтиәниләрең белән киңәшләшик, дип караган идем дә, аны үзегез беләсез бит инде... Кая соң әле ул?

И л д а р. Марсель кайтмады әле...

Л ә й с ә н. Ничек? Безнең автобустан төшкәнебезгә өч сәгать бит инде...

И л д а р. Белмим... Берәр яры тоткарлангандыр...

Л ә й с ә н. Ничектер уңайсыз килеп чыкты...

И л д а р. Әйе шул... Сөйләшүләрегез дә охшаган... Аптырап калдым башта...

Л ә й с ә н. Регина беләнме? Без юри шулай эшли идек. Кызык иде...

*А л с у ханым килеп керә. Ләйсәннең аяк киемен күреп, шундук кунак барын аңлап ала.*

А л с у. И Ходаем... Кайттыгыз дамы әллә?! Кибеткә генә чыгып керим, дигән идем. Марсель сыр ярата бит, сыр алып кайтырга оныткаммын... *(Сөйләнеп, залга үтә.)* Исәнме, кызым!

Л ә й с ә н. Әни, исәнме!

А л с у. Якындагы кибет ябылган. Тегендәрәк барырга туры килде. Әле бит уйлап барам, мәйтәм, хәзер мин чыгып киткәч кенә кайтып керәләр инде болар. Сизенеп барам... Марсель кая соң әле? Үзендәме әллә? Монда чагында шулай кереп бикләнә торган иде... Улым!.. *(Марсельның бүлмәсен ачып карый.)* Кая соң Марсель?

И л д а р. Кереп өлгермәдең, мең сүз әйттең, бытбылдык... Чәйләреңне кара...

А л с у. Барысы да әзер анда!.. Марсель кая соң?

Л ә й с ә н. Ул әле кайтып җитмәгән икән...

А л с у. Ничек инде? Илдар, син өсләреңне алыштыр инде...

И л д а р *(хәзер генә үзенең нинди кыяфәттә басып торганын аңлап)*. Японский городовой. Нәрсә мыңгерәп торам соң әле... *(Кулындагы чынаякны кая куярга белмәгәч, Алсуга суза.)* Мә әле, мә... Миңгерәдем... *(Урындыктагы тәлинкәләргә күрсәтеп.)* Җый әле боларны... *(Үз бүлмәләренә кереп китә.)*

А л с у. Кызым, ничек кайтып җиттегез? Марсель кая соң? Мунчага төшмәгәндер бит әле?

Л ә й с ә н. Ул кайтмаган әле. Без автобустан өч сәгать элек төшкән идек. Ул миңа, башта туган апаларыңа кереп чык, диде. Минем бит монда туганнарым бар, беләсез инде. Мин шуларга киттем. Ул кайтырга тиеш иде. Шалтыратам – не доступен. Килдем – монда юк. Сумкаларны алып киткән иде ул...

А л с у. Кая туктап калды икән инде? Алай кеше белән әллә ни сөйләшеп тора торган гадәте дә юк иде...

Л ә й с ә н. Илдар абый мине Регина белән бутады...

А л с у *(«Сөйләмә дә инде», дигәндәй ишарә ясый)*. Төннәрен йоклый алмый, гел Регинаны күрәм, ди... Охшагансыз да бит... Әйдә әле, чәй эчик...

*Аш бүлмәсенә үтәләр.*

Л ә й с ә н. Әни, мин үзем, син утыр.

А л с у *(өстәл янына утырып)*. Регинаның бүлмәсендә бер нәрсәгә тидертми. Кактусларына да үзе су сибә... Марсель кая икән соң? Аның аягы һаман авыртамы?

Л ә й с ә н. Зарлана... Үзегезнең исәнлекләр ничек?

А л с у. Без шул бер көе инде. Илдар гына: әле кан басымы күтәрелә, әле шикәре... Эшеннән нигә чыгардылар соң?

Л ә й с ә н. Чыгардылар, дип... Мин аның кая эшләгәнен дә белмим... Иртән чыгып китә, кич кайта торган иде... Акчасы да әллә ни...

А л с у. Ай Аллам... Нинди акчага яшәдегез соң, балам?

Л ә й с ә н. Мин эшлим бит... Аннан шул сез җибәреп торган белән инде...

А л с у. Син анысын Илдар алдында ычкындыра күрмә...

*И л д а р абзый килеп керә. Ул киемнәрен алмаштырган.*

И л д а р. Нәрсәне минем алда әйтергә ярамый ул?!

А л с у. Марсельнең... Аягы һаман авырта, ди... Син бит ачуланасың...

И л д а р. Ачуланмаска. Кем кушкан аңа машинада чабарга? Әллә эш эшләп имгәнгәнме? Машина алып бирик дип, миемне корыттың, әнә, нәрсә булды...

А л с у. Ярар, башлама инде... Егет кеше...

И л д а р. Егет кеше элек баш белән уйлый... Теләсә кемгә тагылып...

А л с у. Илдар...

И л д а р. Хәзерге егетләрен әйтер идем. Без студент чакта эшләмәгән эш юк иде... Минем үземнең бригада. Эш белешеп киләм дә китәбез. Вагон бушатыргамы, порттта берәр нәрсә төяргәме... Аннан тагын кем кочегар, кем охран... Төне буе капчык ташый идек, чурт та булмады... Бервакыт карбыз бушаттык. Анда йөздек инде... Общежитиеда безнең этаж идәне гел карбыз кабыгы белән тулган була иде!.. Бар иде яшь чаклар... Бөтен общежитиены кулда тотып тора идем. Мишка бар иде, Панкратов, Пермьнән... Ике метрга якын буе, җилкә, мин сиңа әйтим...

А л с у. Коры чәй генә эчеп утырма әле. Менә сезгә дип пешергән идем, эремчек пирогы...

Л ә й с ә н. Рәхмәт...

И л д а р. Ну, малай, гайрәт тә иде үзендә. Шул минем бүлмәгә исереп килеп кергән. Каядыр эчкән дә инде, җитмәгән моңа...

А л с у. Сизденме?!

Л ә й с ә н. Ванилин кушкан идеңме әллә?

А л с у. Әйе, чеметем генә. Тәме бөтенләй башка!

Л ә й с ә н. Әйе, шул!..

И л д а р. Шул... Нәрсәдер кычкырырга тотынган иде теге, чалып ектым да... Минем менә шуның буйлы пычагым бар иде... Муенына терәп куйдым тегенең. Мәйтәм, авылда байтак кына сарык чалдым, син сарыкны да ике уйлап тормыйм! Бетте теге...

*Ишеккә шакыйлар. Ишек ачыла.*

Л ә й с ә н. Кайтты бугай!..

*Л ә й с ә н белән А л с у ишек төбенә чабып чыгалар. Ишектән М ө н ә в ә р керә.*

А л с у. Улым, кая...

М ө н ә в ә р. Апа, исәнме?

А л с у. Син икәнсең әле.

М ө н ә в ә р. Абзый өйдәме?

А л с у. Илдар, Мөнәвәр килгән.

И л д а р *(чыгып)*. Ә-ә... Ярый... Сез, ни, чәйләрегез суынадыр...

А л с у. Әйдә, кызым... *(Аш бүлмәсенә чыгалар.)*

М ө н ә в ә р. Нихәл, абзый?! Исәнлекләр ничек? Күрендеңме врачка?

И л д а р. Ул мудакларга күренгән белән... Алар кадәр генә үзем дә беләм мин...

М ө н ә в ә р. Үз чиреңне үзең әйбәтрәк беләсең инде... Кунакларыгыз бармы әллә?

И л д а р. Малай кайтты, хатыны белән...

М ө н ә в ә р. Ә-ә! Марсель өйләнгән дәмени? Нишләп күрешергә чыкмый?

И л д а р. Юлдан, арыган, ятып тора... Син карларны да күрәмәгәнсең...

М ө н ә в ә р. Мин аны күрдем дә, апа берни әйтмәгәч...

И л д а р. Хатын-кызга нәрсә аңа. Хәзер соң, иртәгә кереп чыгарсың инде...

М ө н ә в ә р. Марсель кайткан бит, өч бөртек карны гына күрәр инде...

И л д а р. Аның аягы бит...

М ө н ә в ә р. Ярар... Абзый, минем баш тегеләйрәк иде бит...

И л д а р. Шулай булмаса, кермисең дә син...

М ө н ә в ә р. Духтырым син булгач, кая барыйм инде!? Син дә бит, әнә, берәр җирең авыртса, врачка күренәсең!

И л д а р. Алсу!

А л с у *(чыгып)*. Әйе...

И л д а р. Синең бардыр бит анда?..

А л с у. Хәзер...

И л д а р. Хәзер бер эчкәч, китәсең инде син.

М ө н ә в ә р. Курыкма, абзый, иртәгә иртүк килеп җитәм.

А л с у *(банкадагы спиртны стаканга сала, аңа су куша. Ләйсәнгә)*. Мөнәвәр безгә килеп, булышкалап йөри. Эчүен эчә инде, үзе болай әйбәт кеше...

Л ә й с ә н. Ә...

А л с у *(стакан белән кабымлык алып чыгып)*. Мә...

И л д а р. Бар син, бар... Мә...

М ө н ә в ә р. Сезнең исәнлеккә! *(Эчеп куя.)* Булды бу! Рәхмәт! Иртәгә киләм...

И л д а р. Карарбыз. Бар.

*Мөнәвәр ишеккә борыла. Ишек ачылып китә. Әллә суыктан, әллә бераз төшереп алганнан кып-кызыл М а р с е л ь килеп керә.*

М а р с е л ь. О! Мөнәвәр абый, сәлам! Ничек хәлләрең?

М ө н ә в ә р. Исәнме! Әйбәт кенә! Исән-сау гына кайтып җиттегезме?

М а р с е л ь. Кайттык.

М ө н ә в ә р. Тагы да ябыккансыңмы соң?

М а р с е л ь. Бардыр инде...

А л с у. Марсельнең тавышымы соң, әллә ишетелә башладымы?..

Л ә й с ә н. Миңа да шулай тоелды...

М ө н ә в ә р. Ярар, мин чыгыйм. Сине юлдан арып кайткан, дигәннәр иде! Керермен әле, сөйләшербез...

М а р с е л ь. Ыхы!

*М ө н ә в ә р китә. Л ә й с ә н белән А л с у чыгалар.*

М а р с е л ь. Сәлам, эти...

И л д а р. Исәнме, улым! *(Аны кочаклап ала.)*

А л с у. Әй, улым, сагындырып кына йөрисең! Кил әле, бер кочаклыйм! Ябыгып беткән...

М а р с е л ь. Сәлам, әни!.. *(Ләйсәнгә.)* Син килдең дәмени?

Л ә й с ә н. Мин сине кайтып җиткәнсеңдер, дип торам...

А л с у. Кая йөрдең, улым, нишләп туры өйгә кайтмадың?

И л д а р. Туктагыз инде, кешене ишек төбендә бастырып тотмагыз...

М а р с е л ь. Русланны очраттым. Аның малае туган икән...

Л ә й с ә н. Кайсы Руслан?

И л д а р. Зариповтыр инде...

Л ә й с ә н. Ул укып бетердемени? Укып бетермичә өйләнмим дигән иде.

А л с у. Бабасы укытып чыгарды инде...

И л д а р. Теге «Нур» кибете хуҗасының кызына өйләнде бит... Алсу, әйдә, чәйләр эчерт, ишек төбендә тормагыз...

М а р с е л ь. Әни, мунча яккан-мы?

А л с у. Яккан, улым, яккан. Чәйләр эчәрсез дә мунчага төшәрсез... Әйдәгез, әйдә!..

*А л с у белән И л д а р аш бүлмәсенә үтәләр.*

Л ә й с ә н. Ник телефоныңны сүндердең? Мин, как дура, килеп кердем, ни әйтергә белми басып торам монда...

М а р с е л ь. Батарейка беткән. Зарядник синдәме? Бирерсең әле. Миңа шалтыратырга тиешләр.

Л ә й с ә н. Кем?

М а р с е л ь. Эш буенча.

Л ә й с ә н. Минем сумкада, хәзер алып бирәм...

М а р с е л ь. Үзем алам, син бар, утыр.

Л ә й с ә н. Кызыл сумка кая соң? Күчтәнәчләрне алыйк әле...

М а р с е л ь. Кая соң ул?.. Чёрт... Русланның багажнигында калган...

Л ә й с ә н. Марсель...

М а р с е л ь. Нәрсә, Марсель? Юри калдырдыммы әллә? Иртәгә алырбыз... Өйдә чәй бетмәгәндер әле...

Л ә й с ә н. Күчтәнәч бит ул...

М а р с е л ь. Күчтәнәч, күчтәнәч... Бар әле, утыр...

*Л ә й с ә н аш бүлмәсенә чыга, М а р с е л ь үз бүлмәсенә кереп китә.*

А л с у. Марсель кая?!

Л ә й с ә н. Өсләрен алмаштыра, хәзер чыгар...

А л с у. Ябык инде. Монда да ашавы юк иде, хәзер бөтенләй кипкән...

И л д а р. Мин яшь чакта Марсельдән дә ябык идем! Клёш чалбарлар, чәч – җилкәдән! Нәрсә генә кыланмый идек инде!..

А л с у. Автобуста авыр булмагандыр бит? Марсель бик арыган күренә...

Л ә й с ә н. Марсель йоклап кайтты ул...

И л д а р. Автобус юньле нәрсә түгел инде... Менә поездда рәхәт. Күпме йөрдем мин поездларда. Иң яратканым, поездда чәй эчү иде. Анда гранёный стаканны подстаканникка утыртып, баллы чәй бирәләр иде! Андый чәй беркайда да юк... Хәзер дә шулаймы икән? Күптән йөргән юк.

Л ә й с ә н. Мин узган ел Анапага барган идем. Без арзанлы вагонда бардык. Подстаканниклар пластмасс иде. Чәе дә тәмле түгел...

И л д а р. Хәзер юктыр шул... Бәлки, элек тә тәмле булмагандыр, юлда булганга гына шулай тоелгандыр. Ләкин, бик тәмле кебек истә калган!.. Берьюлы шулай кайтабыз. Купеда мин, тагын бер иптәшем һәм бер офицер. Бу офицер берзаман безнең дәүләт политикасы, җитәкчеләр турында күңелендә булганнарын

сөйли башламасынмы. Эһе, мин әйтәм!..

А л с у. Чәе суынып бетә инде...

И л д а р. Иптәшем, Коля седых, бик әйбәт малай иде, батырып үтерделәр. Шуңа караш кына ташладым, теге аңлап алды. Коляның үзе белән магнитофоны бар иде. Ул вакытта безгә загранкадан алып кайталар иде, японскийларны. Шуның өчен батырдылар да инде аны, ул заманда шулай иде бит... Теге кабызып куйды, сиздермичә генә... Офицерыбыз сүзен сөйләп бетерде. Коля магнитофонны чыгарып күрсәтте. Мин – корочканы. Ул вакытта минем «внештатный сотрудник комитета государственной безопасности» корочкасы бар иде... Үлде офицерыбыз. Свердловскига кадәр безгә «Арарат» кына эчертеп барды...

*Шорты кигән М а р с е л ь чыга. Кулында пакет.*

А л с у. Улым, чәең суынып бетте бит инде...

М а р с е л ь. Мунчада сөлге бармы?

А л с у. Әллә мунчага төшәсеңме?

Л ә й с ә н. Чәй эч инде башта... Без сине көтәбез бит...

М а р с е л ь *(шкафтан сыра бокалы алып, пакетына сала)*. Эчәсем килми әле... Син барасыңмы?

Л ә й с ә н. Соң бит инде...

М а р с е л ь. Үзеңә кара...

А л с у. Пироглар пешергән идем...

М а р с е л ь. Әни, минем ашыйсым килми...

И л д а р. Ярар, чәйләрне мунчадан соң эчәр. Пары беткәнче кереп чыксын...

А л с у. Сөлгеләр куйган анда, минлек пешердем...

М а р с е л ь. Ярар...

*Марсель чыгып китә. Уңайсыз тынлыкта калалар.*

И л д а р. Әй, мин яшь чакта чабына да идем! Иң беренче булып төшә идем. Бөтенесе кереп чыкканчы хәл җыеп, ахырда тагы бер кереп чыга торган идем. Хәзер шул эссе мунчага кереп булмый...

**Өченче күренеш**

*Төн. И л д а р абзый зал бүлмәсендә телевизор кабызып, кәнәфидә йоклап киткән. Ул бик тынгысыз йоклый.*

*Марсельның бүлмәсеннән Л ә й с ә н чыга. Ул залга күз сала. Аннан Регина бүлмәсенә керә. Ут кабыза. Бүлмәдәге кактусларга, диварлардагы фотоларга, йомшак уенчыкларга күз сала. Бер уенчыкны тотып, караватка утыра. Аннан өстәл тартмасын ачып карый. Аннан музыкаль шкатулка һәм көндәлек дәфтәре ала. Башта аның эчендәге кипкән яфрак һәм берничә чәчәкне алып карый. Шуннан укый башлый. Бераз укыгач, көндәлек эченнән фото килеп чыга. Аларның бергә төшкән фотолары. Ул елап җибәрә. Музыкаль шкатулканы ача, аннан «К Элизе» яңгырый. Фарфор балеринаны бастырып куя. Балерина шул музыкага шуып, әйләнеп йөри башлый. Ләйсән фотога карап ята, бераздан йоклап китә.*

*Илдар абзый төш күрә. Аның төшенә тау бите керә. Анда чия агачлары. Бу – чия тавы. Шул агачлар арасында бер к ы з биеп йөри, шуннан юк була... Илдар абзый саташып уяна. Уянгач та, ул моның өнме, төшме икәнлеген аңлый алмый. Телевизорын сүндерә. Көйне ишетә. Шуннан идәндә Регина бүлмәсеннән төшеп торган ут яктысын күреп ала. Ул әле*

*дә өн белән төш арасында. Нәрсәнедер күрми калудан курыккан сыман, ашыгып, шул утка таба юнәлә. Бүлмәгә күз сала. Караватта йоклап яткан Ләйсәнне күреп коелып төшә. Калтыранып, аның янына килә. Караватa каршында тезләнә. Озак кына карап тора. Аннан торып, юрган алып, аның өстенә яба. Карап, сокланып тора, аның иреннәре селкенә, күрәсең, ул нидер сөйләргә тырыша, ләкин авазлары ишетелми. Ләйсәнне чәченнән сыйпый. Ләйсән уянып китә. Каршындагы Илдар абзыйны күреп, башта куркып китә.*

Л ә й с ә н. Әти... Мин йоклап киткәнмен...

И л д а р. Юк, юк, уянма, кызым, йокла, йокла... Мин монда...

Л ә й с ә н. Теге бүлмәдә йокы алмады, ә монда...

И л д а р. Үз урыныңда рәхәт ул. Йокла, кызым...

Л ә й с ә н. Әти...

И л д а р. Әү, кызым!

Л ә й с ә н. Бу мин, Ләйсән...

И л д а р. Әйе, кызым... Регина, син йокла...

Л ә й с ә н *(елый)*. Илдар абый...

И л д а р. Әйе... Әйе, кызым... Беләм, Ләйсән кызым... Регина юк, ул үлде... Саташуым түгел... Юк... Мин беләм, син Регина түгел... Сез шундый охшагансыз... Ул да шулай йоклап китә торган иде, мин кереп, утын сүндереп чыга идем.

Л ә й с ә н. Әллә ничек...

И л д а р. Нәрсә?

Л ә й с ә н. Регинаның булмавын күз алдыма китерә алмыйм... Үлем минем өчен һәрвакыт картлык белән бәйле булырга тиеш кебек иде... Яшьтәшләремне югалтканым юк иде...

И л д а р. Әйе, үлем картлар өчен уйлап чыгарылган нәрсә дә бит... Картлар үләргә тиеш, картлар...

Л ә й с ә н. Бу безнең Петербургта төшкән фото... Регина фотода гел матур чыга иде...

И л д а р. Әйе... Кечкенәдән фотога төшәргә ярата иде... Ә хәзер... *(Тартмадан калын альбом тартып чыгара.)* Менә... Регина бөтен булган фотоларны җыеп, гаилә альбомы ясаган иде... Монда әби-бабайлар... Апайлар...

Л ә й с ә н. Ә бу егет кем?

И л д а р. Танымыйсыңмы?

Л ә й с ә н. Белмим... Сезме әллә?!

И л д а р. Охшамаганмы?! Әллә мине гел шундый капкорсаклы идем дип уйлыйсыңмы?! Әйтәм бит, Марсельдан да ябык идем...

Л ә й с ә н. Марсель тазарак шул! Башка кеше әйтсә, ышанмас идем...

И л д а р. Без ябыграк идек тә, ныграк идек шул, хәзергеләр тумый картайганнар... Минем яшь чактагы фотолар байтак иде дә, гел кызлар белән төшкән булгач, Алсу апаң юк итеп бетерде аларны!

Л ә й с ә н. Ә!

И л д а р. Көнләшә иде. Минем бөтен пластинкаларны, бабиналарны чыгарып атты. Ә анда Boney m77, Abba, Полад Бюльбюль-Оглылар... Бөтен яшь чактагы музыкаларны харап итте. Кайчак тыңлыйсы килә, ә юк...

Л ә й с ә н. Ой, ә бу кем?

И л д а р. Регина. Беренче фотосы! Монысы Марсель, чаптырып ята...

Л ә й с ә н. Алсу апа шундый яшь!.. Марсель... Сез... Регина... Бу балык тоткандамы?

И л д а р. Әйе! Марсель кечкенә чагында балык тотарга ярата иде...

Л ә й с ә н. Ул монда шундый бәхетле! Елмая!

И л д а р. Ул вакытта без бөтенләй башкача аралаша идек. Хәзер, күреп торасың бит инде, ничектер бер-беребезне аңламый башладык.

Л ә й с ә н. Марсель сезне ярата...

И л д а р. Регина мине ярата иде... Үзем гаепле... Мин бит аларның ничек үскәннәрен күрми дә калдым. Бала тәрбияләүне күп акча эшләп, аларга бөтен кирәк-яракны табу дип кенә уйлаганмын... Ялгышканмын... Менә бу шкатулканы командировкадан алып кайткан идем аңа. Вокзалда сатып алдым. Ат бәясе тора иде, ә алдым. Төн уртасында кайтып кереп, уятып, сиңа бүләк иттем. Хәтерлисеңме?

Л ә й с ә н. Мин...

И л д а р. Әйе, әйе... Ул үзе дә шул балерина сыман иде, балакаем...

*Пауза. Биеп әйләнүче балеринага карап торалар.*

Л ә й с ә н. И! Бу кем куян булып киенгән?!

И л д а р. Марсель! Регина – тиен! Әнә, шулай Кыш бабай булып киенеп котлый идем мин аларны...

Л ә й с ә н. Яңа ел да җитә бит...

И л д а р. Әйе... Икенче Яңа ел... Регина Яңа елга безгә бирәр сюрприз әзерли иде... Мин аны һәркөнне күрәмдер шикелле... Ул мине ярата иде... Юк, син курыкма!.. Мин саташмыйм... Тынычлана гына алмыйм... Киләсе елга барысы да башкача булачак...

Л ә й с ә н. Ничек тә тынычланырга кирәк. Аңа анда рәхәтрәктер...

И л д а р. Ике тормыш арасында эленеп калдым шул мин... Яратмыйм бу посёлокны. Монда кайтып кына харап булдым мин... Яратмыйм. Ни авыл түгел, ни – шәһәр... Шуңа яшәве дә – әллә яшисең, әллә юк. Вакыт үткәрү. Кешеләре икеле-микеле... Монда кайтканчы, үз авылыма гына кайткан булсам...

Л ә й с ә н. Сезнең авыл кайда соң?

И л д а р. Ерак, республиканың икенче читендә... Егерме еллап кайткан юк инде... Бу – хатынның районы. Ул инде... Монда кайтыйк дип тинтерәтте... Аның туганнары монда. Безнең авылда беркем калмады инде, чыбык очлары гына... Ә шулай да авылга кайтасы килә. Безнең таулы як. Матур. Аръякта чия тавы бар...

Л ә й с ә н. Чия тавы?

И л д а р. Әйе... Тау битендә урман кебек чияләр үсә. Яз көннәрен күз алдыңа китерәсеңме?!

Л ә й с ә н. Ап-актыр!

И л д а р. Матур инде, галәмәт. Яшел чирәмгә ак кар яуган кебек. Тау бите дә булгач, кар дивары төзелеп куелган, диярсең. Керәсең дә чумасың. Башка дөнья.

Л ә й с ә н. Япония сакуралары күз алдына килде.

И л д а р. Японияне белмим, ә чия тавы хәтердә... Шунда кайтасым килә... Чия тавының һавасын сулыйсым килә... Чия төбенә ятып, умарта кортларын тыңлап ятасы килә... Бик зурдан кубып, тормыш итә башлаган идем бит мин. Атасыз малай булуга карамастан, үз акылым белән зур урыннарга урнаша алдым... Өч йөз кеше иде минем кул астында... Аннан туган яклар дип, монда кайттым, дивана... Ә монда тормыш туктаган... Нервыланып, ничектер сәламәтлекне югалттым... Шунда инде башка берни дә майтара алмаячагымны аңладым. Балалар зур эшләр эшли алса гына дип, аларның тәрбиясенә тотынмакчы идем, соңарганмын... Алар инде үз юлларын ярганнар иде... Аннан бу посёлок Регинаны тартып алды... Мин аңа Чия тавын да күрсәтә ал-

мый калдым, ел саен кайтып киләбез дип хыяллана идек... Ә бит башкачарак булырга тиеш иде...

Л ә й с ә н. Нәрсә ул?..

И л д а р. Кая?

Л ә й с ә н. Ишетәсезме?

И л д а р. Ә... Курыкма, кызым... Күршенең эте улый...

Л ә й с ә н. Әллә ничек... Бүре тавышы кебек...

И л д а р. Соңгы арада шулай безнең капка төбенә килеп улый, үзем дә төне буена йоклый алмый ятам... Куркытырга чykканчы, юк була...

М а р с е л ь *(кереп)*. Нишлисең монда?

Л ә й с ә н. Йоклап китә алмагач кергән идем, монда изрәп киткәнмен... Син уяндыңмыни?

М а р с е л ь. Уянмаска... Нәрсә улый ул анда?..

И л д а р. Маратның эте...

М а р с е л ь. Ул эт һаман исәнмени? Минем белән бер яшьлек бугай инде ул...

И л д а р. Әҗәлен эзләп йөрүедер инде. Төне буе шулай нервыны ашап чыга... Хәзер, куркытып керим әле... Алайса, йокы бирми ул сезгә... Каһәр суккан, бәйдә дә түгел бит инде... *(Чыгып китә.)*

М а р с е л ь. Әйдә, ятабыз...

Л ә й с ә н. Марсель...

М а р с е л ь. Нәрсә?

Л ә й с ә н. Син әтиең белән сөйләш инде...

М а р с е л ь. Сөйләшәм бит...

Л ә й с ә н. Әти белән алай сөйләшмиләр... Хәлләрен булса да сора, күңеле булыр...

М а р с е л ь. Мин аның күңелен күрергә кайтмадым...

Л ә й с ә н. Марсель...

М а р с е л ь. Башка монда кереп йөрмә. Күрмисеңмени, музей ясаганнар бит, мавзолей...

Л ә й с ә н. Марсель, аңа авыр. Ул, Регинаны күрәм, ди... Ул мине Регина дип уйлый. Мин куркам... Мин аның кем белән сөйләшкәнен аңламыйм. Ул минем кем икәнемне бер аңлыйдыр, бер аңламыйдыр кебек, кабат Регина дип эндәшеп куя...

М а р с е л ь. Мин бит сине кисәтеп куйдым. Игътибар итмә... Ул болай да нормаль түгел иде, саташа башлаган...

Л ә й с ә н. Ул бит синең әтиең!

М а р с е л ь. Беләм, әйткәннәре бар!..

Л ә й с ә н. Әниең көне буена пешергән, әзерләнгән. Син өстәл янына утырып, бер кисәк пирог белән чәй дә эчмәдең...

М а р с е л ь. Минем ашыйсым килми иде...

Л ә й с ә н. Ашыйсы килүдәмени эш?..

М а р с е л ь. Не доставай, а. Әйдә, ятабыз... Әйдә, дим... Нәрсә утырасың? Әллә картның әкиятләре ошап киттеме?! Әле мең ишетерсең, ул барысына да шуны сөйли...

Л ә й с ә н. Ул – синең әтиең... Син болай кыланып, мине авыр хәлгә куясың...

М а р с е л ь. Сиңа нәрсә инде...

Л ә й с ә н. Әгәр дә үзеңне кешечә тота белмәсәң, мин иртәгә китәм... *(Чыгып китә.)*

М а р с е л ь. Шул гына кирәк иде...

*И л д а р абзый әйләнеп керә. М а р с е л ь балеринаны күзәтеп тора.*

И л д а р. Улый-улый да, куам дип чыга башласаң, чыгып җиткәнче юк була. Эзе дә юк... Чыккан саен бер чит кара машина гына тора безне узыбрак...

М а р с е л ь. Кара машина?.. *(Пәрдәне ачып, тәрәзәдән карый.)*

И л д а р. Тагын улый инде... Каһәр суккан, хуҗасы нинди – эте шундый. Мылтыкны алып чыгып атармын әле...

М а р с е л ь. Атмыйсың бит инде...

И л д а р. Ничек инде?..

М а р с е л ь. Син ничә еллар буена атам да атам дип сөйләнәсең, бер атканыңны күргән юк...

И л д а р. Әле бит болай улаганы юк иде...

М а р с е л ь. Башта хуҗасын атам дип яный идең...

И л д а р. Сез озакка кайттыгызмы?

М а р с е л ь. Туйдың дамы әллә?

И л д а р. Вот ё-моё! Эш буенча сорыйм.

М а р с е л ь. Мөнәвәр бөтен эшләрегезне эшләп тора түгелме соң?

И л д а р. Мөнәвәр эшләгән эш – эшмени ул. Нәрсә турында әйткәнне беләсең бит.

М а р с е л ь. Белмим.

И л д а р. Башыңны җүләргә салма. Тиздән суд.

М а р с е л ь. Бетмәдемени әле бу?

И л д а р. Бетмәде. Мин аны барыбер утыртам.

М а р с е л ь. Утырткан, ди.

И л д а р. Син барасыңмы судка?

М а р с е л ь. Юк белән йөрисең. Аларга каршы бара алмаганыңны аңлыйсың бит. Тынычлан.

И л д а р. Ул синең сеңлеңнең үлемендә гаепле... Мин аңа җәзасын бирмичә тынычланмыйм.

М а р с е л ь. Кем гаепле булса да, Регина юк инде.

И л д а р. Мин аны күрәм...

М а р с е л ь. Күрәсең инде... Мавзолей ясап куйгансың да. Аңа да тынычлык юк, үзеңә дә.

И л д а р. Аның жаны тыныч түгел...

М а р с е л ь. Син үз җаныңны кайгырт. Аңа хәзер барыбер инде.

И л д а р. Сиңа да барыберме?

М а р с е л ь. Регина үлде дип, миңа да үләргәме инде хәзер?

И л д а р. Сиңа үләргә кушкан кеше бармыни? Яшә. Кешечә.

М а р с е л ь. Кешечә яшәрлек тормыш әзерләп куймагансыз шул.

И л д а р. Синеңчә, кешечә яшәү – типтереп яшәү буламы?

М а р с е л ь. Әйдә, ятыйк әле...

И л д а р. Барасыңмы судка?

М а р с е л ь. Ник син гел хәлеңнән килмәгән нәрсә белән булышасың? Аларга каршы судны җиңеп чыгып булмаганны беләсең бит...

И л д а р. Син бит күрдең...

М а р с е л ь. Мин нәрсә күрмәм... Көпә-көндез Фиркать абыйны бәреп киттеләр – Фиркать исерек булган... Азатны ничәү кыйнап, дивана ясап калдырдылар... Боларны беркем күрмәгәнме? Күргән. Барысын да күреп торалар. Туксанынчы елларда аталары Әмзә урманына күпме кешене ташыган, күпмесен май заводы котельныенда яндырган. Аларны күрмәгәннәрме? Барысын да күргәннәр, күрәләр, беләләр.

И л д а р. Әйтүче генә юк...

М а р с е л ь. Ә беләсеңме ник?

И л д а р. Ник?

М а р с е л ь. Чөнки алар көчле. Бөтен район хәзер алар кулында.

И л д а р. Көчлегә дә закон булырга тиеш.

М а р с е л ь. Көчлегә закон була алмый. Закон ул уйдырма гына. Закон көчсезләрне көчле булудан тыеп тору өчен уйлап чыгарылган... Нишләп табигатьтә көчленең көчсезне ашарга хакы бар, ә кешеләр арасында булмаска тиеш, ди? Бер сарыкның да «ул безне ашый» дип, бүрене судка биргәне юк.

И л д а р. Димәк, мин – сарык...

М а р с е л ь. Син түгел, без. Күпчелек. Шуңа без күбәү дә инде. Бүреләргә җитәрлек булсын өчен.

И л д а р. Синеңчә, нишләргә кала инде безгә?

М а р с е л ь. Акыллы булырга. Хайваннарның гына сайлау мөмкинлеге юк. Ә безнең бар. Без, акыллы булсак, сарыктан бүрегә әйләнә алабыз. Ерткычлар белән сугышмаска, килешеп, аларга иптәш булырга, ерткыч булырга...

И л д а р. Күтеп торалар ди анда сине. Талашмыйча, сугышмыйча гына үз ишләре иткәннәр, ди. Авызларыннан тартып алмасаң, үзләре китереп биргәннәр, ди.

М а р с е л ь. Гомерең буена талаштың инде. Бөтен җирдә җитәкчеләр белән дә, власть белән дә. Гомер буе телевизордагыларны сүктең. Бөтен дөньясыннан акыллы булдың. Тик нишләптер син һаман җимерек диваныңда утырасың, ә алар телевизорда. Берсе дә Илдар янына килеп, киңәш сорамый...

И л д а р. Синең бүре буласың килә инде, димәк...

М а р с е л ь. Минем йокым килә.

И л д а р. Теләсә кемгә иптәш булганчы, ялгыз булуың мең артык... Бүреләр бик сирәк ул... Бүреләрнең токымын корыттылар инде... Бүре булам дип, шакал була күрмә.

М а р с е л ь. Сарык булганчы, шакал булуың мең артык. Белгәнемчә, шакалны берәү дә ауламый, берәү дә ашамый.

И л д а р. Ауламый да, хөрмәт тә итми.

М а р с е л ь. Миңа хөрмәт кирәкми, курыксалар, шул җитә.

И л д а р. Барасыңмы судка?

М а р с е л ь. Киттем, ятам...

*М а р с е л ь чыгып китә. И л д а р басып кала. Аның сөйләшергә исәбе бар кебек, ләкин барысы да инде ятканнар. Р е г и н а бүлмәсенә кереп утны яндыра. Аннан сүндерә.*

**Дүртенче күренеш.**

*Икенче көн. Аш бүлмәсендә өстәл янында М ө н ә в ә р утыра. Аның каршысында А л с у. Мөнәвәргә ашарга салганнар, ул чемченеп утыра. Л ә й с ә н идән юа. Мөнәвәр күз кырые белән генә бөгелгән-сыгылган арада аны күзәтә.*

А л с у. Гомере буена җикеренде. Гомере буена кизәнде... Һава кыйнады... Шулкадәр мөмкинлекләр бар иде. Холкы аркасында, ни көнгә калдык инде. Малайга фатир да алып бирә алмыйбыз. Сөт-каймак сатып ятабыз... Шул яшемә җитеп, өстән сасы фуфайканы сала алмыйм...

*Л ә й с ә н бу сүзләр М ө н ә в ә р алдында сөйләнгәнгә читенсенә.*

А л с у. Үзенә нәрсә аның, чыгып та караганы юк...

Л ә й с ә н. Әтинең саулыгы юк бит инде, әни.

А л с у. Минеке бармы?

Л ә й с ә н. Сез безнең турыда борчылмагыз. Бу яшьтә без сезне кайгыртырга тиеш инде, сез безне түгел...

А л с у. Кая сез безне кайгыртасыз инде. Һаман суд юлында йөреп, бөтен булган акчаны тотып бетерде... Гомер буена йомышын җилгә каршы йомышлады. Нинди адәмдер.

Л ә й с ә н. Ярар, әнкәй, соңрак сөйләшербез әле боларны.

М ө н ә в ә р. Минем өчен борчылма син. Мин сезне ишетмим.

А л с у. Ярый әле Мөнәвәр бар. Ялт иттереп карларны көрәп куйды әнә. Каян гына килеп чыккандыр, Алланың рәхмәте. Мин терлекләргә печән биреп керим инде. Үзе мәңге кайтып җитмәс, ахры. Кая гына китеп олаккандыр. Әйтми-нитми чыга да китә.

Л ә й с ә н. Марсель әтисенә охшаган икән алайса.

А л с у. Охшамасын иде инде. Марсель бит ул эш белән йөридер... Ә моның нинди эш, базар буенча хатын-кызлар белән ләчтит сатып йөри... Хәзер мин... *(Чыгып китә.)*

Л ә й с ә н. Сез бу як кешесе түгелмени?

М ө н ә в ә р. Бу дөнья кешесе мин!

Л ә й с ә н. Туганнарыгыз бармы соң?

М ө н ә в ә р. Булырга тиеш. Минем кадәр җир таптаган кешенең туганнары күп була инде ул!

Л ә й с ә н. Кызык! Сез сәяхәт итәргә яратасыз, димәк?

М ө н ә в ә р. Җир шары әйләнә, дип, аңа гына утырып йөрергә яратмыйм, үзем дә хәрәкәт итәргә тырышам! Абзый кайтмыйча апа мине кунак итми. Тәртип, малай... Кая китте икән соң ул?

Л ә й с ә н. Белмим. Иртән берни әйтми генә чыгып китте, ди... Ә сезгә ничә яшь?

М ө н ә в ә р. Санаганым юк!

Л ә й с ә н. Гаиләгез, балаларыгыз бармы?

М ө н ә в ә р. Бар...

Л ә й с ә н. Ничәү? Кая алар хәзер?!

М ө н ә в ә р. Кая гына юктыр инде безнең балалар!..

Л ә й с ә н. Ә нишләп төпләнеп яшисегез килми?

М ө н ә в ә р. Миңа болай рәхәтрәк!.. Ә сез кайчан өйләнешеп өлгердегез соң әле?

Л ә й с ә н. Өйләнешеп, дип... Гражданский брак...

М ө н ә в ә р. Иң әйбәте шул инде! Мин дә бер-ике аерылгач, өйләнешүне яратмый башладым. Паспорт пычратып.

Л ә й с ә н. Шулай еш өйләндегезмени?

М ө н ә в ә р. Хатын-кызлар ярата шул мине. Сөйкемле сөягем бар. Ә мин, хатын-кыз затын хөрмәт иткәнгә, карыша алмыйм... *(Урамда машина тавышы ишетелә.)* Кайттымы соң, машина тавышы бар...

Л ә й с ә н. Чәйне яңартырга кирәк...

М ө н ә в ә р. Туңып кайткандыр шул!

*Пакетлар, әллә нәрсәләр күтәренгән Р а ф а э л ь килеп керә. Ул илле өстендә. Пеләшләнә башлаган, ябык кына, нык ир-ат.*

Р а ф а э л ь. Әй, шпана! Үлешеп беттегезме әллә? Кая югалдыгыз?

*Аңа карап торган Л ә й с ә н белән М ө н ә в ә р не күреп ала.*

Р а ф а э л ь *(Ләйсәнне күреп, әллә нишли).* Вот, ё-моё? Дөрес кермәдемме әллә?

Л ә й с ә н. Ә сезгә кем кирәк?

Р а ф а э л ь. Илдар монда яшиме?

Л ә й с ә н. Әйе!..

Р а ф а э л ь. Ә сез кем?

Л ә й с ә н. Мин, Марсельның хатыны, ә бу... Күрше абый...

Р а ф а э л ь. Марсель өйләнде дәмени? Вот разбойник! Главное, мине туйга да чакыручы юк, әйтүче дә... Ярар, колакларын бормыйча булмас... Соң, килен, син булса да

урнаштыр инде боларны! *(Пакетларын идәнгә куя.)* Үзләре кая югалдылар соң болар? Әллә абзардамы?

*А л с у апа килеп керә.*

А л с у. Анда ук, мин әйтәм, Рафаэльдыр, таныш түгел машина күреп алдым да!..

Р а ф а э л ь. Нихәл?! Кая качып беттегез? Килеп керүем булды, бер таныш түгел кешеләр басып тора, аптырап киттем. Мин бит адрес буенча йөрмим, бөтенесен якынча хәтерлим. Бүре кебек, на нюх! Бабай кайда соң?

А л с у. Иртүк чыгып китте, бер сүз әйтмәде...

Р а ф а э л ь. Иртә-таңнан әйтми-нитми кайда йөри ул?! Төнлә булса, бер хәл!

А л с у. Үзем дә аптырыйм инде! Төнлә йөрерлеге калмагач, хәзер көндез күз шатландырып булса да кайтадыр! *(Көлә.)*

*М ө н ә в ә р бу шаяртудан бигрәк тә кеткелдәп көлә.*

А л с у. Син үзең генәме әллә? Венера кая?

Р а ф а э л ь. Калдырдым! Әйдә авылга, дигән идем, минем подружкалар, Яңа елны алар белән каршылыйм, дияргә тотынды. Ярар, мәйтәм, на фиг, каршылагыз! Мин авылга, дидем дә – выжт!

А л с у. Әй, дөрес тә эшләгәнсең! Бәйрәмдә бергә-бергә күңелле бит ул!

Р а ф а э л ь. Ә теге засранец кая?! Марсель?!

Л ә й с ә н. Йоклый...

Р а ф а э л ь. Йоклый?! Вот сиңа мә! Өйләнерлек җегет булган, үзе обедка кадәр йоклый! Кешеләр эшләп арыды бит инде! Кая әле ул!

А л с у. Уятма инде, йокласын!

Р а ф а э л ь. Хәзер йоклатам мин аны!.. *(Марсельнең бүлмәсенә кереп китә.)* Подъём всему личному составу!

Л ә й с ә н. Бу кем соң?!

А л с у. Рафаэль – Илдарның двоюродный браты...

М ө н ә в ә р. Күңелле кеше!

А л с у. Илдар кебек, сибиряк!

*Ул арада Марсельнең бүлмәсеннән тавышлар ишетелә. Р а ф а э л ь чыга.*

Р а ф а э л ь. Кара син моны! Бигрәк кызу канлы! Ташбаш! Кизәнгән була!

А л с у. Әйттем бит, йокласын, дип!.. Мин терлекләремне эчереп бетерим инде, машинаңны күреп кенә кергән идем!

Р а ф а э л ь. Сез һаман мал асрыйсызмыни әле?

А л с у. Асрамаган кая! Шулар белән беркая чыгып китәр хәл юк... Ярар, мин хәзер. Кызым, син чәйләр эчерт!.. *(Чыга.)*

Л ә й с ә н. Ярар!

Р а ф а э л ь *(утырып)*. Ярар...

*М а р с е л ь бик канәгать түгел чырай белән юыну бүлмәсенә үтә.*

Р а ф а э л ь. Хей! (*Пакеттан суыра торган конфет-әтәч алып.)* Мә әле, килен, иреңә бирерсең!

Л ә й с ә н *(көлеп туйгач)*. Ярар, ачуын чыгармагыз инде!

*М а р с е л ь юыну бүлмәсеннән аш бүлмәсенә үтә. Бер бокалга чәй ясап, үз бүлмәсенә кереп китә. Барысы да бер сүзсез моны карап торалар.*

Р а ф а э л ь. Кызык икән монда

хәлләр... Илдарның өендә дә шулай булыр икән... Күрше, дисең инде алайса?

М ө н ә в ә р. Булышкалыйм шунда...

Р а ф а э л ь. Ярар. Илдар үзе ничек соң?

М ө н ә в ә р. Читлеккә яңа эләккән ерткыч кебек...

Р а ф а э л ь. Да... Кызык дөнья... Син монда нәрсә көтеп утырасың?

М ө н ә в ә р. Аракы эчертүче булмасмы дип утырам.

Р а ф а э л ь. Эчертүче юкмы?

М ө н ә в ә р. Абзыйның рөхсәтеннән башка юк шул.

Р а ф а э л ь. Алайса, бар инде син, туганкай. Картлач кайткач керерсең. Хуҗа үзе өйдә югында, килен янында утырмыйлар инде.

М ө н ә в ә р. Сугылырмын әле мин...

Р а ф а э л ь. Сугыл, сугыл, әлбәттә!

*М ө н ә в ә р чыгып китә.*

Л ә й с ә н. Куып чыгардыгызмыни?

Р а ф а э л ь. Кумадым бит! Әйттем генә! Нәрсә монда түр башына менеп утырган. Ир-ат өйдә булмаганда, ни калган аңа монда!

*М а р с е л ь керә. Ул киенгән. Су эчә.*

Л ә й с ә н. Кая җыендың?

М а р с е л ь. Барып киләсе җир бар.

Л ә й с ә н. Озаккамы?

М а р с е л ь. Белмим.

Р а ф а э л ь. Син, малай актыгы, абыеңны күрмисең дәме соң?

М а р с е л ь. Күрәм... Менә утырасың...

Р а ф а э л ь. Исәнләшмисең дәмени?

М а р с е л ь. Исәнләштек бит инде.

Р а ф а э л ь. Синеңчә, исәнләшү шул буламы? Күзең дә ачылмаган, сугып ега яздың.

М а р с е л ь. Йоклаган кешегә килеп бәйләнмиләр аны. Исәнме, Рафаэль абый.

Р а ф а э л ь. Исәнме, энекәш! *(Аны кочаклап ала.)* Ә мин сиңа бүләк алып кайттым! *(Суыра торган әтәч бирә.)*

М а р с е л ь. Рәхмәт! *(Әтәчне гарнитурга ташлый.)*

Р а ф а э л ь. Менә сиңа мә! Элек ярата идең, үрле-кырлы сикерә идең!

М а р с е л ь. Хәзер дә бик шатландым. Ашыгам гына...

Л ә й с ә н. Минем синең белән сөйләшәсем бар.

Р а ф а э л ь. Сөйләшегез әле! Мин абзарларга чыгып, картлачның байлыкларын карап керим! *(Чыгып китә.)*

М а р с е л ь. Нәрсә? Әйдә, тизрәк әйт, тирлим.

Л ә й с ә н. Нишлисең син?

М а р с е л ь. Нишләдем соң әле мин?

Л ә й с ә н. Син туганнарың белән кешечә сөйләшә беләсеңме?

М а р с е л ь. Үз туганнарым белән ничек сөйләшәсен үзем белермен.

Л ә й с ә н. Ә минем белән?

М а р с е л ь. Синең белән сөйләшкән дә юк бит әле, нәрсә ошамый соң сиңа?

Л ә й с ә н. Юк шул. Мине монда алып кайтып ыргыттың да...

М а р с е л ь. Әйдә, аннары сөйләшербез, мин ашыгам.

Л ә й с ә н. Кая барасың?

М а р с е л ь. Эшем бар.

Л ә й с ә н. Кайчан кайтасың?

М а р с е л ь. Белмим. Бушагач та кайтырмын.

Л ә й с ә н. Ник син әтиеңә бу-

лышырга теләмисең? Регина синең сеңлең иде бит...

М а р с е л ь. Син дә миемне кимермә, зинһар. Мин киттем.

Л ә й с ә н. Мин синең белән барам.

М а р с е л ь. Юк.

Л ә й с ә н. Ник?

М а р с е л ь. Хатын ияртеп йөри торган очрашу түгел.

Л ә й с ә н. Мин монда үзем генә калмыйм.

М а р с е л ь. Хәзер кайтам мин.

Л ә й с ә н. Нишләдең син? Әйдә, сөйләшик әле. Әллә нинди син.

М а р с е л ь. Башлама инде... Бар да әйбәт булыр, күрерсең...

Л ә й с ә н. Нәрсә булды соң сиңа? Районга башка кайтмыйм дип торган җиреңнән, кисәк кенә кайтырга булдың. Сөйләшмисең-нитмисең, югалып йөрисең, һаман үз эчеңнән нидер уйланасың.

М а р с е л ь. Мин бит безнең өчен тырышам. Мин бит сине кайгыртырга тиеш.

Л ә й с ә н. Без бер-беребезне кайгыртырга тиеш. Киңәшеп эшләргә. Миңа болай ошамый.

М а р с е л ь. Әлегә берни әйтә алмыйм. Соңрак барысын да белерсең. Мин ашыгам...

Л ә й с ә н. Син китсәң, мин дә китәм.

М а р с е л ь. Кая китәсең?

Л ә й с ә н. Башта апаларга, аннан шәһәргә.

М а р с е л ь. Алай итмә инде, зинһар. Син китсәң, эти дә борчылыр. Ул сине күреп, үзгәреп китте...

Л ә й с ә н. Ә син?

М а р с е л ь. Нәрсә мин?

Л ә й с ә н. Мин китсәм, син борчылырсыңмы?

М а р с е л ь. Нинди сүз инде бу?

Л ә й с ә н. Регина исән вакытта син бит мине гел күрә идең, бер игътибар иткәнең булмады...

М а р с е л ь. Борын төбеңдәгене иң соңгы булып күрәсең инде ул.

Л ә й с ә н. Әллә мин сезгә Регинаны алыштырыр өчен генә кирәкме? Син бит, ул үлгәч кенә, минем арттан йөри башладың. Мине аңа охшатканга гынамы?

М а р с е л ь. Әкият сөйләмә инде.

Л ә й с ә н. Мин Регина түгел.

М а р с е л ь. Әлбәттә...

Л ә й с ә н. Ярар... Мин аңладым сине...

М а р с е л ь. Нәрсә аңладың?

Л ә й с ә н. Аның бөтен киемнәрен миңа китереп аудардың...

М а р с е л ь. Чыгарып ташларга идемени аларны?

Л ә й с ә н. Син миннән Регина ясарга уйлагансың. Монда алып кайтып, аны алыштырырга. Миңа кеше язмышы кирәкми. Минем үз тормышым. Уф. Каз тәннәре чыкты...

М а р с е л ь *(телефоны шалтырый)*. Миңа китәргә кирәк. Әйдә, мин кайткач сөйләшеп бетерербез, ярыймы... Чынлап, миңа китәргә кирәк... Гафу.

*М а р с е л ь аны битеннән үбеп чыгып китә. Л ә й с ә н беләкләрен ышкып, беравык нишләргә дип уйлап торганнан соң, әйберләрен җыярга дип, башка бүлмәгә кереп китә.*

*Чыршы күтәреп, И л д а р белән Р а ф а э л ь керәләр.*

Р а ф а э л ь. Картлачның кая киткәнен беркем белми! Ә ул чыршы сөйрәп йөргән икән! Кыш бабай икәнсең! Нишләп машина белән генә бармадың, кәкрәеп каткансың бит.

И л д а р. Күзләр минем хәзер... Рульгә утырырлык түгел...

Р а ф а э л ь. Бераз көткән булсаң, минекенә салып кайта идек.

И л д а р. Син әллә кайтасың, әллә юк.

Р а ф а э л ь. Телефоннан әйттем бит инде.

И л д а р. Әллә хатының җибәрмәс.

Р а ф а э л ь. Бөтенесе дә синең кебек хатын үкчәсе астында аунап ятмый бит! Егет, әйткән икән, эшли!

И л д а р. Кая соң болар, өйдә кеше юкмы әллә?

Р а ф а э л ь. Әле монда иделәр. Чыршы исе таралды! Рәхәт!

И л д а р. Балалар кайткач куярга дидем инде. Бәйрәм төсе кереп китсен дип.

*Л ә й с ә н чемоданын тотып чыга.*

И л д а р. Кызым, кая җыендың?

Л ә й с ә н. Син чыршы алырга барган идеңмени? Без сине югалттык.

И л д а р. Әйе шул. Сиңа дип... Сезгә дип, бәйрәмчә булсын дип. Син соң нишләп чемодан белән?

Л ә й с ә н. Мин... Китәрмен инде. Шалтыраттылар... Чакыртып алдылар. Эштәге кыз авырган. Китәргә кирәк инде...

И л д а р. Әй... Күңелле иде әле... Син дә булгач... Гаилә тулы иде кебек... Марсель кая соң?

Л ә й с ә н. Эшләре бар, чыгып китте... Мин дә китим инде... Сезгә дип мантыйлар пешергән идем, плитәдә... Ярый...

Р а ф а э л ь. Әйдә, илтеп куям машина белән.

Л ә й с ә н. Юк, рәхмәт, монда ерак түгел. Сау булыгыз...

*И л д а р ны хисләнмәскә тырышып кына кочаклаган итә. Чыгып китә.*

И л д а р. Нәрсә булды инде бу?

Р а ф а э л ь. Эшкә барасы бар, ди бит...

И л д а р. Регинаны күргән кебек идем әле... Охшаганнар бик...

Р а ф а э л ь. Суд кайчан?

И л д а р. Берсекөнгә...

*Беренче пәрдә тәмам.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш.

*Бизәлмәгән чыршы янында Р а ф а э л ь белән И л д а р. Алар шәраб эчәләр. Урталарында төргәге белән ябып торган гирлянда.*

И л д а р. Юк, Себердә халык әйбәтрәк. Ярдәмчелрәк. Мин монда кайтканда, эштә кешенең туган көненә бүләк тә алып килә белмиләр иде... Бәйрәмең булса, син аларны эчертергә тиеш дип санайлар иде.

Р а ф а э л ь. Мунчаң искергән, әйдә, җәйгә яңаны мәтәштерик.

И л д а р. Хәтерлисеңме, Мироновның мунчасын?

Р а ф а э л ь. Кайсы ул?

И л д а р. Син минем туган көнгә килгәч барган идек бит. Күл өстендә йөзеп йөри торган!

Р а ф а э л ь. Ә! Андыйны онытып булмый инде!

И л д а р. Капчыгыңны асасың да тукмагыңны кыстырып, кедр җыярга чыгып китәсең... Мүк җиләгедер, гөмбәдер, балык – ниндиен телисең... Аннан – мунчага...

Р а ф а э л ь. Блоктан гына өяләр бит хәзер мунчаны.

И л д а р. Агач мунчага җитми

инде! Миронов мунчасына. Кысла кебек кызарганчы чабынасың да чыгып, күлгә сикерәсең! Күл өстендәге томан таралыплар китә...

Р а ф а э л ь. Арбалет блоктан өясең дә, кедр вагонка белән төрәсең эчтән.

И л д а р. Кедр вагонканың бәясе нарат бурасына төшәдер ул.

Р а ф а э л ь. Төшсә инде... Бер генә яшибез...

И л д а р. Монда бик төзисе дә килми... Авылга күченеп булмасмы, дим.

Р а ф а э л ь. Авылга?

И л д а р. Әйе... Алсу ризалашмастыр шул... *(Шәраб йотып куя.)*

Р а ф а э л ь. Сиңа ярыймы соң?

И л д а р. Ярамый да бит!

Р а ф а э л ь. Ә ник эчәсең?

И л д а р. Киндзмараули! Ә сиңа?

Р а ф а э л ь. Миңа да ярамый!

И л д а р. Ә ник эчәсең?

Р а ф а э л ь. Киндзмараули! Миңа, анысы, куркыныч түгел. Берәр атна эчәм дә туктыйм. Ә синең бит шикәр, малай, кыланырга ярамый.

И л д а р. Ташла инде. Мондый шәрабны кайчан күрермен әле тагын? Яшьлек тәме бар бит моңарда...

Р а ф а э л ь. Һаман яшьлекне сагынып ятып кына булмый инде...

И л д а р. Син сагынмыйсыңмы?

Р а ф а э л ь. Миңа бүген рәхәт.

И л д а р. Яшь чакта рәхәтрәк иде.

Р а ф а э л ь. Кичә эчкән шәрабның тәмен сагынып ятар хәлем юк. Кичәгесе кичә тәмле иде, ә бүген өстәлемдә башка шәраб, янымда син – хәзерге кадерлерәк, үткәннәр юк инде. Һәрбер җыерчыгым, һәрбер ак чәчем, сынып ялганган һәр сөягем бүген минем белән – һәркайсын яратам.

И л д а р. Судлар гына үтсен, авылга кайтып киләм. Чия тавын сагындым. Шунда кайтасым килә. Күченеп кенә китәсе иде...

Р а ф а э л ь. Нихәл соң анда? Җиңәрлекме?

И л д а р. Кем белгән... Үз күзләрем белән күрдем бит... Үзем аны машинадан сөйрәп чыгардым. Көчкә аягында басып тора иде...

Р а ф а э л ь. Шулай булгач, нәрсәдә соң проблема?

И л д а р. Нәрсәдә булсын. Башка шаһитлар юк... Машина ике көн угонда санала. Үзе, имеш, Казанда булган, анда күргән кешеләре дә бар...

Р а ф а э л ь. Син аны караңгыда таныдыңмы соң?

И л д а р. Танымаска инде. Мин генә күрмәдем бит аны. Марсель дә шунда иде. Без өйдән йөгереп чыктык тавышка...

Р а ф а э л ь. Ә Марсель нәрсә?

И л д а р. Судка бармый.

Р а ф а э л ь. Ничек инде бармый?

И л д а р. Мин күрмәдем, ди.

Р а ф а э л ь. Куркытканнармы әллә?..

И л д а р *(җилкә җыера)*. Иң шакшысы – Регинаның канында алкоголь тапканнар. Исерек булган, имеш... Гомерендә шәраб та эчеп карамаган кыз.

Р а ф а э л ь. Менә шундый чакларда яшьлекне мин дә сагынып куям...

И л д а р. Теге чакларнымы?

Р а ф а э л ь. Калмады шул бернәрсә... Геологиядән киткәч, кайтып, гаражларны чистарттым. Бөтен взрывчатка, коралларны елгага аттым...

И л д а р. Хәзер булса, ә! Тәвәккәлләр идеңме?

Р а ф а э л ь. Сорап торган буласың! Шуңа ташладым да инде, тәвәккәллек барлыгын белгәнгә. Ике дә уйламыйча, күтәртер идем, селкетеп алыр идем бераз... Ярый әле ташладым. Судка өмет юк, дисең инде?

И л д а р. Ә кайчан булганы бар?

Р а ф а э л ь. Анысы да хак...

И л д а р. Җиңел генә булмасын әле. Алар да барыбер борчыла бит! Укуыннан булса да куарлар, бәлки. Юристка укып йөри бугай.

Р а ф а э л ь. Аларныкын кумаслар анысы. Шулай да борчусыз түгелдер. Син аларга борча гына булсаң да, бер бәләкәй борча күбрәк җәфалый бит ул!

И л д а р. Гомергә борча булдым инде.

Р а ф а э л ь. Шуңа «Сельхозтехника»дан кудылар да инде сине!

И л д а р. Юк! Анда борча гына булып калмадым бит мин.

Р а ф а э л ь. Нишләдең?

И л д а р. Сөйләгән юкмыни?

Р а ф а э л ь. Юк.

И л д а р. Мин директорны сугып ектым бит.

Р а ф а э л ь. Ник?

И л д а р. Әй, мудак булганга. Аңлаттым, аңлаттым – аңламый. Нишлим инде. Ияк астына берне кундырдым – һавага күтәрелде дә, гөп!

Р а ф а э л ь. Шулай булдымыни әле ул? Калдырырга егетлеге җитмәде инде, шундук куды үзеңне?

И л д а р. Шундук! Йөрәгенә пычак кадаган чучка сыман чиный башлады, кеше алдында бит. Барыбер үчемне алдым мин аңардан!

Р а ф а э л ь. Ничек?

И л д а р. Мине аннары беркая да эшкә алмый башладылар. Монда бит алар бөтенесе бер шайка, шакал көтүе. Хәтерлисеңме минем бизнесмен чакларны?

Р а ф а э л ь. Ә! Шәп бизнес иде ул синең.

И л д а р. Әйтмә! Ә кая барасың? Гаиләне ашатырга кирәк бит. Эш булмагач, «Газ 66»ыма утырдым да, киттем канализацияләр суыртырга. Конкуренция юк. Үз йортлары белән яшәүчеләр монда күп!

Р а ф а э л ь. Рекламаң шәп иде синең! Кем уйлап чыгарды аны?

И л д а р. Нәрсәне әйтәсең әле син?

Р а ф а э л ь. Машинага «говно» дип язып куйганыңны?

И л д а р. Үзем инде! Бук булгач, нәрсә языйм?!

Р а ф а э л ь. Үчеңне ничек алдың?

И л д а р. Чокырлары тулган, хатыны чакыртты... Бардым. Хатыны да аны мудак дип саный икән! Шул уртак фикер... Бик якын итте безне! *(Күз кыса.)*

Р а ф а э л ь. Марсель кайтты, ахры, ишек тавышы булды.

И л д а р. Ахры.

М а р с е л ь *(керә)*. Нишләп караңгыда утырасыз?

Р а ф а э л ь. Караңгыда якты кешеләр аермачык күренә!

М а р с е л ь. Әни яттымы?

И л д а р. Синең бүлмәдә. Гелдәгечә. Кайтканыңны белер өчен синең урынга ятып йоклый.

М а р с е л ь. Ләйсән кая?

И л д а р. Шалтыратышмадыгызмы әллә?

М а р с е л ь. Телефоны сүнгән. Ул да яттымы?

И л д а р. Китте, синең арттан ук...

М а р с е л ь. Ә... Шикәрең күтәрелмәсме?

И л д а р. Күтәрелергә тиеш, эчәм бит.

М а р с е л ь. Әти, син авария урынына чәчәкләр куйма инде, җитәр... Урам уртасы... Бала-чага йөри. Шомлы бит...

И л д а р. Тагын куйганнармы әллә?

М а р с е л ь. Син түгелмени?

И л д а р. Димәк, аны яраткан кешеләр бар әле, онытмаучылар. Бер ел була...

М а р с е л ь. Әйдә җәй көне авылга кайтып киләбез.

И л д а р. Нәрсә калган анда?

М а р с е л ь. Синең барасың килә иде бит. Гел сөйли идең. Алмалы тауга...

Р а ф а э л ь. Чияле тауга!

М а р с е л ь. Чиялемени? Ә, әйе бит әле.

И л д а р. Җәйгә кадәр кышны чыгасы бар әле...

Р а ф а э л ь. Нинди планнар синең, энекәш?

М а р с е л ь. Минемме? Белмим инде. Нәрсәдер эшләргә кирәк. Тормышны җайларга. Эш кирәк... Хатын да булгач.

Р а ф а э л ь. Хатының китте бит инде, бер проблемаң кимеде.

М а р с е л ь. Китсә бит... Кайсыгызның хатыны китеп кайтмаган?

И л д а р. Бигрәк Регинага охшаган...

М а р с е л ь. Кайта әле ул, эти...

И л д а р. Регина кайтмас инде...

М а р с е л ь. Ләйсән дим...

И л д а р. Тере кеше кайтыр да, китәр дә, анысы хак, үлеләргә генә кирегә юл юк... Чияле тауга кайтасы иде. Кыш көне чана шуа идек, агач араларындагы сукмаклардан... Елгага кадәр шуып төшә яза иде... Ике менеп-төшсәң, эт буласың.

М а р с е л ь. Мин теге китүдән нык таушалган син. Нервы бетерә кешене... Мин, әллә монда калыргамы, дим.

И л д а р. Райондамы?

М а р с е л ь. Әйе, үзегезгә генә авырдыр монда.

И л д а р. Монда үләргә генә кайталар инде. Эш тә юк, киләчәккә өмет тә...

М а р с е л ь. Эшләгән кешегә эш табылыр әле...

И л д а р. Ә Ләйсән?

М а р с е л ь. Ире кайткач, ул да кайтыр инде... Мунчаларны да рәтләргә кирәк...

Р а ф а э л ь. Мин дә шулай дим.

И л д а р. Судлар үтсен әле...

М а р с е л ь. Анда ни буласы билгеле бит инде.

И л д а р. Каян билгеле булсын?

М а р с е л ь. Син миңа ачуланма... Тыңла әле... Әти.

Р а ф а э л ь. Сөйлә син, тыңлый бит.

М а р с е л ь. Әйдә, барып йөрмик анда. Адвокатка акча әрәм итеп, судлар өчен түләп... Мунчаларны рәтләрбез. Ләйсән дә, мин дә янәшә булырбыз. Җан газаплап йөрүдән ни мәгънә.

И л д а р. Рафаэль, мин Марсель бәләкәй вакытта аны кыш көне урамда су коенырга алып чыга идем, чыныксын дип. Елый иде. Ләйсән түзә иде... Регина, диюем. Болар бәләкәй чакларында гел бергә иделәр бит. Берсе йомырканың агын гына ашый иде, икенчесе сарысын гына. Без орышмасын дип, күрмәгәндә генә бүлешеп ашыйлар иде – берсе сарыларын, икенчесе... Без авылга күченербез. Сез – бу йортта калырсыз...

М а р с е л ь. Әни риза булырмы соң?

И л д а р. Син монда күченергә хатыныңнан ризалык сорадыңмы соң? Нишләп мин сорап торырга тиеш?

Р а ф а э л ь. Авыл дигәннән, мин булдым бит анда.

И л д а р. Кайчан?

Р а ф а э л ь. Яз көне. Хатынның абыйсы үлгән иде, шуны җирләргә кайттык.

И л д а р. Чияләр чәчәк аткан идеме?

Р а ф а э л ь. Анда бит ел да таудан су агып төшеп, зиратны юа иде... Зиратка урынны да аз калдырган булганнар инде... Су каберләрне

ачып аптыраткач, хәзер тау битенә җирли башлаганнар.

И л д а р. Чия тавынамы?

Р а ф а э л ь. Мин аңламадым да. Анда авыл тирәсен таллар басып бетергән, танырлык түгел. Чия чәчәк атарга иртәрәк иде әле. Шуңа игътибар итмәдемме. Чия тавы иде бугай инде.

*Ишек шакыйлар.*

Р а ф а э л ь. Ишек шакыйлармы соң?

М а р с е л ь. Бу вакыттамы? Мөнәвәр булса гына.

И л д а р. Болай соң йөргәне юк иде. Хәзер...

*Ишек ачырга чыга. Р а ф а э л ь М а р с е л ь га карап тора.*

М а р с е л ь. Ник шулай карыйсың?

Р а ф а э л ь. Печәм мин сине, малай...

М а р с е л ь. Эчәргә ярамаганын да беләсез, эчәсез...

*Коридордан тавышлар килә. И л д а р Кыш бабай булып киенгән Ләйсән белән керә.*

Л ә й с ә н. Яңа еллар котлы булсын! Кая әле! Кемнәр бар монда?

Р а ф а э л ь. Ё-моё, Кыш бабай!

И л д а р. Ишекне ачып җибәрсәм, артыма утыра яздым!

Л ә й с ә н. Йәгез әле, сөйләп җибәрегез, балалар, бу елны тәртипле булдыгызмы?

Р а ф а э л ь. Тәртипле!

Л ә й с ә н. Ботканы күп итеп ашадыгызмы?

И л д а р *(зур корсагын сыйпап).* Күбрәк ашалды шул!

Л ә й с ә н. Бигрәк тәртипле балалар икәнсез! Хуп! Хуп!

Р а ф а э л ь. Бер тәртипсез малай бар бездә, бабай!

Л ә й с ә н. Шулаймыни? Кайсыгыз ул? *(Илдарга.)* Синме, түгәрәк?

И л д а р. Түгәрәк!

Р а ф а э л ь. Юк! Менә монысы!

Л ә й с ә н. Синмени әле ул тәртипсез? Хәзер җәза бирәбез без сиңа!

М а р с е л ь. Ләйсән! *(Сакалына тотына.)*

Л ә й с ә н. Елыйсы килгән бала Кыш бабайның сакалы белән уйный, ди! *(Аны читкә борып.)* Әти өчен генә кайттым... *(Барысы да ишетерлек итеп.)* Йә, нинди тәртипсезлекләр кылдың, сөйлә?

Р а ф а э л ь. Ул кызларны рәнҗетә!

И л д а р. Тәти кызларны!

Л ә й с ә н. Шулаймы?! Ай-һай, явыз икәнсең! Үкенәсеңме?

М а р с е л ь. Үкенәм, бабай!

Л ә й с ә н. Нинди җәза бирәбез инде моңа, балалар?

Р а ф а э л ь. Әтәч булып кычкырсын!

И л д а р. Әйдә, әйдә!

Л ә й с ә н. Әтәч булып!

М а р с е л ь. Ки-ке-ри-күк!

Л ә й с ә н. Гафу итәм! Мә сиңа, бүләк! *(Аңа таяктагы әтәч конфетны бирә.)*

*Шаркылдап көләләр.*

Л ә й с ә н. Йә, син Кыш бабайга нәрсә әзерләдең?

Р а ф а э л ь. Минме? Мин... Шигырь сөйлимме?

И л д а р. Шигырь? Әллә шигырьләр дә беләсең?

Р а ф а э л ь. Белмәс, ди!

А л с у *(кереп).* Әстәгъфирулла! Куркып киттем... Нәрсә бу?!

И л д а р. Кыш бабай килде! Бүлдермә! Сөйлә шигыреңне!

Р а ф а э л ь.

*Вдоль обрыва, по-над пропастью,*
*по самому краю*
*Я коней своих нагайкою*
*стягаю, – погоняю, –*
*Что-то воздуху мне мало,*
*ветер пью, туман глотаю,*
*Чую, с гибельным восторгом –*
*пропадаю, пропадаю!*
*Чуть помедленнее, кони,*
*чуть помедленнее!*
*Вы тугую не слушайте плеть!*
*Но что-то кони мне попались*
*привередливые,*
*И дожить не успел, мне допеть*
*не успеть!*

Л ә й с ә н. Афәрин! Менә сиңа бүләк! *(Сыбызгы тоттыра.)*

И л д а р. Хәрәмләште! Шигырь түгел, җыр бу!

А л с у. Нишләп русча булды соң бу?

Р а ф а э л ь. Нишләтим, татарча җыр тыңлаган юк!

Л ә й с ә н. Син, кызым, Кыш бабайга нәрсә әзерләдең?

И л д а р. Җырласын!

М а р с е л ь. Әни, әйдә, син матур җырлыйсың бит!

А л с у. Китегез әле!..

Р а ф а э л ь. Кыш бабайга каршы килмиләр! Бүләксез каласың.

И л д а р. Җырла әйдә!

А л с у. Китегез әле, аңгы-миңге басып торам...

Р а ф а э л ь. Җырла инде!

А л с у. Тукта... *(Татарча популяр җырны бик оста башкарам дип уйлап башкара.)*

Л ә й с ә н. Кыш бабайны елаттың, кызым! Менә сиңа бүләк! *(Merci конфетлары бүләк итә.)*

Р а ф а э л ь. Килештерәсең дә инде. Җырчы гына буласың калган! Син җырчы булсаң, мин дә татарча тыңлар идем!

А л с у. Әрәм булдым инде, менә шул бичурага багышлап гомеремне!

Л ә й с ә н. Бу бичурагамы?! Йәле, улым, ә син нәрсә әзерләдең бабаңа?! Куандыр әле!

И л д а р. Мин менә чыршы әзерләдем!

Л ә й с ә н. Бу да булдымыни чыршы? Нишләп бизәлмәгән соң бу? Кыш бабайны шулай каршы аласызмы?

И л д а р. Өлгермәдек кенә, бабай! Хәзер ялт иттерәбез аны!

*Көлешә-көлешә барысы бергә*
*чыршы бизиләр.*

И л д а р. Булды бу, бабай! Минем бүләк кая?

Л ә й с ә н. Бүләкме?! Нәрсә көткән идең Кыш бабайдан?

Р а ф а э л ь. Киндзмараули! *(шәраб салган бокаллар күтәреп килә.)*

И л д а р. Бабай, нәрсә булса да ярый! Энә дә – бүләк, дөя дә – бүләк!

Л ә й с ә н. Мондый тыйнак балага энә бүләк итеп булмас, дөя булыр бүләк! *(Капчыгына тыгыла, аннан телефон ала.)*

А л с у. Телефон?

М а р с е л ь. Кыш бабай сиңа үзеннән калган телефонын бүләк итә!

Л ә й с ә н. Туктагыз әле, тукта, бүләк үк түгел бит әле бу! *(Бәләкәй колонка чыгарып куя.)* Бүләкләрнең бүләге!

Р а ф а э л ь. Бүләкләрнең дөясе!

Л ә й с ә н. Музыкаль бүләк! *(телефон экранына баса. Колонкадан Boney m башкаруында «Rivers of babylon» җыры яңгырый.)*

Р а ф а э л ь. Бу бит...

И л д а р. Тукта! *(кереш өлешеннән соң)* Boney m!

Р а ф а э л ь. Boney m!!!

И л д а р. Риверс офф бабилон!

Р а ф а э л ь. Бие әйдә!

*И л д а р кушылып җырлый, үзе орчык кебек бүлмә буенча әйләнә-әйләнә бии. Р а ф а э л ь дә аңа кушыла. Алар башкаларны да биетәләр.*

Р а ф а э л ь. Менә хәзер таныйм картлачны! Үткәннәрне сагынып, борын салындырып утыра торган кешемени безнең Илдар!

*Җыр ахырына Илдар кинәт Ләйсәннең өстеннән Кыш бабай тунын, сакал-мыекларын салдыра.*

И л д а р. Рәхмәт! Рәхмәт, кызым! Бер онытмыйсың! *(кулларыннан үбә.)* Ел да шулай! Яңа ел, синең сюрпризыңнан башка, бәйрәм дә түгел! *(битләреннән үбә.)* Иренмисең дә, алтыным!

А л с у. Әй, Аллам...

М а р с е л ь. Әти...

Р а ф а э л ь. Исерек кенә ул...

И л д а р. Шундый сагындым сине! Чәчләреңнән сыйпыйсым килеп тилмерәм!

Р а ф а э л ь. Картлач, әйдә, тынычланыйк...

И л д а р. Турсаеп елаганыңны сагынам, юатасым килә үзеңне, битләреңнән яшьләреңне сөртәсем килә, балам...

Л ә й с ә н. Гафу, мин бит болай булыр дип уйламадым...

И л д а р. Куеныма яшереп, бөтен дөньясыннан яклыйсым килә...

М а р с е л ь. Әти, бу Ләйсән, киленең... Регина юк...

И л д а р. Сиңа юк ул, сиңа...

М а р с е л ь. Иртәгә суд, исеңә төштеме?

И л д а р. Төште, төште... Әйе... Гафу итегез... Шундый күңелле булды... Яшьлеккә кайткан кук... Яшьлегемнән кемдер минем белән сөйләште сыман...

Р а ф а э л ь. Киндзмараули?

И л д а р. Әйе, әйе... Гомер күрмәгән җырчылар, ә якын туганнарым белән очрашкан кебек... Рәхмәт... Ләйсән кызым...

Р а ф а э л ь *(чыршы төбенә шәраб эчәргә чакырып)*. Әйдә, кил...

И л д а р. Киләм, әйе...

*И л д а р бокалны алырга дип үрелгәндә, аңын җуеп егыла. Хатын-кызлар куркып кычкырышалар.*

Р а ф а э л ь. Шикәре, шикәре күтәрелгәндер...

М а р с е л ь. Скорый, скорый чакыртыгыз!!!

А л с у. Кызым, шалтырат, шалтырат!

*Х а т ы н-к ы з л а р ашыгыч ярдәмгә шалтырата башлыйлар.*

Р а ф а э л ь. Картлач, уян әле, уян... Марсель, әйдә үзебез илтик. Тизрәк була...

М а р с е л ь. Алып киләбез дип әйтегез, шалтыратыгыз больницага! Әйдә, күтәрдек...

*Караңгылык.*

**Икенче күренеш.**

*М ө н ә в ә р белән Алсу.*

А л с у. Озакладылар, караңгы төште инде...

М ө н ә в ә р. Кыш бит, иртә караңгылана... Анда эшләре байтак җыелгандыр.

А л с у. Нәрсә булып бетәр?..

М ө н ә в ә р. Нәрсә буласы билгеле инде.

А л с у. Нишләп алай дисең?

М ө н ә в ә р. Җиңеләселәре көн кебек ачык. Судья да кеше инде – ул да нәчәлстводан курка.

А л с у. Бөтен булган акчаны тотып бетерде... Гомер буе эше сүздән узмады. Монда алып кайтып олактырды да безне... Ни балаларга юньле шартлар юк, ни үзеңә чиста-пөхтә киенеп, кеше арасына чыгарлык җир юк. Шул урам буенда йөрсәң генә... Урам буенда табыла инде ул, машинасы да, бандиты да... Арытты... Күңелнең хәле калмады...

М ө н ә в ә р. Ял итәргә кирәк.

А л с у. Итәрсең монда... Хәзер җиңелеп кайта да тагын көн күрсәтми инде ул. Кара йөзе белән өйдә торырлыкны калдырмый. Тын кысыла башлады инде. Алай иткәне юк иде әле...

М ө н ә в ә р. Ә син нишләп бармадың соң судка?

А л с у. Минме?.. Үз-үзеңне һаман саен җәфаларга, күңелне атлаган саен актарыргамы – нәрсәгә?..

М ө н ә в ә р. Буласына ышанмыйсың, димәк...

А л с у. Булса да, булмаса да... Миңа барыбер...

М ө н ә в ә р. Синең балаң бит...

А л с у. Еладым, ярты ел еладым... Минем балам... Күңелемдәген бер үзем генә беләм... Әгәр дә судта җиңеп, миңа баламны терелтеп бирсәләр, барыр идем... Ә болай... Аны җәзалаганнан миңа ни?.. Кем гаепле булса да, балам юк инде...

М ө н ә в ә р. Әллә син Илдар абзыйның аны күрүенә ышанмыйсыңмы?

А л с у. Мин аңа күптән ышанмыйм инде. Ышанганга бу көнгә килеп җиттек. Артымнан күпме егет йөрде, хәзер бөтенесе зур-зур урыннарда утыра, ә мин, дивана, шул буш куыкның телендә биегән сандугачына алдандым. Чибәр идем бит мин...

М ө н ә в ә р. Анысы бар инде... Хәзер дә әле...

А л с у. Хәзер юк инде... Хатын-кызның вакыты кыска... Чибәрлеккә озак таянырга ярамый, уңышын вакытында җыеп алырга кирәк, гомерлеккә җитәрлек итеп...

М ө н ә в ә р. Бар әле, бар, җыярлык калган!

А л с у. Нәрсәгә ирештем инде мин менә? Ни мәгънә?

М ө н ә в ә р. Нинди мәгънә кирәктер кешегә, аңламыйм. Рәхәт булырга тиеш, шул бит инде мәгънә!

А л с у. Бик рәхәт шул. Мал-туар карап, дүрт стенада бикләнеп ятам. Ни акчасы, ни ирлеге. Шул яшемдә бабай асрап ятарга... Яшәрлегем бар бит әле минем...

М ө н ә в ә р. Ял итәргә кирәк, ял итәргә...

А л с у. Итәргә иде дә бит...

М ө н ә в ә р. Менә син мине аракы эчәргә йөри, дисең инде...

А л с у. Хезмәт ятканга түгел бит инде.

М ө н ә в ә р. Сине күрергә дип киләм... Эшеңне бераз җиңеләйтергә... Мин эшләмәсәм, сиңа төшә бит ул, абзый үзе аркылыны буйга алып сала торган түгел... Мондый хатын-кызны сарайда сасытып ятмыйлар...

А л с у. Күрәм инде, күрәм селәгәйләрең агызганыңны... Әй Аллам, нинди көнгә калдык бит... Синдәй сәрхушләрнең кызыгуы да рәхәт, шуннан да күңел үсенеп китә. Шулай булырга тиеш идемени инде?

М ө н ә в ә р. Син сәрхуш, димә. Сәрхуш булсак та... Теге вакытта кызың өстебезгә килеп чыкмаса, бер дә сәрхуш дип тормас идең әле... *(Аны кочакламакчы була.)*

А л с у. Кит әле, юк белән... Күңелнең иләс-миләс чагына туры килдең, шул гына, очынма... Яшьлегемнең соңгы көзенә...

М ө н ә в ә р. Өлгергән булса, атасына әйтер идеме икән?

А л с у. Кем белгән. Хәзер шул мөһимме? Бәлки, әйткән дә булыр иде. Әйтеп, нәрсә үзгәрә, югалтырмын дип, калтырап торган нәрсәм юк. Кызлар әтиләрен ярата инде... Тугыз ай буена йөрәк астында йөртәсең, төннәрен йокламыйсың, бөтен матурлыгыңны, сәламәтлегеңне суыралар – телләре ачылганда, «әти» дип ачыла. «Әти» дә, «әти»...

М ө н ә в ә р. Малайлар башкачамы?

А л с у. Малай – малай инде ул. Сине чынлап ярата белгән бердәнбер ир.

М ө н ә в ә р. Белмим... Сездә генә шулайдыр ул. Мин әтине ярата идем. Колак артына да кундыра иде – барыбер ярата идем, әнигә хыянәт итсә дә, үпкәләми идем – әтигә ярыйдыр иде кебек... Син Марсельне үзең шулай тәрбияләгән. Син Илдар абзыйны хөрмәт итмәгәнгә шулай. Яратмыйм ирләрен хөрмәт итмәгән хатыннарны...

А л с у. Әле генә сокланган идең түгелме соң?

М ө н ә в ә р. Кешегә сокланган кебек сокландыммыни? Яратмыйм... Мыскыл итәсе килә башлый.

А л с у. Синнән генә мыскыл итterәсе калган иде. Яратмасаң, бар, чыгып кит.

М ө н ә в ә р. Абзыйны көтәм, эшләгәнемне аласым бар.

А л с у. Әйдә, салып бирәм дә эзеңне суыт моннан!

М ө н ә в ә р. Юк инде, хужа кайтсын. Бер тәртип куелган икән, шулай булсын...

А л с у. Соңладылар...

М ө н ә в ә р. Син өметләнмә дә, барыбер җиңеләсез.

А л с у. Юрама әле... Судка тоткан акчалар булса да кире кайтыр иде... Марсельнең дә бернәрсәсе юк. Шуңа булышасы урынга...

М ө н ә в ә р. Марсельнең булыр, бар нәрсәсе дә... Тынычлыгы, бәлки, булмас, анысын әйтә алмыйм.

А л с у. Юрама, дим.

М ө н ә в ә р. Юрамыйм. Белеп әйтәм.

А л с у. Артык белдекле булдың әле.

М ө н ә в ә р. Марсель судка киттеме?

А л с у. Китте инде. Илдарның тагын өянәге тота-нитә калса дип...

М ө н ә в ә р. Өянәге тота калса... Ярар. Баргач, әйбәт. Димәк, мин әйткәнчә булачак.

А л с у. Әллә нәрсә әле син бүген...

*И л д а р кайтып керә. Аяк киемнәрен дә салмый-нитми, башта Марсель бүлмәсенә ыргыла.*

М ө н ә в ә р. Кайттылар да бугай.

И л д а р *(үтешли)*. Кайттымы теге?

А л с у. Кем?

И л д а р. Малаең... *(Үз бүлмәләренә үтә.)*

*Л ә й с ә н белән Р а ф а э л ь керәләр.*

Р а ф а э л ь. Кая китте?

А л с у. Бүлмәдә...

*Р а ф а э л ь И л д а р артыннан кереп китә.*

А л с у. Илаһым, нәрсә булды?

Л ә й с ә н. Марсель кайтмадымы?

А л с у. Юк, бергә чыгып киткән идегез ләбаса. Нәрсә булды соң? Җиңелдекме?

Л ә й с ә н. Җиңелдек анысы...

*Р а ф а э л ь белән И л д а р чыгалар. Илдар бер шешә аракы тоткан.*

И л д а р. Кем әйткән аны аларга? Шул сөйләгән...

А л с у. Нәрсә булды соң?

Р а ф а э л ь. Син кызма әле, тукта...

И л д а р *(Мөнәвәргә).* Син нишләп утырасың монда?

М ө н ә в ә р. Кушканнарыңны эшләдем!

И л д а р. Түләү көтәсеңме?

М ө н ә в ә р. Көтәм инде...

И л д а р *(Алсуга)*. Бир шуңа әйбереңне! Миңа да бер савыт бир әле!

А л с у. Бирәрегез аңлатамы нәрсә булганын?

И л д а р. Кушканны гына эшлә әле!

*А л с у М ө н ә в ә ргә салып бирә. Л ә й с ә н И л д а рга рюмка алып бирә.*

Л ә й с ә н. Мә, эти.

И л д а р. Күзен дә йоммый бит, күрмәдем, ди. Нинди адәмнәр бу? Бертуган сеңлесе бит.

Р а ф а э л ь. Нәрсәдер бар инде монда, болай гына түгел...

И л д а р. Нәрсә булса да, аны атага әйтеп сөйләшергә ярамыймы?

А л с у. Җиңелдекмени?

И л д а р. Җиңелүдәмени хикмәт? Анысы билгеле иде бит инде аның. Монда мине дурак итеп чыгардылар.

А л с у. Ничек инде?

И л д а р. Анысын малаеңнан сорарга кирәк. Шалтыратмадымы ул?

А л с у. Юк.

И л д а р. Мин җүләр икән, күземә күренә икән. Каян белә алалар аны анда?

А л с у. Шуны судта әйттеләрмени?

И л д а р. Әйттеләр генәме. Справка да ясатып килгәннәр бит, выписка.

А л с у. Нинди выписка?

Л ә й с ә н. Кичә скорый чакырткач, врачларның язганнарын.

Р а ф а э л ь. Ул аларга барын да бик иплəп сөйләп маташа иде шул.

А л с у. Ул бит борчылып, андый вакытта нәрсә эшләргә дип сорады.

И л д а р. Сорады. Ә судта мине дурак, диделәр. Каян белгән аларның адвокаты ул турыда?

А л с у. Аның өчен экспертиза кирәктер бит.

И л д а р. Мин «күрдем» дип торганда, ул «күрмәдем» дип торгач, тагын нинди экспертиза кирәк?

Р а ф а э л ь. Печәм мин ул малайны!

А л с у. Үз малаеңны кайтып печ.

Р а ф а э л ь. Миңа Ходай бирмәгән шул, но мондыйны биргән булса, ике дә уйламас идем...

И л д а р. Шул сөйләгән инде. Кайтсын гына.

А л с у. Кызым, шалтырат, кайтмасын!

Л ә й с ә н. Аның телефоны сүнгән.

М ө н ә в ә р. Качкан инде бу...

Р а ф а э л ь. Ә син монда нишләп утырасың?

И л д а р. Мөнәвәр, бар, бар әле, үзеңнекен алсаң...

М ө н ә в ә р. Ярый, абзый, бигайбә! Мин башка килә алмам инде...

И л д а р. Нәрсә булды? Салдык бит инде?

М ө н ә в ә р. Эшкә урнаштым.

И л д а р. Ярар. Бар алайса, риза бәхил. Бар.

М ө н ә в ә р. Апа, Марсель кайтса, әйтегез, мин бүген төнгегә чыгам, язып куйсын.

А л с у. Нинди төнгегә? Кая язсын?

М ө н ә в ә р. Аңа урнаштым бит эшкә.

И л д а р. Кая аңа?

М ө н ә в ә р. Шиномонтажга.

И л д а р. Нинди шиномонтаж?

М ө н ә в ә р. Почмактагы сервиста инде... Марсельнеке бит ул хәзер...

И л д а р. Кайчан урнаштың?

М ө н ә в ә р. Кичә сөйләшкән идек. Исәнлектә! *(Чыгып китә.)*

Р а ф а э л ь. Син белми идеңме?

И л д а р. Менә аңлашылды... Ул сервис... Тегеләрнеке иде бит...

Л ә й с ә н. Кемнеке?

И л д а р. Регинаны бәрдергән кабахәтнеке...

А л с у. Аллам икән...

*Л ә й с ә ннең телефоны шалтырый. Ул кем шалтыратканын күргәч, агарынып китә.*

Р а ф а э л ь. Нишләдең? Җавап бир инде.

Л ә й с ә н. Миңа... Регина шалтырата...

А л с у. Әстәгъфирулла...

Р а ф а э л ь. Җавап бир...

Л ә й с ә н. Алло... Син... Син... Бөтенләй акылыңнан яздыңмы әллә? Җүләрме син? Ничек син үлгән кеше номерыннан шалтыратасың?.. Шаштырасың бит кешеләрне... Акчаң бетсә, аныкына тияргә дигәнме?.. Башың бөтенләй эшләмиме әллә синең?.. Өйдә... Барысы да өйдә... Кер... Барыбер бер керәсең була бит инде... Кер... *(Трубканы куя.)*

И л д а р. Регинаның әйберләрендә актарынганмыни?..

А л с у. Илдар, зинһар, тынычлан, шикәрең күтәрелә...

И л д а р. Минем шикәрем өчен борчыласыңмыни әле син?

*М а р с е л ь керә.*

М а р с е л ь. Әйтегез инде берәр сүз, нәрсә эндәшмисез?

Р а ф а э л ь. Бәлки син әйтерсең?

Л ә й с ә н. Марсель, тизрәк аңлат берәр нәрсә? Дөрес түгел, ялган, диген...

М а р с е л ь. Ялган түгел... Сез белеп кенә бетермисез...

И л д а р. Нәрсәне белмибез? Син сеңлеңне бер шиномонтажкага сатканыңнымы? Егетлегеңне, намусыңны? Ирме син? Кешеме син?

М а р с е л ь. Килер бер көн, син мине аңларсың...

И л д а р. Аңлармынмы? Әле син шундый көннәр килер дип өметләнәсеңме? Бәдбәхет! *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

А л с у. Улым, бар, кит... Соңрак кайтырсың, бар...

Р а ф а э л ь. Кил әле монда!

А л с у. Кагыласы булма! Кулыңны сугып сындырам!

И л д а р *(ау мылтыгы күтәреп чыга, Марсельгә төзи)*. Синең ишеләрне беркайчан аңламадым, моннан соң да аңламам.

А л с у. Илдар!

Л ә й с ә н. Әти!

Р а ф а э л ь. Чамалап...

И л д а р. Андый көннәр җиткәнче, мин юк итәм сине!

М а р с е л ь. Ат әйдә!

А л с у *(Марсельне каплап баса)*. Башта миңа ат!

И л д а р. Кит каршыдан! Син аны шундый ясап бетердең. Кит, диләр!

Р а ф а э л ь. Картлач, тынычлан...

И л д а р. Кысылма...

М а р с е л ь. Әнкәй, комачаулама, атсын әйдә!

Р а ф а э л ь. Малай, кыланма, котыртма атаңны...

И л д а р. Алсу, кит!

М а р с е л ь. Кит, әнкәй!

А л с у. Якын киләсе булма, башта мине ат! Ат! Син гомереӊ буена үзең

генә хаклы булдың. Бер кеше хәленә керә белмәдең. Балаларның киләчәге өчен нәрсә эшләдең соң?

И л д а р. Мин эшләмәгәнме? Кем өчен генә эшләгән соң мин?

А л с у. Җил куып йөрдең гомер буена. Бер кеше белән кешечә була белмәдең. Сиңа гына дөреслек кирәк булды. Таптыңмы дөреслегеңне?

И л д а р. Таптым, гомер буе табып килдем. Менә монда ул дөреслек! *(Күкрәген кыйный.)* Яшәгән бер көнем өчен дә оят түгел.

Р а ф а э л ь. Бир әле син моны, кирәкми... *(Мылтыгын алып куя.)*

А л с у. Ә миңа оят! Миңа оят. Нәрсә бирдек без балаларга?

И л д а р. Гомер бирдек! Белем бирдек! Намус бирергә тырыштык!

А л с у. Торыр урының, урнашып эшләр эшең булмаса, намусың белән нишләргә? Әй, яши дә белде кешеләр. Балаларын кайгырттылар. Үзебезгә бер рәхәт булмады, аларга да шул ук... Ничә еллар кеше чүбе түгеп йөрдең. Машинаңа зур итеп язып куеп бит әле, кызык тапкан. Әй хурлана да идем шуңа. Өйгә кайтканыңны күреп, балалар каршы чабалар иде, имеш, әтиләренең машинасына утырып кайталар. Оят! Уф, йөрәгем... Уф, үләм... *(Дару эчәргә чыгып китә.)*

Л ә й с ә н. Әни... *(Аның артыннан чыга.)*

И л д а р. Озак чапмадылар. Укый белә башлаганчы гына. Регина гына... Укый белгәч тә каршыма йөгерә иде әле. Ә менә бу инде хурлана иде...

*Урамда сирена тавышлары ишетелеп китә, төрле төсле мигалка утлары балкып ала.*

Р а ф а э л ь. Нәрсә ул? *(Тәрәзәдән карый.)* Пожарниклар...

И л д а р. Янгын... Кайдадыр янгын... Нәҗесне чокырдан суыртып алып була, күңелдән суыртып булмый шул. Күңелгә кердеме, канга сеңә, аңга сеңә...

М а р с е л ь. Матур сөйләргә була ул, тирән мәгънәләр салып, ә урамда малайлар мине ничек мыскыл иткәннәрен беләсеңме соң син? Миңа бит кул биреп тә күрешмиләр иде. Фу, кулың сасы дип, елатканчы көләләр иде.

И л д а р. Елакны елаталар инде...

М а р с е л ь. Бүтән мине берәү дә елата алмас...

И л д а р. Ә! Бүре булдым, дисең инде... Ул сервиска эт тә йөрми бит. Аның налогы гына да өстеңнән чыгачак, шуны да аңламыйсыңмыни соң син? Юкка гына сиңа биргәннәр, дисеңме әллә аны?

М а р с е л ь. Карарбыз! Син гомергә миңа ышанмадың. Сиңа Регина гына бар иде... Ул гына әйбәт иде...

И л д а р. Ә син аның истәлеген салып таптадың.

М а р с е л ь. Без барыбер ул судта җиңә алмый идек. Нинди мәгънә?

И л д а р. Мәгънәне аңлый торган кешеме соң син.

М а р с е л ь. Син аңлыйсың инде. Мине кара төндә суеп киткән булсалар да, сиңа барыбер.

И л д а р. Миңа янамадылар, дисеңме?! Янадылар.

М а р с е л ь. Әти, ник үзең белән чагыштырасың, мин бит әле яши генә башлыйм.

И л д а р. Авыр башлыйсың, кыек башлыйсың.

М а р с е л ь. Намус дигән булып, кабердә кортлар ашатып ятканчы, мин якты дөньяны сайлыйм. Телемне аркылы тешләп булса да, мөмкин кадәр каерып алып, үз ишләре булам. Бүре булам.

И л д а р. Шакаллар алар... Син дә шакал...

*Ишек шакыйлар. М ө н ә в ә р керә.*

М а р с е л ь. Нишләп йөрисең монда?

М ө н ә в ә р. Мин абзый янына кергән идем...

М а р с е л ь. Нишләп син эш урыныңда түгел?

М ө н ә в ә р. Анда бит мин барып җиткәнче берни калмаган.

М а р с е л ь. Нәрсә калмаган?

М ө н ә в ә р. Юк сервисың, янган. Берни калмаган...

М а р с е л ь. Ничек?

М ө н ә в ә р. Мин каян белим. Янган дим. Юк. Абзый, мин иртәгә карларны килеп көрәрмендер...

Р а ф а э л ь. Көрәрсең... Бар инде син, туган, вакытсызрак бераз...

М ө н ә в ә р. Ярар, мин әйтеп кенә чыгыйм дигән идем... *(Чыгып китә.)*

*А л с у белән Л ә й с ә н керәләр.*

А л с у. Нәрсә булды? Мөнәвәр нишләп йөри?

Р а ф а э л ь. Сервисны яндырганнар...

А л с у. Нинди... Марсельнекенме?!

Л ә й с ә н. Әстәгъфирулла...

М а р с е л ь *(әтисенә)*. Куанасыңмы?

И л д а р. Җүләр син, улым... Бүре булдыңмы? Шакалныкы шакалча...

М а р с е л ь. Куан әйдә, куан...

И л д а р. Җүләр...

М а р с е л ь. Сиңа Регина гына булды. Ул гына җиңүче. Ул гына бар нәрсәне дә булдыра...

И л д а р. Икегез дә – минем балам.

М а р с е л ь. Нишләргә тиеш идем соң мин?

А л с у. Тынычлан, улым, тынычлан. Бәлки ремонтлап буладыр әле.

М а р с е л ь. Нинди ремонт инде. Көле күккә очкан.

А л с у. Тукта әле син, алай ашыкма әле. Мин карап кына кайтыйм әле. Нәрсә икән анда...

И л д а р. Йөрмә...

*А л с у чыгып китә.*

Р а ф а э л ь. Әшәкелекнең чиге инде бу...

И л д а р. Андыйлар белән кул сугышсаң, мондыйга әзер булырга кирәк... Ярар, бераз кешене кешедән аерырга өйрәнерсең... Куяндай сеңлеңнең үтерүчесе белән ничек кара-каршы басып сөйләшә алдың...

М а р с е л ь. Сиңа куян булды инде ул, гомергә. Ак булды, йомшак булды. Акыллы шул. Минем кебек эчендәге тышында түгел...

Р а ф а э л ь. Җитәр, тынычлан.

М а р с е л ь. Сез бит бернәрсә белмисез. Сезгә мин сеңлемне саттым – шул гына. Сез бит бернәрсә белмисез, бернәрсә... Алай җиңел генә булса икән ул. Алар ике ел очрашып йөрделәр...

И л д а р. Кем?!

М а р с е л ь. Илшат белән Регина...

И л д а р. Аның гаиләсе бар бит.

М а р с е л ь. Гаиләсе бар шул... Синең тәти кызың. Яраткач, нишләсен...

Л ә й с ә н. Марсель, җитәр.

М а р с е л ь. Җитми, белсеннәр. Әллә сине сагынганга атлаган саен кайтып йөри иде, дисеңме? Аерылмады гына. Кияүгә дә чыгып куя иде.

И л д а р. Ул бит глава кызына өйләнгән.

М а р с е л ь. Шул шул. Безнең ише генә булса, күптән ташлап китә

иде инде... Авария урынына кем чәчәк ташый, дисең... Кара машинада кем утыра дисең?

Л ә й с ә н. Туктат.

М а р с е л ь. Туктатмыйм... Белсен... Дөнья ак белән карадан гына тормаганын. Ул дөреслек эзли гомер буена. Ә кайда ул дөреслек? Ничек аны аерып алырга? Кем белә аны? Регина аборт ясатты. Илшат ясаттырды. Үзе дә сездән куркып ризалашты. Регина... Балакаем. Әллә мин аны яратмый идем, дисеңме? Без бит гел бергә идек. Әллә мин сагынмый, дисеңме? Әллә мине төннәрен еламый, дисеңме?.. Ул бит ярты ел буена саташып йөрде. Ул бит... Төннәр буена бала елаганын ишетәм дия иде... Төннәр буе. Менә кая ул дөреслек? Әйт син миңа. Син уйлаганча ак белән кара гынамы дөнья?

И л д а р. Ышанмыйм. Алдыйсың. Яла ягасың!

Л ә й с ә н. Әти, ул дөресен әйтә...

*И л д а р чыршы янына барып утыра.*

М а р с е л ь. Мин аңа күпме аңлатып карадым, күпме кисәттем... Тыңламады...

Р а ф а э л ь. Тукта, ничек ул аны ялгыш машина белән бәреп киткән соң?

М а р с е л ь. Белмим. Регина аны тинтерәтте. Хатынына сөйлим дип яный иде бугай... Мин белмим. Үзем дә аңламыйм. Ул аны өйгә кайтарып куйган инде... Аннан ничек бәргәндер. Йә, аны җибәрмим дип, үзе капотына ташлангандыр...

Р а ф а э л ь. Йә, сөйләмәсен өчен... Бәреп киткән инде...

М а р с е л ь. Нишләргә тиеш идем мин... Күрдем мин аны, күрдем... Исерек иде... Башта Регинаны бәргән, аннан баганага... Үземне дә үтереп китсеннәр идеме? Әллә мин машина белән болай гына капландым, дисеңме? Регинаны кайтарып булмый иде бит инде... Әти-әни картайган... Әтинең шикәре... Мин нишләргә тиеш? Ничек мин аларны карарга тиеш, картлык көннәрендә. Абый, әйт син миңа, нишләргә тиеш идем мин? Берәр ничек булса да түләргә тиеш иде бит инде ул?

Р а ф а э л ь. Боларны түләтә алмыйсың...

М а р с е л ь. Әти! Әти! Берәр сүз әйт...

*И л д а р агарынып калган. Ул елый. Аңа таба кулларын суза. М а р с е л ь аңа килә. И л д а р аны кысып кочаклый.*

И л д а р. Балакайларым... Нәрсә генә кичмәгән икән бит башларыгыздан... Тәтиләрем минем... Песиләрем минем... Куяннарым минем... Ярты ел буена бала елаганны ишетеп яшәгән... Балакаем, нәрсә генә кичермәгән икән бит, сабыем... Ниләр генә уйламагандыр, курыккандыр... Нишләп соң бар нәрсәне дә әйтеп сөйләшә торган булмадык, нишләп үзебездән курка, хурлана торган иттек соң без сезне? Ничек бу җәберләрдән саклый алмадым соң мин сезне? Балаларым чит, хатын яратмый торган көнгә ничек барып җиттем соң мин?.. Әниегез хаклы, җил кыйнап үтте гомерем...

*Эт улаган тавыш.*

Р а ф а э л ь. Бу нәрсә инде?

Л ә й с ә н. Тагын шул... Бигрәк шомлы...

И л д а р. Маратның эте. Хәзер, хәзер тыям мин аны. Мыскыл итмәсен болай. *(Мылтыкны барып ала.)* Маңгаена төбәп атам мин аны

хәзер. Куркытмасын минем балаларны...

*Чыгып китә.*

Р а ф а э л ь *(артыннан кычкырып кала)*. Кая киттең инде, булашма!

М а р с е л ь. Атмый ул, абый, җикеренә генә... Абый, сал әле, берәр нәрсәң бармы?

Л ә й с ә н. Бигрәк бүре тавышлары чыгарып улый...

М а р с е л ь. Атса да, тигезә алмый ул аңа, күзе дә күрми бит...

*Урамда ике мәртәбә аткан тавыш.*

Л ә й с ә н. Әстәгъфирулла...

Р а ф а э л ь. Син атаңны белеп бетермисең әле...

М а р с е л ь. Юк икән шул...

*Мылтыгын сөйрәп, И л д а р керә. Кәнәфиенә барып ава.*

И л д а р. Курыкмагыз, бүтән уламас...

Р а ф а э л ь. Ярар! Бу мылтык бер атарга тиеш иде инде бүген... Хәерлегә булсын.

*Алсу керә, аның төсе калмаган.*

А л с у. Илдар, нишләдең син?

И л д а р. Аттым этне.

Р а ф а э л ь. Бүре кебек улый бит, шомландыра...

А л с у. Ул бит кеше аткан... Кара машина янында...

М а р с е л ь. Илшат... *(йөгереп чыгып китә.)*

Р а ф а э л ь. Вот ё-моё... *(Чыгып йөгерә.)*

А л с у. Скорый чакыртырга, скорый чакыртырга кирәк... Нишләдең син, нишләдең, Ходаем?.. *(Чыгып китә.)*

И л д а р. Кызым! Алтыным... Куяным... Песием минем... Шундый сагындым сине... Без бит синең белән Чия тавына кайтырга тиеш идек... Яз көне. Чияләр чәчәк атканда. Күрсәң иде син шуны. Андый матурлыкны күрсәң, шундый рәхәт булыр иде сиңа. Бөтен нәрсә онытылыр иде. Андый матурлык янында бар нәрсә дә онытыла, барлык кайгы-хәсрәт. Шау чәчәктә утырган Чия тавы – чәчәк аткан карабодай кырын әйләндереп элгән сыман... Таллык аша тар сукмактан килеп чыгасың да өстеңә ишелеп-ишелеп матурлык ага... Ишетәсеңме син мине, кызым, Регина?

Л ә й с ә н *(агарынып аңа карап торган җиреннән)*. Ишетәм, әти...

И л д а р. Күрәсеңме бу матурлыкны?!

Л ә й с ә н. Күрәм, әти...

И л д а р. Син мине яратасыңмы, кызым?

Л ә й с ә н. Яратам, әти...

*Ул сөйләгән арада өйнең диварлары юкка чыга, Чия тавы ачыла. Шау чәчәктә утырган чиялек. Яраткан көе ишетелә. Илдар шунда кереп китә. Ул чияләр арасыннан барганда, җил чыгып бөтен чәчәкләрнең таҗларын очырта, чәчәк бураны куба. Ул ямь-яшел чиялектән атлый. Берзаман чия агачларында җимешләре кызарып пешә, ул җимеш тулы чияләр арасында.*

П ә р д ә.



Әлфис
Гаязов

# ХАТ АЛЫШУ

ПОЭМА

*Ишегалды яшел үлән,*
*Атларыңнан кимертмә,*
*Кулларың язуга белә,*
*Хатларыңа тилмертмә!*
Халык җыры

**1**

Онытылды хат язулар күптән,
Телефоннар – заман ачышы.
Хәбәр биреп, алар очраштыра,
Телефонда телләр ачкычы.

Бүген кеше акка матур итеп,
Сала белми сүзләр тезмәсен.
Уйлары да ярты-йорты гына,
Аңламассың язган җөмләсен.

Элек менә хатлар – хатлар булган,
Төрле яктан торган килгәләп.
Яу кырыннан өчпочмаклы хәтәр
Хатлар килгән, җанны телгәләп.

Озыннары булган, су буедай,
Язылганнар кичләр утырып.
Әллә нинди серле роман итеп,
Ике табак битне тутырып.

Әйе, яза белгәннәр шул элек, –
Сокланырлык һәрбер юллары,
Сыйдырганнар алар үз эченә
Башта йөргән барлык уйларны.

Кирәк булса – җавап көткәннәрне
Бер көлдереп, йә бер елатып,
Кирәк булса – күз яшьләре белән
Язган хәрефләрне чылатып.

Төрле хәбәр: шатлык, кайгы-сагыш,
Сагыну белән чигеп битләрне,
Бер бөтенгә барсын тоташтырып,
Туган яклар белән читләрне.

Күк күгәрчен аша хәбәр язып,
Очырганнар туган җирләргә.
Кош теледәй генә хатлар килгән,
Әллә кайдан, ерак илләрдән.
Һәм көткәннәр җавап, айга карап,
Туган яктан искән җилләрдән.

Хәзер инде күпләр хәтерләми
Кара савытларын, каләмне.
СМСлар гына йөри бары,
Тоташтырып бөтен галәмне.

---

Әлфис ГАЯЗОВ (1956) *– галим, язучы, педагогия фәннәре докторы; РФ мәгариф академиясенең мөхбир-әгъзасы, Россиянең һәм Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе. «Мин бәләкәй бит әле», «Бәхет дагасы», «Актирәк, күктирәк» һ.б. китаплар авторы. Уфада яши.*

Хат язуның тәме, яме бетте,
Барыбыз да күчтек җиңелгә.
Истәлекләр булып калган хатлар
Яши бары безнең күңелдә.

Ә шулай да сагындыра кайчак,
Бер язасы килә хатларны –
Ак кәгазьгә олы фикер салып,
Сүзен ядкарь итеп ятларлык!

**2**

Бала чакка кайта кайчак күңел,
Истәлекләр эзли, җыр эзли,
Еракларда калган сихри галәм
Үз көендә тота гел безне.

Түбә асты – чорма – серле дөнья,
Әллә ниләр анда бар инде!
Бу дөньяның астын өскә куеп,
Уйнаганда урын тар иде.

Шул чормага тарта күңел. Менәм,
Елагандай, баскыч шыгырдый.
Күз алдына килә малай чаклар,
Көтә мине мәйдан – ындырдай!
Ни генә юк монда, сүзсез калдым, –
Хыялдырмы болар, чындырмы?

Яман көчтән саклар диеп йортны,
Беркетелгән артыш чыбыгы.
Ипләп кенә чорма бәпкәсенә
Кыстырылган озын чыбыркы...

Савыт-саба ята, иске чәйнек
Һәм борынсыз иске самовар,
Тәмле ашлар безгә бүләк иткән
Эреле-ваклы чуен казаннар...
Зур таныштай миңа сәлам бирә
Минем белән яшьтәш календарь.

Ә түбәнең биек кайчысына
Кыстырылган әткәй балтасы, –
Ашау-эчү биргән, киендергән
Оста куллар адәм баласын.

Ә бәләкәй чана тора кебек
Тау шуарга мине чакырып.
Сыңар чаңгы, тимераяк ята,
Ялгыз булуына аптырап.
Ничә еллар икмәк бүләк иткән
Куәс чиләк кибеп утыра.

Бер почмакта тынып уйга калган
Безнең бишек – ничек сакланган!
Әйтерсең лә, безнең елау тынгач,
Тынычланып, үзе йоклаган.

Мендәр ята сандык өсләрендә,
Телсез сәгать, ишек келәсе,
Көндәлектә бер «икеле» күреп,
Еласы да килә, көләсе...

Әйтерсең лә, тынып калган өй дә,
Бишек итеп түбә кыегын,
Балачагым изрәп йоклый кебек,
Хәтер сандыгына сыенып...

**3**

Бар да таныш монда, бөтен нәрсә
Минем өчен якын, ят түгел,
Балачагым белән исәнләшеп,
Тылсым илен гизәм мин бүген.

Әллә кайда, күзгә чалынмыйча,
Үз сәгатен көтеп, читтәрәк,
Тузан басып киткән бер урында
Тып-тын гына ята бер төргәк.

Бар икән бит мин белмәгән нәрсә –
Ничек шулай яткан ул анда,
Кирәксезгә чыккан мөлкәт кебек,
Онытылып, катып тузанга?

Кемнәр тормыш дәвам итәр дигән,
Вакыт кысаларын күрмәгән;
Бәлки берсе табар диеп, кемдер,
Бу төргәкне дүрткә бөкләгән?

Ә төргәктә хатлар... Бер-бер артлы
Еллары да, ае, көннәре,
Кичә генә килгән кебек, исән
Почта суккан мөһер эзләре.

Шул хатларны укыйм, тын да алмый,
Бар дөньяны ташлап, онытып.
Саф мәхәббәт – зәңгәр диңгез кебек,
Колач салып йөзәм, җан атып...

Шушы хатлар белән таныштыру
Алдымдагы газиз бурычым,
Мине генә таңга калдырмасын,
Син дә, әйдә, таныш, укучым!

**4**

Ерак калган җитмешенче еллар,
Мәктәп чоры әле хәтердә.
Арткан саен үткән еллар саны,
Безнең өчен алар кадерле.

Ертыгы юк җырның, дисәләр дә,
Мәктәп тормышында кагыйдә:
Мәхәббәт дип, сөю сүзен кушып
Җырлау ул вакытта юк иде.

Ул җырларда – илне, эшне мактау,
Уку, уен, гомум сәясәт,
Мондый җырлар арасына ул чак
Каян килсен сөю, мәхәббәт?

Яшьлек – яшьлек инде. Без барыбер
Яндык, көйдек, хисләр кичердек,
Танышулар, озатулар аша,
Сөю хисен татып исердек.

Әрсезлек юк, бары күз карашы,
Кыюсызлык, чиксез оялу;
Йөрәк түрләрендә кайнап торган
Хис-тойгыңны әйтү кая ул?..

Танышырга, эндәшергә кыймый,
Эзләп үзебезгә тиңнәрне,
Хатлар яздык. Җавап өмет итеп,
Йокылары качты төннәрнең.
Дәресләрдә бер карашны көтеп,
Үткәрдек без озын көннәрне.

Кемдер шушы еллар агышында
Гомерлеккә ярын сайлады,
Кемдер шунда өмет дулкынында
Сөю көтеп йөзде-чайкалды.

Һәм без үстек матур хатлар укып,
Туар көнгә зур өмет баглап,
«Тапшырылмаган хатлар» өчен сыктап,
«Киләчәккә хатлар»ны ятлап,
«Хат ташучы» егет бәхетенә
Сөенү һәм соклану саклап.

Сагынычлы хатлар язган мәлләр,
Йөрәкләрдә янган учаклар,
Искә төшә безне уттан алып,
Суга салган матур ул чаклар.

**5**

Төргәк җебе миңа комачаулый,
Һәм ашыгып аны мин кисәм:
Ә хатларның бу башында – Әнис,
Теге башта – чибәр Әнисә.

Егермедән артык хат сакланган,
Ун көн саен Әнис хат алган.
Әнисәнең хаты – җавап хаты,
Белмим, Әнис аңа ни язган?
Җавап хатын Әнис исеменнән
Әнисәгә бүген мин язам.

Үз өстемә җаваплылык алам,
Аңлыйм аның нинди зурлыгын.
Тагын бер кат исбатлыйсым килә
Бөек мәхәббәтнең барлыгын!

Хат башында Әнис язган элек
Дөнья хәлен, һава торышын.
Минем өчен мөһимрәк ләкин
Олы мәхәббәтнең юл башы.

Һәм азагы... Хатның азагымы?
Аңлау авыр, моны кем белгән...
Йолдыз булып шәхси язмышларда
Мондый хәлләр бик еш сибелгән.

Шуңа алар күңелләрдә яши,
Шигырь булып яки җыр булып;
Кеше маңгаена языла-лар,
Ягыла-лар яра-сыр булып;
Шуңа алар йөрәкләрдә кала,
Канат булып, якты нур булып!

**6**

*Әнис*
«Исәнмесез!
Уку елы тәмамланган чакта,
Физрук абый җыеп бер төркем,
Егетләр һәм кызлар, шатланышып,
Юлга чыгып киттек без беркөн.

Озак бардык. Өйне беренче кат
Ташлап китү булды шул елда.
Безне көтә иде палаткалар,
Агым сулы елга буенда.

Җыйналыштык йөзләп егет һәм кыз,
Мәктәпләрдән, әллә кайлардан...
Шушындагы кызлар арасыннан
Йөрәгем тик сине сайлаган».

*Әнисә*
«Минем дә бит болар хәтеремдә,
Онытырлык түгел ул көннәр.
Безгә шундый ялны оештырган
Комсомолга рәхмәт йөзеннән,
Барыбыз да төрле уеннарда
Катнаштык без теләп, ихластан.
Шуңа да бит яллар матур булды,
Иң беренче көннән, иң баштан.

Учак тирәсендә утырганда
Гармуныңда уйнап үттең син,
Игътибарны шунда җәлеп иттең –
Башкалардан үзгә идең син...»

*Әнис*
«Хат алганга була ике атна,
Җавап яза алмыйм һаман да.
Бар да истә: дулкын уйнаганы,
Кошлар җырлаганы урманда,

Җир җиләге пешкән ул аланда
Сандугачлы таңнар атуы,
Нәкъ җырдагы кебек таң алдыннан
Күк читендә Чулпан калкуы...

Тавышыңның көмеш челтерәве,
Җиз кыңгырау моңы чыңлавы...
Сүзсез калып, дәшми-тынмый сине,
Бары сине генә тыңладым!

Хыялыйлар итте елмаюың,
Гөлләр булып миңа күрендең,
Аңлый алмый булган халәтемне,
Бер яндым да мин бер тереллдем.

Синең көлү! Искитәрлек моңлы,
Әле булса чыңлый колакта,
Көлү түгел – бу җыр кебек иде,
Аккан сулар кебек улактан.

Кыюлыгым җитмәс иде минем
Әйтер өчен шушы юлларны.
Әрсезләнеп шуңа, мин аларны
Хатлар аша сиңа юлладым...

Җавап көтәм. Әгәр хәтерләсәң
Сәяхәтнең озын көннәрен,
Онытмасаң, урман аланында
Сиңа гөлләмәләр биргәнем...

Гаепләмә берүк, бу хатымда
Әллә ниләр язам бугай мин.
Күңелемне минем сихерләдең,
Әсир булдым сиңа шулай мин».

*Әнисә*
«Хәерле көн, Әнис. Бүген иртән
Алдым синең җавап хатыңны.
Шуңа микән әллә, күңелкәем
Йөри күкнең җиде катында.

Укытучым әйтә: елмаюың
Колагыңа кадәр җиткән, ди,
Нәрсә колак, алай гынамы соң,
Колакларың узып киткән, ди!

Узгандыр да. Җавап көттем синнән,
Язарсың дип ныклы ышанып,
Кичә генә җирдә булган күңел,
Бүген күктә оча, хушланып.

Хатларыңны көтеп калам тагын,
Иң мөһиме – син яз, онытма!
Мөмкин булса, кирәк диеп тапсаң,
Араларны берүк суытма!

Син шаяртып кына язасың дип
Шикләнеп тә куям югыйсә.
Ярар, моңа вакыт җавап бирер.
Сәлам белән, дустың Әнисә!»

*Әнис*
«Җавап булыр микән, дигән уйлар
Атна буе башта кайнады.
Шул чакларда сагыш басылсын дип,
Тальянымда шашып уйнадым.

Хатлар аша җылы сүзләр көтеп,
Сагышлардан күңел сыкрады.
Бары дустым, минем тугры дустым –
Тальян минем белән елады.

Бүген тальян уйный шат көйләрне,
Җавабыңны икәү укыдык.
Гармун миңа сердәш, икәү генә
Төнгә тиклем җырлап утырдык.

Мин елмаям назлы сүзләреңә,
Күзләремнән шатлык агыла.
Синең белән булган минутларны,
Мизгелләрне барлап сагынам.

Кыен чакта айга кара, диләр,
Айны көтәм мин дә ашкынып.
Карточкаңны җибәр әле! Юкса
Сагынудан йөрим шашынып.

...Кичә генә төштә күрдем сине –
Ялгыз йөри идең аланда.
Эх, киләсем килде синең янга,
Авыр була ялгыз калганда...

Укуыңда сиңа уңыш телим,
Юлдаш булсын сиңа бөек хис!
Очрашулар өмет итеп калам,
Сәлам белән сиңа – мин, Әнис!»

*Әнисә*
«Алсуланып аткан таңнар миңа
Алып килә сихри тойгылар.
Таныш түгел моңнар, уйлар, хисләр
Ташу булып миндә ургыйлар.

Моңа тиклем яшәгәнмен икән
Берни белми, берни күрмичә.
Бу дөньяга яңа караш туа,
Һәм яңадан туа Әнисә!

Моңа тиклем гади генә булган
Минсез аккан гадәти мәлләр,
Мәктәптә без теләмичә генә
Укып йөргән дәресләр, фәннәр.

Яз җылысы, яуган карның яме
Һәм күзләрнең сары сагышы,
Кешеләргә булган зур ихтирам –
Мин яңача аңлыйм барысын.

Һәм әйтергә куркам – нинди хәл бу?
Кайдан килә шушы галәмәт?
Мин көн саен яңа дөнья ачам,
Шушы микән әллә м...?»

**7**

Менә шулай бер ел үтеп киткән,
Хатлар йөргән ике тарафка.
Яңалык юк кебек хат язуда,
Иң беренче гади карашка.

Кичә тормыш болай түгел иде,
Башка төрле иде уйлар да.
Тик ашыкмыйк әле хат язуны
Без искелек диеп уйларга.

Без шаһите менә шушы мәлдә
Яңа туган сөю хисенең,
Биеклеккә алып менә торган,
Бөеклеккә Кеше исемен.

Һәркем үзе үтте ул заманда
Учакларын яну-көюнең,

Китап-кинолардан карап кына
Өйрәнмәде кеше сөюен.

Бик аз язылса да, китаплардан
Эзли идек сөю эзләрен.
Өчпочмаклы хатлар саклый иде
Йөрәктәге сөю хисләрен...

Без сагына идек өлкәннәрдән
Килгән мирас – изге әдәпнең,
Озак көткән бүләк кебек итеп,
Көтеп алдык сөю сәгатен.

Ялгышлардан саклый иде безне
Әти-әни нәсыйхәтләре.
Сөюне без күңелләрдә йөрттек,
Һәм алыштык вәгъдә хатлары.

**8**

Чит-ят язган адрес күреп, Әнис
Берчак шулай калды аптырап,
Һәм конвертны ачып, тиз-тиз генә
Алды хатны, куркып-калтырап.

Берничә кат укып чыкты аннан,
Көлә-көлә күзе яшьләнде,
Апалары-җиңгәләре язган,
Шаяртканнар шулай яшьләрне:

«Әй, Әнисә, Әнисә,
Әнисә бездә ничә?
Уңганнары берәү генә,
Ялкаулары берничә!

Әй, Әнисә, Әнисә,
Әй, Әнисә – душа мой!
Ничә барсаң йоклап ята,
Шул күңелгә ошамый!

Безнең чибәр Әнисәбез
Хат алырга бик риза.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә,
Көн дә җавабын яза.

Тәрәз төбем тулы чәчкә,
Гөлләр саны унбишләп.
Әнис ничек укый икән?
Әнисәбез – гел «биш»кә!

Кояш җылысын тарата,
Җиләсләтеп җил исә.
Бөтен ягы белән килгән,
Шундый уңган Әнисә!

Барын эшли ул теләсә,
Камыр баса, токмач кисә,
Судан кайта, суга бара,
Утын кисә, утын яра,
Мәктәбендә укый «бишкә»,
Кышын утын яга мичкә.

Һәр кич саен бакча утый,
Бакчасы зур – кырык сутый,
Иртә торып печән чаба,
Көтү куа, сыер сава,
Кич уенда бии, җырлый,
Әйткән сүзе җырлы-моңлы...

Йоклап ятмый, иртә тора,
Кайчагында тик утыра,
Идән юа, аш пешерә,
Йөзе ачык карт кешегә,
Күп сөйләми, тыңлый белә,
Тыйнак итеп кенә көлә!

Әнисә дип яна Әнис,
Әнис диеп – Әнисә,
Иллә әйбәт булыр иде
Болар тизрәк өйләнсә!»

Менә шундый шаян хат язганнар
Уттан җитез уңган җиңгиләр.
Шаярулар, уен-көлке аша
Әнисәне инде димлиләр!

**9**

*Әнис*

«Очрашуга безнең булды бер ел,
Сизмичә дә калдым үткәнен.
Менә тагын бер кат укып чыктым
Хатларыңны синең кичә мин.

Быел безне бик зур эшләр көтә –
Тәмамлыйбыз урта мәктәпне.
Зур укуга бару минем ният,
Бозып авылдагы гадәтне.

Безнең якта яшьләр мәктәптән соң
Авылларын ташлап китмиләр,
Армияне үтеп, җиң сызганып,
Туган җирдә бар да эшлиләр.

Ә мин телим институтка кереп,
Вузда укып белем алырга.
Ә аннан соң, укытучы булып,
Туган якта яшәп калырга.

Быел җәйне очрашырбыз диеп,
Хыялландым – барып чыкмады,
Ничә тапкыр сиңа барам диеп
Әзерләндем, тагын тукталдым.

Студентлар булып китсәк, бергә
Укырбыз да, ял да итәрбез,
Һәркөн саен, көндез, иртә-кичен
Бергә булыр идек икебез!»

*Әнисә*

«Әнис дустым! Рәхмәт тәкъдимеңә.
Хыялларың синең матур да...
Тик мин әле хыяллана алмыйм
Вузда белем алу хакында.

Ташлап чыгып китә алмам, ахры,
Олыгайган әткәй-әнкәйне.
Авылымда гына үткәрергә
Туры килер, ахры, бу җәйне.

Акрынлап бәлки тормышыбыз
Җайланып та китәр, кем белә.
Ул чагында инде белем ташын
«Кимерербез» икәү бик теләп!»

*Әнис*

«Хатың алгач бик нык дулкынланып,
Бик хафалы уйга мин чумдым.
Очрашуга икеләнмим, бары,
Әти-әниең өчен борчылдым...

Бар да әйбәт булыр, син кайгырма,
Язмыш сыный, нәрсә әйтерсең!
Әгәр быел барып чыкмый икән,
Икенче ел килеп җитәрсең!

Ике елдан артык күрмәсәм дә,
Һәр көн саен ныграк сагынам,
Һәр көн саен күңел барып кайта
Синең янга җитез кош сыман.

Сагышларым-көюләремне мин
Җырларыма кушып таратам.
Кыю түгелмен шул! Булса, булыр:
Әллә инде сине я...?»

*Әнисә*
«Хатың алдым... И, еладым, белсәң!
Юешләнеп бетте мендәрем.
Керфек какмый каршыладым таңны,
Елап-үксеп үтте көннәрем.

Рәхмәт сиңа! Ходай ни язгандыр,
Кабул итәм. Сиңа ышанам,
Нишләр идем әгәр син булмасаң?
Ярый син бар, шуңа куанам!

Хатлар түгел, таңда җилләр булып,
Синең якларыңа мин исәм.
Ераклардан бик күп сәлам юллап,
Синең яшьлек дустың – Әнисә!»

**10**

*Әнис*
«Котлыйм сине! Ышанмассың, инде
Артта калды имтиханнар да!
Без атлыйбыз алга, зур дөньяга,
Өмет белән тулы юлларга.

Минем тиздән тагын имтиханнар,
Әзерлек тә болай бар кебек,
Тик шулай да бераз шикләндерә, –
Шәһәр, яңа шартлар иң элек...»

*Әнисә*
«Аттестат та алдык. Чыгарылыш
Кичәсенә барам. Күңелсез...

Шатланырга урын бар да кебек...
Юк та кебек, чөнки мин – синсез!

Шатлык дулкынында түгел шул мин,
Көткән чәчәкләрем сулгандыр...
Кемдер сиңа елмаядыр төсле,
Кемдер сиңа башын салгандыр...

Мин барыбер сине генә көтәм,
Очып барыр идем, кил дисәң.
Очрашуга өмет итеп калам, –
Яшьлек дустың – синең Әнисәң!»

**11**

Шагыйрь җанлы кеше икән Әнис –
Укып аның язган хатларын,
Искә төште үземнең дә шулай,
Кызларга хат язган чакларым.

*Әнис*
«Үтәр идем авыл урамнарын,
Мин сыенып сиңа, сарылып.
Китәлмичә туктап калыр идем,
Чәчләреңә синең уралып.

Син сорама, нигә шатсың, диеп,
Кошчык тоткан сабый баладай...
Шатлыгымның сәбәпләре бик зур –
Хатың килде, очам һавада!

Исемен дә белмим, бер йолдызга
Кичен карыйм, серем сөйләргә.
Күзен кыса кебек шул йолдызкай,
Әллә синнән берәр хәбәрме?

Ике атна хатың килми торды –
Оныттыңмы әллә дигәндә,
Сагышларың төяп хатың килде,
Онытмадым сине, дигәндәй.

Әллә нигә күңел урын тапмый,
Әллә нигә йөрәк талпына...
Бер сәбәп юк икеләнү өчен,
Очрашуга йөрәк ашкына...

Белсәң иде, бер матур көй чыкты,
Уйнаганда кичен тальянда.
Тыңлар идең, әгәр якын булсаң,
Булсаң әгәр минем яннарда...

Моңлы җырым ишетерсең бер көн,
Ә әлегә юллыйм сүзләрен.
Тик ул сүзләр сиңа ошамаса,
Әйт дөресен, яме, түзәрмен...

Минем өчен мөһимнәрдән мөһим
Синең бәя, синең карашың.
Мин ул җырны синең исем белән,
«Әнисә» дип сөеп атадым…»

*Әнисә җыры*
«Талгын җилләр булып иртә-кичен
Синең тарафларга исәрмен,
Җылы куллар булып битләреңнән,
Чәчләреңнән сыйпап үтәрмен.

Иртәнге чык тамчылары булып,
Керфекләрең синең чыланыр,
Чыланыр да, күңелләрең шулчак,
Мине сагынудан моңланыр.

Ай нурлары синең тәрәзәңдә
Көмеш юллар булып сызыла,
Аңла шуны – минем йөрәгемнән
Хисләр нурлар булып сузыла.

Ишетерсең минем җырларымны,
Тавыш бирсә шаян кайтаваз,
Син тоярсың минем сагынуым,
Ләйсән булып яуса җылы яз!»

**12**

Ә төргәктә бары бер хат калды,
Әнисәнең соңгы язганы.
Ачарга дип кулым күтәрелми,
Сизгән кебек сөю азагын.

Ачык кебек инде хәлләр хәзер –
Хатларның да алда соңгысы,
Нинди кара көчләр кадаганнар
Мәхәббәткә утлы сөңгесен?

Ни булганын фараз итә алам, –
Тик кирәкме сезгә фаразым?
Ни булганын белмим, мәхәббәтнең
Очкыннары сүнгән чарасыз...

Тик кызганыч, бик еш шулай була,
Яратканнар берчак аерыла.
Аерыла да, ерак йолдыз булып,
Бер-берсеннән читкә каерыла.

...Ачам хатны. Сорау билгеләре
Төшерелгән конверт читенә.
Әче күз яшьләре булып тамган
Тугыз җөмлә дәфтәр битенә.

**13**

«Бер сәбәпсез дөньям җимерелде,
Ялгыз калдым шыксыз яланда.
Бәллүр бәхет челпәрәмә килде,
Кояш сүнде безнең аланда.

Зур галәмдә мин берүзем калдым,
Йөрәк тибә сыкрап һаман да,
Йөрәк сорый сыкрап һаман да:
Нәр-сә бул-ды? Нәр-сә бул-ды соң?
Нәр-сә бул-ды? Нәр-сә бул-ды соң?»

**14**

Сизелмичә күпме вакыт үтте,
Көн дә инде кичкә авышты,
Ишетелде шунда өй эченнән
Әнкәемнең җылы тавышы:

«Тагын шунда менеп, китап укый!»–
Малай итеп мине битәрли, –
«Караңгыда укыма син, балам,
Шушы яшьтән күзең бетәр», ди...

Бу хатларны ташлап китә алмый
Мин утырам түбә астында.
Чорма серен ачып бетермәде,
Сөйләмәде миңа барсын да.

Хәер, саклый микән сер йомгагын,
Караңгыда чорма-чоланнар?
Хат язганнар үзләре дә күптән
Әби белән бабай булганнар.

Тик мин исәр, – исем китеп менә
Шул тарихны кабат актарам.
Ерак тарих йөрәк аша үтә,
Җанга күчә сары хатлардан.

Һәркем өчен сөю тик үзенчә
Чәчкә ата, җырлый, яндыра,
Яхшылыкка өнди кешеләрне,
Җыр җырлата, шигырь яздыра.
Ә кайчакта учагыннан бары
Истәлеккә көлләр калдыра...

**15**

Шушы тарих белән таныштырып,
Мин үтәдем куйган бурычым.
...Әгәр син дә уйга калган булсаң,
Мин бик шатмын шуңа, укучым!..

Фирдүс
Гыймалтдинов

# УРДА ХАНЫ ҮЗБӘК*

РОМАН

### ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

#### 1

Туктай ханның көймәләргә төялеп, Идел буйлап өскә, башта Болгар, аннан рус кенәзлекләре тарафына юл алырга җыену хәбәрен Баялун хатын беренчеләрдән булып ишетте. Хан тирмәсендәге шымчысын мулдан бүләкләп, ул шунда ук берьюлы берничә кыйтгага чапкыннар җибәрде. Еллар буе Баялун хатын Туктайдан котылу чарасын эзләде. Үз тирәсенә иң ышанычлы кешеләрне туплады. Алар белән аерым-аерым яшерен очрашулар, сөйләшүләр үткәрде. Нәтиҗәдә, Урданың төрле олысларында күпсанлы тарафдарлары барлыкка килде.

Туктайга каршы эшчәнлек башында Баялун хатын, Хәрәзем бәге Котлы Тимер, Исабәк һәм тагын берничә дәрәҗәле аксөяк тора иде. Үзбәк ханзадәне читтәрәк тоттылар, юкса кызу канлы егет, берәр ялгышлык җибәреп, бөтен эшне бозып ташлый ала. Кадакның игътибарын да артык җәлеп итәргә ярамый, мөддәбирнең үз шымчылары да җитәрлек.

Бөтен нечкәлекләрне бер генә кеше – Баялун хатын гына белә. Ул идарәне тулысы белән үз кулына алды. Урда ханы тәхетенә илтә торган яшерен җепләр бары тик аңарга гына тоташа. Беркемгә дә тулысынча ышанмый, беркайчан да башындагы фикерләрне әйтеп бетермәде. Ләкин Туктайдан котылу нияте инде барлык нечкәлекләренә кадәр уйланылган иде. Җай чыгуын гына көттеләр.

Баялун хатынның ышанычлы кешеләре ашыга-ашыга, Урданың төрле олысларына юл алды. Котлы Тимер, Үзбәк, Исабәк, чапкыннан хәбәр килүгә, кораллы кешеләрен ияртеп, Сарайга китте. Каладан ерак түгел, яшеренеп, Баялуннан чакыру көтәсе иде. Сарайга алардан башка да шактый нүкәрләр юнәлде.

Баялун хатынның бер чапкыны исә Яңа Шәһәргә килеп, Кара колагына гына атап әйтеләсе сүзләрне җиткерде. Аны тыңлагач та, Кара, утыз нүкәре озатуында ком чүленә китеп югалды.

Кадак мөддәбир Туктайны Идел буйлап юлга чыгу уеннан кайтарырга

---

*Дәвамы. Башы 1 нче санда.*

маташып караса да, тегесе тыңламады. Су кәрваны егермеләп корабтан тора. Беренчесе – иң матуры, иң зурысы, иң купшы итеп бизәлгәне – ханныкы. Аны су агымына каршы алып барыр өчен генә дә берьюлы илле ишкәкче кирәк. Кадак төп корабка утырган һәркемне җентекләп тикшерергә кушты. Ишкәкчеләргә әллә ни игътибар бирелмәде – алары коллар исәбеннән, кораллары юк, көймәнең аскы өлешеннән барыбер чыга алмаячаклар. Ашык-пошык әзерләнгәнгә, коллар да уяулыгын югалтты – үзләре янына моңарчы күрмәгән-белмәгән бәндә эләгүен беркем дә сизмәде. Йөзен һәрвакыт кара чүпрәк белән каплап йөрүе сәеррәк иде, әлбәттә...

Юлга кузгалганның беренче төнендә Туктай хан үз көймәсендә мәҗлес оештырды, һәммә кеше исерешеп бетте. Хан үзе дә шактый гына кәефле иде. Хәмер эчүдән тәмам хәле тайган хаким көймәдәге аерым зур бүлмәсенә йокларга китәргә җыенгач, Кадак аны озата чыкты.

– Кер әле, Кадак, сөйләшеп алыйк, – диде кинәт моңсуланып калган Туктай хан.

Кадак бусагадан атлап керде. Хан табынга утырырга ымлады, янә хәмер салды. Сүзсез генә эчеп куйдылар.

– Гомер уза, – дип көрсенде Туктай хан, кечкенә тәрәзә аша елга өстенә сузылган ай юлына карап. – Минем туганнарым, балаларым – барысы да мәрхүм. Күбесен үзем Мәңге Күк Тәңре янына озаттым.

– Алар моңа үзләре гаепле, бөек ханым...

– Кем гаепле, кем гаепсез икәнлеген хәзер дәҗҗал гына беләдер. Мин дә алар янына киткәч, Урданы кем кулына калдырырмын? Менә шушы сорау тынычлык бирми интектерә. – Хан янә чәркәләрне тутырды, янә күтәреп куйдылар. – Илбасмышны да саклап кала алмадың. Кара төндә тирмәсенә кереп суеп чыктылар үзен. Ник үтерүче аның сыңар күзен каезлап алган икән, ул хакта уйланганың юкмы?

– Ни дип әйтергә дә белмим, бөек ханым...

– Ә мин беләм. Ногай теге дөньядан да миңа сәламен җибәрде. Аның янәшәсендә бер бәндә бар иде, хәтерлисеңме? Һаман битен каплап йөрүче кеше, бик яманга охшаттым мин аны. Син аның кая олакканын ачыкламадыңмы?

– Аның исеме – Кара. Ул Ногайның тәнсакчысы иде, рус дружиначылары, куып тоткач та, бәкләр-бәген яклаучы төркемне тураклап бетергәннәр. Шигем юк – Кара да шунда үлгәндер.

– Аның каравы минем шигем бар. Исән калгандыр ул Кара. Бик хәтәр кеше икәнлеге әллә каян сизелә иде. Ногай өчен шулай үч алгандыр... – Туктай усал күзләрен Кадакка төбәде. – Әгәр иртәгә минем җанымны алырга килсә, нишлисең?! Кемне тәхеткә утыртырсың?! Җавабың янә юкмы?... Оныгым бар, тик ул әлегә сабый гына. Түкәл-Буганың да башына җиттегез, акылы юк иде аның, әмма Урдага тугры мәхлук иде, мәрхүм...

– Үлем турында артык иртә сөйләшәсең, бөек ханым. Син үзең дә егетләр төсле, тагын балаларың булыр, алдан борчылып куйма.

– Борчылма, имеш... Борчылырга туры килә шул. Борын төбеңдә улыңны суеп, сыңар күзен чукып китсеннәр әле. Илбасмыш миннән соң дәүләт белән идарә итәрлек кеше иде, харап булды... Йә, ярый, бүгенгә тәмам.

– Әгәр син куркасың икән...

– Мин бернидән дә курыкмыйм, Кадак. Хәтта үлемнән дә. Чөнки үзем күпме кешегә үлем китергән бәндә. Сакчыларың ишек төбендә уяу торсыннар, калганы кирәкми. Иртәгә иртән күрешербез.

Туктай хан, мөддәбиренең чыгып китүен дә көтеп тормый, өсте-башын салмый, ятагына менеп ятты. Кадак зур саклык белән ишекне япканда, ул инде гырылдап йоклый иде.

Төнлә ятак янына кара шәүлә килеп басканын Урда хакиме сизмәде. Шәүлә, ханга якынрак иелеп, каршындагы исерекнең чыннан да Туктай хан икәнлегенә инанды. Аннан соң кесәсеннән кечкенә генә капчык чыгарып, аның эчендәге ап-ак он сыман нәрсәне ханның иреннәренә тидерде. Авызы кипкән Туктай йокы аралаш иреннәрен теле белән ялап куйды. Шәүлә теге онны янә өстәде.

Йоклап яткан ханның тыны кысыла башлады. Ул уянып китте, күзләрен акайтып ачты. Сулыш үтмәгән бугазына ике куллап ябышты, ләкин берни эшләтә алмады. Күзләре шартлар дәрәҗәгә җитте. Бөтен тәне калтыранырга кереште. Коты чыккан карашы аның өстенә иелгән үлем илчесенә текәлгән иде. Туктайның оят җире юешләнде, бүлмәгә нәҗес исе таралды, аяклары тарткалашырга тотынды. Ул кычкыра да алмый, бары тамак белән гырылдый гына. Ниһаять, авызы читеннән күбек катыш кан агып чыкты. Аяклары янә тарткалашып алды да күзләрен акайткан Туктай тын калды.

Шәүлә Туктайның кулларын муеныннан аерып, күкрәге буйлап сузды, аякларын тигезләде.

– Урының җәннәттә булсын, хакимем Ногай, – дип пышылдады шәүлә. – Мин синең өчен үч алдым, тыныч йокла!

Шәүлә ханның күзләрен йомдырды, авызы читендәге күбек катыш канны сөртеп алды. Туктай нәкъ тере төсле, йоклап кына киткән кебек иде.

Корабның хан өчен дип махсус эшләнгән бүлмәсендә кечкенә генә тәрәзә бар иде. Шәүлә шунда юнәлде һәм, елан шикелле тышка шуышып чыгып, суга сикерде. Аның ашыкмый гына ярга таба йөзеп китүен беркем дә күрмәде...

Ханның үле гәүдәсен Кадак табып алды. Ул шунда ук кораблар кәрванын туктатырга боерды. Хан бүлмәсенә беркемне дә кертмәскә кушты. Кәрваннан өч кенә кораб калдырылды, алардагы нүкәрләрне күчереп утырттылар. Кадак көймәләрнең төп төркеменә кире Сарайга таба борылырга әмер бирде.

– Елга буенча унлап чакрым төшегез дә, безне көтегез, – диде ул Лачын бәккә. – Беркемне дә ярга чыгарма, тик кенә утырсыннар.

– Баш өсте, бөек мөддәбир, – диде Лачын бәк, мондый әмерне ишетүенә гаҗәпләнеп. – Сөекле ханым исән-саудыр бит?

– Мин хан сүзләрен җиткердем, димәк, ханыбыз сау-сәламәт. Бар, тизрәк бул, кузгалыгыз, ханның күзеннән югалыгыз! – дип җикеренде түземлеге бетә башлаган Кадак.

Төп төркем күздән югалгач, Кадак хан корабына иң якын кешеләрне җыеп, Туктай хакимнең мәрхүм икәнлеген хәбәр итте. Халык башта шым булды, аннан төрле яктан сораулар ява башлады:

– Үз үлеме белән киткәнме?!

– Кичә генә кәефе әйбәт иде ләбаса, бернидән дә зарланмады!

– Кемнең кулы тигән безнең ханыбызга?!

Кадак бәкләрне тынычланырга өндәде.

– Ханның хәл-әхвәлләре турында мин барыгыздан да күбрәк беләм. – Ул каршындагы аксөякләрне күздән кичерде, аңа каршы әйтүче табылмады. – Соңгы вакытта Туктай ханыбыз тыны кысылуга зарлана иде. Төнлә сулыш алырга авыр дип сөйләде. Хәтта багучылар чакыртып, берничә мәртәбә өшкертергә дә туры килде. Әлбәттә, без моны сер итеп сакладык, чөнки ханның авыру хәбәре таралса, өннәрендә качып яткан дошманнар юха елан төсле шунда ук борыннарын төртәчәк. Кичә йокларга ятканда да, сәламәтлегеннән зарланып алды. Мин Туктай ханны үзем табып алдым. Ул йоклаган төштән үлеп киткән. Әйдәгез, бергә кереп карыйбыз – кан да, муенына уелган бау эзләре дә юк.

Бәкләр бер-берсенә карашып алды да, Кадакка иярделәр. Мөддәбир әмере буенча ханның нәҗескә буялган киемнәрен алмаштырганнар, ул, чыннан да, нәкъ йокыга киткән төсле ята. Берәм-берәм килеп, йөзенә текәлеп карадылар – яра-фәлән бөтенләй юк. Ханның үлеме табигый икәнлегенә инангач, янә тышка чыктылар.

– Ханның гомере елгада өзелде, аның шул елга куенында сыену урыны табуы дөрес булыр кебек, – диде Кадак. Җәмәгать аның белән килеште.

Туктай яткан бүлмәгә аның кораллары, берничә сандык белән алтын-көмеш, бизәнү әйберләре куелды. Шунда ук аның яраткан атын да кертеп бәйләделәр. Тегесе башта караңгы бүлмәгә керүгә нык карышты, эчкә узгач та, куркынып, бер күзе белән түшәктә җансыз яткан хуҗасына карап алды.

Корабның түбән өлешендәге колларның ишкәкләргә тотынган килеш, кул-аякларын бәйләп калдырдылар. Башта берни аңламаган бәндәләр хәлләрнең хәерлегә бармаганлыгын аңлап чәбәләнергә маташты. Әмма нүкәрләр колларга караганда көчлерәк иде.

Кадак мөддәбир белән бәкләр ярга чыкты. Махсус калдырылган нүкәр корабның төбен берничә урыннан балта белән чукып тиште. Бәйләнгән коллар бу тамашаны сүзсез генә күзәттеләр. Корабка су тула башлады.

Туктай озак батты. Бәкләр ашыкмый гына әле бер, әле икенче якка авышып, акрынлап төпкә киткән көймәгә карап тора бирде. Менә колларның ялварып елаган тавышлары да тынды. Тагын күпмедер вакыттан соң ханы янәшәсенә бәйләп калдырылган ат яман кешнәп җибәрде. Җанны алырдай кешнәү иде бу, хәтта колларның үлем алдыннан зар елавыннан да куркынычрак булып чыкты. Ниһаять, су корабны тәмам йотты.

– Ханның соңгы җәйләү урынын күрсәткән кешеләргә үлем икәнлеген онытмагансыздыр дип өметләнәм. – Кадак мөддәбир янындагыларга усал караш ташлады. Аның башында инде Туктай кайгысы юк иде. Вакытны бушка уздырмый, Илбасмышның бишектәге улын тәхеткә утыртып калдырырга кирәк. Бала үсеп җиткәнче, дәүләт идарәсе Кадак кулында булыр. – Сез хәзер корабларга төялеп, Идел буенча түбән төшеп, Сарайга кайтасыз. Мин ат белән кайтам. Ханыбызның туганнарына кайгылы хәбәрне җиткерергә тиешмен.

Яр буендагы корабларның берсеннән атлар чыгарылды, Кадак егермеләп нүкәре озатуында далага китеп югалды...

...Үзенә таба җилдерүче атлы җайдаклар төркемен ул караңгы төшкәндә

шәйләде. Ерактан ук аңларга мөмкин иде – аларга якынлашучы төркем шактый ишле, утызлап кешедән тора. Төркем нәкъ Кадакка таба юнәлә, күрәсең, бередән үтәсен белгәннәр, сагалап торганнар.

– Укларны әзерләгез, кылычларыгызны барлагыз, – дип әмер бирде мөддәбир, тирләп чыккан учы белән үз коралын кысып тотып.

Беренче уклар һаваны ярып сызгырып үтте, ләкин төркем тирә-якка таралышты, берсенә дә зыян килмәде. Атлыларның максаты үзләрен камап алу икәнлеген соң аңлады Кадак. Яшен тизлегедәй хәрәкәт иткән җайдаклар, аны-моны аңышырга ирек бирми, кылыч белән генә сугышырлык арада иде. Караңгы далада бәрелеш башланды. Кылычларның бер-берсенә сугылуыннан чыккан очкыннар яугирләрнең йөзләрен яктыртып ала иде.

Көчләр тигезсез булып чыкты. Кадакның сугышчылары да азрак, төне буе хәмерле мәҗлес тә үзен нык сиздерде. Хан мөддәбире аркадашларының берәм-берәм ыңгырашып, атларыннан мәтәлеп төшүен җан ачысы белән күзәтте. Ахыр чиктә, ул ялгызы калды.

Төнге юлбасарлар аны әйләндереп алды. Алар арасыннан, күрәсең, башлыклары чыкты. Аны күргәч тә, Кадакның башы әйләнеп китте, авызы кипте. Ул аны явыз ут ялкыны уйнаклаган күзләреннән таныды. Бу – заманында Ногайның уң кулы булган Кара иде.

– Исәнмени син, Кара? – Язмышының хәл ителүен аңлаган Кадак кылычын төшерде.

– Исән, Кадак. Синең белән араны өзми үлеп булмады.

– Аңлашыла... Туктай ханга да Ногай әҗәтен кайтаргансың алайса.

– Кылычыңны күтәр, Кадак. Гадел орышта көч сынашыйк. Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы кем ягында икәнлеген шунда күрербез.

Кадак көрсенү катыш елмаеп куйды, айның саран яктылыгында җирдә аунап яткан нөкәрләренә күз ташлады.

– Шаярта беләсең дип башыма да китермәгән идем, Кара...

Кадак вәзир, кисәк кенә кылычын күтәреп, үз кулы белән бугазын ертып җибәрде. Шаулап кан агып чыкты, иярдә берара чайкалып торган Кадак бер якка авып төшеп, аягы белән тезгенгә эләгеп калды. Моны көтмәгән аты, куркуыннан кешнәп, каршындагы җайдакларга таба ташланды, тегеләре чак кына юл бирергә өлгерделәр. Бер аягы белән тезгенгә ябышкан хуҗасы мәетен өстерәп, Кадакның аты караңгы далага кереп югалды...

**2**

Ханның үле хәбәре килеп җиткәч, аның тирмәсе янына елаучылар җыелды, Сарай аларның туктаусыз зарына күмелде. Тирмәнең үзендә мәҗлес корып җибәрделәр. Аның түренә кайгылы халәткә чумган Баялун хатын утырды. Ул, кайгы уртаклашырга килгән нойоннарга күтәрелеп карамый гына Туктайга атап әйтелгән җылы сүзләрен, озын нотыкларын сабыр гына тыңлады, тәмам булгач, рәхмәт сүзләрен пышылдап саубуллашты. Өч көн, өч төн дәвамында Баялун төп тирмәдән чыкмады. Күңеле тыныч иде – Кара исән-имин килеш әйләнеп кайтып, Туктайны ничек үтергәнлеген барлык нечкәлекләренә кадәр сөйләп бирде. «Хәзер тиз генә Илбасмышның хатынын һәм кечкенә улын Чагатай олысына әтисе янына озат, – дип әмер бирергә ашыкты Баялун. – Әтисе күптән Мәңге Күк

Тәңре хозурында, анда аларга да яхшырак булыр...» Карага ике мәртәбә кабатлыйсы юк, ул шунда ук кушканны эшләргә ашыкты.

Әзерлек эшләре кызганнан-кызды. Котлы Тимер белән Исабәк, Үзбәкнең якын туганнары, яшь ханзадәне Урда хакимлегендә күрергә теләгән башка аксөякләр үзара сөйләшүләр, килешүләр алып барды. Хансыз һәм мөддәбирсез калган дәүләттә бәкләр һәм әмирләрнең ике төркеме оешты. Беренчесенә Үзбәкне яклаучылар тупланса, икенчесенә аңа катгый рәвештә каршы төшүчеләр керде. Яшь ханзадәне якламаганнар, башлыча, Чыңгыз нәселенә кагылышлы нойоннар иде. Үзбәк тирәсенә исә беренче чиратта диннәре ислам булган аксөякләр тупланды.

Нинди генә бәхәсләр тумасын, аны хәл итүнең Урдада бер генә чарасы бар. Ул да булса – корылтай. Туктай хан матәме тәмамланып, озак та үтми, олы дәүләтнең төрле почмакларына чапкыннар җибәрделәр. Сарайда олы киңәшмә узарга тиеш, анда барча олысларның вәкилләре, тавыш бирергә хакы булган бәкләр һәм әмирләр, нойоннар һәм сәргаскәрләр җыела башлады.

Сарайдан бер читтә, далада олы хан тирмәсе корылды. Аның янәшәсенә кечерәкләре тупланды. Корылтайга килгән нойоннар, үз чатырларын урнаштырып, даланы зур бер шәһәргә әйләндерделәр. Корылтай көне килеп җиткәч, барысы да төп тирмәгә ашыкты.

Киңәшмәгә юл алучылар арасында Үзбәк хан да бар иде. Аны Исабәк белән Караның нүкәрләре озата килде. Башка бәкләр дә корылтай станы буйлап ышанычлы сак белән генә йөри – тәхетнең язмышы әлегәчә хәл ителмәгән, ул-бу килеп чыгуы бар.

Үзбәк, тирмәгә кергәч тә, бер читтәрәк урын алды. Баялун хатын белән Котлы Тимер аңа тиешле күрсәтмәләр биреп куйган иде инде – вакытыннан алда кеше-кара күзенә күренмәскә, шыпырт кына утырырга. Шуңа да ул тирмәнең ышыграк урынын сайлады һәм, берәм-берәм кереп, эскәмияләргә утырышучы аксөякләрне күзләргә кереште.

Алар төрле-төрле кешеләр иде. Араларында яшьләр дә, картлар да бар. Куркынып, як-ягына каранганнары да, хан тирмәсендә үз йортындагы төсле йөрүчеләре дә. Кемнәрдер, чит-ятлардан тартынмый, таныш-белешен күрү белән аны кычкырып сәламли, шунда ук кочаклаша. Кайберләре үзара чышын-пышын сөйләшә, карашларының усал һәм астыртын икәнлеге сизелеп тора. Таныш йөзләр биредә бик аз иде. Моның сәбәбен Үзбәк яхшы белә – башта Ногай котыртуы, аннан соң үзенең куркаклыгы белән Туктай хан күп кенә тарафдарының җанын кыйды. Бигрәк тә Чыңгызлар нәселен шактый тунады. Бертуганнарын да кызганмады. Ләкин алмашка килгәннәре дә әллә ни ышанычлы күренми, алыш-бирешнең нәтиҗәсе аксөякләренең сафын бер дә яхшы якка үзгәртмәгән...

Бер мәлне тирмә эчендәге шау-шу, сөйләшкән тавышлар тынып калды һәм бөтенләй сүрелде. Бусагадан башта коралллы нүкәрләр, алар артыннан Баялун хатын белән Котлы Тимер керделәр. Баялун хатын кап-кара ефәк киемнәрдән, башын горур югары күтәргән, беркемгә дә карамый, туры тәхеткә атлады.

Ул тәхеткә менеп утыргач та, аның уң кул ягында Котлы Тимер аягүрә баскан килеш калды. Җәмәгатьне тынычлыкка чакырып, ул уң кулын күтәрде.

– Мөхтәрәм корылтай! Урда дәүләте олы югалту кичерде. Без берьюлы ханыбызны да, аның янәшәсендәге бөек мөддәбиребезне дә мәңгелеккә озаттык. Бу – көтелмәгән, авыр сынау булып чыкты. Хөр мәмләкәтебез хәзерге вакытта башсыз, күзсез. Бер генә дәүләт тә идарәсез яши алмый. Урдага, аның бөеклеген, көчен саклап калу өчен үзенә тиң хаким кирәк. Бүген без бирегә сезне нәкъ менә шул максаттан җыйдык. – Беразга гына тын алып, бәкләр-бәге Баялун хатынга борылды. – Безнең янәбызда бу тәхетнең бердәнбер кануни хуҗасы – мөхтәрәм Баялун хатын, сөекле ханыбыз Туктай аны соңгы сулышына кадәр өзелеп яратты һәм хөрмәт итте. Аның сүзе – хан нәселенең фикере. Чөнки ул Туктай хан ыруыннан иң өлкән кеше. Хатыннарның асылы, зирәкләрнең зирәге, бетмәс-төкәнмәс гыйлем иясе Баялун! Бүген без сиңа киңәш сорарга килдек. Оланнарыңа юл күрсәт! Туктай ыруы бүгенге катлаулы халәттә тәхеттә кемне күрергә теләр иде?

Баялун хатын торып басты. Башын югары тоткан килеш, корылтайга җыелган аксөякләрне карашы белән ашыкмый гына барлап чыкты. Берара Үзбәккә дә текәлеп торды – күзләрендә җылылыкмы, нәфрәтме икәнлеген һич аңлый алмады.

– Безнең йортыбызга олы хәсрәт инде. – Баялун хатынның тавышы нык һәм шул ук вакытта бик хафалы чыкты. – Беребез дә сөекле ханыбыз Туктай шулай вакытсыз безне ташлап китәр дип уйлап та карамаган идек. Ләкин бәла якында гына йөргән икән... Бирегә җыелган җәмәгать яхшы белә – кайгы шәүләсе нәселебезне әледән-әле сынап тора. Моңа кадәр залим кулыннан яраткан улыбыз, сәргаскәребез, Туктай ханнан соң тәхеткә утырырга тиешле Илбасмыш ханзадә мәрхүм булды. – Баялун хатын яулык чите белән күзендәге яшен сөртеп куйды. – Сер түгел, соңгы көннәрдә миңа тәхеткә варислык мәсьәләсе белән киңәш-табыш итәргә шактый кеше килде. Кайберәүләр Илбасмышның улын искә төшерделәр. Әмма бишектәге баланы ханлыкка күтәрү бөтен дөнья каршында көлке генә булыр иде. Илбасмыш баласының әнисе Әрдәнә хатын белән мин үзем күрешеп сөйләштем – ул сабые Икъсарны тәхеткә утыртуга каршы. Алай гына да түгел, бу хакта сүз чыккач, ул ашыгыч рәвештә кирәк-яракларын җыеп, баласын алып, туган ягы Чагатай олысына кайтып китте.

Бу сүзләрне ишеткәч, Чыңгыз нәселенә караган нойоннар утырган якта шау-шу, гауга купты. Әрдәнә хатынның баласы белән бергә сәер рәвештә Сарайдан юкка чыгуы турында моңарчы имеш-мимешләр таралган иде инде. Хәзер ишетелгән хәбәр тын гына торган сазлыкны янә кузгатып җибәрде. Ләкин Баялун хатын үзе әйткәнгә шик белдергәннәрне кырыс итеп туктатты:

– Әгәр кем дә кем ышанмый икән, хәзер үк корылтайдан чыгып китсен һәм, атына атланып, Чагатай олысына чаптырсын. Бәлки, арба эзе буйлап, Әрдәнә хатынны эзләп тә таба алыр. – Корылтайда янә бераз тынычлык урнашкач, Баялун хатын төп сүзенә кереште. – Туктай хан үзеннән соң нәселе дәвамчысы калмавына нык борчылды, без бу хакта шактый сөйләштек. Үлеменең шулай кинәт киләчәген ул, әлбәттә, белмәде. Исән чагында үзенең васыятен миңа һәм мөддәбире Кадакка гына җиткереп кала алды. Сезгә барыгызга да мәгълүм – безнең арада Чыңгыз нәселе вәкиле,

Туктайның якын туганы, Тогърулҗа угълы Үзбәк ханзадә бар. Туктай үз үлеменнән соң нәкъ менә аны хан итеп күрергә теләде.

Тирмә эче кабаттан шау-шуга чумды. Баялун хатын бу юлы нойоннарның тынычлануын сабырлык белән көтеп торды, аннан соң уң кулын күтәрде.

– Мәңге Күк Тәңре каршында ант эчәм – сөекле ханыбыз Туктай үзеннән соң тәхеткә туганы Үзбәк ханны утыртырга васыять итте. Ни кызганыч, бүген янибызда Кадак мөддәбир юк, ул минем әйткәнне һичшиксез раслар иде. Мин корылтайны мәрхүм ханыбызның соңгы теләген үтәп, Үзбәк ханзадә өчен тавыш бирергә чакырам. Ханзадә, яныма кил! – дип мөрәҗәгать итте ул читтә утырган егеткә.

Үзбәк баштарак әлеге сүзләрнең үзенә атап әйтелгәненә ышанмады, аннан соң, аңышып, аякка басты. Буыннарының кинәт хәле киткәнлеген тойды, ул гүя нindидер төш күрә. Берничә йөз пар күз үзенә текәлгән. Ничәмә еллар буе уйлап йөргән хыялы менә шушылай тормышка ашар микәнни? Ул кинәт үз өстенә нинди зур авырлык ишелеп төшүен тойды. Чиксез далалар, киң елгалар, диңгез-таулар, андагы исәпсез маллар, төрле-төрле халыклар, шәһәрләр – хәзер барысы да аныкы булачак. Аларның бүгенгесе һәм киләчәге өчен җаваплылык тулысы белән Үзбәккә йөкләнәчәк.

Баялун хатын каршына килгәч тә, ул тез чүгеп, аны сәламләде. Аннан соң янәшәсендә тураеп басты, тирмәне күздән кичерде. Юк, беркемнең дә йөзендә шатлык күрмәде ул. Берсе дә, ханзадәнең тәхеткә утыруын ялварып, җиргә егылмады. Киресенчә, һәрбер пар күздә нәфрәт, көнләшү, ким дигәндә сынау чагылды. Үзбәк киң итеп сулыш алды, башы әйләнеп китте.

– Үзбәк ханзадә һәрвакыт сөекле ханыбыз Туктайның ышанычлы кешесе булды, – дип дәвам итте Баялун хатын, егетнең кулын кысып тотып. – Сез аның хәрби яулардагы уңышларын да беләсез, Хәрәземгә җибәрелгәч тә, ул һәр гамәле, һәр адымы белән ханыбызның ышанычын тулысынча аклады. Туктай Үзбәк ханзадәнең мәмләкәтебез өчен файдалы хаким буласына гомере буе ышанып яшәде.

– Рәхмәт сиңа, Баялун хатын, – диде Котлы Тимер, корылтайның икенче, иң мөһим өлешенә күчүгә ишарәләп. – Мөхтәрәм җәмәгать, безгә үз сүзебезне әйтергә вакыт җитте. Кем дә кем Үзбәк ханзадәнең Урда ханы булуын хуплый – уң кулыгызны күтәреп, хисапчылар санаганчы төшермәвегезне үтенәм.

Тавыш бирү башланды. Хисапчылар, берәм-берәм як-якка таралышып, күтәрелгән кулларны санарга керештеләр. Баш хисапчы, эш тәмам булгач, сайлау нәтиҗәләрен Котлы Тимергә җиткерде. Колагына пышылдаган мәгълүматны бәкләр-бәге сүзсез генә тыңлап торды. Аннан соң Үзбәккә борылды. Ханзадә үтә дә тыныч, аягында нык басып тора, карашы каядыр еракка төбәлгән.

– Хөрмәтле корылтай әһелләре! Баш хисапчыбыз мәгълүматына караганда, бирегә җыелган вәкилләр арасыннан өч йөз сиксән тугыз кеше Үзбәк ханзадәнең Урда тәхетенә утыруын хуплап чыккан. Ләкин тагын йөз дә унбер әмирнең фикере исәпкә алынмады. Мин сезгә, дәшми калганнарга мөрәҗәгать итәм – арагызда корылтай карарына каршы кешеләр бармы?

Җәмәгать дәшмәде, барысы да үле тынлыкта башларын игән килеш басып тора бирделәр.

– Яхшы, – диде Котлы Тимер, аннан соң Үзбәк ханга борылды. – Чыңгызхан угълы Җүчи, Җүчи угълы Бату, Бату угълы Тотыкан, Тотыкан угълы Мәңге Тимер, Мәңге Тимер угълы Тогърулҗа, Тогърулҗа угълы Үзбәк ханзадә! Урда дәүләтенең тулы вәкаләтле корылтае карары белән син бүгеннән дәүләтебезнең бөек ханы дип игълан ителәсең! Бу мәртәбәле тәхеттә сиңа зирәклек, көч, сәламәтлек, аек акыл, исәпсез уңышлар насыйп булсын!

Үзбәк тез буыннары калтыраганын тойды. Аның хыялларында тәхеткә утыру башкачарак күзалланган иде. Барча кеше аны хупларга, ихлас елмаерга, чиксез шатланырга тиеш кебек тоелды. Тик чынында киресе күзәтелә. Бөтенесе дә тынган. Нидер көтәләр төсле. Аның менә-менә абынып егылуына өметләнәләр, диярсең. Чиксез далаларда җәйрәп яткан, бер ягы белән ком чүлләренә, икенчесе белән биек тауларга, өченчесе белән салкын карлы урманнарга терәлеп торган Урда дәүләте күз алдына килде. Хәзер бу мәмләкәт язмышы аның кулында. Тыштан дошман бәреп керсә дә, эчтән мәкер баш калкытса да, барлык авырлыкларны ханның үзенә генә хәл итәсе. Ә янәшәдәге аксөякләр, туган-тумача булуына да карамастан, аннан көнләшүче, ялгышларына шатланучы, мөмкинлек чыга калса, үзен буып ташларга әзер көндәшләр генә.

Котлы Тимер игълан иткән хан хакимлеге Үзбәккә шушы мизгелдә мәңгегә үзенә ияреп йөриячәк хисне – ялгызлык тойгысын алып килде. Соңгы сулышына кадәр ул аны озатып барды, төн йокысын, ризык тәмен, күңел тынычлыгын, мәхәббәт ләззәтен тартып алды. Дөньяның иң көчле хакимнәренең берсе ялгызлыктан беркайчан да арына алмады...

Буыннарына ныклык бирергә тырышып, бар булган көчен җыеп, Үзбәк хан тәхеткә менде, аннан соң тирмәдәгеләргә борылды.

– Ханның сүзе бар, барыгыз да игътибар белән тыңлагыз! – диде ул әллә кайдан кинәт килеп чыккан ышанычлы һәм көр тавыш белән. – Дәүләтебез Урда – безнең һәммәбезнең дә уртак йортыбыз. Биредә үзен мәмләкәткә файда китерерлек кешегә санаган һәркемгә урын бар. Бүген үзара низагларны читкә куеп, берләшергә, ачу-үпкәләрне онытырга кирәк. Урданы ныгытуга, аның җирләрен киңәйтүгә бар көчебезне юнәлтик. Мин үземә тугрылыкка ант эчкән кардәшләремә чиксез рәхмәтлемен. Сез – таянычым! Ләкин мине әлегә кабул итә алмаган бәкләргә дә бер дә рәнҗемим. Вакыт үтсен, уйланыгыз, бәлки, акрынлап, сез дә минем тарафдарга әйләнерсез. Үземнең гадел һәм булдыклы хаким икәнлегемне раслар өчен мин барысын да эшләрмен. Үтенеч-гозерләрегез, киңәш-тәкъдимнәрегез булса, аларны дикъкать белән тыңлармын. Минем тәхеткә утыруым Яса кануннарына нигезләнгән. Берәр кырын гамәл кылырга ниятләсәгез, шул хакта ныклап уйланыгыз, ялгыш адым ясый күрмәгез.

Үзбәк хан тәхетенә таба борылды.

– Тәхет бүгеннән минеке! – диде ул әллә үз-үзенә, әллә корылтай әһелләренә. – Мин үзем белән бергә янәшә утырырга Баялун хатынны чакырам.

Гадәттә, хисләрен күрсәтмәскә тырышкан Баялун кызарып чыкты, уңайсызланып калды, аннан соң саклык белән генә басып, тәхеткә юнәлде. Үзбәк хан аның янәшәсендә, нәкъ уртада урын алды.

– Ханның беренче әмерен тыңлагыз! – диде ул, үзендә әллә кайдан килгән илаһи көч һәм ышаныч тоеп. Бу хистән тәннәре чымырдап китте. Кичәге гади ханзадә-егеттән Урда ханына әверелү әнә шулай бөтен барлыгы дәрәҗәсендә дә сизеләдер, күрәсең. Әйтерсең, чиксез далалар һәм карурманнар, аңа кадәр хакимлек иткән ханнар рухлары күктән үзенә кодрәт иңдерде. – Урда ханлыгының мөддәбире итеп шушы мизгелдән бәкләр-бәге Котлы Тимер игълан ителә!

Котлы Тимер, бу хәбәрне ишетүгә, хан каршына тез чүкте, рәхмәт сүзләрен пышылдарга кереште.

– Котлы Тимер озак еллар дәвамында Урдага тугрылыклы булуын раслап килде. Аның хезмәтләре халкыбызның күз алдында. Илебез язмышына кагылышлы карарлар кабул иткәндә, мин һәрвакыт аның киңәшләренә таяначакмын. Моны һәммә әмир, нойон, сәргаскәр белеп торсын! Тор, бәкләр-бәге Котлы Тимер, минем уң ягымда урын ал!

Котлы Тимер ханның әмерен үтәргә ашыкты.

– Мин, туган җирләремнән чыгып китеп, ят тарафларда каңгыраеп йөргән чорда янәшәмдә таяныч булырлык кешем – Кыятлар нәселеннән Исабәк иде. Бүгеннән мин аны нәиб[1] дәрәҗәсенә күтәрәм! Ул да һәрбер киңәшмәдә минем янәшәмдә булачак!

Исабәк хан каршына тезләнде. Үзбәк аңа да үз янәшәсендә урын алырга боерды.

– Ә хәзер бавырчыларны, думбрачыларны, җарияләрне чакыртыгыз. Корылтай тәмам, хан мәҗлесен башларга әмер бирәм!

Әле генә тынып торган аксөякләр хәрәкәткә килде. Тирмә ишегеннән бавырчылар күренде, моңлы көйләр агылды. Корылтайда катнашучылар утырыштылар, тамаклары нык ачыгу да үзенекен итте. Майлы калҗа, ат картасы, таралып пешкән сарык ите белән бергә кымыз да елга булып ага башлады. Янына килеп, мактау сүзләрен җиткергән бәкләргә Үзбәк хан кымызны үз куллары белән салып бирде. Янәшәсендә генә бер мизгелдә дошманның башын чабып өзәргә әзер булган тәнсакчылары, шул исәптән җитез Кара торуын белсә дә, Үзбәк үз янына якынайган һәрбер аксөяк тарафыннан мәкер-золым көтә иде. Аның тәне куырылып килә, елмаюы бик зур авырлык белән тартылып кына чыга.

Ул – бәкләрне, бәкләр аны күзәтте. Тәхет өчен көрәшнең әле беренче генә өлеше тәмам. Моны Үзбәк хан бик яхшы белә. Тыныч тормышы нәрсәсе белән ошамады? Мәңгелек куркуда яшәргә мәҗбүр булырмы? Һәр кешедән һөҗүм көтеп калтыранып тору – аның гомерлек газабына әйләнерме? Тирә-юньдә шау-шулы мәҗлес гөрләгәндә, Үзбәкнең башында мең төрле уй әйләнде.

Үзбәк ханны уйларыннан уң кулында утырган Баялун хатын аерды:

– Карарларыңны артык тиз кабул итмисеңме, сөекле ханым? Исабәк Кыятны болай кисәк кенә югары урынга билгеләвең җәмәгатькә ошап бетмәскә мөмкин, – дип пышылдады ул.

Үзбәк Баялун хатынга борылды. Ханның күзләрен күргәч, хатын имәнеп китте. Алар, әйтерсең, җансыз таш кисәкләре, Баялунга булган элеккеге җылылыгы, ихласлыгы сүнгән төсле тоелды аңа.

[1] Нәиб – мөддәбирдән соң дәрәҗәсе буенча икенче урында торган дәүләт эшлеклесе, урынбасар.

– Хан үз сүзен әйтте, Баялун хатын, – диде ул коры гына һәм чираттагы кымыз касәсенә үрелде.

Мәҗлес шактый кәефләнгән иде, Үзбәк, кулы белән ымлап, Котлы Тимерне дәште.

– Тыңлыйм, бөек ханым, – диде тегесе, Үзбәк янына якынрак иелеп.

– Корылтайдагы йөз дә унбер нойон тавыш бирүдә катнашмады. Алар миңа каршы дигән сүзме бу?

– Каршы чыкмадылар, бөек ханым...

– Әмма хупламадылар да.

– Анысы хак. Баш хисапчым һәммәсен дә исемләп белә.

– Исабәк белән уйлашып бетерегез. Йөз дә унбер бәкнең безгә каршы булуын белә торып, дәүләт белән рәтләп идарә итү барып чыкмас. Безгә бу мәсьәләне хәл итү җаен карарга кирәк.

– Уйлашырбыз, бөек ханым.

– Уйлашканда, бер нәрсәне истә тотыгыз – Үзбәк ханны якламауның бәясе артык кыйммәткә төшәчәген бөтен дөнья белеп торсын. Хөкемең гадел, ләкин кырыс булырга тиеш.

– Баш өсте, – диде Котлы Тимер. Аның каршында хәзер бөтенләй үзгә Үзбәк утыра иде. Элеккеге эчкерсез, сабыр, нечкә күңелле егет түгел. Аның урынына чын Хан килде. Һәм ул беренче көннән үк кансызлык мәсьәләсендә үзенә кадәр булган башка хакимнәрдән бер дә кимен куймаячагын аңлатып бирде...

**3**

Сарайчык янәшәсендәге җәйләүдә үтәсе күтәрмә тантанасына озаклап һәм җентекләп әзерләнделәр. Үзбәк аны зур тантанага әверелдерү өчен барлык көчен куйды. Мәҗлескә болай да килергә тиешле олыс бәкләре, нойоннар, сәргаскәрләр, рус кенәзләреннән тыш, Мисыр, Кытай, Византия илчелекләренә чакырулар җибәрелде.

Билгеләнгән көнне олы тантана башланды. Күтәрмә үтәсе мәйдан уен кораллары моңына күмелде. Һаваны дер селкеткән дөңгер тавышлары астында хан нүкәрләре төз рәтләр белән таң калган халык каршыннан үтте. Төп тирмә янына затлы парчалар, келәмнәр төялгән дөяләр ашыкмый гына атлады. Һәр тарафта казаннар асылган, аларның буы һуштан яздырырлык. Үзбәк ханның тәхеткә утыру мәҗлесенә аксөякләр генә түгел, якын-тирә калаларда яшәүче гади халык та җыелды. Хан әмере белән һәммәсенә дә җитәрлек ризык, үзләре белән алып китәргә азык-төлек әзерләнгән иде.

Хан үзе тирмәсенә атына атланган килеш үтте. Аны йөзләп нүкәр саклый килә. Үзбәк, кечкенә бер шәһәрне хәтерләткән стан эченнән узганда, үзенә котлау сүзләре җиткерүче халыкка чак кына елмаеп, уң кулын күтәреп сәламләп үтте.

Аның артыннан, бизәкле арбага утырган көе, хатыны Нәзифә, улы Тимербәк, кызлары баралар. Тирмә каршына җиткәч тә, ияреннән төшеп, хан үзе гаиләсенә арбадан чыгарга ярдәм итте, тәхет тарафына узарга булышты. Озак күрешми торганнан сагынуларын яшермәгән балалары аңа елышса да, Нәзифә сер бирмәде, иренә, хәлләрең ничек дигән төсле, елмаю гына юллады.

Тәхеттә Үзбәк хан янәшәсендә, гаиләсеннән тыш, Баялун хатын да урын алды.

Бер-бер артлы олыс бәкләре, нойоннар, илчеләр, кенәзләр керә торды. Һәммәсе дә, яңа ханны олылап, үзләре белгәнчә котлау сүзләрен җиткерделәр, затлыдан-затлы бүләкләрен тапшырдылар. Үзбәк үзе баллы чыгышларны әллә ни исе китми тыңлады, тугрылыкка антларны да артык җитди кабул итмәде. Тирә-юньдә бәйрәм рухы хөкем сөрсә дә, аның күңелендә шик-шөбһәләр белән тулы зилзилә иде. Ул, әледән-әле якягына карана, тирмәнең төрле почмакларында урын алган тәнсакчыларын барлагач кына, күпмедер дәрәҗәдә тынычланып куя.

Яңа хан каршында тез чүгү тәмам булгач, мәҗлеснең табын өлешенә күчтеләр. Төп тирмәгә һәммәсе дә сыймады – аларга янәшәдә чатырлар корылган иде. Үзбәкнең тирмәсенә исә бары тик Урда аксөякләре генә чакырылды. Иң якын кешеләре, дәүләтнең терәге саналган нойоннар. Тик Үзбәк яхшы белә – аларның барысы да ышанычлы дип әйтерлек түгел. Шуңа да ул, чама белән генә ашап, аз-азлап кына кымыз эчеп, һәркайсының үз-үзен тотышын күзәтте. Корылтайда аны яклап тавыш бирмәгән йөз дә унбер аксөякнең исемнәре аңа инде мәгълүм иде. Һәммәсе дә Чыңгыз нәселе дәвамчылары булып чыкты – кан буенча Үзбәкнең туганнары...

Өч көннән соң күтәрмә мәҗлесенә чакырылган кунакларның күбесе кайсы кая таралышты. Бәйрәм булган урындагы тирмәләрне акрынлап җыештырырга керештеләр, олы казаннарны, арбаларга төяп, Сарайга кире озаттылар. Тик корылтай әһелләре өчен мәҗлес тәмамланмаган иде әле. Хан, аларга беркая да китмәскә әмер биреп, зур ауга чыгарга боерды.

Ау шактый уңышлы үтте. Түшкә-түшкә боланнар махсус корылган станга озатыла торды. Караңгы төшкәч, мәргәннәр үзләре дә шул якка таба кузгалырга җыендылар. Алар барысы да бер төшкәрәк тупланды. Хан рөхсәте белән Исабәк сүз алды.

– Хан оештырган ауда катнашучы мөхтәрәм бәкләр һәм әмирләр! Безнең хакимебез бүген сезнең өчен аерым табын әзерләде, ул муллыгы һәм сыйнигъмәтләре белән һәммәгезне дә таң калдырыр. Тик бу мәҗлескә бары тик корылтай әһелләре генә чакырулы. Үзегезне озата килгән яраннарыгызны без башка урында сыйларбыз. Кирәк-яракларыгызны гына алып, безнең арттан кузгалыгыз.

Җыелган халык өчен бу көтелмәгәнлек булып чыкты. Аудан соң беркайчан да аерым-аерым утыру гадәте юк иде, һәркем үз хезмәтчесе, тәнсакчысы белән йөрергә күнеккән. Кайберләренең күңеленә шик тә керде шикелле.

– Тәнсакчылары да безнең белән бармыймыни?

– Әллә синең тәнсакчың корылтай әгъзасымы, мөхтәрәм бәгем? – дип усал елмайды Исабәк. – Алай икән, урыннарыгызны алмашыгыз, аны корылтайга кертик, син аның җанын дошманнарыннан ышыклап йөрерсең.

Теге бәкнең каршы дәшмәвен күргәч, Исабәк янә аучылар төркеменә мөрәҗәгать итте:

– Үзбәк хан берегезне дә үз табынына барырга мәҗбүр итми. Хакимегез сый-нигъмәтләрен авыз итәсегез килми икән – ихтыярыгыз, хәзер үк чапаннарыгызны җыештырып кайтып ук китә аласыз!

Болай турыдан әйткәнгә беркем дә каршы кайтарып дәшмәде, чышын-пышын килеп, яраннарына, тәнсакчыларына күрсәтмәләр бирергә керештеләр.

Хезмәтчеләр төркеме бер, хан җитәкчелегендәге аксөякләр исә икенче тарафка кузгалды.

Дәрәҗәле мәргәннәргә табын кору өчен кара урман аланы сайланган иде. Тар гына сукмактан узып, нойоннар берәм-берәм шул аланга керә торды, каршыларына әллә кай җирдән хезмәтчеләр килеп чыгып, атларын алып китеп бардылар. Нойоннарның билләрендәге хәнҗәрләренә тимәделәр – монысы эчләренә курку кергән аксөякләрне күпмедер дәрәҗәдә тынычландырды.

Урман аланы берничә зур учак белән яктыртылган. Мәҗлес өчен өч ягы ачык олы чатыр корылган. Аның түрендә Үзбәк хан, каршысында исә кунаклары утырасы. Үзләре аулаган боланнарны да күрде мәргәннәр. Күптән килгән гадәт буенча, кемнең угына иң симезе, иң эресе эләккәнен билгеләделәр.

Тик Үзбәкнең генә боланнарда да, табында да гаме юк иде. Ул бер генә сүз дә дәшми, әйтерсең, нәрсәдер көтә кебек. Аның бу киеренкелеген сизгән бәкләр дә башта шактый тыныч утырды, гадәти шау-шу, күңел ачу сизелмәде. Әмма хәмер-кымыз күбрәк эчелгән саен кәефләре дә күтәрелә барды. Думбрачыларның дәртле көйләре дә моңа ярдәм итте, биергә чыккан җарияләр исә кайбер нойоннарның ашау кайгысын да оныттырды.

Тирә-як дөм караңгылыкка чумды, бары тик зур учакларда шартлап янган озын бүрәнәләрдәге ялкыннан гына кысан урман аланына бераз яктылык сирпелеп торды.

– Бөек ханым, вакыт җитте, – дип пышылдады Котлы Тимер, Үзбәкнең колагына иелә төшеп.

Хан билендәге кылычын капшады. Ышанычлы коралы урынында иде. Янә бер мәртәбә нойоннарны күздән кичерде. Араларында шактый исерешкәннәре дә бар, авызлары чалшайган, бит-куллары майга батып, пычранып беткән. Үзбәк, урыныннан ашыкмый гына торып, уң кулын өскә күтәрде. Думбрачылары, шунда ук уйнаудан туктап, чатырдан чыгып, юк булдылар, аларга җарияләр дә иярде. Кисәк кенә урнашкан тынлыкка аптырап, нойоннар хан тарафына борылды.

– Ханның әйтер сүзе бар! – диде Үзбәк. Тавышы бик усал һәм зәһәр булып чыкты, ул, аланны әйләндереп алган куе агачларга бәрелеп-сугылып, табынга кайтаваз рәвешендә ирешә. – Минем этием – Тогърулҗа ханзадәнең явыз кешеләр кулыннан һәлак булуы барыгызга да мәгълүм. Тәхет тирәсендәге вакыйгалар Урдада һәрвакыт канкоешка, туганның үз туганын үтерүенә бәйле. Мин моны зур ялгышлык, дәүләткә зыян сала торган гадәт дип саныйм. Һәм безгә моңа нокта куярга вакыт. Бары тик бердәм фикердә, бер уйда яшәгәндә генә, дәүләтебез чәчәк атар. Бүгенге мәҗлескә җыелган кешеләр арасында төрле карашлы нойоннар барлыгы миңа билгеле. Арагызда корылтайда мине яклап тавыш бирмәгәннәр дә шактый. Күтәрмә тантанасы бөтен дөньяның Үзбәк хан каршында баш июен күрсәтте. Моны күреп, сез дә шуңа күнгәнсез дип өметләнәм. Бу – корылтай түгел. Әмма сезнең барчагызның да минем яклы икәнлегегезне

белеп яшәү бик мөһим. Үзбәк хан тәхеткә лаеклы дип санаган бәкләр уң, шушы көнгә кадәр элеккеге фикерендә калганнар сул якка күчсеннәр.

Аптыраушта калган бәкләр бер-берләренә карашып алды, аннан соң, урыннарыннан зур авырлык белән торып, хан боерыгын үтәргә керештеләр.

Башлыча үзенә каршы чыккан бәкләрнең сул якта калуына Үзбәк хан эченнән генә куанды. Бер тапкыр кабул итмәгән бәндә беркайчан да якын булмас, иртәме-соңмы фетнә куптарыр. Черек агачны бер сугуда егып аудару хәерлерәк.

– Тәмаммы? – дип сорады Үзбәк хан. Җәмәгать дәшмәде.

Ул арада төрлесе төрле яктан бер төркем нүкәрләр йөгереп чыкты. Алар сул якта тупланган йөздән артык бәкне уратып алды.

– Хан әмер бирә. Кануни хакимгә каршы чыккан мөртәтләрнең башларын кисәргә!

Бәкләрнең кайберләре кылычларына ябышты, тик көчләр тигез түгел иде. Чатыр эче яман кычкырышка, бер-берсенә бәрелешкән кылычларның зеңгелдәвенә күмелде. Ханның уң кулында урын алган аксөякләр бу канкоешны курку катыш җирәнү белән күзәтеп тордылар. Мәетләрдән агып чыккан кан, күлгә җыелып, аларның аяк очларына таба агып китте. Соңгы бәкнең җаны чыккач, нүкәрләр, кылычларын сөртеп, кыныларга тыктылыр һәм, ничек кинәт килеп чыксалар, шулай җәһәт кенә юк булдылар.

Үзбәк алга атлады. Уң кулында үзенә төбәлгән куркулы күзләр, сулда – туракланган җәсәдләр. Ашыкмый гына атлап барган шәпкә ул читегенең каннан лычкылдавын тойды, ләкин юнәлешен үзгәртмәде. Урта бер җиргә җиткәч, хан туктады, кылычтан үткәрелгән адәм калдыкларын күзләде. Аннан соң үзенә акаеп карап торган бәкләргә борылды.

– Болар, – диде ул, бармагы белән артындагы мәетләргә төртеп күрсәтеп. – Болар – Урда дошманнары. Алар элек тә фетнә чыгару белән шөгыльләнделәр, киләчәктә дә мөртәтлектән ваз кичмәсләр иде. Без дәҗҗал әһелләрен тиешле җәзага тарттык. Үзегез дә белеп торыгыз, белмәгәннәргә дә җиткерегез. Үзенең ханы белән килешмәгән, аны якламаган, аның сүзен аяк астына салып таптаган һәрбер бәндәне менә шушындый язмыш көтә. Моны сезгә мин – Үзбәк хан әйтәмен, һәм соңгы сулышыма кадәр әлеге фикеремә тугры булып калачакмын. Ә хәзер... Хәзер кайтыгыз, мөхтәрәм бәкләр, бүген бик уңышлы ау үткәрдек...

Атына атланып, нүкәрләре озатуында урман аланыннан чыгып барганда, төн караңгылыгында ялгыз җайдак шәйләнде. Үзбәк хан, һәммәсенә дә туктарга боерып, уң кулын өскә күтәрде. Борчулы кыяфәтле Кара, ике яугире озатуында, алгарак чыкты. Күбекләнгән атта өсте-башы канга чумган егет абайланды. Ул, килә-килешкә иярennән сикереп төшеп, җиргә мәтәлде, хан каршында тез чүгеп тынып калды.

– Кем буласың син?! – диде авыр көннән алҗыган хан.

– Синең тугры яугирләреңнең берсе генә мин. Тәнсакчылары станында фетнә чыкты, бөек ханым.

– Шуннан?

– Фетнәчеләрне кылыч аша үткәрдек, сиңа шул хәбәрне алып килергә ашыктым, бөек ханым!

Үзбәк, ышанычлы тарафдарларының кайда да барлыгын белүенә шатланып куйды.

– Үзең сугыштыңмы соң, яугир?

– Минем киемнәрне чылаткан кан синең дошманнарыңныкы, бөек ханым!

Үзбәк атыннан сикереп төште, тезләнгән яугирне җирдән күтәрде. Тегесе чыннан да алҗыган, еш-еш сулый.

– Ни атлы буласың, егетем? – диде Үзбәк хан, үзе дә сизмәстән җылылык нотыклары кергән тавыш белән.

– Каугадый мин, бөек ханым.

– Каугадый... – Үзбәк хан артындагы Карага борылды. – Каугадыйны минем шәхси сак хезмәтенә кабул итегез. Мондый булдыклы нүкәрләр ханга киләчәктә дә кирәк булыр.

Кара, хакиме белән килешүен белдереп, уң кулын йөрәгенә куйган көе чак кына башын иде.

Үзбәк ул төнне беренче тапкыр төшендә атка атланып, кан яңгыры астында канлы диңгез буйлап юртканлыгын күрде. Куркыныч өрәкләр булып, каршысына озак вакыт су төбендә ятудан тәне бүртеп чыккан Туктай, бер күзе урынында бушлык ыржаеп торган Илбасмыш, киселгән башларын култык астында тотып торучы мәрхүм бәкләр чыга торды. Ничек кенә качып котылырга тырышмасын, атын күпме генә кумасын, өрәкләр янәшә, аның артыннан бер генә адымга да калышмый. Кан диңгезенең очы-кырые күренмәс төсле. Торган саен ул тирәнәя генә. Менә инде ул Үзбәкнең биленә кадәр күтәрелде. Аты чапмый, ә бәлки йөзә генә ала. Кинәт ат, аның белән бергә Үзбәк тә бата башладылар, авызы-борынына тула башлаган каннан ханның сулышы буылды. Ул, шабыр тиргә батып, үзенең Сарай каласындагы бүлмәсендә уянып китте...

«Кан диңгезе тирәнәйгәннән-тирәнәя, – дип уйланды Үзбәк, күзләрен түшәмгә төбәп. – Димәк, бу әле башы гына, минем кулымнан шактый кешенең гомере өзеләчәк. Нахак корбаннар түгелме алар? Дошманнарның җанын алу дөрес гамәлме?»

Шул ук көнне Үзбәк хан кичекмәстән Үргәнечтән Ногъманетдин Әл-Хәрәзми имамны чакыртып китертергә кушты. Төн йокысын качырган сорауларга бары тик ул гына җавап бирер төсле тоелды...

**4**

Хакимлеккә керешү җиңел эш булмады. Үзбәккә әле аннан, әле моннан аяк чалалар төсле тоелды. Шуңа да карамастан, үз тирәсенә ышанычлы бәкләр, әмирләр акрынлап туплана башлады, моңарчы яңа ханга шикләнеп караучылар да Үзбәкнең озакка килүенә инана иде кебек. Үзбәк хан исә баштанаяк эшкә чумды, иртәдән кичкә кадәр ул киңәшмәләр үткәрә, күпсанлы очрашулар уздыра. Хан сараенда хәмер белән берничә көн рәттән күңел ачу мәҗлесләре онытылды, ханның үз гаиләсе белән күрешергә дә вакыты юк иде. Тәмам алҗып, көчләре бетүен сизгән Үзбәк, озак вакытка сузылган аерылудан соң, үз тарафына төн кунарга хатыны Нәзифәне чакыртты.

Нәзифә, нигәдер, ханның йокы бүлмәсенә куркып, әйтерсең, беренче тапкыр килгәндәй керде. Күзләре Үзбәккә туры карамый, куллары кабалана.

Үзбәк Хәрәземнән чыгып киткәннән бирле болай икәүдән-икәү калганнары юк бит, әллә бер дә сагынмаган инде ирен?! Үзбәк моны Нәзифәнең тыйнаклыгына сылтады, хатыны каршысына килеп, аны кочып алды, иягеннән тотып, йөзен үзенә күтәрде, татлы иреннәрен үпте.

– Менә син дә ханбикә булдың, бәгърем Нәзифә, – диде ул, арыган булса да елмаерга көч табып. Нәзифә бик салкын тоелды. Киеренкелек тупланган төер шикелле. – Әллә син минем хан тәхетенә утыруыма шат түгелме?

Нәзифә мөлдерәмә күзләрен Үзбәккә төбәде.

– Шатлыгым борчуга күмелгән, сөекле ханым, – дип пышылдады ул һәм тыела алмый елап җибәрде.

– Нигә борчыласың, Нәзифәм? Сиңа беркем дә бармак белән дә тимәячәк. Моңа кадәр сезне җил-давыллардан ышыклый алдым, хәзер инде дошманнарым калмады диярлек.

– Тәхетең канга буялганга борчылам, Үзбәгем! Халык бик күп кеше кырылуы турында сөйли, синең кулың белән бер гаепсез кешеләр үтерелгән, диләр...

Үзбәк дерт итеп куйды, йөзе үзгәрде. Карусыз, йомшак Нәзифәсе аңа кинәт ят кеше төсле тоелды. Ул, хатынын кочагыннан аерып, ятагына барып утырды.

– Хакимлек җиңел генә бирелми, Нәзифә, – диде ул кинәт хәле киткән тавыш белән. – Гаепсезләр диюләре дә дөрес түгел, алар минем әтиемнең, әниемнең гомерләрен тартып алган бәдбәхетләр.

– Барысы да түгелдер бит... Балаларыбыз бар, бу әрвахларның каргышы аларга төшмәсме?

Үзбәк күзләре яшьләнүен тойды. Йөрәге кысылды. «Хакимлекнең бәясе – ялгызлык» – дигән уй кинәт күңелен өтеп алды.

– Күземнән югал, Нәзифә, – диде ул бик тыныч тавыш белән. – Минем синең белән сөйләшәсем килми...

Хатыны башын игән килеш ханның йокы бүлмәсеннән чыгып китте.

– Кайсыгыз бар анда?! – дип кычкырды Үзбәк.

Бүлмәгә Мостафа әвнух атылып керде.

– Баш өсте, ханым, мин биредә!

– Рус ягыннан җибәрелгән хәмер алып кер. Өч-дүрт яшь җарияне дә әзерлә. Тиз бул, бер аягың – монда, икенчесе – тегендә!

– Хәзер барысын да үтимен, – дип, хезмәтче абына-сөртенә йөгереп китте.

Ханның, ниһаять, тормыш мәшәкатьләреннән бераз арынып, күңел ачуы турындагы хәбәр Исабәкнең колагына беренчеләрдән булып ирешә. Үзбәкнең соңгы вакыттагы хәләте аны нык борчый иде. Көне-төне дәүләт турында уйлап кына тормыш барамыни?! Мәмләкәт дип, үзеңне бетерергә мөмкин. Икенче көнне, кыюлыгын җыеп, Исабәк ханга ауга чыгарга, аннан соң үзенең утарына мәҗлескә керергә тәкъдим ясады. Узган төннең хәмереннән айнырга өлгермәгән хан моңа шунда ук ризалашты. Бигрәк тә ауга чыгу фикере ошады. Атка атланып, даланы айкамаганга шактый вакыт узган.

Алар Сарай шәһәреннән шактый еракка киттеләр. Актүбә елгасы яры буйлап, байтак кына чаптыра торгач, каршыларында утар пәйдә булды.

– Исабәк, бу нинди урын? – дип сорады моңарчы бу якларны күрмәгән Үзбәк хан.

– Җүчинең углы Бәркә хан салып калдырган утар бу. Ул биредә шәһәр төзергә хыялланган, диләр, ләкин теләген тормышка ашыра алмый. Биредә халык аз яши, шәһәр булып үсеп чыга алмады.

Үзбәк ау кайгысын онытты, утар тирәлеген җентекләп өйрәнде. Бер ягы Актүбәнең биек ярына килеп төртелә. Су юлы буенча хәрәкәт итүче кәрваннарга да җайлы, саклану чарасы буларак та уңайлы. Башына килгән уйны әйләндергәләп, Үзбәк хан ауны дәвам иттерергә боерды.

Сунар уңышлы гына килеп чыкты. Алар көр боланнар көтүенә тап булдылар. Далада төн кунып, күңел ачканнан соң, икенче кичкә хан Исабәк озатуында дустының төп утарына кайтып төште.

Биредә хан килү хөрмәтенә мул табын әзерләнгән иде. Урда хакименең бары тик якын, күңеленә хуш кешеләре генә чакырулы. Котлы Тимер, Каугадый, Чолхан һәм тагын алты-җиде бәкне Үзбәк елмаеп сәламләде. Ул Исабәкнең әти-әнисе белән танышты, үзенә дус һәм терәк булырлык кеше үстереп бирүләре өчен Кыятлар нәселенә рәхмәтен белдерде.

Мәҗлес вакытында Үзбәк ханның күзе чибәр яшь кызга төште.

– Бусы кем була, Исабәк? – дип ымлады ул аңа таба. Тегесе, ханның игътибарын сизеп, кызарып чыкты.

– Минем кызым Үрдүҗә бит, сөекле ханым. Син аны әле кечкенә вакыттан ук беләсең.

– Кара әле, ни арада, үсеп җиткән! Кияүгә бирерлек кызың бар, миннән яшереп ятасың...

– Яшерсәм, бүген биредәге табында күрсәтмәс идем, сөекле ханым! – Аннан нәиб кызына эндәште. – Кызым Үрдүҗә, бире кил әле!

Үрдүҗә каушап калды, ярдәм сораган төсле әнисенә борылды. Тегесе бернидән дә курыкма дигән сыман кызына хан тарафына барырга ымлады.

Ул башын түбән иеп, каршына килгәч тә, Үзбәк торып басты.

– Исәнме, Үрдүҗә, минем исемем Үзбәк, – диде ул, кызны баштанаяк дикъкать белән өйрәнеп.

– Исәнме, бөек хан, – дип, чак кына ишетелерлек пышылдады Үрдүҗә.

– Мин сине балачакта гына күргән идем, бөтенләй буйга җиткәнсең!

– Рәхмәт, бөек ханым...

– Миннән куркырга кирәкми, Үрдүҗә! Мин сине кыерсытырга җыенмыйм, киресенчә, сокланам гына.

– Мин курыкмыйм, бөек ханым...

– Йә, ярый, бар, урыныңа утыр, сине күрүемә мин бик шатмын.

Кызый калтыранган аякларына чак-чак басып, кире китте.

– Иртәгә яучылар җибәрсәм, син каршы түгелме? – дип сорады Үзбәк хан, Исабәк янәшәсендә урын алгач.

Көтелмәгән бу хәбәрдән Исабәкнең кулындагы касәсе идәнгә төшеп китте. Ул ашыга-кабалана хан каршына тезләнде.

– Синең хезмәтчең генә түгел, туганың да булу минем өчен чиксез бәхет, сөекле ханым! – дип, ул Үзбәкнең кулын үбәргә үрелде.

– Тор, Исабәк, син – беренче чиратта минем ышанычлы дустым.

Кызыңны кыерсытмам, бер дә борчылма. Үзе дә синең кебек үк ипле холыклы кешегә охшаган.

– Кызым бик акыллы, бөек ханым, бик акыллы, – дип кабатлый гына алды каушап калган Исабәк.

Хан, сараена кайткач та, үз янына Баялун хатынны чакыртты. Баялун ашыкмыйча, дәрәҗәсен белеп кенә керде. Соңгы вакытта аларның күрешкәне булмады диярлек. Гомумән, тәхеткә утыргач та, аралар бермә-бер суынды төсле. Баялун моңа борчылуын күрсәтмәсә дә, үзе тәрбияләп үстергән кешедәге үзгәрешләрне күңеленнән авыр кичерде.

– Хәлләрең ничек, бөек хан? – дип сорады ул, чак кына башын ия төшеп Үзбәк белән күрешкәч.

– Хәлләр түзәрлек, Баялун хатын. Син иртәгә яучылар әзерлә, Исабәк нәибнең кызы Үрдүҗәне миңа хатынлыкка сорарга барсыннар.

– Алай икән... – дип сузды уйчан Баялун. Үзбәкнең нәиб кызына ярәшүен аңа җиткерергә өлгергәннәр иде инде. – Холкыңа әллә нәрсә булды, сөекле ханым. Нәзифәне дә рәнҗеткәнсең...

Үзбәк, ни гаҗәп, кычкырмады да, кызарынып-бүртенеп сикереп тә тормады.

– Үзе гаепле, Баялун хатын. Минем хакта таратылган гайбәтне тыңлап йөрмәсен иде.

– Ә мин, хәтерләсәң, кисәткән идем...

– Хәтерлим, хан терәге булырлык хатынга охшамаган, дидең. Сүзең дөреслеккә чыкты. Тик хәзер кисеп ташларга мөмкин түгел, яшәсен шунда үз көенә.

– Үрдүҗә ышанычлы дип уйлыйсыңмы?

– Тормыш күрсәтер. Исабәкнең кызы бит, башы бардыр.

– Исабәкне тагын да якынайтасың, сөекле ханым.

Үзбәк уфтанып куйды.

– Ханның язмыш йөге – ялгызлык, Баялун хатын, – диде ул, каядыр еракка текәлеп. – Кемне генә якынайтсам да, мин барыбер берүзем торып калачакмын. Сүзең бетсә, китә аласың. Яучылар турында уйла. Шартына китереп, затлы бүләкләр белән барсыннар. Телисеңме син, юкмы, Үрдүҗә барыбер иртәгә хәрамгә керергә тиеш. Хан үз сүзен әйтте.

Баялун хатын, барысын да аңладым дип, баш иеп, бүлмәдән чыгып китте.

Туйны зурдан кубып үткәрделәр. Үзбәк хан, мәҗлесне үз утары белән генә чикләмичә, Сарайның үзәк мәйданында табыннар кордырды. Урданың затлы аксөякләре өчен тирмәләр күтәрелде. Берничә йөз казан асып, ризык пешерделәр. Бер читтәрәк тамашага килгән гади халыкка да калҗа белән кымыз таратылды. Яшь парлар хөрмәтенә иң оста һәм булдыклы нүкәрләр бәйгеләрдә катнашты, җиңүчеләргә хан кулыннан затлы бүләкләр тапшырылды. Үзбәк хан белән Үрдүҗәнең кавышу көне дәүләт югарылыгындагы бәйрәмгә әверелде. Урда халкының әлегә мондыйны күргәне юк иде. Халык фикере икегә бүленде – берәүләре моны яңа ханның юмартлыгы белән аңлатса, икенчеләре исә исрафта, мәмләкәт милкен юкка-барга әрәм итүдә гаепләде.

Ничек кенә булмасын, эт өрә – кәрван бара. Үзбәк Үрдүҗә белән кавышты, зөфаф кичләрен үткәрде, яңа хатынын хәрәменә кертте.

Ни гаҗәп, Нәзифә иренең икенче хатынын тыныч кабул итте. Алар хәтта дуслаштылар да кебек. Тимербәкнең генә әтисенә мөнәсәбәте үзгәрде. Моны Үзбәк улының карашыннан сизде. «Ярар, үсә төшкәч аңлар, хәзер әнисе өчен гарьләнә егетем», – дип уйлады Үзбәк.

Үрдүҗәнең үзенә килгәндә, баштарак Үзбәкнең аңа күзе нык төшсә дә, ялкынлы мәхәббәте озакка бармады. Тотып, күккә чөеп мактарлык та, ким-хур итәрлек тә хатын түгел иде Үрдүҗә. Төннәрен артык хиссилек белән аерылып тормады, хатын-кыз хезмәтен хәленнән килгәнчә күрсәтте. Холкы буенча да тыныч, сабыр булып чыкты. Ике хатыны янәшәсендә генә көтсә дә, Үзбәк төннәрен үз янына кол базарыннан алып кайтылган җарияләрне чакыруны хуп күрде. Алары күп, алмаштырырга мөмкин, төрле сораулар белән дә башны әйләндермиләр. Нәзифә белән соңгы тапкыр сүзгә кергәннән соң, ул, гомумән, аның белән төн үткәрмәс булды, бары тик әдәп саклап, аны илчеләр кабул иткәндә һәм хан мәҗлесләренә генә чакыра иде...

**5**

Рус митрополиты Пётр Сарайга килү хәбәрен Үзбәк ханга алдан ук җиткерделәр. Хан шунда ук дин әһелен каршыларга, аңа аерым бүлмә бирергә боерды.

– Руханинең башыннан бер генә чәч бөртеге төшсә дә, җәзам кырыс булачак, бел шуны, – дип кисәтте ул Котлы Тимер мөддәбирне. Тегесе каршы дәшмәде.

Митрополитны хан зур илтифат күрсәтеп, мул табын белән кабул итте. Очрашуга Үзбәкнең ышанычлы кешеләре генә чакырылды, гаиләсе дә биредә иде. Бусагадан атлап кереп, баш игән Пётрны хан үзе каршылады, Митрополит утыргач та, аның янәшәсенә тылмачны дәштеләр.

– Юлларны исән-имин генә үттеңме, Пётр митрополит? – дип сорады Үзбәк, озын кара киемле, ак сакаллы чандыр Пётрның муенына асылган тәресен, ике озын колакчынлы баш киемен игътибар белән күздән кичереп. Ерак ара үтсә дә, руханиның өс-башы чиста, карашы ачык иде.

– Урда ханы бөек Үзбәк, юлларым авыр, ләкин уңышлы булды – синең каршыңа исән-имин килеп җитә алдым, – диде Пётр.

– Сиңа Константинопольдә митрополит вазифасын йөкләделәрме?

– Константинополь митрополитка аның руханилар башлыгы икәнлеген күрсәтүче билгеләрне генә тапшыра. Православ халкын җитәкләү йөге Алла тарафыннан җибәрелгәндер дип уйлыйм, бөек хан.

– Нигә син митрополит вазифасын авыр йөккә тиңлисең?

Пётр зәңгәр күзләрен ханга күтәрде, аларның карашлары очрашты. Үзбәк ул караштa, олы акыл һәм зирәклек белән бергә, сагыш чаткыларын да тоемлый алды.

– Син моны миннән яхшырак беләсеңдер, Урда ханы бөек Үзбәк. Һәрбер җитәкчелек ул кешенең иңнәренә йөк һәм үлгәнче үтәргә сикәлтәле озын юл. Синең хәлең минекеннән дә авыррак – мин халкыма рухи азык бирү турында гына борчылсам, син тамакларын да туйдырырга тиешсең...

Үзбәк уйга калды. Рус олысыннан килгән митрополиттан мондый тирәнлек, күңел якынлыгы көтмәгән иде ул. Аларның дөньяга, хакимлеккә карашлары тиңдәш булуы йөрәгенә май булып ятты.

– Константинополь якларында Урда турында ни уйлыйлар? Безгә мөнәсәбәтләре ничегрәк?

– Дөресен әйтим, бөек хан, мин бу мәсьәләләргә кереп, сораштырып йөрмәдем, – диде митрополит. – Алар сораган очракта Урда дәүләтенең православ динен кыерсытмавын, киресенчә, дин әһелләрен төрле авырлыклардан азат итүен, яклап торуын әйттем. Бу сүзләремне андагы кешеләр дә, күктән барысын да белеп торучы Аллабыз да ишетте...

– Мөселманнар диненә мөнәсәбәтең нинди, митрополит? – дип сорады Үзбәк. Алар икесе дә алларындагы ризыкларны да, янәшәдә башка кешеләр барлыгын да оныттылар.

– Теләсә кайсы дин халыкны яхшылыкка һәм татулыкка өнди. Аллага мөрәҗәгать итүнең телләре генә төрле. Һәрхәлдә, мин үзем шуңа чын күңелдән инанам. Дин нигезендә сабырлык һәм түземлек ятарга тиеш.

– Синең тәгълимат буенча, рус халкы безнең Урда баскакларын да насыйп ителгән күренеш буларак кабул итәргә мәҗбүр түгелме?

– Барысы да Алладан, Урданың бөек ханы Үзбәк. Золымны исә кешегә кылган ялгышлыклар өчен җәза дип күрү дөрестер.

– Синең динең сабырлыкны хупласа да, нигә соң рус олысындагы кенәзләр тыныч кына яши белми? Нигә алар әледән-әле сугышалар, халыкны авырлыкка, ачлыкка, үлемгә дучар итәләр?

Пётр митрополит көрсенеп куйды.

– Кешелек бу сорауга гомере буе җавап эзли, Урданың бөек ханы Үзбәк. Бер карасаң, авыр мәсьәләләрне уртага салып, кан коймыйча гына да хәл итеп була кебек. Ләкин кешеләр әлегә бу югарылыкка үсеп җитә алмаган, күрәсең. Шайтан коткысына бик җиңел бирелә без...

– Тверь белән Мәскәү каршылыгында син кайсы яклы?

– Мин беркем яклы да була алмыйм, Үзбәк хан. Мин аларның ике арадагы дошманлыгыннан өстен торырга тиешле кеше...

– Шулай да, кем хаклырак соң? Тверь кенәзе Михаилмы, әллә Мәскәү хуҗасы Юриймы?

Пётр аяз күк сыман ачык күзләрен ханга төбәде.

– Дөреслек Юрий ягында дип уйлыйм, бөек хан. Мәскәү барыбер өстен чыгачак.

– Син моны кайдан беләсең?

– Гомере буе Аллага мөрәҗәгать иткән кешегә сирәк кенә очракларда Алла да үзенең хәбәрләрен юллый. Ул миңа төшләремнең берсендә Мәскәүнең өстен калачагын күрсәтте. Әлбәттә, моңа ышанырга да була, ышанмаска да...

Үзбәк хан, тирән уйга батып, митрополитны ризыклардан авыз итәргә кыстады. Соңыннан исә Пётрга үзенең ярлыгын тапшырды. Анда Пётр митрополитны, архимандритларны, игумен һәм попларны Урда яклавы турында язылган иде. Православ чиркәвенә караган биләмәләр һәм руханилар ясактан һәм салымнардан азат ителде. Электән калган гадәт буенча Урда чиркәү эшләренә тыкшынмый, хәтта руханиларга карата хөкемне дә бары тик православ дине әһелләре генә чыгара ала иде. Руханилардан мал-мөлкәт тартып алган кешенең икеләтә күләмдә кайтарып бирергә тиешлеге дә әйтелде. Ә инде православ динен

кимсеткән, чиркәү, монастырь биналарына зыян салганнарны бер генә җәза – үлем көтә иде.

Ханның кәефле чагын күреп, Баялун хатын Пётр митрополит белән аерым очрашып сөйләшергә ризалык сорады. Үзбәк хан каршы төшмәде. Пётр һәм яраннары, гаиләсе киткәч, хан Котлы Тимер мөддәбирне чакыртып алды.

– Митрополитка һәрьяклап ярдәм күрсәтергә кирәк, җәбергә юл куймагыз, – диде ул. – Пётр – безнең дәүләтебез хакындагы фикерне православ дөньясына җиткерүче кеше, аның каршында безнең дәрәҗәбез югары булу мөһим. Мәскәү белән Тверь турындагы әйткәне дә уйланырлык. Кенәзләр ярлык сорап килгәч тә, Мәскәү Юриен кичекмәстән кертерсең, Тверь Михаилы бераз көтеп торса да, зыян булмас...

– Баш өсте, бөек ханым, – дип, бил бөкте Котлы Тимер мөддәбир.

Кичке якта Пётр митрополитны Баялун хатын янына чакырттылар. Баялун дин әһелен табын корып көтеп тора иде. Митрополит бусагадан атлап кергәч тә, ул, ашыга-ашыга килеп, Пётрның кулын үпте. «Фатиха бир, изге атакай», – дип пышылдады. Каушап калган митрополит, Баялун хатынны чукындырып, шулай ук пышылдап кына: «Фатиха бирәм, кызым», – диде.

Алар табынга утырдылар, Баялун хатын тылмач чакыртты, рус кенәзлекләрендәге хәлләр турында сораштырырга кереште. Бусагадан кергәч тә булган вакыйгага икесе дә әйләнеп кайтмадылар. Пётр митрополит үзенең башына ханның якын кешесенең зур серен салып куйды, сандыгын бикләде...

**6**

...Ногъманетдин Әл-Хәрәзми имам Сарайга бик ялындырып кына килде. Үргәнечтәге күнегелгән йортыннан бер дә китәргә теләмәде. Котлы Тимернең кат-кат үгетләве генә аны юлга кузгалырга күндерде.

Сарайда аңа дип хан утарыннан ерак түгел аерым йорт әзерләп куйдылар. Буш йортлар мәсьәләсе тиз хәл ителә – корылтайдан соң суелган аксөякләр үзләреннән соң шактый мал калдырды, алар барысы да хан кулына күчте.

Ногъманетдин хәзрәт яңа йортка килеп урнашуының икенче көнендә үк Үзбәк хан күпсанлы тән сакчылары һәм яраннары озатуында аның янына юнәлде.

Яңа йорт затлы җиһазландырылган булса да, имам ханны идән уртасындагы намазлыгына утырган килеш каршылады. Үзбәк килеп кергәч тә, ул торып та басмады, баш та имәде. Хан, бусагада борылып, үзен озата килүчеләргә ишек артында калырга боерды.

– Саумы, Ногъманетдин хәзрәт?! – дип, Үзбәк үзе килеп, аксакал белән күреште һәм аның каршына аякларын бөкләп утырды.

– Саумын, Урда ханы, – имам Үзбәккә сынаулы караш ташлады. – Үзгәргәнсең, тәхет элеккеге башсыз егеттән кырыс ир-ат ясаган.

– Тәхет авыр йөк икән, хәзрәт...

– Әле бу башы гына, Урда ханы. Шактый кешенең гомерен кискәнсең дип сөйлиләр, дөресме шул сүз?

Үзбәк, оялып, күзләрен яшерде.

– Гаеплеләрнең башы киселде, хөрмәтле хәзрәт.

– Аларны гаепле дип танырга син Аллаһы Тәгалә түгелсеңдер бит?!

– Мин бары тик мескен бер хан гына. Ләкин минем хан хөкеме чыгарырга хакым бар, хәзрәт.

– Анысын кем әйтте?

– Күп еллар буе шундый гадәт яшәгән.

– Ул гадәтне кешеләр уйлап тапкан бит?

– Анысы хак...

– Әрвахлар төшеңә кереп йөдәтмиме?

– Йөдәтә шул, хәзрәт.

– Димәк, күңелең тыныч түгел. Барысын да гаделлек белән хәл итүеңә үзең дә инанып бетмисең, шуңа әрвахлар йокы бирми.

– Тынычлыкны кайдан табарга, хәзрәт?! Сине шуңа бирегә чакырдым. Зинһар, янәшәмдә тор, авыр чакларымда сөйләшер кешем бул! Урының түрдә, тамагың тук көе кадерләп кенә яшәтермен...

– Син тынычлыкны мәңге таба алмаска мөмкин, Урда ханы. Аны табар өчен үзеңә бик тирән кереп казынырга, сиңа уңайсыз булган сорауларга алдашмый җавап бирергә кирәк. Минем дә бу тормышта ялгышларым күп. Төшләрем дә тыныч кына түгел. Мин тынычлыкны намазда, Коръән китабында, догаларда табам. Синең динеңне мин аңламыйм, шуңа күрә ярдәм итүем икеле.

Үзбәк хан уйга калды. Ногъманетдин Әл-Хәрәзми имамга ул күңелендәге иң зур серен, моңарчы беркемгә дә әйтмәгән яшерен теләген ачып салырга ниятли, ләкин көч таба алмый. Имам аның әйткәненә ничек карар, ни әйтер? Көлкегә алмасмы? Аннан да бигрәк, гаеплегә чыгармасмы? Ул акрын гына сүзгә кереште.

– Ногъманетдин хәзрәт галиҗәнабы, безнең динне мин үзем дә ахыргача аңлый алмыйм, – диде ул, кыюлыгы җитәрлек дәрәҗәгә менүен сиземләгәч. – Ул хорафатларга, багучыларның алдавына, тузга язмаган ышануларга корылган кебек. Мин балачактан безнең йолаларны кабул итә алмадым, сәерсенә һәм курка идем алардан. Ислам минем күңелемә нур иңдерер төсле тоела...

– Дин – бик көчле корал ул, Урда ханы, син моны аңлап эш итәргә тиеш. Без бу хакта Үргәнечтә синең белән күп сөйләштек. Әгәр син исламны дәүләт мәнфәгатьләреннән чыгып кына кабул итәргә җыенсаң, аның бәрәкәтен күрмәссең. Дин – тишек бишмәт түгел, бер тапкыр иман китергәннән соң кире кайту мөмкин түгел. Син боларның барысын да уйлап, бизмәнгә салып үлчәргә тиешсең. Әгәр фикерең нык булса, сине үзем иманга китерергә әзермен.

Үз сараена кайткач та, Үзбәк хан Котлы Тимерне чакыртты.

– Бәкләр-бәге Котлы Тимер, синең белән диван әһеле буларак түгел, дустым буларак сөйләшәсем, киңәшләшәсем килә, – диде ул, янәшәсенә утырырга ымлап. – Бу сүзләр ике арада гына калсын. Мин Үргәнечтә вакытта да бу хакта күп уйландым. Синең башкалаңдагы мәчетләрне, имамнарны, казыйларны күреп сокландым. Моңарчы да ислам диненә мөкиббән идем. Бер яктан, ул кешегә тынычлык иңдерсә, икенче яктан җәмәгатьне туплап торучы зур көч тә. Ислам дине безнең дәүләтебез өчен файда китерергә мөмкин, дип уйлыйм. Мәмләкәтнең төрле почмакларында

Мөхәммәд салаллаһу галәйһи вәссәлам тарафдарлары яши, алар – ышанычлы кешеләребез. Мин, үзем иман китереп, исламны дәүләт дине буларак игълан итәргә ниятлим. Ничек уйлыйсың, дөрес юлдамы мин?

Котлы Тимер шатлыгын яшерә алмады:

– Бөек ханым, синең карарың бик дөрес һәм урынлы дип саныйм! Ислам дине дәүләтебезгә бердәмлек алып киләчәк, безнең көчебезне тагын да арттырачак! Авырлыкларны җиңәргә ярдәм итәрбез, сиңа үземнең көчемне кызганмый булышырмын! Сарайдагы шактый аксөякләр, күпчелек олысларның бәкләре инде күптәннән ислам динендә, шуңа күрә безгә әллә ни авырга туры килмәс.

– Ислам кабул ителгәч, Мисыр солтаны да безнең тарафдарлар исәбенә күчәр иде. Туктай хан башлаган эшне азагына җиткерәсе бар – Кавказ аръягындагы Ширван, Арран, Азәрбайҗан җирләре һичшиксез Урда карамагына кайтарылырга тиеш...

Бу сүзләрдән Котлы Тимернең кәефе кырылды:

– Иран белән бәрелешкә керү дөрес булырмы икән, бөек ханым? Безгә сугыш кирәкмәс төсле...

Үзбәк хан бәкләр-бәгенә усал караш ташлады:

– Ник, Котлы Тимер, син дәүләтебезне киңәйтүгә каршымыни? Өч елга сузылган корылыкны оныттыңмы әллә? Кавказ тауларының итәге атларыбызга, терлекләребезгә су һәм азык чыганагы булачак бит!

– Мин Хәрәзем өчен борчылам. Без Иранга терәлеп үк торабыз бит, гаскәрләребез Кавказ тарафына киткәч, минем олыс ягыннан бәреп кермәсләрме?

– Кермәсләр, борчылма. Чикләрне ныгытырга өстәмә нүкәрләр бирербез. Тагын бер нәрсәне онытма, Котлы Тимер – син олыс бәге түгел хәзер, ә бөек Урданың бөек мөддәбире, тулаем дәүләт өчен уйларга тиешсең...

Котлы Тимер хан белән бу мәсьәләдә бәхәсләшүнең мәгънәсез икәнлеген аңлады. Үзбәк Урданы киңәйтергә ниятли, үзен халык хәтерендә аның мәйданын зурайткан хаким буларак мәңгеләштермәкче. Яши-яши хәйләгә өйрәнгән бәкләр-бәге икенче яктан кереп карарга булды.

– Бөек ханым, Ширван, Арран һәм Азәрбайҗан Урданы яңа биеклеккә күтәрәчәк. Монысына шигем юк. Тик безгә бүген көнбатышка игътибар итү дөресрәктер. Ногай олысында Тоңгыз белән Таз бәкләр дөньяны бутап ята. Аларны акылга утыртырга кирәк. Рус кенәзлекләрендә бөтенләй дә тынычлык юк, үзара сугышып яталар...

– Тоңгыз белән Тазның башларын миңа алып кайтып бирсеннәр. Каугадый җитәкчелегендә нүкәрләр җибәр. Рус кенәзлекләренә дә тәртип кертербез, Котлы Тимер. Хәзер исә иман китерү тантанасына әзерлек эшләрен башлап җибәр...

Үзбәкнең ислам диненә күчәргә җыенуы Урдада зур шау-шу куптарды. Хәтта аның ышанычлы дип саналган кешеләре дә бу карарны өнәп бетермәде. Гомер буе Яса кануннарыннан чыкмаган, Мәңге Күк Тәңре күрсәткән юл буенча барган дәүләт белән мөселман кешесе идарә итә аламыни? Котлы Тимер Үзбәк ханның төп фикердәшенә әйләнде. Ул аның теләген тулысы белән хуплады. Исабәк берара икеләнеп йөрсә дә, ахыр чиктә күнде. Баялун хатын эченнән генә мондый адымны ханның

чираттагы тилелеге дип санаса да, каршы дәшмәде. Хатыннары белән хан киңәшләшеп тормады.

Ханның иман китерү тантанасы Сарайның иң купшы мәчетендә үткәрелде. Аның хансарайдан чыгып, мәчеткә баруын, соңыннан кире кайтуын карарга меңәрләгән халык җыелды. Йөзәрләгән казанда сыйнигъмәтләр әзерләнде. Аларны барча кешеләргә бушлай тараттылар. Халык, ашаудан баш тартмаса да, ханнарының мондый кисәк кенә кабул иткән карарын аңлап бетермәде. Тик, гомумән алганда, Сарайдагыларның кәефләре күтәренке иде. Үзбәк хан аларга бәйрәм арты бәйрәм алып килде, калҗаларны мулдан таратты, элеккеге хакимнәр төсле саран түгел. Бәлки, моңа аның ислам динен тотуы сәбәпчедер...

Әмма дин мәсьәләләре сыйлану һәм күңел ачу белән генә тәмамланмады. Озакламый хансарайдан чираттагы әмер яңгырады – ислам Урда күләмендә дәүләт дине дип игълан ителә. Яса кануннары гамәлдән чыгарыла, аның урынына шәригать кертелә. Халыкка мөмкин кадәр тизрәк иман китереп, мөселман өммәтенә күчү шарты куелды. Хөкем эшенә шәригать белемле казыйлар билгеләнде.

Урданың үзендә хакимлек тәртибе үзгәртелде. Олыслар эреләнде. Алар белән җитәкчелек итәргә Үзбәкнең ышанычлы кешеләре билгеләнде. Болар инде Чыңгыз нәселеннән түгел, шул җирләрдә туып-үскән булдыклы аксөякләр иде. Акрынлап, Урда күләмендә Чыңгызларга караган бәкләр бармак белән санарлык кына калды. Кайсылары күптән үтерелгән, кайсылары качып котылган, ә кайберләреннән хакимлек хокукы тартып алынган иде.

Башта аксөякләр, тора-бара гади халык та ислам диненә тартылды. Хан үзе һәр җомга саен Сарайның иң олы мәчетенә намазга йөрү тәртибен кертте. Анда имам итеп Ногъманетдин әл-Хәрәзми куелды. Аксөякләрнең намазга бармавы ханга хыянәт белән тиңләштерелде. Мәчетләр салдырган олысларга Сарай тарафыннан салымнар түләүдә ташламалар вәгъдә ителде. Бер яктан чыбыркылап, икенче яктан кызыктырып, Үзбәк хан мәмләкәтендә ислам кануннарын урнаштырырга кереште...

Тик барысы да ул теләгәнчә барса иде!.. Шымчылары җиткергәнчә, багучылар халыкны котырту белән шөгыльләнә, тегеләре исә, берәр хорафат кылсә, багучы янына чабалар икән. Үзбәк хан чираттагы кырыс карарын кабул итте – бер ай дигәндә барлык багучылар Урда дәүләтеннән чыгып китәргә тиеш иде. Китмәгән очракта, аларны үлем көтә, дип кисәтелде. Багучылар, камлау өчен кулланыла торган кирәк-яракларын, төнәтмәләрен, тамыр-үләннәрен арбаларга төяп, Сарайдан һәм мәмләкәтнең башка шәһәрләреннән тиз генә чыгып таю хәстәрен күрделәр. Бары тик Багаууган һәм аның сигез тарафдары гына беркая да китмәде. Алар хан билгеләгән соңгы көннең килеп җитүен сабыр гына көтә бирделәр...

## 7

...Багаууган, яшерен юллар буйлап шәһәр читенә чыгып, нык һәм тиз адымнар белән ерак түгел караеп торган урманга юнәлде. Аяк астында беренче кар шыгырдый, күктә ай калыккан. Урамда салкынча, ләкин сулыш алырга бик рәхәт иде. Багучы, уңны-сулны карамый, урманның

чытырманлы төшеннән кереп китте. Ул, дөм караңгылыкка карамастан, әйтерсең, төнлә дә күрә, йә булмаса күптән өйрәнелгән сукмак буенча бара иде.

Үзенә генә мәгълүм бер урынга җиткәч, Багаууган туктап калды. Каршысында, җиргә авып череп барган агач астында өн шәйләнде. Багаууган, башын күккә, ай тарафына күтәреп, улап җибәрде.

Өннән ашыкмый гына Ана Бүре чыкты. Ул Багаууганга текәлде. Күзләре утлы күмер төсле яна иде. Ана Бүре салмак адымнар белән багучы янына килде, шыр сөяккә калган сырты белән аякларын сыпырып үтте. Багаууган чүмәшеп утырды, Ана Бүрене сак кына сыйпады да, иелә төшеп, колагына нидер пышылдады.

Ана Бүре сулкылдап куйды, әйтерсең, күңелсезләнеп калды. Ул, башын түбән иеп, кире өненә кереп китте һәм, озак та тормый, тугыз баласын ияртеп чыкты.

Тугыз бүре баласы тезелешеп утырдылар, Багаууганга кызыксынулы ялтыравык күзләрен төбәделәр. Ана Бүре һәрберсен назлап, юеш теле белән ялады да янә Багаууганга борылды. Ана Бүренең күзләрендә мөлдерәмә яшь иде. Бераз гына басып торды, балаларына соңгы караш ташлады һәм төн караңгылыгына кереп югалды.

Багучы бүре балалары янына килде, кесәсеннән нәрсәдер чыгарып, һәрберсенә авыз иттерде. Багаууганның учын ялаган бүре балалары, һушларын җуеп, җиргә ава тордылар. Багучы аларның тугызын да зур капчыкка салды һәм килгән сукмагыннан кире кузгалды...

Багаууганны Сарайдан ерак түгел тау башында сигез тарафдары – аның кебек үк көчле багучылар көтә иде. Барысы да үзләренең сәер киемнәрен кигән. Берсенең башлыгына болан мөгезе беркетелгән, икенчесенекендә аю тешләрен ыржаеп тора, дөньяда күрелмәгән җан иясен тасвирлаучы битлекле кемсәләр дә бар.

Алар тугызау җыелдылар. Һәрберсенең кулларында дөңгер. Тау башына озын колгалардан чатыр корылды. Колгалар өстенә аю, бүре, күсе, елан, селәүсен тиреләре ябылды. Эченә кереп, һәрбер багучы үзенең көче тупланган бөтиен калдырды. Багаууганның бөтие эченә мәрхүм әбисенең чәчләре, мең еллар элек юкка чыккан хайванның азау теше, киптерелгән елан күзләре, ата аю җенесе, тагын әллә нинди сәер һәм җирәнгеч әйберләр салынган иде.

Бөтиләр куелып беткәч, Багаууган дөңгеренә кага башлады. Аңа бер-бер артлы сигез дөңгер кушылды. Багучылар, чатыр тирәли әйләнеп йөреп, биергә керештеләр. Ул биюнең, әйтерсең, беркайчан да бетәсе юк иде кебек. Багучылар дөньядан аерылып, саташулы йокы халәтенә күчтеләр, күзләренең агы гына күренер дәрәҗәгә җитте.

Офыкта кышкы кояшның беренче нурлары күренде. Багаууган, ничек кисәк кенә башласа, дөңгер кагуын шулай ук кисәк кенә туктатты. Тирә-юньгә тынлык иңде. Багучылар кояш тарафына борылып, тезләнделәр. Һәрберсе эченнән үзе генә белгән әфсеннәрен укый иде.

Багаууган торып басты, аңа башкалар да иярде. Алар бер читтәрәк бәйләп куелган куй янына юнәлделәр. Кешеләрнең сәер кыланмышларыннан куйның коты алынган, ул, аларның үзенә якынлашуын күргәч тә,

чарасызлыктан уфылдап, бәйләвеннән ычкынырга маташты. Тик нияте барып чыкмады. Багауган, килә-килешкә куштанлы киемнәре арасыннан хәнҗәр тартып чыгарып, куйны чалып җибәрде. Малкайның муенынннан сиптереп торган канга багучылар учларын куйдылар, шуның белән сусауларын бастылар. Киемнәре, йөзләре канга буялып, багучыларның кыяфәтләре тагын да куркынычрак рәвешкә керде.

Багауган куйның корсагын ярды. Багучылар шунда ук малның эчке әгъзаларына ябырылдылар. Йөрәген, бавырын, эчәгеләрен, бөерләрен куллары белән өзгәләп алып, колгалардан корылган чатыр эченә кертеп сала тордылар.

Дөңгерләр янә телгә килде. Багучылар биюләренә әйләнеп кайттылар. Дөңгер тавышы көчәйгәннән-көчәя барды. Кояш акрынлап күтәрелә төште. Чатыр эчендә үзеннән-үзе ут чыкты. Ул колгаларны, тире кисәкләрен ялмап алды. Багауган, дөңгерен ташлап, бүре балалары салынган капчыгын алды да дөрләп янучы чатыр эченә атлады. Багучыларның берсе дә биюдән туктамады, дөңгерләренең тавышы далага, тау астында җәйрәп яткан Сарай өстенә тарала иде...

Үзбәк хан җитәкчелегендәге нукәрләр төркеме аларны әйләндереп алганда чатыр инде янып беткән, дөңгерләр тынсыз калган, багучылар исә, үлекләр төсле, кайсы кая аунап яталар иде.

– Багауган! – дип кычкырды Үзбәк хан, атын куй үләксәсе янында туктатып. – Күземә күрен, сиңа бирелгән вакыт тәмам!

Аунап яткан багучылар акрынлап торып утырдылар, тик битлекләре артына яшеренгән йөзнең кемнеке булуын тану мөмкин түгел иде.

Багауган озак көттермәде. Ул янып беткән чатыр эченнән күренде. Кулында зур капчык. Өсте-башы корымга буялган, тик бер генә киеме дә, үзенең тәне дә янмаган да, пешмәгән дә.

– Үзбәк, – диде ул гырылдавык тавыш белән һәм мыскыллы кыяфәттә баш игән булып кыланды. – Урданың бөек ханы, динне яклаучы, тагын әллә нинди дәрәҗәләр иясе! Синең дә минем каршыма килер көнең бар икән.

– Бу синең соңгы көнең, Багауган! – Үзбәк атына атланган килеш Багаугванның усал күзләренә төбәлде.

– Шулай да булсын, Үзбәк, – Багауган иреннәрен ялап куйды. – Без бүген сиңа атап камладык. Киләчәгеңне беләсең киләме?

– Кирәкми, мин синең хорафатларга ышанмыйм!

– Ышанасың... Куркасың да әле. Яңа дин кертәм дип, ата-бабаларың табынган Мәңге Күк Тәңрегә хыянәт иттең. Аллага үзең ышанасыңмы соң син? Йөзәрләгән туганыңның җанын кыйдың, аларның каны елга булып акты, син табынган Алла шушы гамәлләреңне кичерә алырмы? Чыңгызлар ыңгырашып, соңгы авазларын салган вакытта син аларның мәетләре аркылы тыныч кына атлап чыктың. Синнән әле дә кан исе килә, гәрчә син затлы ефәкләргә төренсәң дә, татлы хушбуйлар сөртенсәң дә, ул кан мәңге юылмас. Син табынган Алла мондый вәхшилекне ярлыкармы икән?!

– Авызыңны ябарга киңәш итәр идем, гөнаһ капчыгы! – Үзбәк билендәге кылычына үрелде, шул мизгелдә үк ике яктан ике нукәр йөгереп килеп, багучыны тез чүктерделәр. Ләкин Багауган Урда хакименә текәлеп карый бирде.

– Әгәр гомерем беткән, якты кояш нурларын бүтән күрергә язмаган икән, соңгы үтенечемне кире какма, Урда ханы Үзбәк!

– Әйтеп кара, үтенечеңнең нидән гыйбарәт икәнлеген белгәч тә, карарымны җиткерермен.

– Ул бер дә авыр түгел. Кечкенә, бик кечкенә үтенеч, Урда ханы Үзбәк. Хәзер әйтәсе сүзләремне тыңлап торуыңны гына сорыйм. Мин әйтеп бетергәч, тыныч күңел белән башымны кисә аласың. Бүген биредә без – Урданың иң көчле тугыз багучысы, бергә җыелып, сиңа камладык. Соңгы тапкыр камлавыбыз...
– Багаууган, син әзерме дигән кебек, Үзбәкне карашы белән бораулады, пычранып беткән йөзенә елмаю шәүләсе иңде. Багучы сизә – мәмләкәт хакиме аларның күрәзәләрен ишетүдән бер яктан курыкса, икенче яктан, күңеленә хуш фаразлар булыр дип өметләнә. – Синең гомерең озын булачак, Урда ханы Үзбәк. Бу кадәр гомерне Мәңге Күк Тәңре Чыңгызханның үзенә генә бирде. Ләкин сине үзгә язмыш көтә. Син төзегән калалар, таралып, комга әверелер. Син ирешкән бөеклек үзеңнән соң эреп юкка чыгар. Синең балаларың бер-берсенең җанын кыеп, бертуганнар арасындагы низаг-җинаятьләргә баштанаяк кереп чумар. Бармаклар арасыннан су ничек агып чыгып, җиргә сеңсә, синең бөеклегең дә нәкъ шулай югалыр...

– Сүзең беттеме, багучы Багаууган?!

– Тагын бер генә нәрсәне әйтәсем калды, Урда ханы Үзбәк. Син безнең башларны киссәң дә, без барыбер мәңге синең янәшәңдә йөрербез. Әледән-әле юлыңда тугыз бүре очраса, белеп тор – ул без булырбыз. Балачактан син безгә ышанып яшәдең, ул ышанудан тәхеткә менеп кенә котылып булмый, Урда ханы Үзбәк. Бернинди догаларың да безне җиңә алмас. Без һәрвакыт сине күзәтеп торырбыз. Без – синең яңа дингә табынуыңның ясалма икәнлеген дәлилләп торырбыз...

Үзбәкнең күңеленә, чыннан да, Багаууган сүзләреннән соң курку иңде, ләкин ул сер бирмәде. Акрын гына кылычына үрелде. Багаууган исә, капчыкны ачып, җиргә тугыз бүре баласын чыгарды. Тегеләре, яктылыкка күнмәгән күзләрен чекерәйтеп тордылар да кинәт иректә булуларын аңлап, кайсы кая йөгерешеп юкка да чыктылар.

– Тугыз бүре тугыз яктан сине күзәтеп торыр. Сак бул алардан, Үзбәк. Нәселең өчен борчыл. Бүреләрне күрәсең икән, белеп тор – бәла янәшәңдә генә йөри булыр...

Соңгы сүзләрен әйтеп бетермәде, һавада Үзбәк ханның кылычы сызгырып үтте. Багаууганның башы тәгәрәп китте, гәүдәсе карлы җиргә гөрселдәде. Кара нүкәрләре ул арада калган сигез багучыны тураклыйлар иде.

– Исабәк Кыят, Мисырга илчеләр җибәр, – диде Үзбәк, канлы кылычын кыныга тыгып. – Урда җирендә тулысы белән ислам дине урнаштырылды, халкы мөселман өммәтенә күчте, дисеннәр. Моннан соң солтан безнең аркадашыбызга әверелергә тиеш, иншалла...

**8**

Ислам дине кабул ителгәч, хан тирәлеге шактый нык үзгәрде, дин әһелләре дә хан корылтаена кертелде. Дәрәҗәле имамнардан кала, баш казый да диванга чакырулы, дәүләт өчен аеруча зур әһәмияткә ия булган хөкем карарларын чыгаручы кешегә әверелде.

Диванның эчтәлеге дә башка төсмер алды. Элегрәк бәкләр, әмирләр үз фикерләрен кыстыра алса, хәтта кайвакыт кирегә сукалап та утырса, Үзбәк хан бу гадәткә бик тиз чик куйды. Киңәшләрне үзе кирәк дип санаган вакытта гына сорый, карарларны сүз боткасы оештырып тормый гына үзе кабул итә.

Хан диванында, гадәттәгечә, аның гаиләсе дә катнаша. Уң кул ягында хатыннары Нәзифә белән Үрдүҗә, алар каршысында балалар урын алган. Баялун хатынның үзенең аерым урыны бар. Исабәк, Котлы Тимер сул якта, теләсә кайсы вакытта ханның колагына пышылдап, үзләренең фикерләрен әйтергә торалар.

– Иран тарафына мин зур илчелек җибәргән идем, – дип, сүзен башлады Үзбәк хан. – Аларга хулагуларның хәзерге илханы Олҗайтуга минем сүзләремне җиткерергә кушылды. Сүзем катгый – илхан безгә тиешле Арран, Ширван һәм Азәрбайҗан җирләрен кире кайтарырга тиеш. Мин Олҗайтуга бу мәсьәләне канкоешсыз гына җайларга тәкъдим иттем. Минем илчеләр кире Сарайга кайтып җитте, аларны бирегә чакырып, бергәләп илханның җавабын тыңлыйк.

Хан тарафына Күк Тимер Күрәгән, Байбанйал һәм Байбыка әмирләр килде. Алар, гадәттәгечә, тез чүгеп, Үзбәкнең сүз әйткәнен көткән хәлдә катып калдылар.

– Әмирләрем, сөйләгез, Олҗайту илхан минем тәкъдимгә ни дип җавап бирде?

– Бөек ханым, без меңнәрчә чакрым ара уздык, далаларны, тауларны, чүлләрне һәм суларны кичтек, – дип, курка-курка гына сүз башлады Күк Тимер Күрәгән. – Олҗайту илхан безне колач җәеп каршы алды. Без аңа синең сүзләрне түкми-чәчми әйтеп бирдек.

Әмир тынып калды, янәшәдәге Байбанйал белән Байбыкага, ярдәм сорагандай, карашын борды. Тик тегеләре сүзгә кушылмадылар.

– Йә, шуннан ни? Җавабы нинди?

– Олҗайту илхан сиңа чиксез ихтирамын һәм хөрмәтен белдерергә кушты, бөек ханыбыз, – диде Күк Тимер Күрәгән коелып төшкән тавыш белән. – Ул синең көчеңә, кодрәтеңә, зирәклегеңә соклануын яшерми.

– Арран белән Ширван турында сөйлә, Күк Тимер Күрәгән! – Ханның тавышы кырысланды.

– Олҗайту илхан безнең белән сугышка керергә теләми, шул ук вакытта әлеге җирләрне ул үзенеке дип саный. Безнең гаскәрләр ул тарафка кузгала калса, зур канкоеш булачагын кисәтте. – Агарынган Күк Тимер Күрәгән боларның барысын да бер сулышта әйтте дә, барысына да әзер кешедәй, ханның хөкемен көтеп, башын тагын да түбәнрәк ия төште. – Арран җирләрендә Хөсәен әмир җитәкчелегендәге зур гаскәр тора, без аларны да үз күзләребез белән күрдек...

Үзбәк хан берара дәшми торды. Аннары Котлы Тимергә карап алды. Башка бәкләрне һәм әмирләрне күздән кичерде. Күрәсең, Кавказ аръягына кулын сузу әлегә иртәрәктер. Башта дәүләтнең үз эчендә көчләр туплап, аннан соң гына морадына ирешү мөмкин булыр. Үзбәк хан сабыр итәргә карар кылды. Елмаеп, урыныннан торып басты.

– Хан әмерен тыңлагыз! – диде ул. – Илчеләрем Күк Тимер Күрәгән,

Байбанйал, Байбыка, сезгә хан исеменнән олы рәхмәт. Шулкадәр ара үтәргә курыкмадыгыз, дошман өненә барып керүдән өркемәдегез, ханыгызның сүзләрен түкми-чәчми җиткердегез. Олҗайту шулай җавап биргән икән, димәк, Ходайның насыйбы. Сез, ял итеп алгач та, минем исемнән Олҗайту илханга бүләкләр төяп, янә юлга кузгалырсыз. Олҗайту илханга әйтегез – Үзбәк хан аның кулын ныклап кыса, ул тәкъдим иткән дуслыкны ихлас йөрәктән кабул итә, диегез. Әгәр берәр төрле ялгышлык белән кимсеткәнмен икән, минем исемнән гафу үтенегез.

– Баш өсте, хакимем, – дип чак кына ишетелерлек тавыш белән пышылдады Күк Тимер Күрәгән.

– Сез китә аласыз, – диде Үзбәк хан, аннары янәшәсендәге Исабәк нәибкә борылды. – Күрәсеңме, Исабәк, Иран илханнарының теләсә кайчан сугышка керергә әзер гаскәре бар. Безнең дәүләткә дә бу тәртипне кабул итәргә кирәк. Минемчә, Урда мәмләкәте берничә йөз мең нүкәрдән торган даими гаскәрне ашатып торырга сәләтледер. Ул нүкәрләр, тамак һәм кием кайгысын белмичә, даими рәвештә сугыш һөнәрен чарларга тиеш. Хан аларга үзенең казнасыннан мул итеп акча түләячәк. Бусы бер. Икенчедән, Урда дәүләтенең барча халкына да җитәрлек күләмдә акча сугарга боерам. Акча сугу белән шөгыльләнүче үзәкләр итеп Сарай, Азак, Болгар, Мукшы һәм Үргәнеч шәһәрләрен билгелим. Әлеге үзәкләрдә аерым биналар бүлеп бирергә, аларга ышанычлы сак куярга кирәк. Өченчедән, бүгеннән үк кәрваннар уза торган юлларны төзекләндерә башларга әмер бирәм. Елгалар аша кичүләрне җайларга боерам. Сәүдәгәрләр ял итсен өчен кәрван-сарайлар торгызыгыз. Алар матур, купшы һәм затлы булсын. Сәүдәгәрләр, шул затлылыкны күреп, бөтен дөнья буйлап Урда дәүләтенең хөрлеге турында хәбәр таратыр. Сәүдәгәрне кыерсыткан кешегә – үлем. Сәүдәгәрне талаган кешегә – үлем. Бу әмерне Урданың барча кыйтгаларына таратыгыз! Һәм бүгенгә иң соңгы әмерем. Бәркә ханның Актүбә яры буендагы утарын нигез итеп алып, шунда зур шәһәр салырга боерам. Ул матурлыгы, төзеклеге белән башка калалардан күпкә шәбрәк булсын. Аның үзәгендә хан сарае урнашсын. Аны мәчетләр һәм мәдрәсәләр әйләндереп алсын. Елга буйлап килүче кораблар өчен уңайлы тукталу урыны төзелсен. Бу максат өчен Урданың төрле якларыннан ташчыларны һәм балта осталарын җыеп китерегез. Кавказ тауларында затлы мәрмәр ташлар чыгаруны көйләгез. Төзелеш башлыгын Урда җиреннән таба алмасагыз, читтән эзләгез, хан аңа мул итеп түләргә әзер. Яңа шәһәр Урданың яңа башкаласына әверелсен. Аның исеме Сарай Әл-Җәдид булыр!

Ханның әмерләрен җәмәгать тынсыз калып, шаккатып тыңлап торды. Берьюлы әллә ничә төрле эшкә алыну гадәте моңарчы Урда дәүләтендә күрелмәгән хәл иде. Гомумән, салмак тормыш рәвешенә күнеккәннәр биредә. Җәйләрен күчмә тормыш алып баралар, әледән-әле яуга чыгалар, аннан буш вакытта исә ашыкмый гына гомер итә бирәләр. Үзбәк хан бу тәртипләрне әйләндерде дә ташлады. Казначылар даими гаскәр тотуга, кәрван-сарайлар, аннан да бигрәк яңа кала торгызуга күпме акча китәсен санап карарга маташты. Тик чыгымнарның күләме башларына сыймый иде.

– Бер яктан сәүдәне үстереп, дәүләтебезнең кереме артса, без ул артык акчаларны төзелешкә юнәлтербез, – диде Үзбәк хан, бәкләрнең һәм

әмирләрнең ни турында уйлаганын сизгән төсле. – Башланган эш – беткән эш. Әгәр бердәм булып тотынсак, барысын да ерып чыгарбыз, иншалла! Ханның сүзе тәмам.

Үзбәк тәхетенә утыргач та, Котлы Тимер аның колагына иелде:

– Яңа кала төзетү турында тәкъдимең әйбәт, сөекле ханым, тик күтәрә алырбызмы икән? Хәзер үк әйтеп ташлагач, төзелешне сузарга ярамый бит...

– Сузмагыз, – дип, кырт кисте хан. – Мин Сарайда озак тора алмыйм, буылам. Биредә һәр нәрсәдән кан исе килә... Тагын нинди мәсьәләләр калды? – дип эндәште ул аннан соң киңәшмәгә җыенган җәмәгатькә.

– Бөек ханым, Тверь кенәзе Михаил бер елга якын синең белән очрашуны көтә, аны кабул итсәң, яхшы булыр иде, – диде Исабәк нәиб кыяр-кыймас кына.

– Ни кирәк аңа?

– Синнән Тверь җирләренә хуҗа булыр өчен ярлык алмакчы була.

Үзбәк хан уйга калды.

– Мин русларның митрополиты Пётр белән очраштым, матур гына сөйләшү килеп чыкты, – диде ул уйчан кыяфәттә. – Акыллы, төпле кешегә охшаттым. Белгәнегезчә, православ чиркәвен ясак түләүдән азат итүче ярлыкны тапшырдым, чит диндә булуларына карамастан, аларның руханилары безнең яклау астында. Мәскәү кенәзе Юрий да килде, аңа да ярлык тапшырылды. Юрий шулай ук күңелемә хуш килде. Хәзер менә Тверь башлыгы ишек төбендә көтеп тора. Митрополиты ярар, анысы бөтен рус олысына хезмәт итә. Бу кенәзләр артык күп түгелме ул җирләрдә?

– Элек-электән Урда Тверь кенәзлегенә илтифат күрсәтеп килде, – дип кыстырды Котлы Тимер.

– Анысы миңа мәгълүм. Тик Мәскәү кенәзлеге дә күтәрелеп китәргә маташа шикелле.

– Аларның артык күтәрелүе безгә зыян китерергә мөмкин. – Котлы Тимер ханның фикерләрен үзенә уңайлы яккан борырга ниятләде. – Рус кенәзлекләре үзара тарткалашып, бер көчкә берләшә алмый, ә бу безгә файдага гына.

– Әмма ул тарткалашу-сугышлар халыкка күп зыян китерә, нәтиҗәдә, без дә ясакны тиешле күләмдә ала алмыйбыз.

– Керми калган ясак безгә каршы яуга күтәрелгән бердәм рус дружиналарына караганда кыйммәтлерәктер, сөекле ханым...

– Рус җирләрендә тынычлык булмау сиңа да отышлы, бәкләр бәге Котлы Тимер, – дип, бәкләр-бәгенә борылды Үзбәк хан. Сынаулы караштан Котлы Тимернең йөрәге «жу» итеп китте. – Андагы хәлләрне җайлаштырып йөреп, минем Ширван һәм Арран тарафларыннан игътибарым китә. – Үзбәк, мөддәбиренең куркуын күреп, аны тынычландырырга тырышып, елмаеп куйды. – Һәрберегез үз җаен гына карый, ә миңа тулаем дәүләт турында уйлыйсы. Рус олысына карата минем үз мөнәсәбәтем бар, анда да тәртип сала алырмын шикелле. Ләкин әлегә берегезгә дә әйтмим, бөтен эшне бозып куюыгыз бар. Тверь кенәзе Михаилны дәшегез!

Кенәз, ханның кабул итү бүлмәсенә кереп, Үзбәк каршында тез чүкте.

– Бөек хан, Тверь кенәзеннән кечкенә генә бүләкләрне олы итеп кабул ит! – диде ул. Аны озата килүче ике кеше хан каршына затлы тиреләр,

көмеш савытлар, купшы бүрекләр куйды. Хан аларга битараф рәвештә күз салды да, Михаилга торып басарга боерды.

– Сүзеңне әйт, Тверь кенәзе Михаил, – диде Үзбәк, каршындагы кунакны җентекләп өйрәнеп.

– Синнән фатиха алырга, Тверь җирләренә хакимлеккә ярлык сорарга килдем, бөек хан! – диде Михаил кенәз, Үзбәкнең күзләренә туры карап. – Алга таба да Урдага, сиңа тугры хезмәт итәргә ант эчәм. Ясакны вакытында түләү генә түгел, арттыру ягын карарга да ризамын.

Үзбәк җанланып китте.

– Нәрсә хисабына ясакны арттырмакчы буласың, Михаил кенәз? – дип сорады, казначыларына үткен караш ташлап.

– Новгород җирләрендә андый мөмкинлек бар дип уйлыйм. Тик миңа синең ярдәмең кирәк, бөек хан.

– Нинди ярдәм, ничек сиңа булыша алам?

– Миңа озак вакыт Урдада булырга туры килде, бөек хан. – Михаил кенәз бүлмәдәге әмирләргә күз салды. Алар арасында Михаилга сыену урыны, шактый кыйммәт бәядән көмеш бирүчеләр бар иде. Ләкин бу хакта ул ханга берни дә әйтмәде. Бирегә эләгү өчен Исабәк нәибкә ришвәт төртүен дә белдерми калдырды. – Ул арада Мәскәү кенәзе Юрий миңа каршы фетнә күтәргән. Новгородта элек-электән минем кешеләр күзәтчелек тота иде. Юрий кенәз, Ржев кенәзе Фёдор белән әшнәлеккә кереп, минем кешеләрне кулга алган. Новгород җирләрен үзенеке дип игълан иткән. Алай гына да түгел, Фёдор, гаскәр җыеп, минем Тверь җирләренә бәреп кергән, халыкны талаган, бик күп җәбер-золым алып килгән. Улым Дмитрий гына әлеге канкоешны туктата алган. Әмма Тверь биләмәләренә зур зыян салынды. Урдага китәсе Новгород маллары исә Фёдор белән Юрий кулына керде. Ярлык белән бергә Юрийны акылга утыртырга ризалык сорыйм.

Үзбәкнең кәефе китте, кашлары җыерылды. Ул Исабәккә борылды.

– Юрий кенәзнең золымы хакында ник миңа бер сүз дә әйтмәдегез?! – диде ул усал тавыш белән. Исабәк дәшмичә башын түбән иде. Үзбәк торып басты. – Хан әмерен тыңлагыз! Мәскәү кенәзе Юрий, үзенең астыртын гамәлләрен аңлатыр өчен кичекмәстән минем каршыма килеп җитсен! Михаил кенәзгә ярлык бирергә боерам! Новгород җирләренә ул хуҗа булсын! Моңарчы аның акыллы идарәсе казнабызга шактый керем бирде, алга таба әлеге керемнең күләме арттырылсын! Сәргаскәр Тайтимер! – Сәргаскәр, урыныннан сикереп торып, башын түбән иде. – Гаскәр җыеп, Михаил кенәзне озата чыгарсың. Новгород җирләрендә тәртип урнаштыруда катнашып, гаепленләрнең башын кисәргә әмер бирәм!

Тайтимер ханның әмерен җиренә җиткереп үтәде – Михаил кенәз дружиначыларына кушылып, Урда нүкәрләре рус олысында кан елгалары агызды. Сарай базары ул яклардан куып китерелгән коллар белән шыплап тулды. Урдага кичекмәстән чакыртылган Мәскәү кенәзе Юрий исә ике ел буе хан белән очраша алмады. Бәлки, бу хәерлегә дә булгандыр – ул ара эчендә Үзбәкнең дә ачуы сүрелгәндер, шуңа ул вакытның озакка китүенә шатланырга гына тиеш иде. Хәзергә исә Юрий Сарайда яшәде, андагы чиркәүгә йөрде, Мәскәү тәхетендә исә бертуган энекәше Иван утырып калды...

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Язга чыгу белән Сарай халкы далага кузгалды. Әйтерсең, бөтен дөнья берьюлы урыныннан купкан, җигүле арбаларның, аларга урнаштырылган тирмәләрнең саны исәпсез. Башка еллардан аермалы буларак, бер тирмәнең түбәсендә ярымай ялтырый – анысы ханның юлда гыйбадәт кыла торган мәчете.

Утрак тормышка ничек кенә кызыкмасын, күчмә гадәтләрдән барыбер арына алмады Үзбәк. Бер җирдә таптану күңеленә ятмады, бигрәк тә көннәр җылытып, кояш кыздыра башлагач. Кайчандыр яшьлеге шаулап үткән Кавказ тауларын күрү теләге дә зур иде.

Юлга чыгар алдыннан ул бәкләр-бәге Котлы Тимер белән саубуллашты – ышанычлы киңәшчесенең инде күптән туган җире Хәрәземдә булганы юк, эшләре дә күп җыелган, сагыну хисләре дә күңелендә ташып тора. Котлы Тимер белән бергә Үзбәк улы Тимербәкне дә Хәрәземгә озатты. Тимербәк, бераз үсә төшкәч, кайчандыр хан идарә иткән Яңа шәһәргә барып, үзенең хуҗалык эшләрендәге осталыгын күрсәтергә тиеш иде. Бердәнбер улына хакимлек серләренә төшенә башларга вакыт.

Ногъманетдин әл-Хәрәзми имам Сарайда калды. Ул, ерак юлга чыгудан баш тартып, мәчеттә гыйбадәт кылуны хуп күрде.

Хан кәрваны Сарайдан кузгалып китте. Ашыкмый гына хәрәкәт итеп, тулы бер шәһәр сыйган бу олы төркем Бештау итәгенә юнәлде...

Гадәттәгечә, кәрван дала буйлап дистәләрчә чакрымга сузылды. Киңлеге белән офыкны иңләсә, алдагы олаулар арттагыларыннан берничә көнлек юлны үтәргә өлгергән. Биредә ханның ышанычлы нүкәрләре, гаиләсе, җарияләре, бавырчылары, яраннары. Кәрванның нәкъ уртасында хан тирмәсе. Ул йөз егерме үгез җигелгән киң арбага күтәртелгән. Арбаның көпчәкләре ике кеше буеннан да югарырак. Тирмәгә, кирәк-ярак булса, арбаны туктатмый гына менеп-төшеп йөриләр, чөнки үгезләр беркая да ашыкмый, салмак кына атлый бирәләр. Янәшәдә кечерәк тирмәләр хәрәкәт итә. Күчмә мәчеттән биш вакыт азан тавышы ишетелә, җомга көннәрендә Үзбәк үзе дә җәмәгать белән анда кереп намаз укый.

Дәүләт эшләрен хәл итү юлда да туктатылмый. Хан диван утырышларын үткәрә, карарларын чыгара. Аларны шунда ук чапкыннар киң дәүләтнең төрле почмакларына җиткерергә ашыга. Үзбәк кабул итәргә өлгермәгән, йә вакыт тапмаган илчеләр дә кәрванга ияргән. Аларына хан җәйләвенә барыр өчен тәхет тирәсендәге әмирләрнең күңеленә ачкыч табарга туры килә. Ә ул ачкыч – чылтырап торган көмеш тәңкәләр. Хәйләкәр аксөякләр ханга гозер белән килгән кешеләргә тәхет янына юл ачу өчен шактый югары бәя куялар иде. Икенче елын Сарайда Үзбәк хозурына эләгә алмый интеккән Мәскәү кенәзе Юрий да шулар исәбенә керде...

Кәрван, ашыкмый, гүзәл табигать почмакларында тукталышлар ясый-ясый, Бештау итәгенә килеп җитте.

Искиткеч матур җир иде бу. Уң якта артык биек булмаса да, биш биек кыясы белән офыкны кискәләп үткән мәгърур Бештау. Аның бер өлеше яшеллеккә күмелгән, икенче җирләрендә коңгырт, кызгылт ташлы урыннары ачылган. Тау итәгенең төрле урыннарыннан шифалы чишмәләр бәреп чыккан,

аларның тешне сындырырлык салкыны да, җанны тынычландырырлык җылысы да бар. Кайсы тозлы, кайсы татлы. Таулардан ары исә киң уйсулык җәйрәп ята. Биредә елга-күлләр дә, агачлык-болыннар да бар. Сул кул якта түбәләре мәңге эремәс кар белән капланган уйчан картлач Эльбрус...

Хан станы шушында урын алды.

Кәрван киң болын уртасында тукталды. Үзбәк хан арбада йөртелә торган тирмәдә юлда чакта гына яшәсә, биредә, дәүләт эшләрен алып бару, чит җирләрдән килгән илчеләрне кабул итү өчен төп тирмә корылды. Аны Үзбәк хан теләгәнчә ясадылар.

Тирмә купшылыгы һәм матурлыгы белән Сарай халкын да шаккатырды. Тыштан карап торышка ук аның биш йөздән артык кешене эһ тә итми сыйдыра алуын чамаларга мөмкин иде. Тирмәнең терәкләре булган баганалар алтын белән тышланган. Бусага шулай ук алтыннан – аңа ялгыш баскан кешене үлем көтә. Тирмә киездән эшләнсә дә, эчке һәм тышкы яктан алтын җепләр белән чуарланган ефәк тукымаларга төрелгән. Түбәсе исә алтынга манылган тоташ ефәктән корылган.

Хан тирмәсенең үзәгенә тәхет урнаштырылды. Анысы да әле яңа гына эшләнеп беткән иде. Тәхет берничә кешене утыртырлык зурлыкта, аның аяклары көмеш, култыксаларына алтын да өстәлгән, аркалыгына затлы ташлар сибелгән.

Кояш нурларында балкып торган тирмә янәшәсенә биек колга күтәрелде. Аның очында Урда әләме җилферди башлады.

Хан тирмәсе тирәсенә калганнары да урнашты. Алардан урамнар, мәйданнар барлыкка килде. Арбаларны стан тирәли тезеп чыктылар – әйтерсең, алардан шәһәр кирмәне оешты. Чыннан да, берникадәр ара ераклыгында аларда сакчылар урын алган, стан, нүкәрләрнең ышанычлы күзәтүе астында, тыныч йоклый ала иде...

Әллә Бештау итәге, аның шифалы суы һәм һавасы күңеленә дәва булды, әллә һәр почмагы үлем хатирәләре белән бәйле Сарайдан китеп бару ярдәм итте – Үзбәк хан бер төнне үз янына беренче хатыны Нәзифәне чакыртты.

Нәзифә аның тарафына оялып, башын түбән иеп керде. Бу күренештән Үзбәкнең күңеле тулды, риясыз хатынын рәнҗеткәнен аңлаудан йөрәге кысылды. Ул, үзе урыныннан торып, аңа таба атлады, ике як иңеннән тотып, озак кына карап торды.

– Күзләреңне миңа күтәр, Нәзифә, – диде ул, хатынының калтырануын тоеп. Хатыны дымланган күзләрен ханга күтәрде. – Мин сине нык сагындым, Нәзифәм! Әгәр кызулыгым белән каты бәрелгән булсам, ачуланма миңа. Соңгы вакытта авыр булды, синең монда бер генә гаебең дә юк!

– Мин дә сине сагындым, сөекле ханым, – дип пышылдады Нәзифә һәм иреннәре белән Үзбәккә үрелде.

Озак күрешми тору файдага булган дияргә дә мөмкин – алар янә икәү тәүге зөфаф киче хисләрен искә төшерделәр. Әйтерсең, бу – ике ярның Кавказ таулары арасында моннан егерме ел элек үткәргән беренче кавышулары...

– Мин сине мәңге яратачакмын, Нәзифә, – диде Үзбәк, хатынын озатыр алдыннан. – Бер нәрсәне белеп яшә – син тәхет варисының әнисе, дәүләтебездә дә, минем янәшәмдә дә урының түрдә булыр!

Тик Нәзифә бу сүзләргә шатланмады, киресенчә, куркып калды шикелле.

– Бөек ханым, хәзер әйтелгәнне икебез генә белеп торсак хәерлерәк булыр. Варис дип игълан ителгән кеше кыл өстендә йөрүчегә әверелә бит... – Нәзифә, Үзбәккә күз ташлагач та, янә тегенең күңеленә ошамаган фикер белдерүен аңлады. Ханның карашында ачу уты кабынган иде. Сүзне икенчегә борырга маташып, хатын иренә елышты. – Минем варисның әтисе түгел, ә бөек ханның яраткан хатыны буласым килә. Синең янәшәңдә генә мин үземне иминлектә хис итәм, күңелем тынычлана. Зинһар, үзеңнән этәрмә мине...

Тик ханның күңеле суынган иде инде. Ул, Нәзифәдән читләшеп, урыннан торып басты һәм хатыны белән коры гына саубуллашты...

Икенче көнне хан тәхет кырына Баялун хатынны чакыртты. Тирмәдә чит-ят кеше юк, алар икәү генә очраштылар. Ара-тирә бавырчылар гына кергәләп, сый-нигъмәтләрне, кымызны яңарта торды.

– Бөек ханым, мине табыныңа чакыруың мескен хезмәтчең өчен зур шатлык, – диде Баялун хатын. Үзбәк бу сүзләрдә киная күрсә дә, сүзне артык куертмады.

– Гафу ит, Баялун хатын, соңгы вакытта эшләрем бик тыгыз булды, синең белән рәхәтләнеп сөйләшеп утырырга җай чыкмады. Сорауларың шактый җыелгандыр, мин барысын да дикъкать белән тыңларга әзермен.

– Әллә ни күп сорауларым юк, сөеклы ханым. Синең өчен борчылудан тыш, гаиләң иминлеге сагында торам. Аларга да синең игътибарың кимеде, һаман дәүләт дип кенә чабасың...

– Гаиләмдә тәртип кебек... – Үзбәк Баялун хатынга сынаулы караш ташлады. – Баялун хатын, әйләнеп-тугланып йөрмә, әгәр минем якыннарым арасында берәр төрле низаг килеп чыккан икән, турысын әйт. Син – ханга ачы хакыйкатьне дә курыкмый белдерергә хакы булган сирәк кешеләрнең берсе.

– Низаг турында сүз бармый, бер дә борчылма, – диде Баялун, бавырчының тирмәдән чыгып китүен көтеп, беравык дәшми торганнан соң. – Синең сеңелкәшең Көнчәага борчый мине. Ул яшьли ятим калды, әниегез Әрибах хатын вафатын бик авыр кичерде. Бөек хан сеңлесе булу авыр вазифа ул. Үз тиңен табып, кияүгә чыгарга күптән вакыт инде аңа. Аңлашыла ки, ире аксөякләр нәселеннән булырга тиеш. Ә ул, әнә, синең меңбашы Каугадый белән җылы мөнәсәбәттә икән...

Үзбәк имәнеп китте. Аның борыны астында сеңлесе нииндидер меңбашы белән гыйшык уены оештырганмыни?! Әллә инде бу Баялун хатынның берәр төрле мәкере генәме?

– Син белештереп сөйлисеңме, Баялун хатын?!

– Баялун хатын белмичә сөйләми, бөек ханым. – Учакка тагын бераз утын өстәргә җыенса да, Баялун Үзбәкнең шартларга җитүен сизенеп, аны тынычландырырга ашыкты. – Тик син бер дә борчылма, беркем дә куркыныч гамәлләр кылмаган. Яшьләр бер-берсенә җылы мөнәсәбәтен сүздә генә күрсәтә, анысы да кеше алдында түгел.

– Сиңа килеп җиткән бит! Димәк, башкалар да почмакларда пышылдаша!

– Баялун хатын һәрвакыт кирәгеннән күбрәк белеп тора, бөек ханым. Син алай кызма әле, минем Көнчәаганы дә, Каугадыйны да яманлыйсым

килми. Киресенчә, Көнчәаганың ирсез йөрүенә без гаепле. Гаиләдә олы кешеләр буларак, аңа тиң яр табу – безнең бурыч. Алар исә бер генә дә кырын гамәл кылмады...

– Әллә ниләр уйларга мәҗбүр иттең, Баялун хатын, – диде Үзбәк, бераз тынычлана төшеп. – Сине нәрсә, Каугадый минем яныма Көнчәаганы ярәшергә җибәрдеме әллә? Калымы җитмәс, юк эш белән йөрисең.

– Юк, минем Каугадый белән әшнәлеккә керү уемда да юк. Ләкин Көнчәаганы урнаштыру хакында кайбер фикерләрем бар.

– Йә, әйтеп кара, дикъкать белән тыңлыйм...

– Мәскәү кенәзе Юрий... Ул яшь-яшь, ләкин тол калган. Мәскәүдә бер кызы гына бар. Бәлки...

Үзбәк сикереп үк торды.

– Син нәрсә, Баялун, безнең ыру эшләре белән дәүләтнекен бутарга йөрисеңме? Нинди Юрий?! Алар христиан бит! Урда ханының сеңлесен безнең баскаклыктагы кенәзгә хатынлыкка җибәрергә җыендыңмы?! Әллә акылдан шаштыңмы?!

Баялун хатын, бик тыныч халәттә, дәрәҗәсен белеп кенә торып басты, ханга чак кына башын иде.

– Бөек ханым, синең ачуыңны чыгарырга теләмәгән идем, гафу ит. Тик мин бу тәкъдимне хатын-кыз буларак та, хан ыруы әгъзасы фикереннән чыгып та бик ипләп уйладым. Син дә ашыкмый гына, барысын да бизмәнгә салып кара. Бәлки, әлеге никахтан Урдага файда килер? Баскаклыктагы рус кенәзлеге безнең казнаның шактый өлешен тутырып тора. Ул җирләрдә фикердәшебез булу отышлы гына кебек. Хәер, барысы да бөек хан кулында. Ә хәзер мескен колыңа китәргә рөхсәт ит.

– Китә аласың, Баялун хатын, – диде Үзбәк, тәрбиячесе булган кешегә кычкырып ташлавына оялып.

Башын горур югары күтәргән хәлдә Баялун хатын тирмәдән чыгып китте. Баялунның ханга үпкәсе дә, аның ачуыннан куркуы да юк иде. Холкын белә инде ул аның. Тузына да, аннан соң тынычлана. Иң мөһиме, митрополит Пётрның гозерен үти алды. Юрийны хан озакламый һичшиксез кабул итәчәк. Ә инде кенәз хан сеңлесенә өйләнгәч, рус олысына карата Үзбәкнең мөнәсәбәте үзгәрергә тиеш. Дәүләтен ныгыту белән тешләнеп яткан хаким сеңлесенең Мәскәүгә килен булып баруының файдасын аңлар.

Баялун хатын ялгышмады – Үзбәкнең күңеленә аның тәкъдиме бик ныклап кереп утырды. Баялун юләр түгел, урынсыз фикер әйтмәс. Чыннан да, Көнчәаганы Мәскәү Юриена кияүгә биреп куйсаң? Бәхәссез, сеңлесенә беренче эш итеп православ динен кабул итәсе була. Анысы авыр түгел. Ә Урда, Үзбәк нәрсә отачак? Көнчәаганың Юрийдан туган балаларында ике кан катнашачак. Шул исәптән Урда ханнары каны. Ул балаларга дөрес тәрбия бирсәң, рус халкы да кабул итәрлек, шул ук вакытта канында һәм җанында Урдага тугрылык яшәгән егетләр үстерергә мөмкин. Алар, үсә төшкәч, акрынлап, кануни рәвештә рус кенәзлекләренә хуҗа булыр иде. Ярлык бирүче ул – Үзбәк бит. Рус җирләрен бернинди канкоешсыз Урда дәүләтенең аерылгысыз өлеше итәргә мөмкин. Ул җирләрдәге кенәзләрнең бертуктаусыз чәкәләшеп торуына чик куела. Үзбәк, Баялун хатынның зирәклегенә янә бер кат сокланып, башында туып килгән хыялларга һәм татлы йокыга чумды...

Икенче көнне хан тирмәсенә рус кенәзе Юрийны чакыртырга боерды. Тегесе Урда хакиме белән очрашу болай капылт кына килеп чыгар дип уйламаган, бик кабаланып җыенды. Елдан артык саклап тоткан бүләкләре белән бусаганы атлап кергәндә, чак кына мәтәлеп китмәде. Җитмәсә, ислам динен кабул иттек дип шапырынсалар да, хан тирәлегендә тәңречелектән калган тәртипләрне саклый бирделәр. Юрийга озын чапан кидереп, ике ут арасыннан чыгардылар – имештер, явыз ниятле кеше янып көлгә әверелә, яхшы бәндә исән калырга тиеш. Тирмә катына килгәч тә, як-яклап бусагага басмаска, атлап кына чыгарга өндәделәр. Белә инде Юрий ул тәртипне. Бусагага аяк тидергән кешене шунда ук суеп ташлыйлар...

Ханга бүләкләрен китергәч, Юрий аның йөзендә җылылык көткән иде, ялгышкан булып чыкты. Үзбәк күз дә салмады. Йокымсыраган кыяфәт белән кенәзнең мактау сүзләрен тыңлады, әйтерсең, янәшәсендә чебен безелди...

– Сөйлә, ник Тверь кенәзе Михаилның яраннарын Новгородтан куып чыгардың? – дип сорады, ниһаять, Үзбәк хан, тез чүккән килеш калтыранып торган Юрийга явыз карашын юнәлтеп.

– Бөек хан, минем эш түгел, Ржев кенәзе Фёдор барды анда.

– Фёдорны син котырткансың. Мине алдамакчы буласың, ахры. Яман эшне Фёдор башкарган, ә аның артында юл күрсәтеп торучы – син. Шактый гына гаскәр дә биргәнсең.

– Бөек хан, син беләсең бит, Новгородта Михаилның яраннары утыра. Алар, халыкны нык талап, ачуын чыгарган. Боярлар, ярдәм сорап миңа мөрәҗәгать итте. «Кил, зинһар, Юрий кенәз, безне үз яклавыңа ал, юкса Михаил талап иза чиктерә», – диделәр. Мин килешмәдем. Шуннан Фёдорга барганнар. Дружиначылар мәсьәләсендә... Әйе, яшермим, бирдем шунда бераз...

– Бераз гынамы? Бераз булса, Фёдор Тверь җирләрен тар-мар итә алмас иде. Синең сугышчылар күп булганга җиңгәннәр.

– Бөек хан, син рөхсәт итсәң, мин бер әйбер әйтәм. Әгәр Новгород җирләре Мәскәүгә тапшырылса, бернинди гауга да чыкмас иде. Михаил аларны кычкыртып талый, синең исем белән яный. Имештер, Урда ханы комсыз, һаман да мал сорый, ди. Ә ул малны үз сандыкларына тутыра. Мин алай итмәс идем, сиңа да җитәрлек ясак җыеп, Новгород халкын да бөлгенлеккә төшермәс идем...

– Мәскәүне кемгә калдырдың?

– Энекәшемә...

– Ни атлы ул?

– Иван.

– Тагын кемең бар?

– Кызым...

– Хатының кая киткән?

– Мәрхүмә ул... – Юрий мышкылдап куйды. – Билгесез зәхмәт килгән иде, Мәскәүдә шактый халык кырылды... Хатынымны саклап кала алмадым.

Үзбәк янә күзләрен йомды.

– Син китә аласың, Мәскәү кенәзе Юрий, – диде ул.

– Кайтып укмы?

– Кайтырсың әле, ашыкма. Хан үз сүзен әйтмәде...

Юрий, ханга арты белән борылмаска тырышып, ишеккә таба юнәлде.

Үзбәк янәшәсендәге Исабәккә карады да:

– Исабәк нәиб, иртәгә зур ау оештыр. Берничә көнгә таулар ягына китәрбез. Минем дә бөтен ыруым барсын. Кичтән кузгалырбыз. – Хан, киңәшмә тәмам булуына ишарәләп, урыныннан торды, аннан, кинәт искә төшереп, Исабәккә янә сүз катты: – Оныта да язганмын. Безнең белән бергә ауга меңбашы Каугадый да чыксын. Минем гаиләне саклауны аңа йөкләгез.

– Баш өсте, бөек ханым, – диде Исабәк, хакимне иелә төшеп озатып калып.

Ханның якыннары белән ауга китүен стан кызыксынып озатып калды. Әле беркайчан да аларның мондый галәмәтне күргәннәре юк иде. Ауга, гадәттә, ирләр генә йөрсә, бу юлы хатыннар да иярде. Аларның яшьрәкләре атларга ук атланган, олылары исә арбаларга утырганнар. Аеруча игътибарлылар бу төркемдә меңгә якын кешене санады.

Үзбәк ханның уенда ау кайгысы түгел иде. Ул кара атка атланган төз гәүдәле сеңлесе Көнчәага белән сокланырлык баһадир Каугадыйны игътибар белән күзәтте. Бер-берсенә карашып елмаешкан чаклары бар. Хәтта, җаен табып, атларын янәшә атлатып, нидер сөйләшәләр дә. Димәк, Баялун хатынның шымчылары ялгышмаган. Хәер, шымчы да кирәкми, болар тәмам бер-берсенә берегеп баралар. Үзбәк хан моны да үз максатларында кулланырга карар кылды...

Уңышлы аудан соң оештырылган киң мәҗлес тәмам булгач, һәммәсе үз тирмәләренә таралышты. Үзбәк хан Баялун хатынны гына үз янында калдырды. Әлегә аларның ниятен хәтта иң ышанычлы кеше дип саналган Исабәк тә белергә тиеш түгел иде.

– Син хаклы икән, Баялун хатын, – диде Үзбәк, тирмәдән һәммә кеше дә чыгып киткәч. – Көнчәага белән Каугадый, хан каршында да тартынмый, сайрашыпмы-сайрашалар.

Баялун җавап кайтармады.

– Көнчәаганың православ динен кабул итәсе була, моңа килешерме?

– Килешмәгән кешеләргә ханның хөкеме бер, сөекле хакимем...

– Бу очракта сүз хөкем турында түгел. Көнчәага – минем бертуган сеңлем, без бергәләшеп, күп газап аша үттек. Син, аның белән сөйләшеп, үзен безнең ниятебезгә күндерергә тиеш.

– Рөхсәтең булу белән сөйләшәм, бөек ханым.

– Безнең тәртипләрне беләсең. Мин сеңлемне хатынлыкка тәкъдим итә алмыйм. Аны Юрий кенәз ярәшеп алырга тиеш. Калым түләп.

– Бусы өчен дә борчылма, мин барысын да оештырырмын, бөек ханым.

Үзбәк хан елмаеп куйды.

– Рус җирләрен белеп булмый, анда төрле кеше яши, – диде ул, серле күзләре белән Баялун хатынга карап. – Сеңлемә зыян килмәсен өчен саклаучысы һәм яклаучысы итеп, меңбашы Каугадыйны ияртеп җибәрергә телим.

Күпме мәкер күргән Баялун хатын да бу кадәресен көтмәгән иде. Ләкин, атлаган саен каршы төшеп, ханның кәефен җибәрергә ярамый.

– Ханның хөкеме билгеле дигән идем бит, сөекле хакимем. Яратышкан йөрәкләр өчен моннан да кырысрагы булырга да мөмкин түгел. Ихтыярың,

барысы да синең кулыңда... – Баялун хатын сөйләшүне дәвам итәргәме-юкмы дип уйланып торды да бер карарга килде. – Үзеңнең йөрәгеңдә нинди давыллар уйный, сөекле ханым? Йөзеңдә нур юк, хәрәмдәге җарияләр эшсез интегәләр...

– Җарияләрдән туйдым, көн саен сарык ите ашап булмый икән, – диде Үзбәк, ачылып китеп. – Араларында атланып чабарлык бер генә юньле бия юк.

– Минем гаеп, сөекле ханым, гафу итә күр...

– Бәлки, миндә дә бардыр анысы...

– Озакламый мин бөек ханга тиң бия табачакмын. – Баялун хатын, үзенең янәшәсендә буйга җитеп үскән, киребеткән холыклы Тайдуланы күз алдына китерде дә ихтыярсыз елмаеп куйды. – Ләкин иярли алырсыңмы икән?

– Борчылма, Баялун хатын, сине иярли алган ир-атлар нәселеннән бит мин, – дип кайтарып шаяртты Үзбәк хан. Мондый ачыктан-ачык сөйләшү алар арасында күптән булганы юк, ихлас әңгәмәне сагынган икән ул. Чама белән эчелгән хәмер дә сиздерә, күңеле нечкәрде. – Син миңа ачуланма инде, Баялун хатын. Бишектә тирбәтеп үстергән балаң игелекләреңне онытмады. Тик тәхет кырысландыра икән...

– Хакимнең язмышы шундый була, бөек ханым.

– Хакимнең язмышы – ялгызлык...

– Борчылма, син ялгыз калмассың. Көннәреңә җылылык, төннәреңә яктылык иңдергән кешене табып бирермен.

**2**

Аудан кайтып, берничә көн үтмәде, Үзбәк хан әвнухы Мостафаны чакырды.

– Мостафа, бәлки, синең җарияләрең арасында мин назлап та, кайчан күрешкәнебезне дә онытып бетергән берәр җен пәрие бардыр? – дип сорады ул ишек катында бөгелеп төшкән хезмәтчесеннән.

– Бөек ханым, минем хәрәмемдә әле син татып та карамаган хур кызы, саргаеп, хакиме белән тәүге очрашуын көтә, – диде Мостафа хатыннарныкына тартым нәзек тавыш белән.

– Анысы кем тагын? Кайдан китерелгән кол?

– Миңа анысы караңгы, сөекле хакимем, ул назлыбикәне миңа зирәк һәм юмарт Баялун хатын китерде, бөек ханыбыз өчен күчтәнәч диде.

– Кызык. Исеме ничек, кай яклардан?

– Кайлардан икәнлеген белмим, әйтми. Бик киребеткән, асылларның асылы Баялун хатыннан бер дә ким түгел. – Мостафа үзен кешегә дә санамауларын һәм әйткән сүзләренә әллә ни игътибар бирмәүләрен белгәнгә, ни әйтәсен әллә ни уйлап тормый иде. Бары тик ханнан гына көләргә ярамый, калганнарын теләсә ничек әвәләргә рөхсәт. – Сөйләшүләре тырт та пырт, ханбикә булган, диярсең. Ләкин, сөекле ханым, сез аны күрсәгез! – Әвнух кинәт җанланып китте, тураеп ук басты, куллары белән кызның сыннарын тасвирлый башлады. – Ул нечкә билләре, чем-кара чәчләре, көлгә калдыра торган карашы, ә бәдәннәре, бәдәннәре...

– Йә, чү, тпру! Кая чаптырдың, тәмуг кисәве?! Алай шәп булгач, ник яшереп ятасың?

Мостафа янә бөкшәеп төште:

– Чакырмадың, ханым. Көн дә әйтим дип йөрим, син дәшмисең...

– Баялун хатын бүләге, димәк? Ни атлы икәнлегең әйтәсеңме-юкмы, дөя тигәнәге?!

– Гафу, бөек ханым. Исеме – Тайдула. Бик каты киребеткән һәм усал. – Мостафа күзләрен ханга күтәрергә җөрьәт итте. – Сау-сәламәт, сине генә көтә, пешкән җиләк төсле. Бүген өзмәсәң, иртәгә корт кимерә башлар...

– Тиз сытып чыгарырмын ул кортларны... Беркем дә кагылмаган, димәк?

– Тикшердек. Тимәгәннәр, бар яктан да сау-сәламәт.

– Китер бирегә! Үзең күземнән югал! Юкса, авызың ачылган саен тирмәм ныграк сасый!

Мостафа әвнух тизрәк чыгып китү ягын карады.

Тайдула, чыннан да, һушны җибәрерлек иде. Аны күргәч, Үзбәк телсез калды. Моңарчы кочагына кергән киң сөякле хатыннардан аермалы, бусы бигрәк тә нәзберек, кагылсаң, уалып китәр төсле. Чем-кара озын толымнары биленә кадәр төшкән. Күкрәкләре йомры, өстенә бөркәнгән япмасы астыннан да түгәрәкләнеп шәйләнеп торалар.

Хан бу могҗизага берара шаккатып карап торды, аннан, тамагын кырып, кызны үз тарафына чакырды.

– Бире кил, курыкма...

Кыз, ялан аякларына кыяр-кыймас басып, ханга таба атлады, башын күтәреп карамады. Янына ук килеп баскач, Үзбәкне аның тәненнән килгән хуш ис әсир итте. Ул, бер бармагы белән сак кына иягеннән тотып, кызның карашын үзенә таба күтәрде.

– Исемең ничек синең, чибәркәй?

Кызның күзләре зур һәм төпсез иде. Анда бер мизгелдә олы сагыш та, курку да, хәтта нәфрәт тә күренеп китте. Күренде дә юк булды. Упкын гына калды. Үзбәк шул упкынга очып төшүен сизмәде дә.

– Тайдула...

– Мин Үзбәк булам. Урман кызымы син?

– Дала кызы мин, бөек ханым. – Тайдула беренче шәпкә үзен ялмап алган курку хисен җиңде кебек.

– Ә мин дала хакиме.

Үзбәк, кызның кулын учына алып, җиләк-җимеш, ширбәт-шәраб куелган табынга әйдәде. Тик кыз бер генә сыйга да кагылмады, уңайсызланып утыра бирде.

– Әллә син миннән куркасыңмы, ай кызы? – Үзбәк соңгы вакытта кырыс сүзләргә генә күнеккән теленә наз һәм җылылык өстәргә, матур сүзләр табарга маташты. Ул нигәдер беренче тапкыр хатын-кыз заты белән очрашкан яшь егет хәлендә калды.

– Синнән бөтен дөнья курка, бөек хан...

– Бөтен дөньяга шул кирәк, тик мин сине кыерсытмам.

– Зур рәхмәт сиңа, сөекле ханым...

– Шөкер, сөекле дә булдым! – Үзбәк елмаеп җибәрде. Аннары аның куллары кызның кайнар тәненә үрелде. Ул иреннәре белән башта Тайдуланың муенына кагылды, аннан соң түбәнрәк төште. Башы әйләнә, дөньясының асты өскә килә. Сихерләнгән төсле, бөек дәүләт хакиме хатын-кызның гасырлар буе сынатмаган әсирлек богауларына кереп чумды...

Хан күңелендә дөрләп кабынган учак җылысын аның тирәсендәгеләр дә тойды. Үзбәк тынычлана төште, яраннарына карата йомшарды, йөзендә, ниһаять, елмаю күренә башлады. Моның Тайдула белән бәйле икәнлеге беркемгә дә сер түгел – хәрәмгә яңа гына кергән кыз һәр кич саен хан тарафына чакырыла торды, аннан ул таң аткач кына чыга иде.

Баялун хатын Тайдулага киңәшләрен бирде, төрле хәлләрдә үзен ничек тотарга, нәрсә әйтергә, ни турында дәшми калырга кирәклеген өйрәтте. Икенче яктан, ул Мәскәү кенәзе Юрийны да эшкәртә торды. Юрий баштарак Көнчәагага өйләнүне юләрлек сыман кабул итсә, Баялунның татлы сайравына биреште. Үзбәк белән туганлашу, чыннан да, Мәскәү кенәзлегенә күтәрелергә булышачак. Көнчәаганы гына әллә ни өнәп бетермәде – Юрий хатын-кыз матурлыгын башкачарак күз алдына китерә иде. Ләкин хакимлек хакына ни генә эшләмәссең?!

**3**

Җәйләүдән Сарайга кайткач та, Үзбәк хан, беренче эш итеп, Котлы Тимер озатуында яңа кала төзелешенә юл тотты. Актүбәнең биек сул як ярында эш кайный иде. Хан инде кайбер биналарның акрынлап калкып чыгуын сокланып күзәтте. Урамнар юнәлеше, киң мәйданнар да абайлана. Кайбер корылмалар таштан, икенчеләре агачтан күтәрелә. Купшы сарайлар башлыча шәһәр үзәгенә урнашкан. Аларга затлы ташларны көймәләр белән алып киләләр, алны-ялны белмәгән коллар бу йөкләрне ярдан өскә күтәрә.

Үзе өчен махсус корылган тирмәгә кергәч, Үзбәк хан төзелеш башлыкларын чакыртты. Таш биналар өчен Кытайдан яллап китерелгән Чан Ши галиҗәнаплары, агачларына Болгардан чакыртылган балта остасы Алмыш карт җаваплы иде. Үзбәк аларның хисапларын игътибар белән тыңлады, бүлдереп, тылмач аша төзәтмәләр кертте, күрсәтмәләр бирде. Хан биредәге хезмәттән канәгать иде.

– Шәһәрнең тышкы диварларын таштан күтәрәбезме, әллә агачтанмы, бөек хан? – дип сорады баштанаяк кызыл киемнәргә төренгән Чан Ши.

– Нинди диварлар? Минем шәһәремдә диварлар булмаячак!

Кытай белгеченең гаҗәпләнүдән күзләре дә түгәрәкләнде төсле.

– Ничек инде, диварсыз башкаланы дошманнар талар бит...

– Әлегә җир йөзендә Урда дәүләтен таларлык дошман юк, – дип кырт кисте Үзбәк хан. – Син, Кытай остасы, кушканны эшлә, кушмаганга тыгылма. Безнең өчен кадерле кунак син, чөнки сине яллау Урда казнасына бик кыйммәткә төшә...

Чан Ши хәйләле күзләре белән ихлас елмайды, кыска һәм сирәк сакалын сыпырып куйды.

– Сарай әл-Җәдиднең йөрәге һәм үзәге – минем хансараем Алтынташ булырга тиеш. Ул матурлыгы һәм затлылыгы белән һәркемне таң калдырсын.

– Кызганыч, бөек ханым, Кавказ тауларыннан китерелгән ташлар синең сараеңа андый ук купшылыкны бирә алмый... – Чан Ши гафу үтенгән сыман ике кулын ияк астына куеп, чак кына бөгелде.

– Әйбәт ташлар кайда соң?

– Мисыр якларында бар, бөек хан. Тик аннан кадәр китертү кыйммәткә дә төшәр, вакытны да күп алыр.

– Мин беркая да ашыкмыйм, вакытым күп.Ниндирәк ташлар кирәген яраннарыма аңлатырсың, Мисыр солтаны үтенечемне аяк астында калдырмас.

– Яхшы, бөек ханым. Ләкин бу төзелеш тәмамлану вакытын озайтачак, мин дә озаграк вакытка кадерле кунак булып калырга мәҗбүрмен инде, – дип янә хәйләкәр елмайды Чан Ши.

– Әҗерен алырсың, борчылма. Алтынташ каршында үзәк мәйдан ясагыз. Җәмигъ мәчетендәге бәйрәм намазларыннан соң йөзләрчә мең кешегә табын корып, яугирләр арасында бәйгеләр үткәрерлек зурлыкта. Мәчеттән ерак түгел мәдрәсә урнаштырыгыз. Мәдрәсәнең читтән чакырылган мөгаллимнәр яшәр өчен аерым биналары булсын. Үзәк мәйданга шулай ук китапханә дә терәлеп торырга тиеш – аны Сарай әл-Җәдиднең гыйлем үзәге итәргә кирәк. – Үзбәк Алмыш остага мөрәҗәгать итте. Кытай белгеченнән аермалы буларак, Болгарныкы киң сөякле, баһадирлардай нык гәүдәле, куе ак сакаллы кеше иде. – Алмыш оста, синең эшләрең ничек бара? Агач җитәрлекме, сыйфаты яхшымы?

– Агачны үзебезнең Болгар якларыннан җибәрәләр, бөек ханым. Елга буйлап агызалар, биредә салларны тотып кына алабыз. Бу эшне күпкә җиңеләйтә. Болгардан начар агач җибәрмиләр, борчылма, сөекле хакимем.

– Синең кул астындагы хезмәткәрләр булдыклымы, җитәрлекме?

– Җитәрлек тә, булдыклы да, бөек ханым.

– Мәчетләр белән беррәттән Сарай әл-Җәдидтә чиркәүләр дә торгызырга кирәк. Алары агачтан булыр. Бу эштә тәҗрибәле рус осталарын сайлап ал, Алмыш карт. Туган җирләрендә нинди – биредә дә шундый ук гыйбадәтханәләр күтәрсеннәр. Без рус диненең яклаучысы, шуңа күрә чиркәүләргә агачны кызганмагыз.

– Син дигәнчә эшләрбез, бөек ханым.

– Кытай белгече, шәһәр халкын су белән ничек тәэмин итәрбез? Чит илләрдә йөргән вакытта мин өйләргә кадәр үзе агып килүче арыкларны күрдем, бездә дә шуны корырга мөмкинме?

– Мөмкин генә түгел, ул арыклар инде төзелеп, җир астына яшерелде, бөек ханым. Эчә торган су һәрбер бинага үзлегеннән килеп торачак. Җәен җылынмый, кышын катмый торган итеп эшләдек. Юынтык сулар да үз юлы белән яшерен арыклар аша агып китәчәк.

– Алтын-көмешләремне каерып сорасаң да, башлы кеше икәнсең тагын үзең, – диде Үзбәк хан, әле генә ишетелгәннәрдән канәгать калып.

– Баш ризык чәйнәү өчен генә бирелмәгән, бөек хан. – Чан Ши рәхәтләнеп елмаеп куйды.

Төзелеш барган урында Үзбәк хан бер атна торды, һәрбер эшне җентекләп күзәтте, осталар хезмәтенең асылына төшенергә тырышты. Башкалага кайтып китәр алдыннан, ике белгечне чакырып, тагын өч елдан шәһәрне торгызып бетерергә боерды. Бик катлаулы бурыч куелса да, тегеләр кайтарып, каршы дәшмәде...

Юлга кузгалгач та, Үзбәк хан Котлы Тимер белән, озата баручылардан аерылып, алгарак китте.

– Башкала бик матур килеп чыгарга тиеш, – диде ул, эчендәге шатлыгын яшермичә.

– Бөтен дөньяга даны таралырлык кала күтәрәсең, хакимем...

– Алтынташ сараеның түбәсенә куеласы ай алтыннан булсын. Хәзер үк хәстәрен күр. Ул ай зурлыгы белән шаккатырсын.

– Чыгымнар арта, хакимем...

– Чыгымнарны санама, керемнәр турында уйла, Котлы Тимер! – Үзбәк хан бәкләр бәгенең акча мәсьәләсен кузгалтканын бик үк өнәп бетерми иде. – Үзең Хәрәзем шәһәрләрен төзегәндә, бер дә чыгым дип тормадың. Рус олысында тәртип урнаштырырга кирәк. Алардан кереме дә артыр. Тик бүген анда тынычлык юк. Мәскәү кенәзе Юрий белән Тверь Михаилы үзара сугышып ята.

– Безнең дә өлеш бар инде, бөек хан, Тайтимерне ияртеп җибәрдек бит...

Үзбәк Котлы Тимергә каты гына җикеренәсе иде дә, тыелып калды. Дөрес сүзгә җавап юк, Урда гаскәрләренең гадәтен хан яхшы белә. Сугыша да, талый да беләләр...

– Рус олысына тынычлык иңдерер өчен анда әйдәп барырдай көчле кенәз кирәк.

– Кенәзгә көчне бирүче син, бөек ханым. Тик бер нәрсәне исеңнән чыгарма – тамагы артык туйган этнең иртәме-соңмы хуҗасына ташлана торган гадәте бар.

– Михаил белән Юрий. Кайсы безгә тугры хезмәт итәр дип саныйсың? – Үзбәк хан Котлы Тимернең соңгы җөмләсен ишетмәмешкә салышты.

– Икесе дә хакимлеккә омтыла. Көнчелек утында яналар. Тверь халкы усалрак, Михаил да шуларның сыңары. Юрий исә йомшаграк. Мәскәү әле яңа гына күтәрелеп килә, Юрийның күндәмлегендә моның да йогынтысы бардыр. Ике начарның берсен сайла дисәң, мин Юрийга тукталыр идем.

– Фикереңне ишеттем, Котлы Тимер, – диде Үзбәк хан һәм алардан шактый ераkта калган гаскәриләренә борылды. – Нәрсә, сез әллә йоклап ук киттегезме?! Ханны кичектергесез эшләр көтә, атларны тизрәк юрттырыгыз!

### 4

Берәр карар кабул итсә, Үзбәк хан аны тормышка ашыруны озакка сузмый иде. Юрий белән Көнчәага мәсьәләсендә дә шулай булды. Баялун хатын аша әзерлек үткәреп, көннәрнең берендә үз тарафына Мәскәү кенәзен чакыртты. Бу киңәшмәдә Үзбәкнең бөтен гаиләсе белән бергә Көнчәага да, сәргаскәрләр арасында Каугадый да бар иде.

Юрий кенәз, башын түбән иеп, хан каршында тез чүкте, аннары гозеренә күчте:

– Бөек хан! Рус олысы – синең ышанычлы ныгытмаң, тугры хезмәте белән мәмләкәтеңә көч бирә торган җир. Синең колың Юрийга сүз катырга рөхсәт ит. Әгәр минем сүзләрем сине рәнҗетсә, кичекмәстән башымны кисә аласың. Ләкин хәзер мескен колыңның акылы түгел, йөрәге телгә килеп сөйли. Биредә яши башлаганнан бирле, үземне кая куярга белмим. Яшь егетләр төсле кайнар мәхәббәт утында янам.

Хан тирәсендәге халык тынсыз калды. Рус кенәзенең нишләве бу? Хакимгә мәхәббәт мәсьәләләре турында сөйлиләр димени?! Тик Үзбәкнең йөзендә гаҗәпләнү дә, ачу да күренмәде.

– Сөйлә, Мәскәү кенәзе Юрий.

– Бөек ханым, мин синең киявең булырга телим! – Җәмәгать «аһ!» итте. Имамның кулыннан дисбесе төшеп китте. – Сөекле сеңлең Көнчәаганы миңа хатынлыкка бирсәң, җир йөзендә миннән дә бәхетлерәк кеше, миннән дә тугрырак колың булмас!

Тынлык урнашты. Бу тамашаның ни белән бетәсен көтеп, барысы да катып калды. Үзбәк күз кырые белән генә Көнчәаганы, аннан Каугадыйны күзәтте. Сеңлесе еларга җитешкән, ул, ханга таба борылып, «юк» дип язылган кыяфәте белән җавап көтә. Каугадый исә югалып калган, тик хисләрен тышка чыгармый. Үзбәккә сеңлесе кызганыч булып китте. Ул әнисенең төсен саклаган, аның чын мәгънәсендә якын бердәнбер кешесе бит. Әмма Көнчәага үз бәхетен үзе аңламый бугай. Хан яугирләре арасындагы гади сәргаскәр урынына олы биләмәләр тоткан кенәз тәкъдим ителәә. Яши-яши барысын да аңлар. Ахыр чиктә, мәхәббәткә Үзбәк хан ышанмый. Якынлык таләп итүче көч, дәрт, ләззәт көтеп башны югалту гына бар. Анысы да озак тормый, эреп юк була.

Үзбәк урыныннан торды.

– Безнең гадәтләр буенча, сеңлем өчен, гаиләдәге иң олы кеше буларак, мин җаваплы. Төп ыруда яшәгән чорда аның язмышын минем карарым хәл итә. Икенче яктан, әгәр туганымны ярәшкәннәр икән, аңа тиң күләмдә калым да түләнергә тиеш. Син аны мин сораган кадәрле бирергә әзерме?

– Әзер, бөек хан, берсүзсез әзер.

– Алайса, хан сүзен тыңлагыз.

Үзбәк калымны санап чыгарга кереште. Көмешне мулдан, атларны табын-табын, затлы җанвар тиреләрен тау-тау атады. Хан каршына китереләсе мал күләмен ишеткән саен, Каугадыйның кәефе кырыла барды, азакта ул, гомумән, Юрийның ярәшүенә дә, яратып йөргән кызының читкә китеп баруына да битараф калды кебек.

– Калымны китергәч, сөйләшүне дәвам итәрбез, – диде Үзбәк хан. Аннан, тәхетенә утырып, бүгенгә кабул итү тәмам булуына ишарәләде. Барысы да ишеккә ашыктылар, Көнчәага гына китмәде, абыйсы тарафына юнәлде.

– Сөекле ханым, яраткан абыем, харап итә күрмә мине! – диде ул, Үзбәк каршында башын иеп.

Хан, сеңлесе янына килеп, аны кочып алды, сак кына кулыннан тотып, үз янына утыртты.

– Минем өчен теләсә нинди алтын-көмештән, атлар көтүеннән һәм башка затлы әйберләрдән кадерлерәк булган сеңлем Көнчәага! Әллә мин сиңа явызлык кылырга җыенам дип уйлыйсыңмы? Киресенчә, яхшылык кына эшләргә телим. Иң олы максатым – сине бәхетле итеп күрү. Син минем өчен мәрхүм әниебезнең төсе.

– Тик минем Мәскәү кенәзенә кияүгә чыгасым килми!

– Мәскәү кенәзе нечкә күңелле кеше, бер дә борчылма. Аның беренче хатыны авырып үлгән. Сиңа иптәш булырлык кызы бар. Ул сине кыерсытмас. Урының түрдә булыр. Руслар бер генә хатын белән яши, хәрәм дә тотмыйлар, бар ирлек җылысы сиңа гына тияр. Рус олысында иң дәрәҗәле хатын син булырсың. Балаларыгыз дөньяга килер, аларда безнең нәсел каны агачак. Мин аларны башка рус төбәкләренә кенәз итеп

билгеләрмен. Менә шулай, акрын гына без, кан коймыйча, рус олысын үзебезнеке итәрбез.

– Дәүләтебез өчен мин үз-үземне корбан итәргә тиешмени?!

Үзбәк көрсенеп куйды. Башка берәрсе булса, күптән тетмәсен тетәр иде дә, сеңлесе белән алай сөйләшә алмый ул. Шуңа күрә, чамалы сабырлыгын җыеп, Көнчәаганы үгетләвен дәвам итте.

– Дәүләт безнең гаиләгә тапшырылган икән, кая китәсең, яраткан сеңелкәшем? Безнең башка чарабыз юк. Әтиебез, әниебез бу дөньядан рәнҗетелеп, иза чигеп китеп барды. Безгә алар өчен үч аласы, хезмәтләребез һәм гамәлләребез белән рухларына дога ирештерәсе...

Көнчәага бераз тынычлана төште бугай.

– Син безгә кунакка килеп йөриячәксеңме?

Үзбәк хан ирексездән елмаеп куйды.

– Урда ханы чит җиргә барса, ул җир шул мәлне үк аның кулына күчә. Юк инде, мин сезне һәрвакыт үземдә, дәүләтебезнең теләсә кайсы почмагында кунак итеп каршыларга әзер. Рус җиренә Үзбәк ханның килеп йөрүен андагы халыкка күрергә язмасын...

Көнчәаганы озаткач та, хан авыр уйларга чумды. Күңеле тыныч түгел. Сеңлесен рәнҗетте шикелле. Карышмый да кебек, шул ук вакытта эчтән Үзбәккә үпкәле тоела. Тик хакимлекнең үз кануннары. Йөзләрчә мең халык арасында ялгызлыкта яшәгән төсле, кайбер уңайсыз карарларны да дәүләт хакына кабул итәргә тулы килә.

Бераз булса да ял итәсе килеп, ул төнгә үз янына Тайдуланы чакыртты. Тайдула аны, чыннан да, тынычландырды, һәр төндәгечә, нәкъ беренче тапкыр очрашкан төсле, беркайчан да кабатланмый торган ләззәт чоңгылына чумдырды. Тукталышлар ясамый, берничә үрне рәттән менгәннән соң, алҗыган Үзбәк чалкан ятып, назлы кызны күкрәгенә кысты. Алар, дәшмичә, тыннары гадәти хәлгә кайтканын көттеләр. Беренче булып, Тайдула сүз башлады:

– Бөек ханым, сиңа кергәнче, Көнчәага белән сөйләшеп алдык. Баялун хатын да бар иде...

– Ни турыда сүз булды?

– Мәскәү кенәзе Юрий тәкъдиме хакында...

– Көнчәага ни уйлый?

– Курка, сөекле ханым. Хатын-кызга ят җиргә чыгып китү, ят ир кочагына керү бер дә җиңел түгел.

– Син дә ят ир кочагында бит.

– Син үзгә...

– Көнчәаганы тынычландырдыгызмы соң?

– Баялун хатын сүзләрен тапты кебек. – Тайдула уйланып торды. Аннан сүзен дәвам итте. – Көнчәага чукындырудан да курка.

– Анда куркырлык берни дә юк.

– Беләм...

– Кайдан беләсең?!

Ялгыш сүз ычкындыруын аңлаган Тайдула акланырга ашыкты:

– Син, бөек ханым, барлык диннәрнең дә яклаучысы. Христианнар мөселманнар белән бер рәттә йөри. Үзгә дин кабул итү куркыныч түгел,

минемчә. Хәер, минем үземә дә ислам күбрәк ошый, әгәр Көнчәага хәлендә калсам, шулай ук карышкан булыр идем...

– Алланың исемнәре төрле, ә менә ышану өчен ихласлык кирәк. Зинһар, сөеклем, бу көннәрдә Көнчәагага терәк һәм киңәшче бул, аңа дөрес сүзләр генә әйт, авыр чакларында юат. Ул минем өчен бик кадерле кеше.

– Хәлдән килгәннең барысын да эшләрмен, бөек ханым, – диде Тайдула, Үзбәкнең күкрәгенә ныграк елышып.

**5**

Юрий кенәз алдамады – ярәшкәннән соң бер айдан артык вакыт үтмәгәндер, калым төялгән арбалар, көтүе белән атлар Үзбәк ханга китереп тапшырылды. 1317 елның җепшек февраль ае иртәсендә Сарайдагы барлык чиркәүләрдә дә кыңгырау чаңы купты. Урда башкаласындагы иң купшы, иң олы христиан гыйбадәтханәсендә Көнчәага ханбикәне чукындыру йоласы үткәрелде. Моннан соң инде ул, исемен алмаштырып, Агафья дип йөртеләчәк.

Мәскәү кенәзе Юрий белән Агафьяның туйлары тугыз көн, тугыз төн дәвам итте. Үзбәк хан сый-нигъмәтләрне кызганмады. Көтүе белән сарык, куй, атлар суелды. Табын, хакимнең яраннары белән генә чикләнмичә, Сарайда яшәүче барча халык өчен юмарт корылды. Мәҗлеснең азагында, үзенең бәкләре һәм әмирләре каршына чакырып, Үзбәк хан киявенә рус олысында бөек кенәз булуга ярлык тапшырды.

Мәскәү Юрие хәзер инде Үзбәк каршында тез чүгеп калтыранып торучы бәндә түгел, аның гаиләсе әгъзасына әйләнде. Аңа да хан кырында, тәхет янәшәсендә урын табылды. Ул үзен чиксез горур тота иде. Ниһаять, Мәскәү Тверьнең борынына чиертте! Хәзер Михаил аңа каршы сүз генә әйтеп карасын! Шулай да, Юрий ялгызы гына туган ягына кайтырга шүрли иде – Тайтимер озатуында Михаил кенәз кылган явызлыклар Сарайга бик тиз килеп ирешә.

Үзбәк хан исә, әйтерсең, аның уйларын укып бара. Ул, торып басып, чираттагы карарын игълан итте:

– Казначылар, әмеремне тыңлагыз! – диде ул көр тавыш белән. – Сеңлем Көнчәагага, бирнә рәвешендә, киявем Юрий кенәз китергән калымнан да ким булмаган мал тапшырасы. Аны озатып барыр өчен Урда нүкәрләрен җибәрегез. Алар Юрий кенәз тулы хакимлек алганчы Мәскәү олысында торсын. Кирәк икән, явызларның җанын алырга ризалык бирәм. Нүкәрләр башлыгы итеп... – Хан яраннарын күздән кичерде, аннан соң башын иеп торган Каугадыйга текәлде. – Нүкәрләрне җитәкләргә меңбашы Каугадыйны сайлыйм. Каугадый, хан тарафына кил!

Коелып төшкән Каугадый хан янына юнәлде, килеп җиткәч тә тез чүкте.

– Синең колың Каугадый теләсә нинди әмереңне үтәргә әзер, бөек хан! – диде ул, кипкән иреннәрен теле белән ялап куеп.

– Башыңны миңа күтәр, Каугадый батыр!

Меңбашының күзләрендә Үзбәк ачу һәм үпкә чаткылары тоемлады кебек. «Бигрәк гарьчел икән бу бәндә», дигән уй бер генә мизгелгә кабынды да таралып юк булды.

– Каугадый батыр, мин сиңа бик кадерле кешем – сеңлем Көнчәага гомерен ышанып тапшырам. Аны күз карагыдай сакларга хан алдында ант эч!

– Бөек ханым, сөекле сеңлең Көнчәаганы җил-давыллардан, яман күзләрдән, яман сүзләрдән, явыз кешеләрдән аралап торырга ант итәм! Әгәр шушы антымнан ваз кичсәм, хыянәтемне минем һәм туганнарымның каны белән юарга хаклысың, Урда җире хакиме!

Каугадый сак кына Көнчәагага караш ташлады. Тегесе, рус киемнәренә киенгән, муенына тәресен таккан көе, аңа текәлгән. Кызда ул үзенә карата кызгану да, кайчандыр янган мәхәббәт ялкынын да күрмәде. Әйтерсең, әйләндереп салганнар, үзгә кешегә алмаштырганнар. Хан сеңлесе салкын һәм хиссез. Гүя, чукынуга да, кенәз хатыны булуга да алдан хәстәрләнгән, ә Каугадый белән кызык өчен уен гына оештырган. Хан нәселенә ничек кыланса да килешә, берни эшләтә алмыйсың... Нәфрәтен басып, Каугадый янә каршындагы ханга күтәрелеп карады. Хан аның мескен халәтеннән көлә төсле тоелды.

– Кан белән юармын, бөек ханым, барча ялгышларны да төзәтермен, – дип пышылдады ул. Үзбәк бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенеп тормады.

Сарайдан зур кәрван юлга кузгалды. Алдан Мәскәү кенәзе Юрийның арбасы бара. Анда Көнчәага утырган. Аннан ары кенәзнең боярлары, яраннары, хезмәтчеләре, тәхет әһелләре. Аерым бер төркемдә – хан сеңлесенең ярдәмчеләре. Боларны авыр хәрби киемнәргә киенгән, нык аяклы биек атларга атланган дружиначылар әйләндереп алган. Тимер очламнары, сөңгеләр язгы кояш нурларында җем-җем килә.

Рус кешеләреннән соң Каугадый нүкәрләре бара. Боларының атлары да тәбәнәгрәк, киемнәре дә җиңелрәк.

Үзбәк хан шактый ара атка атланган килеш Юрий янәшәсендә барды, ярты көнлек юл үткәч, Мәскәү хакиме белән саубуллашты.

– Сеңлемә яхшы ир була күр, Юрий кияү, мине кунакка килеп йөрерлек итмә, – дип, усал елмайды ул.

– Шатлыклы мәҗлесләрдә генә күрешергә насыйп булсын, бөек ханым! Барысы өчен дә рәхмәт үзеңә! – диде тегесе.

Үзбәк хан, атта утырган көе, арбадагы сеңлесе белән сөйләшеп алды да, хәерле юллар теләп, Сарай ягына борылды.

Юрий белән Көнчәага Каугадый хозурына калды. Ул яшь кияү белән кәләшне көн дә, төн дә күзәтте. Караңгы төшкәч, ялга туктаганда, кенәз арбасы янына килеп, эчтә ниләр булганын тыңлап торырга күнекте. Хан әмере белән җибәрелгән кеше буларак, аңа чикләүләр юк иде. Һәр төн аның Көнчәагага карата мәхәббәт хисләрен үтереп, нәфрәтен уята барды. Күпме назлы сүзләр сөйләп, күпме хыялланып та, ул хан сеңлесенә кагылырга да кыймады, менә хәзер Көнчәага рус кенәзе кочагында ләззәттән ыңгырашып ята. Ничә тапкыр кулы кылычка үрелде, ир белән хатын бер-берсенә береккән мизгелдә икесен дә суеп үтерергә ниятләде. Тик батырлыгы җитмәде. Болай башсыз кыланырга ярамый. Көтә белергә кирәк. Каугадый, битарафлык битлеген киеп, кан саркыган йөрәген учына кысып, берни булмагандай, яугирләрен Мәскәү ягына чаптыра бирде. Тик күңелендәге үпкә, ачу, әрнү инде ярларыннан ташып чыгар төсле иде...

Көнчәага бары тик язмышына гына буйсынды, тәнен Юрийга тапшырса да, йөрәген иректә калдырды. Мәскәү кенәзе дә коры кеше булып чыкты. Урда җирләреннән чыгып китү белән, йөзеннән елмаю да качты. Ул яшь

хатыны янына төннәрен генә килә, бер авыз сүз сөйләшми, бик тупас рәвештә ирлек бурычын үти һәм китеп тә бара. Каугадыйдан Көнчәага ояла, ләкин аңа хисләрен күрсәтми. Сирәк вакытта гына карашлары очрашып китә. Сөйгән ярының күңелендә ачу, үпкә, рәнҗеш икәнлеген хан сеңлесе беренче көннән үк аңлады. Меңбашы ни генә уйламасын, артка юл юк. Элек сөйләшенгән сүзләр җилгә очты, ул хәзер башка ир хатыны, Каугадый белән берәр төрле мөнәсәбәткә кереп, ыруының кара данын чыгара алмый...

Мәскәү аларны чиркәүләр чаңы белән каршылады. Барча халык урамга чыккан. Кырыс Урда яугирләреннән шүрләсәләр дә, ул яклардан кайтып килүче хан кызын күреп калырга телиләр. Көнчәага дә аларны күзәтте. Өскиемнәре бер дә Сарайдагыча түгел. Йөзләре кырыс, авыр тормыш тамгасы сугылган. Хатыннар тыйнак, ирләр барысы да көрәк сакаллы.

Ниһаять, алар шәһәр үзәгендәге кенәз утарына җиттеләр. Иркен ишегалды биек дивар белән әйләндереп алынган. Төп йорт нык, калын имән бүрәнәләрдән салынган. Болдыр янәшәсендә боярлар тезелешеп баскан.

Юрий кенәз хатынына арбадан төшәргә ярдәм итте, башын югары күтәреп, боярлар тарафына юнәлде. Тегеләр, кара бүрекләрен салып, башларын иделәр, кенәзне үз телләрендә сәламләделәр. Бер хатын, җәһәт кенә йөгереп килеп, яшь парга зур түгәрәк ипи һәм касәгә салынган тоз сузды. Ире артыннан кабатлап, Көнчәага дә ипине чеметеп алды, тозга бармак очын тидерде.

Кенәзне энекәше Иван килеп кочаклап алды. Абыйсыннан аермалы буларак, моның йөзендә нур бар, ипле һәм ачык күңелле кеше икәнлеге сизелеп тора. Көнчәага белән дә Иван ихлас елмаеп, русча ниндидер сүзләр әйтеп исәнләште.

Каршылаучылар арасында Юрийның кызы Софья да бар иде. Көнчәага этисенең баласына карата салкынлыгына игътибар итте. Кыз да артык талпыну күрсәтмәде. Күзләре төпсез, тирән сагышлы иде аның. Юрий ияртеп кайткан хан сеңлесенә баш кына какты да читтәрәк торган бер төркем хатын-кызлар арасына кереп югалды.

Өй эче Көнчәага күнекмәгәнчә караңгы иде. Йорт җиһазлары барысы да агачтан эшләнгән, алардагы кебек күпсанлы keләмнәр, мендәрләр, җәймәләр юк диярлек. Хан сеңлесенә аның бүлмәсен күрсәттеләр. Арбадан кирәк-яракларын китерделәр. Ялгызы гына калгач, Көнчәага, күңеленә таш булып тулган хисләрен бушатып, үксеп елап җибәрде...

Кичен Юрий кенәз мәҗлес корды. Табынга дин әһелләре, боярлар, хан җибәргән гаскәр башлары чакырылды. Көнчәаганы кенәз түргә, үз янәшәсенә утыртты.

Мул иде рус табыны. Ризыклары төрле-төрле, матур итеп бизәлгән. Ашамлыклар, бетмәс шикелле, бер-бер артлы чыга торды. Тик Көнчәаганың гына тамагыннан ризык үтмәде. Бу бәйрәмдә ул юк иде. Ире аны бик тиз онытты. Торып басып, нидер сөйләнгән боярлар белән чәкешә-чәкешә хәмер эчте. Хан сеңлесе Каугадыйның да ару гына исерүен чамалады. Азакка таба, иреннән рөхсәт сорап, Көнчәага үз ягына китте. Табын исә таңга чаклы гөрләргә калды.

Бүлмәсенә барганда, ул бер ишек артыннан елаган тавыш ишетте. Саклык белән генә ишекне төртте, эчкә узды. Сәкесендә Софья бөгәрләнеп яткан иде.

Көнчәага аның янына килеп, янәшәсенә утырды. Софья елаудан туктады, шешенгән битен әтисенең яңа хатынына борды. Көнчәага елмаерга тырышты, кызның чуалып беткән чәчләрен рәтләде.

– Гафу ит мине, Софья, – диде Көнчәага, үзе дә еларга җитешеп. – Үз ихтыярым белән килмәдем. Әниеңне дә алмаштырырга җыенмыйм. Тормыш ул бездән сорап тормый, үз җае белән ага. Без – аның коллары гына. Ханның ырудашы да, кенәзнең кызы да – һәммәбез дә коллар. Шуңа күрә язмышка буйсынырга туры килә... Бер дә борчылма, мин сине рәнҗетмәм.

Кыз, телне белмәсә дә, аңлады төсле аны. Тынычланып калды кебек. Ул кечкенә учы белән Көнчәаганың кулын кысты. Алар бик озак әнә шулай бер-берсенә сүзсез генә карашып утырдылар. Аннан соң Софья мендәр астыннан чүпрәк-чапрак кисәкләреннән җыештырып тегелгән курчагын тартып чыгарып, хан сеңлесенә сузды.

– Һай, нинди матур курчак! – дип ихлас сокланды Көнчәага. – Миңамы бу?

Софья, «әйе» дип, башын какты.

– Үзең тектеңме? – Көнчәага куллары белән ишарәләп, соравын кызга төшендерергә маташты. Тегесе аңлады бугай, янә баш какты. – Мине дә өйрәтерсең әле, яме? Ә хәзер йокла, ял ит.

Көнчәага Софьяның өстенә юрганын япты, мендәрен рәтләде. Аннары үз бүлмәсенә юнәлде. Аның кулында гөнаһсыз сабый үзлеге белән ясаган нәни курчак иде. Көнчәага ул төнне шул курчакны күкрәгенә кысып йоклады...

**6**

Ханнан бөек кенәзлек ярлыгын алып кайту ул әле бөтен рус җиренә хакимлеккә ирешү түгел иде. Юрий үзенең өстенлеген сугыш һәм канкоеш белән яулап алырга тиешлеген бик яхшы аңлый. Моның өчен беренче шәпкә Тверьне буйсындырырга кирәк. Шымчылары Михаил кенәзнең Юрий дружиналарына каршы чыгарга әзерләнүен җиткерде. Мәскәү башлыгы кичекмәстән гаскәр җыярга боерды.

Урдадан Каугадыйга ияреп килгән нүкәрләрне Мәскәүдән ераграк тоту максатыннан, Юрий станы итеп Кострома шәһәрен билгеләде. Акрынлап шушында яугирләр туплана башлады. Юрийның чапкыннары төрле почмакларга йөгерде. Мәскәү әләмнәре астына башта Суздаль, аннары Новгород басты. Урда нүкәрләре белән берлектә зур гаскәр оешты.

– Тверь җирләренә озакка кереп чумарбыз төсле тоела, – диде Каугадый Юрийга, бәрелеш алдыннан соңгы тапкыр киңәшмә үткәргәч. – Яшь кәләшне озакка ялгыз калдырырга курыкмыйсыңмы?

– Нишләмәк кирәк, хатын көтә белергә тиеш...

– Урда ханнары яуга барганда да, хатыннарын үзләре белән бергә ала.

– Мин Урда ханы түгел бит.

– Аның каравы Көнчәага – хан кызы. Аңа мондый нәрсә ят түгел, ул күнеккән. Үзең белән алсаң, Үзбәк галиҗәнапларының дә күңеле булыр.

Каугадый Юрийны Көнчәаганы үзе белән бергә алырга ник үгетләвен үзе дә аңлап бетермәде. Акылы түгел, йөрәге сөйләде. Соңгы вакытта ул Көнчәаганы бик сирәк күрә, сагына да бугай. Кенәз хатыны алар белән бергә яуга барса, тукталган урыннарда кызны күзәтергә, бәлки, берәр сүз дә катырга мөмкинлек чыгар...

Юрий, озак уйлап тормый, бу тәкъдимгә күнде.

1317 елның кара көзендә, тәүге салкыннар җирне катырып җибәргәч, Костромадан олы гаскәр юлга кузгалды. Берләштерелгән дружиналар Тверь биләмәләренә бәреп кереп, Ростов, Переяславль, Дмитров, Клин шәһәрләрен таладылар. Аларга каршылык күрсәтерлек көч табылмады. Артларыннан җимерелгән йортлар, тар-мар ителгән утарлар, мәсхәрәләнгән мәетләр аунап калды. Урда нүкәрләре белән беррәттән рус дружиначылары да кимен куймады, җиңелүгә дучар булганнарны куркыныч язмыш көтә иде. Төркем-төркем коллар Урда ягына озатыла торды...

Михаил кенәз гаскәрләре белән Тверь шәһәренә кереп бикләнде. Соңгы вакытта ул каланы ныгытуга күп көч куйды, аның диварлары теләсә нинди һөҗүмгә каршы торырлык иде.

Юрий кенәз җитәкчелегендәге гаскәр, шәһәр янына килеп җитеп, аны камап алды. Ике арада чапкыннар йөрергә кереште, Михаилны Мәскәү кенәзенә буйсынырга үгетләделәр. Ләкин тегесе килешмәде – Юрий артык мәкерле бәндә, аңа ышанырга ярамый. Хакимлек өчен туганын да сатып җибәрергә әзер.

Тверь капкасы төбендә таптанып торудан тәмам алҗып, Юрий гаскәрләрне кенәзлекнең төрле тарафларына таратты. Яклаучысыз калган җирле халыкны янә талау, изү башланды. Яхшы коралланган Урда нүкәрләренә, тимергә киенгән дружиначыларга сәнәк белән каршы тору мәгънәсез иде. Михаилның шымчылары кенәзлек җирләрендә булып яткан коточкыч хәлләр турында хәбәрләр китерә торды. Ниһаять, кенәзнең йөрәге түзмәде. Ул, дружинасын ияртеп, кан дошманы Юрий йөргән якка юнәлде.

Ике гаскәр Тверьдән кырык чакрым ераклыкта, Идел буендагы Бортенев авылы янәшәсендә очрашты. Янә килешү тәкъдим итеп килгән Юрий чапкыннарын Михаил кире борып җибәрде – Мәскәү кенәзеннән соң аның җире көчләнгән хатын-кыз халәтендә калган, яндырылган авыллар һәм мәет өемнәре күңеленә нәфрәт салды. Юрий кырында хан сәргаскәре Каугадый тору да куркытмады – гаделлек Тверь ягында, Үзбәк Мәскәү кенәзе кылган башбаштаклыкны хупламаячак. Кирәк икән, Сарайга барып җавап тотар. Дружиначылары Юрийныкына караганда азрак булсын, ләкин аның сугышчылары берсе-берсе унны егарлык.

1317 елның 22 декабрендә ике гаскәр яу кырында очрашты. Бер як икенчесен аямады, кан елгалары Идел бозына агып, аны кызгылт-көрән төскә буяды.

Михаил кенәзнең тоемлавы хаклы булып чыкты – Тверьләрнең үзен-үзе аямыйча көрәшүенә Юрий һәм Каугадый гаскәриләре түзә алмады. Кичке эңгер-меңгердә башланган орыш караңгы төшкәндә тәмамланды да. Юрий кенәз, дружинасының калдык-постыкларын ияртеп, урман эченә кереп югалды. Каугадый, нүкәрләренең белә торып үлемгә баруын аңлагач, аннан алдан ук яу кырын ташлап киткән иде.

Күпсанлы әсирләр арасына Юрийның бертуган энекәше Борис та эләккән булып чыкты. Аны Тверьгә җибәреп, сак астына алдылар. Михаил кулына тагын бер кыйммәтле кеше төште – Юрий кенәзнең тирмәсендә Урда ягыннан килгән хатын-кызны табып алдылар. Аны Михаил хозурына китерделәр. Аңлашыр өчен тылмач чакырдылар.

– Кем син? – дип сорады Михаил кенәз.

– Агафья, Мәскәү кенәзе Юрийның хатыны...

Михаил Юрийның Урдадан хан сеңлесенә өйләнеп кайтуын ишеткән иде. Димәк, бу Агафья – Көнчәага була... Юрий, хатынын яуга ияртеп килү өстенә, аны якларлык көч тә таба алмаган. Шул да булдымы бөек кенәз?!

– Ялгышмасам, сине элек Көнчәага дип йөрткәннәр?

– Әйе, Агафья – минем чиркәү кушкан исемем...

Михаил кенәз авыр көрсенеп куйды.

– Әйберләреңне җый, Үзбәк хан сеңлесе Көнчәага. Ирең Юрий сине ташлап качып китте, алдын-артын карап тормады. Минем йортымда кадерле кунак булырсың, җәбер-золым күрмәссең. Кенәз сүзен бирәм үзеңә!

Көнчәага-Агафья, рәхмәтен белдереп, башын ия төште.

Тирмәдән чыккач та, Михаил кенәз дружина башлыгы Фёдорны чакырып алды.

– Фёдор, безнең Мәскәү «дустыбыз» койрыгын ике боты арасына кыстырган эт сыман үз корсагын коткарыр өчен качып котылды. Хәтта хан биргән хатынын да оныткан. Агафья хәзер шушы тирмәдә, әйберләрен җыештыра. Аны ныклап сак астына алыгыз, зыян килә күрмәсен. Кадер-хөрмәт күрсәтеп, Тверьгә озатыгыз, минем утарда яхшы бүлмә бирегез. Ул бүлмәне тәүлек буе сакласыннар. Агафья әсир түгел, минем кунагым. Аның башыннан бер генә бөртек чәче төшсә дә, җаныңны җәһәннәмгә олактырам, аңладыңмы?

– Аңладым, бөек кенәз!

– Ашатуны минем табыннан оештырсыннар, ни сораса шуны бирсеннәр.

– Барысын да җиренә җиткереп үтим, бөек кенәз!

Юрий белән каршылыкка Көнчәага-Агафья да килеп кушылу Михаилның күңеленә бер дә ошамады. Хан сеңлесен сатулашу өчен кулланырга җыенмый ул. Шул ук вакытта аны бик акыллы итеп Мәскәүгә кайтарырга кирәк. Ничек кайтарырга – шайтан белсен! Юрий карурманда адашып йөри бит...

**7**

Икенче көнне иртән Михаил кенәзгә Тверь капкасы төбенә Каугадый җитәкчелегендәге Урда гаскәре килүне хәбәр иттеләр. Михаил, атына атланып, шунда ашыкты.

– Бөек кенәз, сине исән-сау күрүемә чиксез шатмын, – диде Каугадый, кенәзне елмаеп сәламләп. – Мин хан сәргаскәре Каугадый булам.

– Исәнме, Каугадый? Бу юлы ни йомыш белән йөрүең?

– Дуслашырга ниятлим, бөек кенәз.

– Син Юрий кенәз белән бергә минем җирләрне таладың, миңа каршы сугыштың. Ник кинәт дуслашырга уйладың әле?

– Безнең бирегә Мәскәү кенәзенә ияреп килүебез – Юрий коткысы һәм мәкере нәтиҗәсе генә. Бөек хан аңа Тверьгә һөҗүм ясарга кушмады. Мине дә алдап алып килде, шуңа күрә кичә мин, орышта катнашмыйча, нүкәрләремне читкә бордым.

Михаил кенәз уйга калды. Хан сәргаскәре сүзләрендә хаклык бар иде кебек. Урдаларның яу кырын баштан ук ташлап качуын да үз күзләре

белән күрде. Әгәр алар китмәсә, кичәге бәрелеш бер дә Тверь файдасына тәмамланмас иде.

– Тверьгә рәхим ит, Каугадый, кунагым булырсың! Гаскәреңне дә туйганчы сыйларбыз, шәһәребез янәшәсендә үзең сайлаган урынга стан корсыннар. Үзеңне исә кенәз табынына чакырам!

Михаил янәшәсендәге Фёдорга тиешле күрсәтмәләр бирде. Нүкәрләрне калага кертергә ярамый, алар яман эшләр майтарырга мөмкин. Ләкин әйбәтләп ашатырга, хәмерне дә кызганмаска кушылды.

Каугадый берничә яраны белән Тверь кенәзе табынына утырды. Алар күптәнге дуслар кебек кәеф-сафа кордылар. Каугадый Юрийны эт итеп сүкте, аның булдыксыз гаскәр башы икәнлеген кат-кат кабатлады.

– Әйе, Юрий кенәз өчен минем үземә дә оят, – диде Михаил, чираттагы чәркәне бушаткач. – Хатынын да яклый алмады бит, шайтан алгыры нәрсә!

Каугадый айнып киткән төсле булды. Аның йөзеннән елмаюы юкка чыкты, табында гаме калмады.

– Хатынын? Көнчәаганымы?!

– Әйе. Агафьяны. Бөек ханның бертуган сеңлесен.

– Кайда ул?

– Биредә, минем утарымда. – Михаил, Каугадыйның ихлас борчылуын күреп, аны тынычландырырга ашыкты: – Алай каударланма инде син! Ул минем кадерле кунагым рәвешендә. Юрий аны ташлап качты бит, мин сыендырдым. Мәскәү кенәзе башын иеп килсә, кайтарып җибәрермен. Килмәсә, бөек хан янына илтермен...

Тирән уйга калган Каугадый бераз аңышты кебек. Ул янә чәркәгә үрелде, Тверь кенәзенең зирәклеге һәм мәрхәмәте өчен күтәреп куярга өндәде.

Шактый утырдылар, Каугадый хәмердән иләсләнде, ләкин һәр күтәрелгән чәркә саен ачуы ныграк куба торды. Көнчәага биредә, кул сузымы арада гына. Ханга Каугадыйга карата мәхәббәте хакында әйткән микән ул? Әйткәндер, алар Үзбәк белән аеруча якын, диләр. Тегесе ничек җавап биргән? Каугадыйны гади бер сәргаскәр, булдыксыз сугышчы, хәерче, мескен бәндә итеп тасвирлагандыр. Хан сеңлесенә тиңдәш түгеллеген, түбән катламга керүен дә өстәгәндер. Көнчәага исә, аның белән килешеп, кенәз хатыны булуга, алтын-көмешкә, хакимлеккә кызыккандыр.

– Мин бөек ханга сеңлесенең исән-иминлеген җиткереп, Сарайга чапкын җибәрергә тиешмен, – диде ул кинәт Михаилга.

– Тверьдә кунак рәвешендә кадерләп тотылуын дә әйтсен, хөрмәтле Каугадый!

– Әйтәм, барысын да әйтәм. Ләкин, чапкын киткәнче, мин Көнчәаганы үз күзем белән күреп, икәүдән-икәү сөйләшергә телим.

– Яхшы, Каугадый сәргаскәр, иртәгә ул очрашуны оештырырмын.

– Иртәгә түгел. Бүген.

Михаил исерек Каугадыйга шикләнебрәк карады. Урда нүкәренең башында нинди уйлар бөтерелгәнен аңларлык түгел. Шулай да, үзенә күрә бер усаллык чак кына тоемланып үтә. Ул Михаилга каршы берәр мәкер әзерләмиме икән?

– Шактый эчелде, Каугадый, бәлки...

– Хәзер үк дидем бит!

Кенәз ярдәмчеләрен чакырды, аларга Каугадыйны Көнчәага янына озатырга боерды. Авыр гәүдәсе кыска аякларында чайкалган Каугадый торып басты, озак тормый кайтачагын әйтеп, хезмәтчегә иярде.

Көнчәага ишеге төбендә ике дружиначы баскан. Аларга Каугадый һава сулап керергә боерды, хезмәтчене дә, безнең сүзне тыңлап торасы булма дип, кире Михаил тарафына җибәрде. Хан кешеләренә карышырга ярамый иде...

Зур гына бүлмәгә кергәч тә, Каугадый ишекне эчтән бикләде. Караңгылыкка күзләре бераз күнеккәч, тәрәзә янында боегып утырган кыз сынын абайлады.

– Саумы, Көнчәага! – диде Каугадый.

Хан сеңлесе биредә Каугадый тавышын ишетермен дип уйламаган иде, каушап калды, аннары йөгереп килеп, егеткә сарылды:

– Каугадый, син мине коткарасыңмы?!

– Коткарам, Көнчәага, коткарам. – Каугадый кызның аркасыннан сөйде, аның тәне һәм чәчләре исеннән башы әйләнеп китте.

– Юрий кенәз исәнме?

– Исән, сине ташлап, яу кырыннан качты, табаннары гына ялтырап күренеп калды.

– Мине Мәскәүгә алып кайтырга килдеңме?

Каугадыйның янә ачуы кабарды. Әйтерсең, ул монда юк, хан сеңлесе һаман да Мәскәү кенәзе хакында сораштыра.

– Алып кайтырмын, бер дә борчылма... – Ул, кызны үзеннән аерып, баштанаяк күзләп чыкты, аннары билбавын чишә башлады.

– Нишләвең бу, Каугадый?! – дип гаҗәпләнде куркынган Көнчәага.

– Күптән икәү бергә булырга хыялландык бит, әйдә, мөмкинлек чыкты, теләгебезне шушында булса да чынга ашырыйк, – дип ыржайды сәргаскәр.

– Син ни сөйлисең?! Мин хәзер Юрий кенәз хатыны бит...

– Борчылма, мин җирәнмим. Чишен!

– Урда кануннары буенча...

– Нинди Урда кануннарын сөйлисең син! Син хәзер рус хатыны Агафья!

Көнчәага үксеп елап җибәрде, тик Каугадый аңа игътибар итмәде. Эшен башкарып чыкканда да, хан сеңлесе аны елап озатып калды. Хан нүкәре исә, чабуларын җыештыргалап, кире кенәз янына, хәмер эчәргә кереп утырды...

Үзенең нинди явызлык кылуын, моның өчен хан хөкеменең ни дәрәҗәдә усал булуын Каугадый икенче көнне генә, айный төшкәч кенә аңлады. Көнчәага Үзбәк ханга үзен көчләүләрен сөйләмәс дип, кем кистереп әйтә ала? Үзбәк колагына бу хәбәр ирешсә, Каугадыйны мәсхәрәле үлем көтәчәк. Һәм Урда нүкәре үз юләрлеге белән килеп туган авырлыкны чишеп чыгу юлларын эзләргә кереште. Үзе исә һәр төн саен Көнчәага белән бикләнеп, аны көчләү гадәтенә ияләште...

Ул арада Тверь тарафына яңа дружиналар җыеп, Юрий кенәз килеп басты. Аның гаскәрләре Идел елгасының бер ярына, Михаил кенәзнекеләр икенчесенә тезелештеләр. Каугадый, Юрий якынаю хәбәрен ишеткәч тә, аңа кушылырга ашыкты. Бөек хан аны Мәскәү кенәзенә иярткән иде бит, хәзер Михаил белән бергә булу хәерлегә түгел.

Каршы яклар орышка кермәде, бер-берсе белән арадашчылар аша сөйләшүләр алып барды. Ахыр чиктә уртак фикергә килделәр. Ике кенәз очрашып, тынычлык хакындагы солыхның шартларын расладылар. Михаил Юрийга дружинасы белән исән-имин килеш Мәскәүгә кайтырга юл ача. Юрий сугышчылары бүтән Тверь җирен таламый. Тверьдә тоткынлыкта утырган Мәскәү кенәзенең бертуганнары – Борис белән Афанасий һәм, әлбәттә, Көнчәага азат ителәләр. Шулай ук Новгород боярлары да ирекә чыгарга тиеш. Ә инде бөек кенәз булырга кем хаклы икәнлеген кылыч белән хәл итмәскә, Урдага икәү бергә барып, бөек хан хөкеменә тапшырырга килештеләр.

Каугадый ике рус кенәзенең сөйләшүләрен, бер-бер артлы ант эчеп тәре үбүләрен сүзсез генә күзәтте. Көнчәаганы агуларга җибәрелгән ышанычлы нүкәре Дангаа, мөгаен, Тверьгә барып җитеп, кушылганны җиренә җиткереп үтәгәндер дип өметләнде...

Дангаа караңгы төшкәч, Каугадый станына кайтып төште. Беренче эш итеп, сәргаскәргә хисап тотарга ашыкты.

– Монда сөйләшергә ярамый, әйдә, атларга атланып, тирә-якны әйләнеп килик, – дип тәкъдим итте Каугадый.

Алар икәү караңгылыкка чумдылар, бозланып каткан Идел ярыннан атларын атлаттылар.

– Ничек, минем әмеремне үти алдыңмы, Дангаа? – дип сорады Каугадый, станның утлары да күренмәс булгач.

– Үтәдем, Каугадый сәргаскәр. Көнчәагага әзерләнгән ризыкларга син биреп җибәргән әйберне яхшылап сиптем. Ашына да, ипигә дә, эчә торган суына да.

– Бик әйбәт. Рәхмәт үзеңә, Дангаа, бу яхшылыгыңны мәңге онытмам!

– Кешегә генә чыга күрмәсен инде...

– Миннән чыкмый. Ә менә синнән... – Каугадый бишмәте астыннан җәһәт кенә кыска хәнҗәрен тартып чыгарды һәм Дангааның муенын суеп җибәрде. – Менә синнән чыгарга мөмкин иде.

Дангааның җансыз гәүдәсе кар өстенә барып төште. Каугадый аның мәетен яшереп азапланмады, атын гына ияртте дә кире станга борылды. Иртәгә таң белән барыбер Мәскәүгә кайтасы иде...

...Көнчәаганың үлем хәбәрен беренче булып Михаил кенәзгә ирештерделәр. Иртәнге аш китергән хезмәтче хатын Агафьяны йоклаган килеш тапкан, күпме тырышса да, уята алмаган. Йөрәге табанына төшкән Михаил, беркемгә дә бер сүз дә әйтмәскә боерып, Көнчәага тотылган йортка ашыкты.

Көнчәага-Агафья йоклаган төсле яткан, ләкин тын алмый. Бер кулына кечкенә курчакны чытырдатып тоткан. Михаил кенәз бер бармагын хан сеңлесенең муен астына тидереп карады. Салкын тәндә җан юк иде.

Башын ике куллап тотып, Тверь хакиме аякларын сузып, идәнгә утырды. Шул гына җитмәгән! Ханның якын туганы аның биләмәләрендә әсирлектә вакытта үлеп китсен әле!

Көнчәага яткан бүлмәне бикләп һәм яхшылап сакларга кушып, Михаил үз ягына чыкты. Ышанычлы дусты Александр боярны чакыртты. Барысын да аңа бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

– Үлеме ни сәбәпле булганын ачыкларга мөмкинме? – дип сорады, аны тыңлаганнан соң йөзе караңгыланган Александр бояр.

– Агулангандыр, мөгаен. Йоклап киткән җиреннән уянмаган... Урда ханы Тверьны җир белән тигезләячәк хәзер.

– Ашыкма әле, Михаил кенәз. Без Юрий белән сөйләшеп карыйк. Мәскәү кенәзе безне аңлар, рус җирләренә яу китертмәс.

– Бик рәхәтләнеп китерәчәк, әйтте диярсең. Мондый мөмкинлекне кулыннан ычкындырамы инде ул?!

– Үзем Мәскәүгә барып сөйләшим. Аңа кадәр Агафьяны җирләмәгез. Мин сүзләрен табармын шикелле...

– Ә таба алмасаң?!

– Гаеп үземдә булыр. Хәзер үк юлга кузгалам, төрле сүз чыкканчы эшне тиз тотарга кирәк!

Михаил кенәз дусты белән кочаклашып саубуллашты. Тверь хакименең ни уйларга, ни эшләргә, ни кылырга белмәгән вакыты иде. Александр боярны фикереннән кайтарып торырга бу мизгелдә акылы җитмәде...

Дусты Мәскәү кенәзе каршына баргач та, тиешле сүзләрен таба алмады. Юрий, Александр бояр авызыннан яман хәбәрне ишеткәч тә, илченең башын кистерде. Каугадый исә, гаскәрен җыеп, кире Сарайга, Үзбәк хан хозурына ашыкты. Көнчәага үлеме хакында ханга үзе сөйләп бирсә, хәерлерәк булыр. Кем беренче кычкырса, шуның сүзе – хакыйкать. Күңелендә үз башының исән калуына шик булса да, Каугадый бар булган батырлыгын җыйды.

**8**

Үзбәк хан каршына басканчы, Каугадый Исабәк белән очрашып, Көнчәага белән булган фаҗига хакында аңа сөйләп бирергә карар кылды.

– Бөек солтаныбызның бәкләр-бәге, зирәкләрдән зирәк, гаделләрдән-гадел нәиб Исабәк! Мескен колың синә ярдәм һәм яклау сорап килде, – диде ул, мул бүләкләрен өеп куеп тез чүккәннән соң.

– Тыңлыйм, Каугадый сәргаскәр, сөйләп кара, – диде Исабәк ялкау гына.

– Бәла, бөек нәиб, зур бәла... – Каугадый тавышына кызгану катыш кайгы чыгарырга маташты. Күз читеннән ике тамчы яшь тә сыгарга хәле җитте.

Исабәк шул мизгелдә үк уянды.

– Сөйлә, нинди бәла тагын?!

– Көнчәага харап булды, бөек нәибем...

– Ничек харап булды?!

– Тверь кенәзе Михаил безгә һөҗүм итеп, сөекле ханыбызның сеңлесен әсирлеккә төшерде. Көнчәаганы җәзалап үтерделәр...

Исабәк сикереп үк торды, Каугадыйны тезләнгән җиреннән өстерәп күтәрде.

– Ни сөйлисең син, саташкан сарык?! Хан сеңлесенә кемнең кулы күтәрелә алды?!

– Михаил кенәз үтерде аны, – диде Каугадый, бу юлы инде куркуыннан чынлап торып елап.

Исабәк Каугадыйның шаяртмавын аңлады. Тынычлангач, сәргаскәрдән барысын да бәйнә-бәйнә сорашты. Каугадыйны тыңласаң, Тверь кенәзе

Михаил Юрий белән бергә Урда гаскәрләрен мәкерле төстә үз җирләренә керергә мәҗбүр иткән, аларга яман зур яу белән ябырылган, Көнчәаганы кулга алып, аны агулап үтергән.

Мондый әкиятне Исабәк ханга кереп сөйли алмый иде. Каугадый үзе Үзбәкне ышандырырлык сүзләр тапсын. Урда хакиме нинди хөкем чыгарыр – нәибнең анда эше юк.

– Ханга дигән бүләкләреңне үзең белән алдыңмы? – диде Исабәк, Каугадыйдан читләшеп.

– Үзем белән, бөек нәиб, – дип мышкылдады алып гәүдәле сәргаскәр.

– Алайса, мин хан янына киттем, сине чакыртырлар, әллә кая югалма. Башың исән калуын теләсәң, бу галәмәтне сөйләр өчен дөрес сүзләр таба тор.

...Үзбәк хан Каугадыйны санаулы гына яраннары янында кабул итте. Вакыт кичкә авышкан, хаким дә нык арыган. Ләкин Исабәк: «Рус җиренә киткән сәргаскәр үтә дә мөһим хәбәр белән кайткан», – дигәч, вакытын табарга булды.

Каугадыйның үз-үзен тотышы баштан ук сәер иде. Бүләкләрен биргәндә, куллары калтырый, йөзе елаудан шешенеп беткән төсле.

– Сөйлә, Каугадый, рус җирләрендә ниләр булып ята? – дип сорады Үзбәк, күңеленә кинәт төшкән шомны куып җибәрергә тырышып.

– Яман хәлләр, бөек ханым... – Каугадый гадәттәгечә әтәчләнми, пышылдап кына җавап кайтарды.

– Аңлатып әйт, минем синнән башка да эшем бетмәгән!

Каугадый янә яшьләнгән күзләрен ханга күтәрде. Ул бик нык куркынган халәттә, бөтен тәне калтырана. Шушындый олпат гәүдәле сугышчыны мондый кыяфәттә күрү бик сәер иде.

– Сөекле ханым, зинһар, гафу ит мине. Синең яраткан сеңлең, безнең күз карасыдай карап торган Көнчәага... Мин аны саклап кала алмадым... Тверь кенәзе Михаил аның җанын кыйды...

Каугадый ханны котырта, аннан көләргә маташа төсле тоелды Үзбәккә. Рус кенәзе ханның бертуганына ничек кул күтәрсен, ди?! Була торган хәл түгел! Тик сәргаскәрнең үз-үзен тотышы моның чынбарлык икәнлеген раслап тора.

Үзбәк, ашыкмый гына торып, Каугадый каршына килде, аны, ике куллап якасыннан тотып, идәннән күтәрде.

– Син ни сөйлисең, бетле корка?! – дип ысылдады Үзбәк. – Минем белән болай шаяртырга ярамаганлыгын белмисеңме әллә?!

– Мин... Мин шаяртмыйм, бөек хан... Михаил сеңлеңне үтерде...

Кабат шул сүзләрне ишеткәч, Үзбәк тәмам тынсыз калды. Каугадыйны чатырдатып тоткан көе ул Исабәккә таба борылды. Тегесе тәхет янәшәсендә башын игән килеш тора иде. Бүлмәдәгеләр дә хафалы кыяфәттә күзләрен түбән төшергәннәр.

Яман ачуы купкан Үзбәк хан Каугадыйны бар көченә төртеп җибәрде. Тегесе чалкан барып төште. Икенче мизгелдә Урда хакиме күн кәвеше белән тегенең муенына басты. Сулышы кысылган сәргаскәр гырылдый башлады.

– Син, мәгънәсез дәҗҗал! Минем сеңлем артыннан селәгәеңне агызып йөрүеңне күрмәдемме?! Хан кияве була алмавың өчен үчең шушымы?!

Базар мәйданына чыгарып, дүрт ягыңны кыйбла итәм, ат койрыгына бәйләтеп өзгәлим, башсыз мөртәт!

Исабәк, бу тамашаның ни белән бетәсен аңлап, Үзбәк янына ашыкты:

– Зинһар, бөек ханым, тынычлана күр! Сине гаделсезлектә гаепли күрмәсеннәр! Кенәзләр өстеннән хөкемне баш казыйга тапшырыйк!

Үзбәк аягының көчен киметә төште, Каугадый, йөткеренә-йөткеренә, бераз булса да, сулыш алды.

– Юрий белән Михаилны минем каршыма китертегез! – диде ул капылт кына тынычланып калган тавыш белән.

– Мәскәү кенәзе Юрий юлда, синең янына ашыга, – диде тыны кысылудан чак кына тавышы ишетелгән Каугадый.

– Тверь Михаилы?!

– Синең тарафка килергә курка, бөек хан, гаебен таныгангадыр. Үсмер улын гына җибәргән, диделәр.

Хан тәхетенә юнәлде, бүлмәдәгеләргә борылмый гына:

– Ахмыл бәк! – дип ташлады.

– Монда мин, бөек ханым. – Ахмыл, баскан көе, башын тагын да түбән иде.

– Хәзер үк рус җирләренә чыгып кит. Михаил кенәзгә әйт – килмәсә, хан аңа үзе барачак, диген. Кенәзлегенең ташын ташка таратып чыгармын. – Тәмам аңышып, тәхеткә утыргач, янә Каугадыйга мөрәҗәгать итте: – Сеңлем Көнчәаганың җәсәде кайда?

– Бөек ханым, Юрий кабул итмәгәч, Михаил кенәз Көнчәаганы Ростовтагы зур чиркәү кырында җирләткән...

– Кияү, минсиңәйтим! Хатынын кешечә озатырга да җай тапмаган! Икесен дә хөкемгә! – Хан усал караш белән яраннарын күзләп чыкты. Һәммәсе дә куркынган, аның кырыс карарын көтәләр. Ләкин бүтән ул тәхет янәшәсендә канкоешка юл куймаячак. – Ялгызымны гына калдырыгыз, – диде ул, хәле киткәнне тоеп. – Исабәк, минем яныма Караны чакырт!

Һәммә кеше китеп беткәч, бүлмәгә шәүлә сыман Кара керде. Еллар аны үзгәрткән, ул картая төшкән, ләкин төз кыяфәтен дә, җәһәт атлавын да югалтмаган. Чәч толымнарында гына ак юллар шәйләнә.

– Сүзеңне тыңлыйм, бөек хан! – Кара тәхеттә тирән хафага баткан Үзбәк каршында башын иде.

– Олы кайгы килде, Кара... Минем сеңлем Көнчәага... Аны Тверьдә үтергәннәр...

– Ходай үзеңә җиңеллек бирсен, бөек хан. Көнчәаганың урыны җәннәттә булсын!

– Син шыпырт кына Тверьгә барып, сеңлем белән чынлыкта ниләр майтарганнарын белеп кайт. Михаил белән Юрий Сарайга чакыртылды, аларны хөкемгә тартачакмын. Тик син кайтып җитми торып карар чыгармыйм. Тизрәк әйләнергә тырыш, миңа хакыйкать кирәк.

– Хәлемнән килгәнен эшлим, бөек ханым, хәзер үк юлга кузгалам.

– Сак бул, Кара. Минем тирәдә дошманнарның бетәсе юк кебек...

Кара җавап бирмәде, ханга алды белән баскан килеш ишеккә китте.

– Исабәк! – дип кычкырды Үзбәк, Кара чыккач. – Мәчеткә барам, анда беркем дә булмасын. Ногъманетдин хәзрәтне күрергә телим. Һәм тагын

бер нәрсә... Минем сак хезмәтен көчәйтегез. Явыз бәндәләр гаиләмә якын ук килде, Алла сакласын...

Ногъманетдин имам, гадәттәгечә, Үзбәк ханны утырган көе генә сәламләде. Аның кайгысы хакында ишеткәч, эченнән генә догаларын укыды, аннан соң ясинга кереште. Үзбәк хан, имамның моңлы мәкаменә оеп, акрынлап тынычлануын сизде. Күз алдына Көнчәаганың елмаюлы йөзе, аның шатланып көлүе, абыйсына, бердәнбер якын кешесенә елышу мизгелләре килеп басты. Үзенчә, сеңлесен бәхетле итәргә хыялланды бит ул. Ник киресе чыкты? Кемнең явызлыгы аркасында сеңлесе якты дөньяны ташлап китеп барды?!

Ясин чыкканнан соң Ногъманетдин имам Үзбәккә бакты.

– Күңелеңдә кара кайгы, бөек хан, – диде ул, дисбесен тарткалап.

– Сүзең хак, Ногъманетдин хәзрәт! Көтелмәгән, авыр югалту бу минем өчен.

– Үзеңне гаепле тоясыңмы?

– Белмим, гаеп кемдәдер... Язмышы шулай язылган, күрәсең...

– Аның язмышын борып җибәрүчеләр бардыр бит? Мәскәү кенәзенә кияүгә үзе теләп чыкмады дип беләм.

– Анысы хак, хәзрәт...

– Чит дингә күчүе дә үз ихтыяры белән түгел...

– Көнчәаганың үлеменә мин гаепле димәкчеме син, Ногъманетдин хәзрәт?

– Мин гаепләүче түгел, бөек хан. Хөкем дә чыгара алмыйм. Анысы бары тик Аллаһы Тәгалә хозурында. Мин бары тик сине хәзер эчтән көйдергән сорауларыңны авыз тутырып әйттем. Шул сорауларны ихлас йөрәктән үзеңә бирсәң, кылган гамәлләреңне кабул итә алсаң, кайгың бераз җиңеләер.

– Әйе, мин Көнчәаганы ул теләмәгән адымнарга этәрдем, килешәм. Тик моны аның бәхете өчен эшлим дип уйладым.

– Аның шәхси бәхетен кайгырттыңмы, әллә инде дәүләт мәнфәгатен өстен куйдыңмы?

– Көнчәага өчен дә, дәүләткә дә шулай яхшырак булыр төсле тоелды, хәзрәт.

– Сеңлеңнең үлемен дөрес кабул итми торып, синең күңелең тынычланмас, Үзбәк хан.

– Бәлки, бу багучылар каргышыдыр? Аларны юк итәр алдыннан миңа каршы тугыз бүре баласы белән әфсен йоласы үткәреп яталар иде...

– Багучылар – хорафат кына. Син гаепне башкалар җилкәсенә күчерергә телисең, моннан синең хәлең җиңеләймәс. – Ногъманетдин хәзрәт, сөйләшү тәмамланганын аңлатып, урыныннан торып басты. – Мин синең белән очрашуга һәрвакыт шатмын, бөек хан. Газиз җанлы имамыңны авыр вакытта гына түгел, шатлыклы чакларыңда да бераз искә төшергәлә...

Хәсрәтле уйларга баткан Үзбәк хан мәчеттән чыкканда, урамда инде дөм караңгы иде. Ул, күпсанлы тәнсакчылары озатуында, үзенең хансараена юл алды. Кайткач та, ризыктан баш тартты, ялгызы гына каласы килде. Ишек кагудан ул сискәнеп китте.

– Кем бар анда? – дип сорады ул, үзе дә аңышмыйча хәнҗәренә сузылып. Бусагадан әвнухы Мостафа атлап кергәч, уңайсызланып, коралын кире куйды. – Ни кирәк сиңа, борчымагыз дидем бит!

– Гафу итә күр, сөекле ханым, ләкин сиңа әйтми булдыра алмадым. Тайдула хатын җибәрде мине. Кичекмәстән ханны күрергә телим, аңа әйтәсе сүзем бар диде...

– Мул итеп акчасын да биргәндер, шуңа монда тизрәк йөгереп килгәнсеңдер, бетле сарык! – Ачуы килсә дә, Үзбәк хан, бәлки, Тайдула кәефен үзгәртер дип уйлап алды. – Ярый, бик кирәк икән, килсен, чакыр.

Тайдула бу кичтә башка вакыттагы халәтенә охшамаган иде. Гадәттә, елмаеп, нур чәчеп торган, хан кочагына тизрәк чумарга ашкынган кызны алмаштырганнар, диярсең. Ул уйчан, сагышлы, моңсу.

– Саумы, Тайдула... – Үзбәк тә бу юлы урыныннан сикереп торып, аңа таба ашкынмады.

– Исәнме, бөек ханым! Шушындый авыр хәбәр алган көнеңдә синең ялгызлыгыңны бозуым өчен мең мәртәбә гафу үтенәм! Ләкин мин килми булдыра алмадым...

– Зыян юк... Утыр, миңа ялгызыма бик күңелсез.

Хан үзенә сыенган кызның озын, кара толымын сыпырды.

– Күтәрә алмаслык олы кайгыңда Ходай сабырлык бирсен, сөекле ханым. Сиңа, мәрхүмнәргә дога ирештереп, исәннәр хакына яшәргә кирәк.

– Шулай да бит... Көнчәаганың үлеменә мин генә гаепле. Каугадыйны яратуын белә торып, Мәскәү кенәзенә ияртеп җибәрдем...

– Хакимнең язмышы катлаулы була, бөек ханым. Син моны кирелектән түгел, ә бәлки мәмләкәтне ныгытырга теләп эшләдең бит.

– Сүзләрең хак, Тайдула, тик мондый бәя белән дәүләтне күтәрү артык кыйммәткә төшә. Чыннан да, Көнчәаганың кенәздән балалары туар, алар рус олысында хакимлеккә килер дип өметләндем...

– Бала... – Тайдула бер генә мизгелгә тынып калды да, иреннәре белән Үзбәкнең колагына үрелде. – Безнең балабыз булачак, сөекле ханым, – диде ул, кайнар сулышы белән ханны кытыклап.

Хан һушсыз калды. Гаҗәпләнеп, Тайдулага текәлде.

– Бала? Син корсакка уздыңмыни?!

– Әйе, бөек ханым. Соңгы арада кәефем керделе-чыктылы, күңелем болгана, тиз арыйм, талчыгам. Бу айда менә күремем дә килмәде. Күрәсең, Ходай сиңа, гаебең юклыгын ишарәләп, минем аша сабый җибәргәндер.

Үзбәк бу сүзләргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Саклык белән генә Тайдуланың корсагына учын тидерде. Моны күргән Тайдула елмаеп куйды:

– Син берни дә сизмәссең, бөек ханым, бәләкәчебез әле яралып кына килә бит.

Берьюлы өстенә ишелгән вакыйгалар ташкыныннан Үзбәкнең башы әйләнеп китте. Ул шунда ук Мостафа әвнухны дәште, Тайдулага аерым бүлмә бирергә боерды. Аннан соң шәхси табибы Ибраһимны йокысыннан уяттырып, кызны җентекләп тикшерергә кушты. Моның өчен Ибраһимның махсус белемле кендек карчыклары бар иде. Алар Тайдуланың чыннан да көмәнле булуын раслагач, әле генә ишеткән сүзләргә ышанып, никах хәстәрен уйлап, Үзбәк хан йокыга китте...

Бу төндә башка сәбәпләр белән йокысын югалткан кешеләр дә бар иде Сарайда. Каугадый, хан яныннан чыгып китәрәк, хакимнең Караны

чакыртуын ишетеп калды. Кара – сер томанына төренгән, шул ук вакытта бик күп имеш-мимешләрдә исеме яңгырган бәндә. Аны ханның шәхси үтерүчесе, ышанычлы кешесе, диләр. Каугадыйның бер генә дә шиге юк – Көнчәага белән булган хәлләргә ачыклык кертү өчен хан теләсә кемнең телен чишә алырлык нүкәрен җәлеп иткән. Хан каршында дер калтырап басып тору, аның үкчәсе астында изелү генә җитмәгән, тагын бу хафа да өстәлде!

Каугадый Карага каршы үз нүкәрләрен җибәрә алмый. Бары бер генә юл кала – үтерүчеләрне читтән яллау. Бу очракта кая барасын ул яхшы белә – шәһәрнең руслар яши торган өлешендә көмеш чыңлавына теләсә нинди гамәл кылырга риза бәндәләр бар. Йөзен чүпрәк-чапракка төреп яшереп, Каугадый төн караңгысында шул якка юнәлде.

Төн урталарына барысы да җайланган иде. Егерме кешедән торган юлбасарлар төркеме башлыгы үзен Порфирий дип атады. Йөзен яшереп, вата-җимерә русча сөйләп, Каугадый аңа бүген Сарайдан Тверь ягына чыгып китәчәк атлылар төркемен куып тотарга һәм барысын да суеп чыгарга кушты. Порфирий сораган бәяне икеләтә түләде, эш җиренә җиткерелеп башкарылса, юлбасарлар җитәкчесенә азактан өстәмә акча вәгъдә итте. Караның бу, чыннан да, соңгы тапкыр хан әмерен үтәргә китүе булды – Үзбәк аны күпме генә көтмәсен, кырыс тәнсакчысы кире әйләнеп кайтмады...

## 9

Үзбәк хан Тайдула белән никахын, гадәттәгечә, киң колач белән үткәрде. Тайдула үзен болай зурлауга шатлыгын яшермәде, ханына мактау һәм рәхмәт сүзләрен кызганмады. Үзбәкнең дә күңеленә яшь хатыны хуш килә иде. Бу – назлы төннәргә генә бәйле түгел. Тайдула беркайчан каршы сүз әйтмәс, ханны карашыннан ук аңлар, авыр вакытта юату җаен табар. Үзбәк Тайдулада ышанычлы кешесен, чын таянычын тапты кебек. Моңарчы битәрләп килгән ялгызлык хисе таралды төсле тоелды.

Никахтан соң алар икәүдән-икәү калдылар. Мөмкинлеген табып, Тайдула сүзен башлады.

– Бөек ханым, беренче балабыз кыз булуын теләр идеңме, әллә малаймы? – дип сорады ул, иренең нык күкрәген кулы белән акрын гына сыйпап.

– Алла кемне җибәрсә, шуңа ризамын, Тайдула.

– Шулай да? Әйтик, малай дөньяга килсә, аны нинди киләчәк көтәр?

– Хан улының киләчәге билгеле – ул хаким тамгасы белән туа.

– Синең бер улың бар бит инде – Тимербәк...

– Тимербәк – минем олы улым. Ул акыллы, булдыклы һәм шул ук вакытта яхшы күңелле егет булып үсеп килә. Синең карыныңдагы бала да аңа охшар дип өметләнәм. Кем генә дөньяга килмәсен, балаларым үзара сугыш, канкоеш оештырмасын дип, Алладан сорыйм. Дәүләтебез киң, аны тагын да зурайтырбыз. Һәркемгә дә урын җитәр. Туганлыкны дошманлык белән бозуга минем риза-бәхиллегем юк. Болай да тәхет тирәсендә бик күп кешенең гомере фида кылынды.

– Улыбыз туа калса, мин аны Бөек Урда ханы дәрәҗәсенә менәрлек асыл зат итеп тәрбияләр идем, бөек ханым...

Үзбәк хан яткан урыныннан торып, өстенә алтын белән чигүле чапанын бөркәнде, аннан Тайдулага киемнәрен ташлады.

– Киен, Тайдула, сиңа китәргә вакыт, – диде ул коры гына. – Тәхет варислыгы турында мин өздереп әйттем, аңламыйсың шикелле... Бала дөньяга тумас борын, аның өчен хакимлек кайгыртып йөрисең... Хатыным булырга өлгермәдең, дәүләт эшләренә тыкшынасың...

– Гафу ит, сөекле хакимем, кәефеңне кырасым килмәде, бары тик...

– Хан үз сүзен әйтте. Бусага әнә теге тарафта.

Тайдула ашыга-кабалана чыгып китү ягын карады. Үзен көтеп торган Мостафа әвнухка ул ачулы караш кына ташлады да, күлмәк чабуларын күтәрә төшеп, Баялун хатын ягына йөгерде. Ханның сөекле хатынын мондый халәттә беренче тапкыр күргән әвнух исә баскан урынында авызын ачып, шаккатып калды.

Вакыт соң, Баялун хатын йокыга әзерләнеп ята, шулай да ул ишегеннән атылып кергән Тайдуланы тыныч кына каршылады. Икәүдән-икәү калгач, күз яшьләрен агызуга ирек биргән кыз, мышкылдый-мышкылдый, барысын да сөйләп бирде, аннан соң ялвару катыш өмет тулы күзләрен Баялунга төбәде.

– Миңа нишләргә, киңәш бир, зирәк Баялун хатын?!

– Юләр икәнсең, Тайдула, сине акыллы зат дип уйлаган идем, ялгышканмын... Балаң тумас борын аңа тәхет даулый башлыйлармыни?! Малай икәнлегенә инансаң да, аны хәзердән кычкырып йөриләрмени?! Ханны олы улына каршы котырта башлавың үз башыңа әйләнеп кайтмагае, хакимебезнең холкы бик авыр, сак бул. – Баялун уфтанып куйды. – Ярый, хәзер берни дә үзгәртеп булмый, телеңне тыя белмәсәң... Бүтән бу хакта авызыңны ача күрмә. Ачуы озакка бармый Үзбәк ханыбызның, бераздан суыныр, үз янына чакыртыр. Берни булмагандай кер, бүгенге сөйләшүне исенә төшермә. Башта балаңны тәхеткә утырырлык кеше итеп үстер. Аннан соң күз күрер... Үзбәк хан, әлбәттә, олы улы Тимербәкне дәвамчысы итмәкче. Ләкин, белгәнеңчә, дүрт аяклы ат та абына. Тимербәкнең берәр ялгышлык җибәргәнлеген көтик, үзе җибәрмәсә, оештырырга да мөмкин. Бик иртә тотынгасың, хатын, болай йөрсәң, барысын да бозып куюың бар.

– Гафу ит, Баялун хатын, моннан ары уйлап сөйләрмен... Ярдәмеңнән генә ташлама.

– Йә, җитәр, битеңне юып ал да йокларга ят. Сиңа мондый халәттә артык борчылырга ярамый. – Баялун хатын шыр сөяккә калган куллары белән Тайдуланың чәчләрен сыпырды. – Мин сине бик яхшы аңлыйм. Мин дә... Мин дә әни булган кеше бит. Аны, әйтерсең, беркем дә хәтерләми. Ә минем йөрәгем түрендә һаман газиз улым Хызырбәк хатирәсе яши. Ни кызганыч, мин аны үстереп кеше итә алмадым, ул бик яшьли китеп барды. Залимнәр кулыннан корбан булды. Ул вакытта мин дә синең төсле яшь, чибәр һәм акылсыз идем. Минем ялгышларны кабатлама, Тайдула. Тәхет тирәсе – утлы дала сыман. Җилнең кайдан искәнлеген һәрвакыт тоемлап торырга кирәк, юкса янып үлүең ихтимал...

Тверь кенәзе Михаил Урдага килеп җиткәндә, Үзбәк хан зур станы белән Азов диңгезе ярында, Дон елгасы буенда җәйләүгә тукталган иде. Үзен озата баручы улы Константин һәм бирегә алданрак җибәрелгән боярлар

белән алар кичкенә бер шәһәргә охшаган меңнәрчә тирмәләрне күрделәр. Уртадагысы – иң зурысы, аның алтын түбәсе кояш нурларында ялтырый, юлчыларның күзләрен камаштыра.

Баштарак Тверь халкы Михаил кенәзне Урдага хан хозурына җибәрергә теләмәде. Яу килә калса, яраткан кенәзләрен якларга чыгарга әзер иде алар. Тик Михаил моның белән килешмәде, нахак гаептән үзен Ходай саклар дип өметләнде. Хан станына якынайган саен, аның исән калуына ышанычы кимегәннән-кимеде. Җәйнең соңгы көннәре, көз җитүе һавадагы салкынлыктан ук тоемлана. Аның да кояшы баю ягына юнәлдеме? Тверь, Владимир кенәзлеге белән бәйле якты хыяллары беркайчан да тормышка ашмасмы? Ничек кенә булмасын, Тверьдә яу килгәнне көтеп калтыранып ятканчы, хан каршына барып, аның хөкемен тизрәк ишетү яхшырак кебек. Туган җиренә дә монгол явын кертмәс, кенәзлеген талауга, халкын үтерүгә юл куймас. Ә калганы... Калганы Ходай кулында, язмышка буйсынырга гына мөмкин.

Михаил кенәз төркемен стан ягыннан чаптырып килгән нүкәрләр уратып алды һәм үзләре артыннан ияртте.

– Хан әмере белән без сине сакларга тиеш, – диде нүкәрләр башлыгы Арык Буза. – Качып китәрсең дип курыкмый ханыбыз, аннан котылырлык кыйтга җир йөзендә юктыр. Үзеңә башкалар зыян салмасын, көндәшең Юрий белән орыш чыкмасын өчен куелдык. Сиңа һәм озата килгән кешеләреңә тирмә әзер. Ханның, вакыты табылып, үз янына чакыртуын шунда көтәрсең.

– Каугадый биредәме соң?

– Мин сорауларга җавап бирүче түгел, рус кенәзе. Син үзең безнең каршыда җавап тотарга килдең.

Михаил янә уйга калды. Әсир дә итмиләр, алтын читлектән дә чыгармыйлар. Аның хөкем алдына басарга тиешлеге дә Урда халкына мәгълүм. Икенче яктан уйлап карасаң, килә-килешкә арканлап алмадылар, хөрмәт белән эндәшәләр, табыннары да әзер. Үзбәк ханның башында нинди уйлар икән? Михаил бу фалларны барыбер яхшыга юрады. Һәрхәлдә, Урда солтаны Тверь кенәзенә үз фикерен әйтергә мөмкинлек бирә, ә бу исә яклау табуга өмет чаткысы калдыра...

Ике ут арасыннан чыгып, ханның купшы тирмәсе бусагасын атлап кергәч, Михаил, гадәттәгечә, тез чүкте, бүләкләрен тапшырды. Үзбәк бүләкләргә карамады да, битараф кыяфәт белән тәхетендә утыра бирде. Ул бик тыныч күренә. Михаил кыюлыгын җыйды. Әгәр бу мизгелдә Үзбәкнең йөрәгендә нинди утлар янганлыгын белсә, чәчләре үрә торыр иде. Хан, сеңлесен теге дөньяга озаткан кеше тирмәдә пәйда булгач та, аны кылычы белән тураклап ташларга ниятләде. Нәфрәте чиксез иде бу бәндәгә. Тик тыелып калды, алай гына да түгел, бер генә хисен дә тышка чыгармады. Йөрәгендәге ачу Мәскәү кенәзе Юрий һәм Каугадый тарафыннан салынгалыгын яхшы аңлый иде Үзбәк хан. Тверь кенәзенә озаграк дәшми карап торгач, җаны янә бер мәртәбә әйләнде. Михаил ханга туры карый, карашында курку да, астыртынлык та юк. Юрий белән Каугадый коткысына гына бирелеп, ялгышмыймы икән Үзбәк? Михаилны нахакка рәнҗетеп, күңеленә авыр гөнаһ алмасмы?

Сүзсез торуның озакка сузылуын чамалап, Үзбәк Михаилга эндәште:

– Ни әйтергә килдең, Тверь кенәзе?

– Дөньяның иң зирәк һәм көчле хакиме, кыш белән җәйне бер вакытта күрүче җирләр хуҗасы, мөселманнар һәм насаралар яклаучысы, бөек солтан, мәрхәмәтле Үзбәк ханым! Синең каршыңа килеп, үземә карата әйтелгән гаепләүләрнең ялганга корылуын җиткерәм. Динебез өчен җәфа чигеп үлгән Христос тәресен үбеп ант эчәм, синең сеңлең...

Үзбәк хан, кинәт кулын күтәреп, җитте дип ишарәләде. Сеңлесен искә төшерү белән, янәдән өянәге кузгалды, йөзе авыр кайгыдан чытылды.

– Синең гөнаһларың шактый, Тверь кенәзе Михаил. Син аларның һәммәсе буенча да җавап тотарга әзерме?

– Әзер, бөек ханым! Әгәр гаебем расланса, язмышымны үзең кирәк санаганча хәл ит. Ләкин һәрбер гаепләүгә дә җавабым бар.

– Бәдретдин казый, бире кил! – диде Үзбәк хан.

Башына зур ак чалма чорнаган, өсте-башы гел актан гына булган урта яшьтәге ир-ат тәхет янына ашыкты.

– Тыңлыйм сине, бөек ханым, – диде ул.

– Тверь кенәзе Михаил нинди гөнаһлар кылуда гаепләнә, исебезгә төшер.

– Баш өсте, бөек ханым. – Бәдретдин казый кулындагы кәгазьне ачып җибәрде, тураеп басты һәм тантаналы тавыш белән укырга кереште: – Бик күп чыганаклардан мәгълүмат җыйганнан соң, йөзләрчә кешенең аңлатмаларын тыңлаганнан соң, Тверь кенәзе Ярослав угълы Михаилга карата без түбәндәге гаепләүләрне ирештерәбез: ул ханга җибәрелергә тиешле ясакның бер өлешен үзенә алып калган; әлеге байлыкларны Ливониягә, Урда дошманнарына илтеп тапшырган; баскаклардан һәм күршедәге кенәзләрдән акча алып торып, бурычын кайтармаган; үзенә буйсынган кенәзләргә карата җәбер-золым кылган; бөек хан җибәргән гаскәргә һөҗүм иткән һәм...

Соңгысын укыргамы-юкмы дип, Бәдретдин казый төртелеп калды, күз чите белән генә Үзбәк ханга караш ташлады. Хаким тыныч кебек иде.

– ...Һәм, бөек ханым, Тверь кенәзе Ярослав углы Михаилның иң зур гаебе – астыртын рәвештә Урданың сөекле кызын үтерү...

Хан тәхетеннән торды. Карашы авыр һәм кайгылы иде.

– Урданың сөекле кызы – минем яраткан бертуган сеңлем. Бу җинаять өчен мин гадел хөкем чыгара алмыйм, чөнки хисләрем акылымнан алда йөри. Безнең дәүләтебез исә гаделлеккә һәм мәрхәмәткә корылган. Моны изге Коръән китабыбыз да таләп итә. Шушы фикерләргә таянып, мин әмеремне әйтәм. Баш казый Бәдретдин, үзе белән тагын берничә казыйны алып, хөкем эшенә керешсен. Гаепләнүченең барлык әйткәнен дә дикъкать белән тикшерегез, дәлилләрен өйрәнегез. Шаһитлар булса, аларны да чакырыгыз. Хөкем кылу өчен станнан читтәрәк тирмә корыгыз, аны ныклы сак астына алыгыз. Беркем дә килеп, казыйлар эшенә тыкшынмасын, бу тәртипне бозганнарга – үлем. Гаебе расланмаган икән, Тверь кенәзе Михаил шикле кеше генә булып кала. Аны торак һәм ризык белән җитәрлек күләмдә тәэмин итегез. Хөкем җентекләп үткәрелсен, минем беркая да ашыгасым юк. Сүзем тәмам.

Бу сүзләрне төрле кеше төрлечә кабул итте. Михаил кенәз, рәхмәт

йөзеннән, җиргә кадәр башын иде. Каугадый куркуыннан тирләп чыкты. Баш казый исә, үзенә күрсәтелгән олы дәрәҗәгә шатлануын яшерми, хан кушканны үтәргә ашыкты.

Михаил кенәз үзенең тирмәсенә кайтты. Улы Константин белән боярлар аны түземсезлек белән көтеп торалар иде. Тверь хакиме хан тарафындагы очрашу хакында аннан-моннан гына сөйләп бирде, елмаерга тырышты. Иң мөһиме – хан гадел хөкем вәгъдә итте. Хәзер үзен якларлык кешеләрне табарга кирәк.

– Хан янәшәсендә бик кодрәтле хатын бар, аның исеме Баялун, – диде Константин. Тормыш аны вакытыннан алда картайткан. Бу аның төскыяфәтендә дә, фикер йөртүендә ярылып ята. – Рус җиренә хәерхаһлы дип тә сөйлиләр.

– Нишләргә кушасың, Константин?

– Баялун хатынга баш орып, аннан яклау сорарга кирәк. Ул ханны мәрхәмәтле хөкем кылырга инандырыр.

– Хөкемне хан түгел, баш казый чыгарачак.

– Баялун хатынның сүзе кайда да үтә. Аларга да йогынты ясар.

– Белмим тагын, Константин. Һәрхәлдә, мин хан хатыннары тирмәсенә керә алмыйм, минем арттан нүкәрләр күзәтеп тора...

Константин нык бер карарга килде:

– Үзем барам! Кирәк икән, мине мәңгегә Урдада әсир хәлендә калдырсыннар, әманәт итсеннәр, әмма син исән-сау килеш Тверьгә кайтырга тиеш, әтием!

Соңгы вакыттагы хафалардан нык ябыккан, әлсерәгән Михаил кенәз көчсез куллары белән улын кочып алды:

– Барысы да Ходай кулында, балам. Әгәр җиребез, динебез өчен шушында үләргә насыйп икән, аны үзгәртү мөмкин түгел.

– Ләкин кул кушырып утырырга да ярамый. – Константин җитди кыяфәт белән боярларга борылды. – Василий бояр, син соңгы елларда җыелган ясак күләме теркәлгән кәгазьләрне барлап чык. Аларда барысы да төгәл язылган. Иван дәдәй, Каугадыйның Юрий кенәз белән бергә яуга килүен расларлык дружиначыларны тап. Көнчәага тотылган бүлмәне саклаган егетләрне алып килдеңме, әти?

Михаил кенәз моңаеп калды:

– Алар сәер рәвештә юкка чыкканнар, улым. Эзли башлаган идек, берсе дә урынында юк. Тверь якларында күптән түгел Порфирий атлы бәндә юлбасарларын күргәннәр. Бәлкем, алар теге сакчыларның башына җиткәндер. Кемдер махсус яллап җибәргән, ахрысы, аларны.

– Кем икәнлеге билгеле – Каугадый белән Юрий кулы уйнаган биредә. Александр воеводаны җибәреп, Порфирийны башкисәрләре белән бергә эләктереп, бирегә алып килергә кирәк.

– Табарсың, ди, аларны...

– Эзләгән табар, әти! Эшкә керешик, кайгыдан каңгырап утыру ирләр гамәле түгел!

Баялун хатын урыс кенәзенең улы Константинны кабул итәргә вакыт тапты, әмма өздереп кенә, буш вәгъдәләр бирмәде. Хан үзенә сирәк якын җибәрә, Тайдулага да соңгы вакытта Үзбәк ачулы. Икесенең берсе Михаил

кенәзне яклап сүз әйтерлек түгел иде. Шулай да, Баялун үз янына баш казый Бәдретдинне чакыртты.

– Тверь кенәзен нинди хөкем көтәчәк, Бәдретдин казый? – дип сорады ул каршысында чалмалы башын иеп торган дин әһеленнән.

– Анысы Тверь кенәзе кылган гамәлләрнең авырлыгына бәйле булачак, сөекле Баялун хатын. Эшкә керешми торып, моны әйтүе авыр. Әмма Михаил кенәзнең гөнаһлары бик авыр, әгәр аларның берсе генә дә расланса, ул Урдадан исән-имин китә алмас.

– Аңа нахак гаеп ягалар түгелме соң?

– Эшне тикшерү барысын да ачыклар. Мин үзем генә түгел, мөхтәрәм Баялун хатын, миннән кала тагын алты тәҗрибәле казый әлеге мәсьәләне җентекләп өйрәнә. Күңелегез тыныч булсын, ханны да, сезне дә гаделсез дип атарга урын калмас.

**10**

Михаил кенәз хөкемдарлар каршына басты. Ул тирмәгә җыелган кешеләрне күздән кичерде. Башларына зур ак чалмалар ураган ил картлары утыра. Җәмгысы җиде дин әһеле. Урдага алар төрле кыйтгалардан җыелган, шуңа, һәрберсенә ярарлык итеп, берничә телдә сөйләшүче тылмачлар куелган.

Төп гаепләүче вазифасы Каугадыйга йөкләнүен белгәч, Михаил куырылып килде. Шул мөртәт аның табынында утырган көе Юрийны уңлы-суллы яманлады, Михаилга хөрмәте зур дип, антлар эчте, капчык-капчык бүләкләр төяп китте бит! Бу икейөзле бәндәгә үпкәсе кайнап чыкты, гарьлегеннән әллә ниләр әйтәсе иде дә, тыелып калды.

Кан дошманы – Мәскәү кенәзе Юрий да бирелә. Ул да Михаилга каршы якта, гаепләүчеләр исәбендә.

Баш казый Бәдретдин белән бергә утырган руханилар озаклап дога укыды, чиратлашып, Коръәнгә уң кулларын куеп, гадел хөкем чыгарырга вәгъдә бирделәр. Бик озакка сузылган керештән соң гына эшне тикшерү башланып китте.

Каугадый, әле бер яктан, әле икенче яктан төшеп, Михаилны таларга маташса да, күп нәрсәгә Тверь кенәзенең җавабы бар иде. Бик вакчыл кеше, ул күпме ясак җыелуын, кемнән бурыч алып, кайчан кайтаруын җентекләп кәгазьгә теркәгән. Әлеге язуларны казыйларга тапшырды. Һәрбер битендә ясак бирүчеләрнең, баскакларның кул тамгалары бар иде.

Хөкем көннәр, атналарга гына түгел, айларга сузылды.

– Кайчан бетә инде бу мәсхәрә?! – дип, Михаилның сызлануы белән улы Константин килешмәде.

– Әти, хөкем озаккарак сузылган саен безгә кулайрак. Ул арада шаһитларыбыз артыр, сине якларлык кешеләребез күбәер.

– Үлемеңне көтү үлемнең үзенә караганда авыррак икән, улым. Иманым камил, мине исән килеш чыгарып җибәрмәсләр. Каугадый бик мәкерле эш итә, әле алай, әле болай боргалана. Чиста күңел белән тизрәк Ходай хозурына китеп баруың мең кат кадерлерәк, көн саен казыйлар каршында акланып тәмам туйдым...

...Үзбәк хан, атына атланган көе, киң далага чыкты. Аның артыннан

күпсанлы тәнсакчылары ияргән иде. Көн матур, чалт аяз! Һәм ул, яшь чагын исенә төшереп, хакимлек йөгеннән, бер генә мизгелгә дә ялгызын калдырмый торган яраннарыннан арынырга уйлады. Кинәт кенә малкаен кызу итеп юрттырып җибәрде, ханның мондый кыланмышын көтмәгән сакчылар ни эшләргә белми бер урында таптанып калдылар.

Шактый вакыт дала буйлап чапканнан соң, Үзбәк хан артына борылып карады. Нүкәрләр күренми, аның җитез атына тиңдәш табылмаган. Ул юртагын тыныч адымга күчерде. Тирә-як бик тын, чикерткәләр черелдәве генә ишетелеп тора.

Кинәт Үзбәк хан каршыда ниндидер түмгәк күреп алды. Атын шунда юнәлтте. Якынрак килеп, ияреннән сикереп төште. Түмгәк түгел иде бу. Аның каршында Караның киселгән башы ята иде!

Тәнсез башның күзләре ачылды, ул телгә килде:

– Бөек ханым, гафу ит, сиңа бил бөгә алмыйм... Сине вакытсыз ташлап китүемә ачулана күрмә.

– Кара, кем кылычтан үткәрде сине?

– Мин хәзер бик тыныч урында, хакимем. Йоклыйм инде, арыдым мин...

Кара күзләрен йомды. Үзбәк, ни уйларга да белмичә, артына борылды һәм сискәнеп китте. Аңа терәлеп диярлек Илбасмыш басып тора. Ул баштанаяк канга баткан, Үзбәккә сыңар күз белән карап тора, икенчесе каезлап алынган.

– Ни кирәк сиңа?! – Үзбәк, коты алынып, Илбасмышка текәлеп катып калды.

– Миңа берни кирәкми, Үзбәк. Ә менә сиңа ни җитми?

Илбасмыш Үзбәккә таба атлады. Канга буялган кулларын аңа сузды. Тагын бер мизгелдән ханның муенына ябышырга әзер иде... Шабыр тиргә баткан хәлдә Үзбәк хан үзенең тирмәсендә уянып китте. Ул, төшендәге куркудан айнып бетә алмый, янәшәсендә яткан хәнҗәрен тартып чыгарды, берәр явызы юкмы дип, тирмә эчен күзләде. Ялгызы иде хан.

Кичке якта хан баш казый Бәдретдин белән бергә Каугадыйны һәм Исабәк нәибне кабул итте. Тверь кенәзе Михаил өстеннән хөкем тәмамланган, гаепләнүчегә карарны игълан иткәнче, аны хан белән килештерергә керделәр.

– Гадел ханыбыз солтан Мөхәммәд Үзбәк хан! Синең әмерең белән без, җиде казый, Тверь кенәзе Ярослав улы Михаилның кырын гамәлләрен һәм авыр җинаятьләрен һәрьяклап тикшердек. Кайбер гаепләүләр, чыннан да, нахак булып чыкты. Ләкин иң авырлары расланды. Михаил үзенең күршесендәге кенәзләрне талап яшәгән, аларны куркытып тоткан. Әледән-әле чит биләмәләргә гаскәре белән бәреп керергә гадәтләнгән. Дөрес, Урдага ясак түләү мәсьәләсендә хилафлыклары юк, әмма таланган малны үзендә калдырган. Аның күләмен тәгаен генә ачыклап булмады. Шулай да, бу хан казнасына керми калган байлыклар дип уйларга кирәк. Тверь җирләре аша Мәскәү кенәзе Юрий дружинасын ауга озата барган вакытта синең сәргаскәрең Каугадыйга явызларча һөҗүм иткәнлеге расланды. Урда вәкиленә кул күтәрү зур гөнаһ, моның өчен җәзага тартмасаң, башка кенәзләр дә азынырга мөмкин, бөек ханым. Иң авыр җинаяте исә – хан нәселеннән булган сөекле кызыбызны әсирлеккә алып, зинданда җәзалап

үтергү. – Бәдретдин казый, тамагын кырып, ни әйтерсең дип, Үзбәк ханга текәлде. Тегесенең йөзе уйчан һәм тирән борчулы иде.

Үзбәк янәдән бүген таң алдыннан күргән төшен барлады. Йокысын бүлеп йөрүче әрвахлар, һичбер шиксез, аны кисәтергә килгән. Кара исән түгел, димәк, кемдер махсус рәвештә аның башына җиткән. Илбасмыш исә Үзбәкне ашыгыч һәм ялгыш карардан сакланып калырга өндәде шикелле.

– Дәлилләрегез төплеме?

– Төпле, бөек ханым. Без Михаил кенәз китергән барча язуларны өйрәндек, аның ягын яклаган барча шаһитларны да тыңладык. Хөкемебез гадел дип, Коръән белән ант итә алабыз.

Үзбәк янә уйга калды. Бәдретдин казый Изге Китап белән уйнамас. Тик күңелендәге шикләре артык көчле.

– Эшне яңабаштан тикшерегез! – диде ул аптырап калган баш казый белән сәргаскәренә. Исабәк тә нык гаҗәпләнде, барысы да уч төбендә төсле аңлаешлы кебек бит!

Баш казый Бәдретдин ханның әмерен үтәргә ашыкмады.

– Михаил кенәз үлемгә хөкем ителергә хаклы. Олы явызлыклар кылган кеше ул. Син боерасың икән, без бу эшне яңабаштан тикшерербез. Тик Тверь кенәзе безнең каршыга богауланган килеш бассын. Аның, гаепле булып та, ирektә йөрүе беренче чиратта синең дәрәҗәңне яман төшерә. Бөек ханыбыз һәм халкыбыз намусын чиста килеш саклау – безнең изге бурычыбыз...

– Мин Михаил кенәз янында үзем булдым, – дип сүз кыстырырга җөрьәт итте Каугадый. – Аңа ышанырга ярамый, сөекле ханым. Сарык тиресе ябынган бүре ул, сине матур сүзләр белән җайлап, үзе астыртын төстә золым кылып йөри...

– Теләсә нишләгез, ләкин Михаил кенәзне гадел хөкем итегез, – дип кырт кисте Үзбәк хан. – Сүзем тәмам.

Михаил кенәзнең тирмәсенә нүкәрләр кереп, кулларын һәм аякларын богауладылар. Кенәз карышмады, язмышы хәл ителүен ул күптән сизенгән иде.

– Көннәрем төтен кебек таралды һәм хыял төсле юкка чыкты, – диде ул күзләренә яшь тулган улы Константинга. – Хаиннар алдында акланып булмады, Ходай каршына пакь күңел белән барам. Гайсә пәйгамбәр дә шушы юлны үткән. Һәр чорның үз корбаны була икән...

Җомга көнне Михаил кенәз янәдән хөкем каршына басты. Беренче тапкырдан аермалы бер генә нәрсә – аның куллары һәм аякларындагы богаулар. Карар үзгәрешсез калды.

Баш казый Бәдретдин белән Каугадый кабат хан хозурына килделәр. Үзбәк хөкем карарын янәдән тыңлады.

– Әгәр сез Михаил кенәзне гаепле дип таныгансыз икән, үзегез белгәнчә аның язмышын хәл итегез. – Үзбәкнең уйлары бу мизгелдә әллә кайда читтә йөри төсле иде.

– Без хәзер дә аны үлемгә лаеклы җинаятьче дип күрәбез. – Баш казый икеләнерлек урын калдырмады.

– Бөек ханым, син рөхсәт итсәң, Михаилны бүген үк җәзага тартырга тәкъдим итәм. – Каугадыйның тавышында түземсезлек ярылып ята, Тверь кенәзен болай озаклап исән килеш тоту аның үзәгенә үткән төсле.

– Ашыкмагыз, – диде Үзбәк хан. – Исабәк, бире кил!

Исабәк хан каршында башын иде.

– Исабәк, станны ауга чыгарга әзерлә. Терек елгасы буйларына барасым, мәгърур Кавказ тауларын күрәсем килә. Тверь кенәзен дә алырсың. Бәлки, акылына килеп, казыйлар атап үткән явыз адымнарын ни сәбәпле кылуын аңлатырга кыюлык табар.

– Баш өсте, бөек ханым! Михаил кенәзне богауларда алып барасымы?

– Канга тозагына утыртыгыз. Теле ачылыр өчен аннан да яхшысы булмас.

Михаил кенәз чатырына янә нүкәрләр килде. Алар сүзсез генә тоткынның богауларын салдырдылар. Аннан соң канга кертелде. Канга ике авыр агач кисәгеннән ясалган. Уртада – муен, ике якта куллар өчен тишекләр калдырылган. Такталарны икегә аерып, шул тишекләргә Михаил кенәзнең муенын һәм кулларын керттеләр, аннан соң ике тактаны бер-берсенә ныклап беркетеп куйдылар. Канга авыр һәм уңайсыз иде. Такталардагы шырпылар кулына, муенына кадалды, ләкин Тверь кенәзе тешен кысып түзде. Әтисенең мескен хәлен күреп, күз яшенә буылган Константинга ул сабыр булырга кушты, аннары, хәленнән килгән рәвештә утырып, аркасын чатыр баганасына терәде. Дөресрәге, аркасы баганага җитмәде, канганың арткы өлеше төртеп тора иде. Шулай да, Урдага Кытай якларыннан китерелгән бу җәза чарасына бераз булса да күнегергә мөмкинлек туды. Ике кулы белән берни эшли алмый – алар, өскә күтәрелгән хәлдә, ике яктан канга тактасындагы тишекләрдән тырпаеп торалар.

– Псалтырьне китер, улым, – дип пышылдады Михаил кенәз. – Изге китапны укысам, бәлки, хәлем җиңеләер, үлемем дә тизрәк килер. Ходайдан шуны сорармын. Син исә, Константин, исән кала алсаң, абыең белән берлектә Порфирий атлы юлбасарны эзләп табарга тырыш. Исән килеш хан янына алып килегез. Порфирий үзен кемнәр яллаганын да, нинди йомыш кушканнарын да белә. Юлбасар – куркак җан, мондый канга ише нәрсә белән өркетсәләр, барысын да сөйләп бирер. Без, күпме генә эзләсәк тә, ул сатлыкны тота алмадык. Ләкин бөтен серләр дә нәкъ менә анда...

Хан станы янә хәрәкәткә килде. Бу кәрвандагы бер олауда улы Константин, берничә бояры һәм хезмәтчесе белән бергә Тверь кенәзе Михаил да бар иде.

Михаилның сабыр канатларын сындырыр өчен Каугадый әмере белән әледән-әле кенәзне олау артыннан җәяү атлаттылар. Аның киемнәре тетелеп бетте, шыр сөяккә калган аяклары көч-хәл белән хәрәкәт итә, чәчләре, сакаллары озын булып үсте, ул исән килеш өрәккә охшап калды. Кыска гына вакытка тоткынны кангадан азат итеп торалар иде. Ул вакытта да кул-аяклары богауланган килеш калды. Егерме биш көн дәвамында Михаил кенәз әнә шулай мәсхәрәләнгән хәлдә ауга ашыгучы хан артыннан өстерәлде.

Үзбәк хан Тверь хакименең ни хәлдә булуы хакында хәбәрдар, әмма аны үлемгә тартырга ашыкмады. Ауда күңеле ачылыр дип өметләнде, Ходайдан берәр төрле билге көтте. Ләкин Аллаһы Тәгалә бернинди ишарәләр дә җибәрмәде, әллә Кавказ һавасының тәэсире – хан хәтта төшләр дә күрмичә тынычлап йоклый иде.

Михаил кенәзгә карата нинди гамәл кылырга? Ничек гомерлеккә үкенечкә калырлык ялгышлык җибәрмәскә? Хан тирәлеге Тверь кенәзенә

чыгарылган хөкем карарын яхшы беләүк. Халык арасында һәртөрле чышын-пышын сүзләр йөрүе дә мәгълүм. Үзбәк хан бертуган сеңлесе өчен үч аласы урынга куркаклык күрсәтә дип сөйләшәләр икән яраннары. Аларга нәрсә, кызык кына булсын. Рус кенәзе үлеме дә тормышларындагы сансыз тамашаларның берсенә генә әйләнеп калачак. Ә менә үлем карарын Үзбәк хан расларга тиеш, аның өчен җаваплылык казыйлардан бигрәк Урда хакиме намусында... Тик артыгын сузарга ярамый...

...Михаил кенәз кангага богауланган рәвештә изге Псалтырь укый иде.

– Тагын бер битне ач, улым, болары тәмам, – дип, ярдәм сорап эндәште ул Константинга. Аннан соң, чак кына ишетелерлек итеп пышылдап укуын дәвам итте: «Сердце мое смутися во мне, и страх смертный прииде на мя...»

Чатыр ишегендә авыр сулап, кызарып чыккан хезмәтчесе Святослав күренде.

– Каугадый белән Юрий бирегә киләләр, бөек кенәз! – диде ул, җөмләсен бер тында әйтеп салып.

Константин агарынып чыкты. Михаил сер бирмәде.

– Псалтырьне алып куй, изге китап таплана күрмәсен, – диде Михаил һәм Константин ярдәме белән торып басты. – Ни өчен килүләрен беләм мин аларның. Көтә-көтә зарыгып беттем инде...

Тоткынның чатырын, махсус рәвештә, станның үзәгенә якын төшкә, сәүдә алып барыла торган мәйдан янына куйдырганнар иде. Михаил моның сәбәбен ул вакытта ук аңлады – бөтен халык алдында мәсхәрәләп үтерер өчен шулай иттеләр. Әллә кайдан мәйданга өстерәп йөрисе юк иде тоткынны.

– Михаил кенәз! Хан әмере буенча расланган хөкем карарын кабул итәргә чык! – дип яман тавыш белән урамнан ук кычкырды Каугадый.

Михаил чатырдагыларны күздән кичерде. Улы Константинга озак кына карап торды.

– Минем язмыш хәл ителгән, үз башыгызны саклагыз. Улым, Баялун хатын тирмәсен эзләп тапсаң, хәерлерәк булыр. Каны кызган хаиннар аны-моны уйлап тормый, суеш башларга да күп сорамас. Баялун хатын сезне җәберләргә ирек бирмәс... Бәхил булыгыз, Тверьны саклагыз, туганнарым!

Михаил кенәз тирмәсе бусагасыннан атлап чыгу белән, ике әзмәвер нүкәр аны кангасы читләреннән эләктереп алып, бар көчләреннән этеп җибәрде. Кенәз тузанлы җиргә барып төште, тик тиз арада торып басарга көч тапты. Тагын берничә нүкәр йөгереп килде, янә җиргә аудардылар. Бу юлы инде аңышырга ирек бирмәделәр. Башта йодрыклары, аннан соң аяклары белән үтергәнче кыйнадылар, изделәр. Тверь кенәзенең җаны чыкканлыкка инангач исә, канганы салдырып, кулларын аркан белән бәйләделәр дә, атлы нүкәр, тузан туздырып, мәетне стан тирмәләре арасыннан тарттырып китеп барды.

Бу тамашаны карап торган Юрий кенәзнең йөзендә елмаю күреп, Каугадый, ачуланып, төкереп үк куйды.

– Дошманың мәрхүм, шуңамы шатлыгың?! Син аны хөкемгә тарту өчен ни эш кырдың соң?!

– Каугадый, синең көч белән күп нәрсә башкарылганын мин яхшы беләм. Бер дә борчылма, буш итмәм, бүләкләрне мулдан алырсың! – диде Юрий, Каугадыйның шелтәсеннән кыенсынып.

– Бүләк, бүләк! Атлан атыңа, хезмәтчеләреңне ал, Михаилны чүл бүреләренә ризык итеп калдырырга ярамас. Кенәз иде ул, аның артында үзенә тиң батыр сугышчылары торды, туган җирен соңгы сулышына кадәр саклады. Киттек, мәетен алып кайтыйк!

Михаилның мәетен станнан ерак түгел бер чокырда таптылар. Кыйналган, бәргәләнгән, аны инде танырлык түгел иде.

– Нәрсә акаеп бактың?! – дип җикеренде Каугадый, ияреннән сикереп төшеп. – Мәетне каплагыз, ул сине барыбер энекәше төсле хөрмәт итте бит!

Юрий кенәз хан сәргаскәре боерганны үтәргә ашыкты. Ләкин ул үзе Михаилның үлегенә дә тынычлык бирергә җыенмый иде. Мәетне бер такта кисәгенә бәйләп куеп, Мәскәүгә озаттылар. Михаилның җәсәде бары тик бер елдан гына Тверь җирләрендә соңгы сыену урынын тапты. Юрий әмере белән ул Тверь белән Мәскәү арасында сатулашу чарасына әверелде. Нәтиҗәдә, Тверьләр Мәскәүнең таләпләренә түбәнчелек белән күнеп, данлыклы кенәзне үзләренә алып кайтып җирли алдылар...

Юрий кенәз Үзбәк хан кулыннан рус җирләрендә бөек кенәзлеккә ярлык алып, кире Мәскәүгә кайтып китте. Ләкин күптән көтелгән һәм өметләнгән тамганы Урда хакиме кулыннан кабул иткәндә, Юрий аның күзләрендә үзенә карата ихтирам да, ышаныч та тоймады. Киресенчә, хан бик нык уйчан һәм битараф иде.

## БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Юрийны озаткач та, Үзбәк хан, киңәш-табыш итәргә дип, Хәрәземнән Котлы Тимерне чакыртты. Алар өчәү генә җыелыштылар – Үргәнечтәге бәкләр-бәгеннән кала Исабәк нәибне генә дәште хан.

– Рус олысына тынычлык иңдерергә кирәк, – диде Үзбәк хан, маңгаендагы җыерчыкларын бармаклары белән сыпыргалап. – Тверь кенәзе Михаил үләр алдыннан васыять калдырган. Анда Тверьнең төп өлеше – олы улы Дмитрийга, көньяк тарафлары – уртанчы улы Александрга, төньяк-көнбатышы – Константинга, көнбатыштагы җирләре төпчек Василийга тапшырылырга тиешлеге әйтелгән. Мин мәрхүмнең соңгы васыяте белән килештем... Михаил кенәзнең балаларына комачауларга җыенмыйм, этиләреннән калган малны бүлеп, тик яшәсеннәр, үзара сугышып кына ятмасыннар. Мине бүген рус олысының көнбатышындагы хәлләр күбрәк борчый. Литвалылар кенәзлеге көч җыя, Польша белән Венгрия баш күтәрә, алар рус кенәзлекләре җирләренә күз төшереп торалар. Ә бу – Урданың үзенә дә янау дигән сүз. Минемчә, без бары тик рус олысын ныгытып кына көнбатыштагы дошманнарны җиңә алачакбыз.

– Рус кенәзлекләрен ныгытуың аларның безгә каршы баш күтәрүе белән тәмамланмасмы, бөек ханым? – дип сүз кыстырды Котлы Тимер.

– Мине рус җирләрендә әүмәкләштереп, Иран илханнарын исән калдырасың килә инде, – дип, теле белән Котлы Тимерне чагып алды Үзбәк хан. Аннан, сүзне артык куертмаска карар кылып, тыныч кына дәвам итте: – Андый куркынычны мин күрмим. Бүген, ни кызганыч, рус җирләрен берләштерерлек кеше юк. Мәскәү кенәзе Юрийга ярлык бирдем дә, ул артык җебек кешегә охшап тора. Буйдак та, җитмәсә... – Үзбәкнең

йөрәгенә янәдән Көнчәаганы күз алдына китерүдән кан саркыды. – Бер кызы гына бар, малайлары юк.

– Мәскәүдә Юрий югында хакимлек итүче энекәше яши, Иван исемле. Аның ике малае үсеп килә, үзе дә акыллы, дип сөйлиләр. Митрополит та үзен бик якын итә икән. – Исабәк нәиб тә үзенең рус олысларындагы хәлләрдән хәбәрдар булуын күрсәтергә ашыкты.

– Иван дисең, алайса? Ярый, биһуш. Җае чыгып, аның белән очрашу мөмкинлеген оештырыгыз. Һәрхәлдә, Юрий кенәзгә минем хәерхаһлыгым тәмам... Тик шулай да, рус биләмәләренең үзара тату яшәве мөһим. Аларның тарткалашыннан Урдага зыян күбрәк булачак. Шуңа күрә Мәскәү белән Тверьне килештерер өчен, ике арада берәр никах кирәк. Юрийның Софья атлы кызы бар дип беләм. Константин шактый күндәм егеткә охшаган иде. Аны Софьяга ярәштерегез, Тверьгә дә, Мәскәүгә дә моның минем әмерем булуын җиткерегез. Литвалылар хакиме Гедиминның да кызы җитлегеп килә. Тверьдә утыручы Дмитрий аңа өйләнсә, рус олысына бер бәла кимеп торыр иде. Атып очкан укка караганда табын янында туйлап утырудан бермә-бер файда тияр. Мәмләкәтебезнең хөрлеге өчен барлык мөмкинлекләрне дә кулланырга кирәк...

Кечкенә генә киңәшмәдә барган җитди сөйләшүне бусагадан атлап кергән әвнух Мостафа бүлдерде. Урталай бөгелгән килеш катып калып, ул:

– Гафу итә күр, бөек ханым, зинһар, гафу итә күр! Асма да, кисмә, турама да, кылычтан да үткәрмә, бик мөһим сүзем бар, шуны гына тыңларга вакыт тап, зинһар! – дип лепердәде.

– Мостафа, ниткән хәл бу тагын?! Син безнең сөйләшүне тыңлап тордыңмы әллә?! – Үзбәк ханның йөзе үк чытылып килде, шундый мөһим фикерләр хакында гәпләшкән вакытта мәхлук әвнухның тыкшынуы яман ачуын куптарды.

– Синең сүзеңне бүлдереп керүемнең җитди сәбәбе бар, бөек хакимем! – Мостафа үзенең хаклы гамәл кылуына тәмам инанган бугай, тураеп ук басарга җөрьәт итте. – Сөекле ханым, солтан Мөхәммәд Үзбәк хан, әле генә синең хатының Тайдула Урдабызга ханзадә бүләк итте! Синең улың дөньяга килде!

Үзбәк хан дөньясын онытты. Ул, тәхетеннән сикереп торып, кош тоткан бала сыман:

– Ханның улы туды! – дип шәрран ярды. Аннан Исабәккә борылды: – Шатлыклы хәбәр алып килгәне өчен Мостафаны ханнарча бүләкләргә! Сабыем белән аның әнисе исән-саудыр бит, Мостафа?

– Шөкер, икесе дә таза-сау, бөек хан! Улыңның тавышы да синеке төсле, диварларны дер селкетә торган, сөбханалла!

– Котлы Тимер, Исабәк, киңәшмәбез шуның белән тәмам. Фикерләрегезне ишеттем, рәхмәт.

– Ыруың арту белән котлыйм, бөек хан! – Котлы Тимер Үзбәк каршында тез чүкте.

– Нәсел дәвамчыларыңның ишәюе дәүләтебезгә муллык китерсен, солтаным! – Исабәк тә бәкләр-бәгенең үрнәгенә кушылды.

Үзбәк хан аларны ишетми иде инде. Ул, ашыга-ашыга, Тайдуласы тарафына ашыкты. Мостафа әвнух аның артыннан калмаска тырышып

йөгерә, «бигрәк матур егет», «гел үзеңә охшаган» дип әйткәләп, ханына ярарга тырыша.

Хан килеп кергәндә, Тайдула янәшәсендә кендек әбисе Ширин карчык кына калган иде. Әни кеше арыган хәлдә бөгәрләнеп яткан, орчык кадәрле генә сабые аның мул сөттән тулышкан күкрәгенә ябышкан, кечкенә учларын өскә күтәргән дә, үзенә туклану өчен беренче ризыкны табарга маташа. Ханны бусагада күргәч тә, Тайдула, арыганлыгын да онытып, елмаерга маташты.

– Гафу ит, җанкисәгем, сине торып сәламли алмыйм бүген...

– Ни сөйлисең син, Тайдула?! Бүген синең алдыңа бөек хан үзе тезләнергә хаклы!

Ширин карчык, биредә калырга ярамаганлыгын аңлап, ишеккә ашыкты, үзе белән бергә Мостафаны да әләктерде. Тегесе китәргә теләмәгән иде, ләкин кендек әбисе елан шикелле бер генә ысылдап куйды – әвнухның шунда ук йөзе үзгәрде. Үзбәк, Тайдула һәм яңа туган сабый өчәү генә калдылар.

– Ул синең шикелле үк көчле, – диде хатыны, күзләре чак кына ачылып килгән нарасыйга ымлап. – Үзенең малын белә, кендегә киселгәч тә беренче шәпкә үк күкрәгемә омтылды.

– Сөбханалла! – Үзбәк кинәт яшьлегенә кайткан төсле булды, беренче тапкыр Тимербәкне күргән мизгелләре капылт кына исенә төште. – Баһадирлардай нык егет күренә, ничек синдәй сылу хатын мондый батырны карынында йөртә алды?

– Күз тидерә күрмә, бөек хан...

– Күзем каты түгел, Тайдула хатын... – Хан сүзсез генә торды да карарын җиткерде: – Улымның исеме Тәнибәк булсын! Озакка сузмый сөннәткә утыртып, исем куштырырбыз, бөтен Сарай истә калдырырлык мәҗлес оештырырбыз!

Тайдула, урыныннан торып, баласын сак кына бишеккә салды, аннары ханның иреннәренә үрелде:

– Чын мәхәббәт җимеше татлы була ул, ханым-солтаным! Әни булу бәхете өчен Аллаһыга һәм сиңа зур рәхмәт!

Үзбәк хан, Тайдуланың тиргә баткан чәчләрен учы белән сыпырып, сак кына иреннәреннән үпте.

– Сиңа ял итәргә кирәк, Тайдула. Синең өчен генә түгел, миңа да зур бәхет бу. Бүгенге көн өчен Алланың рәхмәте яусын үзеңә!

**2**

Ираннар илханы Олҗайтуның үле хәбәре, соңарып булса да, Сарайга килеп җиткәч, Үзбәкнең күңеле янә каударланып чыкты. Үзеннән соң Олҗайту тәхетен 12 яшьлек улы Әбү Сәедкә калдырган. Андый яшь илбашчыдан әллә ни рәт чыкмас, мөгаен. Хаким алмашыну да дәүләтне күпмедер дәрәҗәдә тетрәндереп җибәрә, сәргаскәрләрнең кемгә барып баш иярgә белми йөргән чаклары. Мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга һич ярамас. Мисыр солтаны Әл-Мәлик Ән-Насыйр белән дә тиешле сөйләшүләрне үткәреп куярга өлгерде. Ул да Иран илханнары җиренә Сүрия тарафыннан Диярбакыр тирәләрендә һөҗүмгә әзерләнә иде.

Әлеге яуга керешергә ният кылгач та, хан иң элек Котлы Тимер белән Исабәкне үз янына чакырды. Һөҗүмгә әзерләнүе турында иң якын тарафдарларына бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Исабәк ханның һәр сүзен килешеп тыңласа, Котлы Тимернең йөзе каралганнан-карала барды.

– Кәефең ник китте, Котлы Тимер? – диде Үзбәк хан, бәкләр-бәгенең уйлары башка тарафта бәргәләнүен чәч тамырлары белән тоеп.

– Олҗайту хан белән без солыхта бит, бөек ханым, Урданың килешүне бозуы хәерлегә булырмы икән?

– Олҗайту күптән вафат. Хәзерге ыгы-зыгыдан файдаланып калмау зур ахмаклык билгесе. Солыхыбызга Әбү Сә螺еднең бер генә катнашы да юк.

– Кавказ тарафындагы сугышлардан соңгы елларда рәт чыкмады. Андагы мохит үзе үк безгә каршы димме...

– Ул яклар турында ни беләсең соң син, Котлы Тимер?! – Үзбәкнең тәмам ачуы купкан иде инде. – Әллә соң сиңа үзеңнең Хәрәзем мәшәкатьләре Урда мәнфәгатьләреннән өстенрәкме?! Дәүләт турында уйлар урынына үз җаеңны гына кайгыра башладыңмы?!

Котлы Тимер агарынып китте. Ханның холкы авыр булуын белә, ләкин Үзбәкнең мондый гаепләүләре бәгыренә тиде.

– Бөек ханым, мине болай рәнҗетмә. Мин һәрвакыт мәмләкәтебез сагында торучы бәндәң, синең ышанычлы кешең...

– Нигә алайса син, илханнар мәсьәләсе килеп чыкса, һаман да аларны яклап чыгасың?! Ширван, Арран, Азәрбайҗан – безнең җирләр! Һәм мин, исән булсам, аларны Урдага кире кушуга ирешәчәкмен!

– Бөек ханым... – дип сүз башларга җыенган иде дә, Котлы Тимер, бәхәснең мәгънәсезлеген аңлап, дәшмәскә булды.

– Исабәк, нукәрләрне тупла. Кавказ аръягына яуны мин үзем җитәкләрмен. Хан үз сүзен әйтте. Китә аласыз.

Котлы Тимер белән сөйләшүдән соң Үзбәкнең тәмам кәефе кырылды. Уң кулы, фикердәше, һәрбер талпынышында куәтләп торырга тиешле кешенең каршы дәшүе күңелен тырнады. Кайчаннан бирле ул әлеге җирләрнең Урдага, бигрәк тә шәхсән Үзбәкнең үзенә зур әһәмияткә ия икәнлеген аңлатырга маташа, Котлы Тимер исә чукрак диярсең, һич төшенми!

Гаскәре башында юлга кузгалыр алдыннан, авыр уйларыннан бераз гына арынырга теләп, Үзбәк төнгә үз янына Тайдуланы чакыртты. Хатыны, гадәттәгечә, күңелне дәртләндерде, башында кайнаган мең төрле борчуны онытып торырга булышты. Әйтерсең, ул ханның бөтен теләкләрен дә аңлый, көчле кулларның үзенә юнәлеш бирүен дә көтеп тормастан, аның ихтыярына буйсына.

– Син бик нык алҗыгансың, бөек ханым, – диде Тайдула, кайнар мәхәббәт уены тәмамланып, иренең киң күкрәгенә башын куеп яткач. – Йөрәгең дөп-дөп тибә... Яуга бару сине берәр төрле хафага салмагандыр бит?!

– Эш яуда түгел, Тайдула. Котлы Тимер... Ул минем бу сугышны башлавымны бик үк өнәп бетерми. Якын дустың сине хупламавын белә торып юлга чыгу авыррак...

– Ник син аның сүзләренә игътибар итәсең, бөек ханым?! Урданың бердәнбер кодрәтле хакиме син ләбаса!

– Котлы Тимер – күптәнге дустым, миннән өлкән кеше. Аның фикере минем өчен зур әһәмияткә ия.

– Ә ул, шуны белә торып, синең хисләреңдә уйный. Кулыннан килсә, сине рус кенәзләре белән генә сугыштырып торыр иде, монысы Сарайдагы һәркемгә мәгълүм. Синең үзенә карата олы ихтирамыңны Котлы Тимер үз максатларында куллана.

– Ни сөйлисең син, Тайдула?! Сарайда Котлы Тимер белән минем арадагы мөнәсәбәтләр хакында сүз йөртүчеләр бармыни?! – Аптыраштa калган Үзбәк хан ятактан торып ук утырды, кашлары җыерылып килде, уттай янган күзләре хатынына текәлде.

Давыл башланырга торуын аңлаган Тайдула хәлне йомшартырга ашыкты:

– Юк-юк, бөек ханым, мин боларны һич кенә дә синең кәефеңне җибәрер өчен әйтмәдем, зинһар, гафу итә күр!

– Сөйли башлагансың икән, азагына кадәр бәян ит. Хан үз тирәсендә нинди гайбәтләр йөргәнлеген белеп торырга тиеш.

– Яхшы, бөек ханым... Гайбәтләр шактый. Котлы Тимер сине җитди кабул итми, һаман да яшь егеткә тиңли дип сөйләүчеләр бар. Имештер, синең алдыңда баш игән төсле кыланып, артыңда үзен Урданың чын хакиме, бөтен карарларны да кабул итеп, синең телеңә иңдерә торган кеше дип мактанып йөргән. – Ханның йөзе тагын да кырыслана баруын күреп, Тайдула аны янә җайларга ашыкты. – Юк-юк, бу имеш-мимеш, гайбәт кенә бит! Котлы Тимер алай сөйләмәс, котыртучыларның нахагыдыр бу, бөек ханым!

Тайдула, елан төсле шуышып килеп, тәне белән ханга елышты, кайнар иреннәре Үзбәккә үрелде.

– Мин сине ихлас яратам, шуны белеп тор, бөек ханым, – дип пышылдады ул. Ләкин Үзбәкнең кинәт бозга әйләнгән җанын аның назлы сүзләре дә эретә алмый иде инде...

Гаскәренең сул канатына җитәкчелек итәргә дип, Үзбәк хан Хәрәземнән олы улы Тимербәкне чакыртты. Аның төмәннәре Урда нүкәрләренә инде Кавказга кузгалган мәлдә, юлда кушылдылар.

Үзбәк хан улын атына атланган көе каршылады. Тимербәк чын ир булып үсеп җиткән. Буй-сынына ярашлы хәрби киемнәрдән иярендә төз утырган егеткә сокலануын яшерә алмады Үзбәк.

– Исабәк, күрче, балам ничек буйга җиткән! – дип тел шартлатып куйды ул.

Әтисе янына килеп җитү белән Тимербәк атыннан сикереп төште һәм Үзбәк каршында тез чүкте.

– Бөек ханым! Синең әмереңбуенча төмәннәремне җыеп килеп җиттем! Гаскәреңә безне кабул итеп, үзең кирәк санаганча боерык бирә аласың. Синең бер генә сүзеңне ишетү белән, үзем дә, нүкәрләрем дә җаннарын фида кылырга әзер!

– Йә, Тимербәк, алай бик тиз үләргә ашыкма. – Үзбәк хан шатлыгыннан елмаеп, улына кире иярен утырырга кушты. – Минем табынга утырып, бераз тамак ялгап ал, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләрсең. Ничек бар – шулай, яшермичә. Миннән кала янәшәбездә Исабәк кенә булыр, ә син аны кечкенәдән яхшы беләсең.

Атлылар төркеме, ханның күпсанлы тәнсакчылары озатуында зур төркем рәвешендә хәрәкәт иткән төп гаскәргә чапты. Әлеге төркемнең нәкъ уртасында, арбага куелган көе, хан тирмәсе хәрәкәт итә иде. Киләкилешкә иярдән сикереп төшеп, Үзбәк, аның улы Тимербәк һәм Исабәк салмак кына барган арбага сикереп менделәр. Үзбәк бавырчыларга табын хәстәрен күрергә кушты.

Аз-маз ит, кымыз белән тамак ялгап алгач, Үзбәк белән Тимербәкнең, ниһаять, телләре ачылды. Моңарчы җәелеп китеп аралашканнары сирәк булды. Бала чактагыны искә алмаганда, хакимлеккә килгәч тә, хан үзенең гаиләсе белән мөнәсәбәтләрне бик коры тотты. Шуңа да очрашкан чакларда ят кешеләр төслерәк уңайсызлык бар иде. Улыннан ятсынуына Үзбәк оялып та куйды – аның чын ир-атка әйләнеп куюын күрми дә калды бит!

– Хәрәзем якларында хәлләр ничегрәк? – дип сорады хан, улына сынаулы караш ташлап. – Котлы Тимернең бертуганнары олыс белән идарәне ничегрәк алып бара?

– Аллага шөкер, олысыбыз һаман үсештә. Бәкләр-бәгенең энекәшләре бер тик тормый, зур төзелешләр белән шашынып йөриләр, кәрваннар артканнан-арта. Мин бирегә кузгалганчы алар гаскәр җыярга ярдәм итте, барлык кирәк-яракны табышты. Бөек ханым, сиңа иң җылы теләкләрен җиткерергә куштылар, рәхмәтен белдерделәр һәм авыр яуда уңышка ирешүеңне теләделәр.

– Котлы Тимер төсле, бертуганнары да матур сөйли икән... – Кинәт моңсуланып, Үзбәк хан көрсенеп куйды. – Бәкләр-бәге минем бу хәрби йөрешемне өнәп бетермәде, анысын мин тәгаен беләм. Сүзгә керүебез дә шул Иран илханнары аркасында килеп чыкты бит. Юкса, Хәрәзем дә алардан зыян күрде, ләкин Урданың үзенә тиешле Арран, Ширван, Азәрбайҗан җирләрен яулавына мөддәбирем һаман каршы чыга... Мин аңа барысы өчен дә бик рәхмәтле, ләкин зур эшләрне чын күңеленнән фикердәш кешеләр белән генә майтарырга мөмкин... Үзеңнең биләмәләреңдә тәртипме?

– Тәртип, рәхмәт! – Тимербәк ихлас, малайларча елмаеп куйды. Котлы Тимергә кагылышлы сүзләрне ул әллә аңламады, әллә, әтисенә бу хакта сөйләшү авыр икәнлеген сизеп, дәвам итмәскә карар кылды. – Миңа кадәр анда бик булдыклы бер кеше идарә иткән икән, барысын да җайлап калдырган. Хәзер дөньяны дер селкетүче хан вазифасына күчкән дип сөйлиләр.

Улының үзен шулай ярымшаярту белән мактавы Үзбәкнең күңеленә бик хуш килде. Тимербәк янәшәсендә аңа рәхәт һәм тыныч иде. Кан якынлыгы барлык киртәләрне дә алып ташлады, каршында утырган егетнең сөйләвен тыңлаган саен тыңлыйсы килде.

– Үзеңнең тормышыңны җайлау турында уйламыйсыңмы соң, Тимербәк?

Егет уңайсызланып куйды, кинәт җитдиләнде, касәсен төшерде.

– Бөек ханым, сиңа яу алдыннан әйтергә яхшысынмый тордым, үзең сүз башлагач, өстемнән таш төшкән төсле булды. Бу орыштан Иран илханнарын тар-мар итеп кайткач, никах укытырга ниятлим. Сине анда олы кунак дәрәҗәсендә күрү минем өчен чиксез шатлык булыр иде!

– Тимербәк, иләм, әлбәттә! Тик табынны мулдан әзерлә – бөтен

ыруыбызны ияртермен, – дип шаркылдап көлеп җибәрде Үзбәк хан. – Сайлаган ярың кайсы нәселдән, нинди өммәттән?

– Мөселман бәндәсе ул, бөек ханым. Яңа шәһәрнең баш имамы кызы.

– Тукта, тукта, Борһанетдин имамны әйтүеңме?

– Нәкъ шуны, бөек ханым.

– Кай арада кызлары шулай буй җиткән? Мин анда идарә иткән вакытта тез тиңентен генә иде бит олы баласы. Ни атлы дисең?

– Гөлзөһрә аның исеме, бөек ханым.

– Сөбханалла, бигрәк матур исем! Төс-кыяфәте дә, акылы да тиңдәш булсын! Әйдә, Исабәк, тартынып утырма! Чәркәләрне бушатып куярга кирәктер бит!

Гәпләшә-гәпләшә, хәрби мәсьәләләргә дә күчтеләр. Хан тирмәсенә башка сәргаскәрләр да чакырылды. Ширван яклары, Азәрбайҗан, Арран, аларны әйләндереп алган таулар, таулардагы тарлавыклар һәм сукмаклар җентекләп кәгазьгә төшерелгән иде. Урда яугирләре бу якларга һөҗүмгә еллар буе әзерләнде, шымчылары һәрбер кыйтганы өйрәнеп чыктылар. Һөҗүмне дә шул сызымнар нигезендә фаразладылар. Урда кулында тагын бер өстенлек бар иде – тауларда яшәүче кумыклар һәм лезгиннар аларга ярдәм итәргә алынды. Бу исә Кавказны төнлә күз йомып кичеп чыга алырлык юл күрсәтүчеләре табылу дигән сүз.

**3**

Ширван җирләренә Урда гаскәрләре көчле ташкын булып бәреп керде. Иран илханнарының чик буе сагында торган аз санлы хәрби төркемнәре кайсы кая таралышты. Әйтерсең, төньяктан килгән бу баскынчыларны туктатырлык бер генә әмәл дә юк иде.

Барган шәпкә нүкәрләр авыл-калаларны таладылар, йорт-җирләрне яндырдылар, көтү-көтү терлекне үзләре белән куалап алып киттеләр. Ширван җирләренә яман афәт килде.

Әбү Сәед хәлләрнең кай якка барганлыгы тиз аңлады. Илханнар Ираны өч ут арасында кыздырыла иде. Бер яктан Мисырдан Әл-Мәлик Ән-Насыйр гаскәрләре бәреп керде. Икенче бер тарафта – Хөрәсәндә аңа каршы баш күтәргән әмир Ясавыр җитәкчелегендә фетнә куптарылды. Ләкин иң куркынычы, һичшиксез, Ширванда. Урда явы килсә, элеккеге үчләрен алып, бар нәрсәне тар-мар итәчәк, дәүләтне юкка чыгарачак. Шуңа күрә ул, Хөрәсән белән Шам якларына ике әмирен җибәреп, барлы-юклы калган төп гаскәрен үз җитәкчелегендә Үзбәк ханга таба юнәлтте.

Үзбәк хан морадына ирешә иде кебек. Аның гаскәрләре, әллә ни каршылыкка юлыкмый, тиз арада Ширван җирләрен яулап алып, Азәрбайҗанга юнәлде.

Хан җитәкләгән нүкәрләр кәрван юлыннан баралар иде. Тирә-якта аларга янарлык дошманнар күренмәде. Юл аларны биек манаралы, мәчетле, таш диварлар белән әйләндереп алынган корылмага алып килде. Әле яшь чагында ук Сарайдан китеп дөнья гизеп йөргәндә, Үзбәк хан бу якларга килеп чыккан иде. Шушында ул беренче тапкыр дөнья мәшәкатьләреннән ирекле кешеләр – суфилар[2] белән очрашты. Диварлар артында суфиларның

[2] Суфичылык – дөнья мәшәкатьләреннән ерак торып, Аллаһыга рухи якынлык һәм чисталыкка нигезләнгән агым.

бөек акыл иясе Пир Хөсәен хәзрәтнең тәкыясе[3] урнашкан. Ул үзенең матурлыгы белән һәммә кешене таң калдыра, Үзбәк тә ул вакытта әлеге корылманың сихри көченә каршы тора алмады. Тәкыя эчендә исә үзгә бер мохит хөкем сөрә, анда вакыт тукталган сыман күңелгә самими тынычлык иңә.

– Хәтерлисеңме бу хәнәкәне? – дип мөрәҗәгать итте Үзбәк хан янәшәсендәге Исабәккә.

– Бик яхшы хәтерлим, сөекле ханым. Без яшь чакта биредә шактый вакытыбызны үткәргән идек.

– Мин суфилар белән әңгәмәләр алып бардым, ә син йокы симерттең, – дип, дусларча шаяртты хан.

– Кемгә нәрсә мөһимрәк бит инде, бөек ханым. Син белем эстәгәндә, мин яшьлегем белән ял итү җаен күрдем...

– Безнең танышларыбыз исәнме икән, кереп күрешеп, хәлләрен белешеп чыгыйк, булмаса.

– Бик хуп, мин риза, сөекле ханым. Нүкәрләргә ял итәргә кушармын. Моннан безнең алдынгы төмәннәребез үтте, шуңа күрә дошманнан курыкмасак та була.

Үзбәк хан, ияреннән төшеп, нык атлап, хәнәкәгә юнәлде. Артык тыныч иде хәзер монда. Кәрван-сарай бушап калган. Абзардан атлар пошкырган, терлекләр күшәгән тавышлар да килми. Урда хакиме хәнәкәнең эчке өлеше тояклар белән изелеп беткәнлегенә игътибар итте. Йөрәге берәр төрле яманлыкны сизде.

Төп бина бусагасын ул бисмилласын әйтеп атлап керде. Зур бүлмәдә ачылып куелган китаплары каршында гади киемнән, башларына чалма ураган дистәдән артык кеше утыра иде. Аларның берничәсе генә ишек катындагы Үзбәккә башларын күтәреп карады да кире укуларына чумды.

Бүлмә эче караңгы иде, аңа күзләре күнеккәнче шактый вакыт кирәк булды.

– Әссәламегаләйкүм, мөхтәрәм җәмәгать! – диде Урда ханы, берьюлы барысына да мөрәҗәгать итеп. Тик сәламен алучы ишетелмәде. – Мин сезгә яхшы ният белән килдем, курыкмагыз. Габбас хәзрәтләрен күрергә телим, мондамы ул?

– Габбас хәзрәтләре күптән мәрхүм, юлчы. Аның белән сөйләшәсең килсә, хәнәкәбезнең арткы ягындагы зиратка чык, – диде, ниһаять, җыйнак сакаллы бер карт.

Үзенә сүз каткан кеше табылуына шатланып, Үзбәк хан аның янәшәсенә килеп утырды. Гади киенгән кешеләр арасында ул үзенең затлы чапанында, ныклы күннән эшләнгән хәрби киемнәрдә бик сәер күренә иде, әлбәттә. Асылташлар белән бизәкләнгән кылычы, алтын йөгертелгән киң билбавы, гаҗәеп матур чигүле итеге бу караңгы бүлмәдә ят бер нәрсәләр кебек тоелды.

– Ни атлы буласың, ил карты?

– Фәррах суфи мин, юлчы.

– Габбас хәзрәтләре күптән вафатмы?

– Биш еллап элек Аллаһы хозурына озаттык үзен. Үзең аңа ни йомыш белән? Яугирме әллә син?

[3] Тәкыя – мавзолей, каберлек урыны.

– Яугир дип... Яугирләрнең башлыгы дисәң, дөресрәктер.

– Габбас хәзрәтләрен кайдан беләсең?

– Яшь чакта, моннан егерме еллап элек, бу тарафларга килеп чыкканым булды. Ул чакта бик озаклап дөнья, ахирәт хакында гәпләшеп утырган идек.

– Алай икән... – Суфи янә китабына кереп чумды.

– Хәнәкәнең хәлләре ару гынамы?

– Ару... – Фәррах суфи кабат укудан аерылырга мәҗбүр булды. – Безгә күп кирәкми бит. Җан асрарлык ризык, оят җирләрне капларлык кием булса, шул җиткән. Хәзер хәлебез бераз авырайды, билгеле, әмма Аллаһы Тәгалә ярдәме белән анысы дә җайланыр, иншалла!

Үзбәк хан сагаеп калды. Капылт кына хәнәкәгә атлагач, күңеленә иңгән шом янә әйләнеп кайтты.

– Нидән авырайды, Фәррах суфи?

– Синең яугирләрең кереп, хәнәкәбезне талап чыктылар. Малларыбызны куып алып киттеләр. Шөкер, үзебезгә тимәделәр, анысы өчен дә зур рәхмәт үзеңә, бик булдыклы егетләрне иярткәнсең.

Оятыннан шартлар дәрәҗәгә җитте Үзбәк хан.

– Күпме мал таладылар, Фәррах суфи?

– Безнекен генә түгел, күрше-тирә авылларныкын да җыйдылар. Җәмгысы илле меңләп баш терлектер. Шуларның утыз меңе сыерлар, калганнары сарык. Аннан кала, хәнәкәдәге кайбер кирәк-яракларны алудан да тарсынмадылар, барысын да кырып-себереп, капчыкларына тутырдылар.

– Мин акылсыз яугирләремнең олы хатасы өчен синең алдыңда гафу үтенәм, Фәррах суфи, – диде йөзе каралып, ачуыннан тавышы зәһәрләнеп чыккан Үзбәк хан. – Ялгышны, һичшиксез, төзәтербез, мин, хан буларак, сүз бирәм.

– Зыян юк, сугыш вакытында була торган хәл. Безнең зарларыбыз берни түгел, Аллаһы Тәгалә каргышын җибәрмәсен. Без Аллаһыдан синең нукәрләреңнең гөнаһысын кичерүне сорап, җомга намазын да укыдык. Кабул булырмы ул догаларыбыз – анысы Ходай хозурында.

Исабәк Үзбәкнең хәнәкәдән тәмам кәефсез чыгуын ерактан ук чамалады. Мондый халәттә ханга сүз катмавың хәерлерәк, ләкин тегесе үзе эндәште:

– Изге суфи Пир Хөсәен хәнәкәсен талаган яугирләрне ачыклап, гаскәр каршында җаннарын алыгыз. Башкаларга сабак булырлык итеп кылыгыз ул хөкемне. Барлык таланган малны кире кайтарыгыз. Сыерлар утыз мең, сарыклар егерме меңнән дә ким булмаска тиеш. Тагын бер тапкыр нукәрләрнең изге корылмаларга кул күтәргәнлеген ишетсәм, башта сәргаскәрләрнең, аннан синең башың очар, Исабәк!

Пир Хөсәен хәнәкәсендәге сөйләшү Үзбәк ханның күңелен бик авыр халәттә калдырды. Үзе җитәкләгән данлыклы яугирләрдән ул мондый юләрлекне һич көтмәгән иде. Әйе, күбесе – танавы кипмәгән яшь егетләр, араларында мөселман өммәтенә килмәгәннәр дә байтак. Ләкин һәрбер йөзне, меңне, төмәнне сыналган, акыллы сәргаскәрләр җитәкли бит! Алар нәрсәгә кагылырга ярый, ә нәрсәгә ярамый икәнлеген төшендерергә тиеш ләбаса! Күпме тырышып та, исламга, дини корылмаларга мөнәсәбәтне ныклап сеңдерә алмый, яңа дин монголларның үзендә рәсми төсмердә генә кала бирә кебек, күңелләрен чынлап торып яуламаган...

Төн кунарга хәнәкәдәге карван-сарайда тукталдылар. Караңгы төшеп

килгәндә, алар янына Тимербәк җитәкчелегендәге бер төркем нүкәрләр дә килеп җитте. Улы белән җылы гына очрашса да, Үзбәкнең тәмам кәефе киткәнлеген Тимербәк сизде, артык күп сөйләшмәскә тырышты. Кичке аштан соң алар, икәүләп, урам якка чыктылар.

Кавказ таулары тирәсендә күк йөзе аеруча ачык һәм чалт аяз. Үзбәк моны әле яшь чагында бу якларда адашып йөргәндә үк күңеленә киртләп куйган иде. Бу төнне исә күктә йолдызлар бигрәк тә мул булып чыкты. Үзбәкнең шул җемелдәвек нокталарны күзләвен күргән Тимербәк тә иксез-чиксез галәмгә текәлде.

– Күктә йолдызлар күп, Тимербәк, – диде озак кына дәшми торганнан соң Урда ханы. – Күрәсеңме, җемелдиләр, берсеннән-берсе яктырак янарга маташалар. Кайберләре, көчләрен исәпләмәгән килеш артыгын ялтырап ташлап, мәтәлеп төшеп китә. Төнге күктә, йолдызлардан кала, ай бар. Ул – башкалар арасында уңышка ирешә алган, югарыга үрмәләгән йолдыз. Тик аның яктысы салкын, нуры файдасыз. Иртәгә таң атар, һәм күк йөзендә, бар җиһанга җылылык һәм наз биреп, кояш балкыр. Кояшны мин хаким белән тиңлим. Ул күккә калку белән, башка йолдызлар да, хәтта ай да күренмәс була. Хакимнең нуры тирә-юньгә яшәү көче һәм өмет бирә. Ләкин, кояш шикелле, хакимгә дә ял кирәк. Ул тәүлек әйләнәсе дәүләт эшләре белән шөгыльләнә алмый, арыган чаклары да шактый. Менә шул вакытта, караңгы күктәге йолдызлар шикелле, төрле залим бәндәләр фетнәгә керешә. Башта үзара тарткалаша, аннан соң, үз тиңнәрен җиңеп, явызлык тәхетенә менгәч, кануни хакимгә каршы мәкер башлый. Тик, Тимербәк, тормыш ул табигать төсле. Көн белән төн беркайчан да бергә очраша алмый. Гаделлек белән золым да янәшә тормый. Кояш – гаделлек билгесе. Ул һәрвакыт яктырак, нурлырак. Һәм ул һәрвакыт ялгыз... Аның нурлары җылытырга да, өтеп алырга да сәләтле...

– Хан кодрәте шикелле үк...

Үзбәк, гаҗәпләнеп, улына борылды.

– Сине шагыйранә җанлы дип уйламаган идем, Тимербәк...

– Тормыш күп нәрсәгә өйрәтә икән, бөек ханым. Күккә караш ташласаң, тагын бер уй башка килә. Әгәр кояшның нуры шулкадәр якты икән, нигә аңа айдан һәм йолдызлардан шүрләргә?

– Кызык сорау... Кояш та мәңгелек түгел, Тимербәк. Ул да тутыга аладыр. Шуңа күрә ул, һәр көн саен, билгеле бер мәлдә, теләсә-теләмәсә дә, күккә күтәрелергә мәҗбүр. Үзең әйткәнчә, хан шикелле үк. Әгәр тәхеткә ия булгансың икән, син һәрвакыт яраннарыңның күз алдында торырга тиеш. Ни кызганыч, әниең моны аңламады...

– Син әнигә берүк ачу тота күрмә, бөек ханым. Ул сине ихлас ярата. Бары тик аның хатын-кыз акылы хакимлек, дәүләт каршындагы бурыч төсле илаһи төшенчәләрне аңламый да, кабул итә дә алмый. Еракта торса да, һаман синең язмышың өчен борчылып яши, бер генә мизгелгә дә үзеңне уеннан чыгармый.

Үзбәк хан, тирән уйга калып, башын түбән иде.

– Беренче хатыным Нәзифәгә яхшы ир була алмадым, әмма аның янәшәсендә ышанычлы терәк – сине бүләк иткәнмен икән. Моны аңлау күңелемә рәхәтлек бирде. Ә хакимлеккә килгәндә... Кояш та мәңге түгел.

Урда ханы да. Үзең тәхеткә менгәч, Аллаһы боерса, боларның барысына да төшенерсең, иншалла. Ә хәзер бар, ял ит, мин бераз гына йөреп киләм.

Тимербәк киткәч тә, Үзбәк, ашыкмый гына атлап, дөм караңгы болынга атлады. Артыннан шәүлә шикелле тән сакчылары барганлыгын белсә дә, ул бу мизгелдә ялгызы иде. Ходайга шөкер, алмашка менә дигән улы үсеп килә. Нәзифәнең дә үзенә рәнҗеп ятмавын ишетү күңелен тынычландырды. Болай булгач, Урданың киләчәгенә, үзеннән соң дәвамчысы килүенә нык өмет бар. Тимербәк тә үзенә охшаган – бераз гына хыялый, уйлап гамәл кылучы, шул ук вакытта нык беләкле яугир дә.

Шулай уйланып, күпме баргандыр – каршысында кинәт уттай янып торган парлы күзләр пәйда булды. Кисәк кенә тукталып, Үзбәк хан аларны санады – тугыз пар күз аңа текәлгән иде. Бүре күзләре.

– Багаууган көчекләре үсеп җиткән икән, – дип пышылдады Үзбәк, баскан урынында катып калып. Кылычына үрелергә теләге булса да, куллары тыңламады. Күзләр аңа якынлаша башлады, гырылдаган тавышлар ишетелде. Кинәт йөгереп килеп җиткән тән сакчылары булмаса, ерткычлар, һичшиксез, Үзбәк өстенә ташланасы иде. Ханны әйләндереп алган нүкәрләрдән бүреләр шүрләде, акрын гына артка чигенделәр. Тән сакчылары, җәяләрен тартып, тәтегә уклар салырга керește, әмма Үзбәк аларны туктатты.

– Китсеннәр, алар да Ходай тарафыннан яратылган җан ияләре. Нәкъ безнең шикелле. Китсеннәр... Минем, Аллаһы боерса, гомерем әле бик озын, биредә өзелеп калмас... Тик бик начар фалга охшаган бу бүреләрнең килеп чыгуы, ай-һай, ахыры хәерле булмас шикелле...

Ул төнне Үзбәк хан бик начар йоклады. Төшенә кан елгалары, мәетләр кереп йөдәтте. Котлы Тимер дә килде кебек, аның белән озак кына гәпләшеп утырдылар. Тик иртән ватылган халәттә уянганда, ул әлеге сөйләшүдән бер генә сүзне дә хәтерләми иде...

Әллә чыннан да Аллаһы Тәгалә Пир Хөсәен хәнәкәсендә Урда нүкәрләре кылган гамәлләр өчен каргады – көтмәгәндә, гаскәрдә мур башланды. Башта ул атларны кырды, аннан соң яугирләр дә бер-бер артлы билгесез чирдән җан тәслим кылдылар. Кура елгасы ярларына килеп җиткәндә, яман авыру бөтен гаскәрдә котырына иде. Моның өстенә, таулардан эреп агып төшкән судан Кура елгасы, ярларыннан чыгып, киң колач алып җәелде. Бу халәттә аны кичү мөмкин түгел иде. Бер яктан гаскәрен тезеп, Үзбәк хан, икенче яктан Иранның яшь илханы Әбү Сәед озак кына кара-каршы тордылар – Кура аша атылган ук та очып чыга алмады.

– Кире кайтыйк, Тимербәк, – диде Үзбәк хан, атына атланган көе ярның аргы ягын күзләп. – Бер атнадан артык торабыз, тагын бераздан Әбү Сәедкә каршы сугышырлык кешебез дә калмас. Күрәсең, Аллаһы Тәгалә әлегә безгә бу җирләрне бирергә теләми. Вакыты җиткәч, насыйп булса, теләгебезгә ирешербез...

Үзбәк ханның Кавказ ягына беренче хәрби сәфәре әнә шулай тәмамланды. Сугышчылары дошман угына караганда, билгесез чирдән күбрәк кырылды. Урда яугирләре биек диварлы кирмәннәр урынына капкалары һәрвакыт ачык торган хәнәкәләрне яулаучы буларак истә калды. Иран илханнарының гаскәриләре, Ширван тарафын талауга дучар итсәләр дә, Үзбәк нүкәрләре белән бәрелештән качып, башларын исән-сау калдырдылар...

**4**

Сарайга Үзбәк хан җитәкчелегендә яуга чыгып киткән гаскәрнең калдык-постыклары нык арыган, алҗыган кыяфәттә кайтып егылды. Ширван якларында килеп чыккан авырудан озаклап дәваланасы, хәл җыясылары бар иде. Үзбәк белән Тимербәкне, Исабәкне мур урап узды, ләкин җиңүгә ирешә алмау ачысы тән сырхавыннан газаплырак иде.

Хансарайда бәкләр-бәге Котлы Тимер белән очрашуда Үзбәк хан шактый салкын иде. Мөддәбиренең үзе югындагы хәлләр хакындагы хисабын битараф кыяфәттә тыңлады, артык күп сүз куертмый, тәүге күрешүне тиз тотты.

Кичен хан үз тарафына янә Тайдуланы чакыртты. Хатынның күңеле нигәдер аеруча күтәренке, аның мондый халәтенә Үзбәк гаҗәпләнеп куйды:

– Мондый шатлыгыңның сәбәбе нидә, Тайдула хатын?! Әллә бөек ханыңның җиңүгә ирешә алмавы сине җиде күк катына күтәрдеме, башың түшәмгә тигән?!

– Хатын-кызның яу эшләренә кысылырга, аларга бәя бирергә хакы юк, бөек ханым, – диде Тайдула, җитдиләнеп. – Син – солтаннарның солтаны, әгәр бүген җиңә алмасаң, иртәгә, һичшиксез, тантана итәчәксең. Дөньяда синнән дә кодрәтле башка бер генә ир заты да юклыгын мескен хатының белеп һәм аңлап яши. Минем шатлыгымның сәбәбе исә бөтенләй башка. Мин янәдән көмәнле, бөек ханым!

– Сөбханалла! – гына дия алды Үзбәк хан.

Аларның иреннәре бер-берсенә тартылды, кайнар тәннәре икесе бербөтенгә әверелде. Тайдуланың татлы исеннән, аның хиссилегеннән Үзбәк башын югалтты. Яуда күргән барлык михнәтләре бер мизгелдә эреп юкка чыкты. Тайдула үзенә генә хас сихри бер осталык белән талчыгырга да ирек бирми, ханның гаурәтен дәртләндерә торды. Үзбәк үзен унсигез яшьлек егет сыман хис итте, инде хәле бетте дигәндә генә, ирлек көче аңа янәдән әйләнеп кайта, сөйгән хатынының ымсындыргыч тәне үзенә кабат-кабат җәлеп итә...

Хәлдән тайгач, алар, шабыр тиргә батып, арыслан тиресе астына кереп, бер-берсенә сарылып яттылар.

– Сарайда ни хәлләр бар, Тайдула? – Мәхәббәт уеныннан тиз айныды Үзбәк, күңеле янә үзен борчыган уйларга әйләнеп кайтты.

– Тынычлык, бөек ханым. Синең исәнлегең өчен дога кылдык, җомга намазларында җиңүгә ирешүеңне Алладан сорадык.

– Тик без җиңә алмадык...

Тайдула җавап бирмәде.

– Котлы Тимернең үз-үзен тотышында бер-бер нәрсә үзгәрмәдеме?

– Бөек ханым, үз фикеремне әйтсәм, ул бары тик ханның хатыны сүзләре генә булачак. Миңа дәүләт эшләренә кысылып, син билгеләгән хакимнәргә бәя бирү ялгышлык түгелме икән?

– Юк. Син минем гаиләм кешесе, тәхет әһеле. Сөйлә, Тайдула, бер дә тартынма.

– Котлы Тимер бераз масаеп китте кебек тоела. Моны мин генә түгел, башкалар да сизенде. Синең гаскәреңдә мур башлангач, Сарайда бәкләр-бәгенең бу сугышка каршы чыгуы хакында хәбәрләр таралды. Кайберәүләр

Котлы Тимерне ханга караганда да акыллырак һәм белдеклерәк дип сөйләнгән, имеш...

– Котлы Тимернең яуга каршы төшүен кайдан белгәннәр?! Без икәүдән-икәү генә сөйләштек бит!

– Анысы миңа мәгълүм түгел. Сүзегез ике арада гына булган икән, димәк, аны Котлы Тимер тараткандыр...

Үзбәк ханның өянәге кузгалды. Аның йодрыклары йомарлануын тойган Тайдула, үзен назлап, бер кулы белән маңгаеннан сөяргә кереште.

– Кызма, бөек ханым, тыныч бул. Бәкләр-бәге шактый югары күтәрелде, монысы һәммә кешегә мәгълүм. Тик аны син шулай үсендердең бит. Зинһар, кызып китеп, берәр төрле ялгышлык кыла күрмә. Безнең гаиләбезнең дошманнары болай да җитәрлек, алар рәтенә кодрәтле һәм дәрәҗәле Котлы Тимерне дә өстәү олы хата булыр дип уйлыйм. Сабырлык белән фикер йөрт, бөек ханым. Син, һичшиксез, дөрес юлны табачаксың...

Тайдула, Үзбәкнең киеренке халәтен сизеп, аның уң кулын алды һәм корсагына куйды:

– Сизәсеңме, биредә син дөньяга бүләк итәсе тагын бер җан бар. Бу – синең хак юлда икәнлегеңне күрсәтүче билге түгелмени?! Син балаларыбызның бәхете хакына көчле һәм зирәк булырга тиеш, бөек ханым! Сиңа чын күңелдән ышанучы кешең – Тайдула хатын барлыгын беркайчан да онытма, мин мәңге сиңа тугры калырмын!

Икенче көнне иртән Үзбәк хан, гадәтләрен үзгәртеп, диванны җыймады, хисап тотар өчен Котлы Тимер белән Исабәкне чакыртмады. Намазын да үз ягында ялгызы гына укыды. Аннан соң үз тарафына Баялун хатынны дәшәргә боерды.

– Исән-имин әйләнеп кайтуың белән, бөек ханым, – диде Баялун, бусагадан атлап кереп, Үзбәкне сәламләгәч тә. Аларның икесенә чәй хәстәрләнгән иде, хаким, сәламне ымлап кына кабул итеп, табынга килде.

– Миннән башка ничек яшәдегез, Баялун хатын? Ул-бу хәлләр чыкмадымы, коткы таратучы күренмәдеме?

– Синең дәрәҗәңә зыян салырлык берни дә сизмәдем, сөекле ханым. Барча халык башларыгыз сау булсын дип борчылып торды, догалар ирештерде.

Үзбәк, сүзне озынга сузмаска карар кылып, Баялуннан турыдан-туры сорады:

– Котлы Тимер... Мин югында аны олылаганнар, хан сүзен тыңласа, шул кадәр нүкәр бер дә юкка кырылмас дип сөйләгәннәр, имеш. Хакмы бу?

Баялун хатын сагаеп калды. Хан башлаган сүзнең кай якка баруын төшенә башлаган иде ул.

– Кешенең теле сөяксез, бөек ханым, ни сөйләмәсләр. Барысын да тыңлап йөри башласаң, колагың шиңәр.

– Шулай да, Котлы Тимер минем хакимлекне шик астына куйган кебек. Син моны сизмәдеңме?

– Бөек ханым, бәкләр-бәге гомер-гомергә синең ышанычлы тарафдарың булды. Аннан кер эзләү бер дә дөрес түгелдер... – Баялун хатынның йөрәге чәнчеп куйды, әмма ул ханга моны белгертмәде.

– Алдыңда ялтырап, артыңда калтырап торган кешеләр аз булганмы Урда тарихында? Котлы Тимер дә әүлия түгел. Бәлки, мин күрсәткән ышаныч

һәм хөрмәтне дөрес кабул итми, үзе шул дәрәҗәләргә иреште дип уйлый башлагандыр?

– Котлы Тимер сине тәхеткә утыртканда, зур тырышлык куйды, бөек ханым. Аның хезмәтләре...

– Мин тәхеткә кануни рәвештә хаклы идем! – Үзбәк хан, касәсендәге чәйне эчеп тә бетерми торып басты. – Әгәр Котлы Тимер ярдәм күрсәткән икән, мин аның өчен бурычын тулысы белән кайтардым! Аның мине мыскыллап йөрергә тамчы да хакы юк! Яклама бәкләр-бәген, ул үзенең астыртын икәнлеген раслады!

Баялун хатынның бөтенләй хәле китте, ул көч-хәл белән торып басып, тыныч калырга тырышты.

– Бөек ханым, син миңа улым кебек якын. Хакимлек – озын һәм катлаулы юл. Елан ысылдавын сандугач сайравыннан аера белергә кирәк. Котлы Тимергә ягылган нахакка колак салып, өстеңә гөнаһ ала күрмә...

– Син китә аласың, Баялун хатын, – диде Үзбәк хан, һәм, борылып та карамый, үз ягына кереп югалды.

Хан тарафыннан чыккач, Баялун хатын ашыга-ашыга хәрәмгә юнәлде. Башы әйләнә, күңеле болгана, аяклары тотмый, әмма ул моңа игътибар итмәде.

– Мостафа әвнух! – диде ул, хәрәмгә килеп кергәч тә.

Баялун хатынның тавышын ишетү белән, Мостафа кайсыдыр бер бүлмәдән атылып чыкты.

– Сөекле Баялун хатын, синең мескен колың бирелә, – диде ул, билен бөгеп.

– Кичә кич хан янына кемне озаттың?!

– Кичә кич... Хәзер, искә төшерим... Ә, әйе, хан үз янына Тайдула хатынны чакыртты, ул аннан таң белән генә кайтты.

Мостафага берни дә аңлатмый, Баялун хатын Тайдула ягына ашыкты. Ул килеп кергәндә, тегесе Тәнибәк белән мәш килеп ята иде. Баялунны күргәч тә торып басып, башын иде.

– Балаңны тәрбиячеләргә тапшыр, сөйләшәсе бар, – диде тыны кысылган Баялун. Хәленең мөшкеллегенә күрә утырасы иде дә, тик аягүрә сүзләре үтемлерәк яңгырар төсле тоелды.

– Котлы Тимер өстеннән ханга син яла ябтыңмы?! – Баялунның соравы усал һәм кырыс яңгырады.

– Нинди коткы, ни сөйлисең син, Баялун хатын?!

– Кичә син хан белән төн үткәрдең, бүген ул бәкләр-бәгенә теш кайрый. Мине юләргә санама, Тайдула. Урданың ике хакиме арасын бозу сиңа нигә кирәк?

– Мин? Мин – аларның араларын бозучымыни? – Тайдуланың кинәт йөзе үзгәрде, ул күндәм кыздан күкрәге горур киерелгән киребеткән хатынга әйләнде дә куйды. – Мин түгел, Котлы Тимер барысына да гаепле! Әллә ул халыкны бөек ханыбызга каршы котыртмады, дисеңме? Котыртты. Әллә ул Ширвандагы сугышның ялгышлыгын алдан ук әйтүен кычкырып йөрмәде, дисеңме? Йөрде. Бәкләр-бәге, тәхет янында тәмам көрәеп бетеп, кемгә хезмәт итәргә тиешлеген дә онытты бугай. Акылыңа кил, Баялун хатын, күзләреңне ач! Кемне яклыйсың син?!

– Син... Син... – Баялун хатынның сулышы кысылды, йөрәге шартлар дәрәҗәгә җитеп тибүен сизде. Куллары, аяклары оюын тойды. – Син... Фетнәче!

– Мин фетнәче түгел! Мин – Урдага ханлыкка варис үстерүче ана! Колагыңа киртләп куй шуны, кортка! Һәм башка минем бүлмәгә чакырусыз киләсе булма!

Баялун хатынның йөзе тартышып, авызы ничектер сәер кыйшаеп калды. Башына шаулап кан йөгерде. Ул, гөрселдәп, идәнгә барып төште.

Әле генә бик кыю кыланган Тайдуланың бер мизгелдә бөтен халәте үзгәрде. Коты алынуыннан ул кычкырып елап җибәрде, Баялунга иелде, аны уңайлырак яткырырга маташты. Аннан соң, бүлмәсеннән йөгереп чыгып, бар көченә кычкырып җибәрде:

– Мостафа ага! Кызлар! Табиб чакыртыгыз! Баялун хатын үлем хәлендә!

**5**

...Үзбәк хан Баялун хатынның ятагы янына килде. Аны бераз җайга китергәннәр, йомшак мендәрләр салып, өстенә җылы тиреләр каплаганнар. Янәшәсендә Ибраһим табиб кайнаша, арттарак хатыннары мышкылдап торалар. Ханның карашы Котлы Тимер белән очрашты. Бәкләр-бәге нык хафалы икәнлеген яшермәде. Үзбәк ятакка таба борылды.

Хан Баялунның хәлсез кулын учына алды. Кул салкын иде, ләкин Баялун хатынның күзләре тере, үзен дикъкать белән күзәтәләр.

– Хәлең ничек, Баялун хатын?

Тегесе дәшмәде, күз читеннән генә бер яшь тамчысы йөгереп төште. Үзбәк аны саклык белән сөртеп алды.

– Ул сөйләшә дә, селкенә дә алмый, бөек ханым. Хәзер урын өстенә генә калыр инде, – дип аңлатырга ашыкты Ибраһим.

– Дәва бармы моңа?

– Ни кызганыч, бөек ханым, бу чирне җиңәрлек дару әлегә уйлап табылмаган. Безгә аны тәрбияләп, Ходайдан шушы килеш озын гомер бирүен сорап, догалар кылырга гына кала...

– Моның сәбәбе нидә?

– Берәр төрле көчле борчудан килеп чыга торган чир бу.

Хан, артындагы хатыннарга борылып, алар арасыннан Тайдуланы эзләп тапты.

– Синең бүлмәдә егылдымы ул, Тайдула?

– Әйе, бөек ханым, – диде чак кына ишетелерлек тавыш белән хатыны.

– Ни турында сөйләштегез?

– Баялун хатын минем яныма нык дулкынланган рәвештә килде, ләкин сәбәбен әйтмәде. Башта бераз Тәнибәк белән уйнады, аннары, хәлем юк дип, баланы алып китәргә кушты. Минем хәлләрне сораштырырга кереште, һәм, кинәт...

Тайдула тыела алмый үксеп елап җибәрде.

– Котлы Тимер, Ибраһим ага, Баялун хатынны аякка бастырыр өчен кулдан килгәннең барысын да эшләгез. Мостафа ага, үзеңнең кул астындагы кешеләрдән иң ышанычлыларын бирегә хезмәт күрсәтергә куй. – Үзбәк хан сагышлы карашын хәлсез яткан Баялунга төбәде. – Көчле

хатын ул, бирешмәячәк, безгә аңа ярдәм итәргә һәм догада торырга гына кирәк...

Хәрәмнән чыккач, тән сакчылары озатуында Үзбәк Ногъманетдин хәзрәт янына юл алды. Нүкәрләрен урамда калдырып, бүлмәгә узды. Ногъманетдин имам, идән уртасындагы келәмгә утырган көе китап укый иде, ул ишектән кергән ханга күтәрелеп тә карамады.

– Әссәламегаләйкүм, хәзрәт, – диде Үзбәк, аның каршына аякларын бөкләп утырып.

– Вәгаләйкемәссәлам, бөек хан. Ни йомыш белән килдең?

– Баялун хатын... Кинәт хәле авыраеп китте, урын өстенә калды...

– Мин ни белән ярдәм итә алам инде? Болай әллә ни диндар хатын түгел иде бугай ул, догаларым аңа булышмас, мөгаен.

– Юк, сүз ул хакта түгел... – Сүзне нидән башларга белми, Үзбәк хан кулындагы бүреген әле алай, әле болай әвәләде. Аннан капылт кына бер карарга килде. – Ул аяктан егылганчы безнең арада шактый кискен сөйләшү булып алды. Мин аңа катырак бәрелеп ташладым шикелле...

Ниһаять, Ногъманетдин имам, башын күтәреп, ханга күз салды.

– И олан! Бөтен дөнья газабын үз җилкәңдә күтәрергә маташасың. Барлык авырлыкны да үз өстеңә аласың. Һәрнәрсәдә үзеңнең гаебеңне тоясың. Болай яшәсәң, тәхеттә түгел, җир йөзендә озак тора алмассың. Һәркемнең үз тәкъдире, ул Ходай тарафыннан язып куелган. Бәлки, Баялун карчыкның фани дөньяда ризыгы тәмамлангандыр, Аллаһы Тәгалә аны үз янына чакырырга карар кылгандыр? Сезнең күрешү очраклы гына килеп чыгарга мөмкин, дип уйлаганың булмадымы? Син үзгәртә алмаслык нәрсәләр бихисап бит. Шуларның берсе – үлем.

– Аңлыйм да, ләкин... Мин Котлы Тимернең үземә тугрылыклы булуына шик белдердем, Баялун хатынга исә бу ошамады...

– Ул шигең нидән туды?

– Бер кеше әйткән сүзләрдән...

– Кеше сүзенә ышанып, нигезсез шиккә бирелү – зур гөнаһ. Гайбәт, нахак та гөнаһлар рәтендә. Киңәшем сиңа бер генә – күңелеңдәге шик-шөбһәләрдән арын, алар юкка чыгу белән Баялун хатынның хәле авыраеп китүгә синең гаебең юклыгын аңларсың. Һәм догада бул, бөек хан, Аллаһы Тәгаләгә ихлас мөрәҗәгать итсәң, ул беркайчан да ярдәменнән ташламас.

Үзен битәрләгән уйларына чумып, Үзбәк Ногъманетдин хәзрәт белән саубуллашты һәм хансарайга юнәлде. Үз катына керү белән, Мостафа әвнухны чакыртты.

– Табын кор, кымыз-шәрабны кызганма! Биш-алты иң шәп, моңарчы минем күземә күренмәгән җарияне алып кил. Думбрачыларны да чакырт. Хан күңел ачарга тели, – диде ул, әлеге гамәле башын аз гына булса да ачып җибәрәсенә өметләнеп.

Хан ягы ул төнне гөрләп торды, капылт кына мондый бәйрәм оештыруның сәбәбен беркем дә аңлый алмады. Таң беленгәндә генә җарияләр һәм думбрачылар таралышты, Үзбәк исә ялгызы йокыга талды.

Иртән уянганда, башы бер дә җиңеләймәгән, киресенчә, хәмер эчеп саташып ятудан тәмам кәефе кырылган иде. Аннан-моннан тамак ялгап алгач, хан үз тарафына Котлы Тимерне дәште.

Бәкләр-бәге бик сак кына, башын игән көе керде.

– Синең әмереңбелән килдем, сөекле ханым!

– Котлы Тимер, үзеңә, миңа, егермеләп тән сакчыма шалама киемнәр әзерлә. Безгә дәрвишләр булып киенергә кирәк. Хансарайның арткы капкасыннан гына чыгып китәрбез. Бу хакта синең белән миннән кала беркем дә белмәсен!

Котлы Тимер бу кадәресен үк көтмәгән иде, әллә инде хан айнып бетмәгән дигән төсле, хакименә аптырап текәлде.

– Акылымнан шашмадым, Котлы Тимер. Кушканны үтә!

Күп тә үтмәде, хансарайның арткы ишегеннән бер төркем дәрвиш күренде. Аларның йөзләрен танып булмый, чүпрәк-чапракка уралганнар. Алдан атлап баручы бәндәнең генә йөрешеннән үк көч һәм кодрәт тоемлана.

Үзбәк хан, юлдашлары озатуында, Сарайдагы олы базарга юнәлде. Биредә ул әле бер, әле икенче сәүдәгәр янына килеп, нәрсәнең ни бәя торганлыгын, Урдага кай тарафлардан килгәнлеген сораштырды. Каршыларында хәерче басып торганын аңласалар да, көр тавышлы дәрвишкә тупас җавап биргән кеше табылмады. Барысын да бәйнә-бәйнә аңлатып бирделәр, белгәннәрен түкми-чәчми сөйләделәр.

Шактый вакыт базарны өйрәнеп йөргәннән соң, Үзбәк ханның тамагы кипте. Ул Котлы Тимерне шундагы бер чәйханәгә дәште. Тән сакчылары урам якта калды, үзләре эчкә үттеләр. Үзбәк, беразга гына тукталып, эчтәге тамашаны өйрәнеп торды. Аннан соң биш-алты кеше утырган өстәлгә таба юнәлде.

– Агалар, сезнең янәшәдә урын алырга рөхсәтме? – дип сорады ул.

Чал сакаллы олы яшьтәге абзый аңа күтәрелеп карады.

– Дәрвишләр, димәк... Утырыгыз, урын җитәрлек бит. Кай яклардан килүегез?

– Ширваннан, – диде Үзбәк һәм Котлы Тимергә карап елмаеп куйды. Тегесенең болай да киеренке халәте тагын да тирәнәйде төсле.

– Ә, Ширван! Әле күптән түгел генә безнең ханыбыз шул яклардан җиңелеп кайтты, – диде агай.

– Сезнең гаскәрләр килгәндә, без аннан чыгып киткән идек инде. Шушындый көчле мәмләкәт Илханнарны чынлап та тар-мар итә алмадымыни?

– Хан үзе бик җыенган да, мөддәбире Котлы Тимер каршы булган, диләр.

– Ничек итеп?

– Имештер, нүкәрләргә бозылган ризык җибәргән, тегеләр шуның белән агуланганнар.

– Урда ханы мөддәбиренең мәкерен белми яшимени?

– Котлы Тимер аңа тәхеткә утырырга ярдәм иткән кеше, шуңа каршы әйтә алмый, күрәсең...

– Үзбәк хан нindирәк хаким? Булдыклымы?

– Үзе бик юмарт һәм киң күңелле кеше ул. Хансарайда берәр мәҗлес үткәрсә, кара халыкны да онытмый, мул өлеш чыгара. Тик дәүләт идарәсенә артык якын килә алмый икән, барысына да Котлы Тимер хуҗа, диләр.

Аның белән бергә Баялун исемле олы кортка да һәр нәрсәгә тыкшына икән. Ханыбыз Үзбәк ятимлектә үскән бит, күрәсең, бу азгыннар аны басымчак итәләрдер.

Әле генә ишетелгәннәрне башыннан янә бер кат үткәрәсе бар иде, Үзбәк тәкъдим ителгән касәдәге чәйне дәшми генә эчәргә кereште. Үзе күз чите белән Котлы Тимергә бакты. Тегесенең йөзе каралган, куллары калтырана. Дөреслектән куркамы, әллә инде аксакалның нахак сүз сөйләвенә ризасызлык билгесеме?

Хансарайга алар бер сүз дә сөйләшми кайттылар. Котлы Тимер ханга ияреп, аның ягына керәсе иде дә, Үзбәк аны бусагада карашы белән туктатты.

– Ял ит, Котлы Тимер. Көн авыр булды, мин дә арыдым. Соңрак сөйләшербез, – диде ул, һәм ни эшләргә белми торган бәкләр-бәге каршында ишекне япты.

Котлы Тимер тәмам аптырашта калды. Хан аны үзеннән читләштерә, аралары капылт кына салкынайды. Ширван белән Арран җирләренә яуга баруга бәкләр-бәге каршы төште, әмма бу үз фикерен әйтү генә иде бит. Гаскәрләргә ул берничек тә аяк чалмады, базардагы гайбәт сүзгә хаким ышанырга тиеш түгел кебек. Бу хәлләрнең Баялун хатынның кинәт чирләп китүе белән туры килүе дә очраклы хәлгә охшамаган.

Уйчан халәттә хансарай буйлап үз катына атлап барганда, аны борылыштан килеп чыккан Мостафа әвнух чак кына бәреп екмады. Бәкләр-бәген күргәч, ул агарынып китте, билен бөгеп, гафу үтенергә кереште.

– Кая чабасың болай, Мостафа ага? – дип сорады бәкләр-бәге, уйларыннан аерылып.

– Беркая да түгел, бәкләр-бәге. Дөресрәге, чабам, әйе. Тайдула хатын чакырткан, диделәр, аның янына ашыгуым.

– Кызык. Баялун хатын аяктан егылырга өлгермәде, инде Тайдула хатын бүлмәсеннән чыгып тормыйсың. Мостафа ага, башта минем яныма кереп чык әле, синең белән сөйләшәсе сүз бар иде.

Мостафа әвнухның бәкләр-бәге әмеренә каршы килергә җае юк, ул, башын түбән иеп, Котлы Тимер артыннан иярде.

– Баялун хатын Тайдула ханбикә янына килгәч, алар ни хакында сөйләштеләр, Мостафа ага? – дип сорады Котлы Тимер, үз бүлмәсенә кереп, ишекләрне япкач.

– Белмим, бәкләр-бәге, белмим, миңа болары мәгълүм түгел.

– Мостафа ага, бу хансарайда син белмичә калган бер генә нәрсә дә, син ишетмәгән бер генә сүз дә юк. Каршыңда бәкләр-бәге торганлыгын оныттыңмы әллә?! – Котлы Тимер кесәсеннән көмеш акчалар белән шыплап тулган янчык чыгарып, әвнухка ташлады. Тегесе шунда ук, өйрәтелгән маэмай сыман, аны һавада очып барган шәпкә эләктереп алды һәм күнегелгән хәрәкәт белән кесәсенә яшерде. – Бусы әнә, телең бераз ачылып китсен, хәтерең яхшырсың өчен. Ә хәзер бар белгәнеңне сөйлә. Ул көнне Баялун хатын ниләр эшләде, кемнәр белән күреште?

Мостафа әвнух, ни эшләргә дә белми, яклаучысын эзләгән төсле як-ягына каранды. Тик бүлмәдә алар икәү генә иде.

– Минем дәрәҗәле исемемә зыян килмәсә...

– Юк-бар белән баш әйләндереп маташма, Мостафа ага! Бар белгәнеңне сөйләп бир, юкса хансарайдан урамга куып чыгарам үзеңне!

– Яхшы, бәкләр-бәге, ихтыярың... Кичә Баялун хатын иртәдән үз ягында булды, бераз башы авыртуга зарланды. Мин аңа кытай чәе китерттем, каты иттереп пешерттердем. Соңрак аны бөек ханыбыз үз янына чакыртты. Алар күзгә-күз шактый озак сөйләштеләр, валлаһи, сүзләре ни хакында икәнлеге миңа мәгълүм түгел!

– Хан артыннан да шымчылык итсәң, бирермен кирәгеңне...

– Юк, син нәрсә, бәкләр-бәге, уйлап караганым да юк бу турыда.

– Йә, ары ни булды?!

– Хан яныннан чыкканда, Баялун хатынның кәефе нык кырылган иде. Ул миннән үткән төнне ханның кем белән үткәрүе турында кызыксынды. Мин Тайдуланы чакыртуын әйттем. Шуннан соң Баялун хатын ханбикә бүлмәсенә юнәлде.

– Ни хакта сөйләштеләр алар?

– Тәгаен генә әйтә алмыйм, ләкин талаштылар кебек. Синең исемең дә берничә мәртәбә яңгырады...

– Моны син аермачык ишеттеңме?

– Әйе, аларның сөйләшүләре кычкырышуга ук күчкән иде, бәкләр-бәге.

– Аңлашылды... Мостафа ага, бар, юлыңда бул, үзеңне Тайдула хатын көтә дигән идең бугай. Файдалы мәгълүматың өчен рәхмәт.

Әвнух чыгып киткәч тә, Котлы Тимер янә үз уйларына чумды. Күңеле ялгышмаган, дөрес сизгән. Аңа каршы ханны котыртканнар, һәм ул котыртучы Тайдула булып чыга. Ә Баялун хатын исә бәкләр-бәген якларга маташкан, күрәсең...

Ул арада Мостафа әвнух, тирләп-пешеп, Тайдула бүлмәсенә атылып керде.

– Кайда болай озак йөрдең, Мостафа ага, көтә-көтә арып беттем үзеңне! – дип җикеренде ханбикә. Аннан соң кинәт кенә йомшады, әвнухка якын ук килде. – Ярый, эшең күп икәнлеге миңа мәгълүм, син хансарай иясе төсле, кая да өлгерәсең. Ә хәзер минем сүземне дикъкать белән тыңла, һәрбер җөмләне күңелеңә киртләп куй. Моңарчы син һәрвакыт Баялун хатын тирәсендә бөтерелдең, аның күзе һәм колаклары булдың, бөтен белгәнеңне шунда ук аңа ирештереп тордың. Инде сизгәнсеңдер, хәлләр нык кына үзгәрде. Олы яшьтәге хатын әлеге авырудан аңына килә алмас кебек. Шуңа күрә үзең өчен бер карар кабул итәргә тиешсең. Миңа хезмәт итәргә әзерме син?

Каушап калган Мостафа әвнух янә ни кылырга да белмәде, аннары, ике тезе белән дә берьюлы идәнгә гөрселдәп, ханбикә каршында баш иде.

– Мостафа синең ышанычлы яраның булырга әзер, сөекле ханбикәм. Синдәй зирәк кешегә хезмәт итү – минем өчен олы дәрәҗә!

– Әгәр мине алдап йөрсәң, шул мизгелдә үк үзеңне хансарайдан кудыртам, моңа гына көчем җиткәне сиңа мәгълүмдер, шәт?!

– Мәгълүм, ханбикәм, мәгълүм. Сине алдамаска, соңгы сулышка кадәр тугрылык сакларга ант әчәм.

– Хансарайда кемнең ни эшләгәнен, ни сөйләгәнен миңа җиткереп торырсың. Бигрәк тә бәкләр-бәге Котлы Тимерне яхшылап күзәт, ул

ханыбызга каршы мәкер уйлап йөргән бәндәгә охшаган. Әгәр эшеңне җиренә җиткереп башкарсаң, буш итмәм. – Тайдула акча тулы янчыкны тезләнгән әвнухка ыргытты, тегесе, аны җәһәт кенә тотып алып, әле генә Котлы Тимердән алган «күчтәнәч» янына яшерде. – Бар, эшләреңне кара, бүтән үзеңне болай озаклап күтәргә мәҗбүр итмә!

Тайдула, ике җариясен ияртеп, Баялун хатын ягына ашыкты. Кызларны ишек катында калдырды, үзе эчкә узды. Баялун янәшәсендә табиб Ибраһим ага кайнаша иде.

– Саумы, Ибраһим табиб, – диде Тайдула, йөзенә мөмкин кадәр кайгылы кыяфәт чыгарып. – Сөекле Баялун хатынның хәлләре ничегрәк? Аякка басуына өмет бармы?

– Өмет беркайчан да сүрелмәскә тиеш, мөхтәрәм Тайдула ханбикә, – табиб, хатынның сәламен алып, чак кына башын ия төште. – Әмма Баялун галиҗәнапларының хәле шәптән түгел. Күрәсең, инде күптән чирләп йөргән, сер генә бирмәгәндер. Хәзерге рәвешкә калуына бер сәбәп кенә кирәк булган. Әллә артык шатланып, әллә көенеп ташлаган. Авыруы аны шул ук мизгелдә аягыннан еккан.

Тайдула күз читендә күренгән яшен сөртеп куйды.

– Ибраһим табиб, зинһар, гафу ит! Баялун хатын мине бала чактан алып үстерде, ул миңа әнием төсле якын. Син рөхсәт итсәң, аңа, исән вакытында, икәүдән-икәү калып әйтәсе сүзләрем бар иде. Авырсынмасаң, эшләрең бетсә...

– Аңладым, мөхтәрәм ханбикә, аңладым. Хәзер үк китәм. Әгәр элегрәк Баялун хатынның мондый халәттә икәнлеген белгән булсам, тынычландыра торган төнәтмәләр белән дәвалый алыр идем. Әмма, ни кызганыч, соңардык. Бу халәтендә аңа ярдәм итәрлек дару юк шул...

Ибраһим табиб чыгып киткәч, Тайдула Баялун хатын янына килде. Ул урынында кымшанмый ята, күзләре генә ханбикә тарафына ут чәчеп карап тора. Тайдула аның хәлсез кулын учына алды.

– Гафу ит мине, Баялун хатын, – диде ул, кинәт ихластан күңеле тулып, шаулап яшьләре бәреп чыкканын тоеп. – Минем сине рәнҗетәсем килмәде. Син үзеңнең дә балаң булганын әйткән идең. Сабыема, аннан соң туасы нарасыйларыма бәхет кенә телим мин. Шуның өчен барлык көчемнән көрәшәм, елыйсы килгән чакта елмаям, җирәнгеч гамәлләрне ләззәтләнгән төсле башкарам. Минем ихтыярсыз әйтеп ташлаган сүзләремне болай йөрәгеңә якын алырсың дип уйламадым. Бәхиллегеңне бир, Баялун хатын, синең рәнҗеш белән китеп баруыңны белеп яшәү миңа бик авыр булыр...

Баялун хатын акрын гына күзләрен йомып алды. Кабат ачканда аның да саркып чыккан яшьләре күренде, Тайдула саклык белән генә аларны сөртеп куйды. Баялун хатынның карашы да, йөзендәге халәте дә үзгәрде сыман. Аннан Тайдулага карата янә җылылык һәм чиксез ярату сирпелгәнен сизде. Ханбикә, инде үксеп үк елап, Баялун хатынның ятагы каршында тезләнде, башын хәлсез карчыкның күкрәгенә салды.

– И минем Баялуным! Гафу итә күр, кадер-хөрмәт күрсәтә алмый калдым! Бер ялгызы, әти-әниләренең, туганнарының үлемен башыннан яңа гына кичергән, тоткынлыкта кыргыйланган кызчык сине күргәч тә якын иткәнен хәзер генә әйтергә көчем житте. Синең яныңа йөгереп килеп,

итәгеңә ябышасы килде. Хәтерлисеңме син мине, туңып, өшеп беткән, ач, яланаяклы ябык кына сабыйны?! Үстердең, кеше иттең, минем өчен барысын да эшләдең. Җир йөзендә татымаган рәхәтлек күкләрдә сиңа һичшиксез насыйп булачак. Мин сиңа мәңге догада торырмын. Зинһар, акылсыз кызыңа рәнҗеп кенә китә күрмә, бәгырем минем, бердәнбер яраткан кешем Баялун хатын!

Ишеккә сак кына каккан тавыштан Тайдула сискәнеп китте, тиз генә торып, өстен-башын рәткә китерде, битен сөртте. Баялунга карады – аның күзләре елмая кебек иде.

– Аңлавың өчен рәхмәт сиңа, Баялун хатын! – Тайдула янә аның кулын учында кысты, аннан соң, тынычлангандай булып, ишеккә борылды. – Кем бар анда, керегез!

Бусагада үзен озата килгән кызлар күренде.

– Бәкләр-бәге Котлы Тимер бирегә килгән, ул да Баялун хатын белән күрешергә тели, – диде аларның берсе.

– Керсен, без китәбез инде.

Бәкләр-бәге белән алар ишек катында очраштылар. Тайдуланы күргәч, Котлы Тимернең, ирексездән, йөзе тартышып куйды, әмма ул елмаерга көч тапты.

– Сине күрүемә бик шатмын, галиҗәнап ханбикә, – диде ул, чак кына башын ия төшеп.

– Мин дә шат, бәкләр-бәге. Баялун хатынны артык борчыма, Ибраһим табиб аңа беренче чиратта тынычлык кирәклеген әйтеп калдырды.

– Миңа кадәр үк аны борчыганнар икән дип ишеттем. – Елмайса да, Котлы Тимернең карашы яман усал иде. – Шулкадәр борчыганнар ки, хәтта телдән язган.

– Котлы Тимер, авыру кеше өстендә сүз көрәштереп тормыйк. Рөхсәт итсәң, юлымда булыйм.

– Әлбәттә, ханбикә галиҗәнаплары. – Котлы Тимер, юл биргәндәй, читкәрәк атлады, Тайдуланы үткәреп җибәрде. Ишек ябылганчы ханбикә аркасы белән аның нәфрәт тулы карашын тойды.

## 6

Ибраһим табиб ялгышмады – Баялун хатын урын өстендә озак ятмый, җан тәслим кылды. Үзбәк хан да, Котлы Тимер дә бу хәбәрне зур кайгы итеп кабул иттеләр, хәсрәтләре ихлас иде. Әлеге югалту элеккеге ике дусны янәдән якынайтты шикелле – Баялун хатынны олылап җирләү хәстәрен бергә күрделәр, өчесен, җидесен укытканда, янәшә булдылар. Берсе дә күптән түгел ике арада булган киеренке сөйләшүгә кабат әйләнеп кайтмады.

Шулай да, аңлашылмаучанлык, яртылаш әйтелгән гаепләүләр упкын төсле үзен сиздереп торды. Моңа нокта куяр өчен Баялун хатынның җидесеннән соң озак та үтми, Үзбәк хан Котлы Тимерне үз тарафына чакырды.

Бүлмәгә кереп, ике кешегә хәстәрләнгән чәй табынын күргәч, бәкләр-бәге җитди һәм шул ук вакытта ихлас сөйләшү көтелгәнлеген аңлады. Гадәттәгечә, киеренке һәм җитди халәттәге хан, әллә ни җәелеп китми генә, бәкләр-бәген табынга дәште.

– Баялун хатын миңа әнием төсле якын иде, – диде ул, әйтерсең, яңа гына өзелеп калган сөйләшүне дәвам итеп. – Урыны җәннәттә булсын... Югалткан туганнарым хәтсез, тик бер генә үлемгә дә әзер торып булмый икән. Барысын да йөрәк аша үткәрергә туры килә. Соңгы күрешүебез дә матур тәмамланмады... Синең хакта сөйләштек, Котлы Тимер!

Бәкләр-бәге дәшмәде, ханны бүлдермичә тыңларга, аңа фикерен әйтеп бетерергә мөмкинлек бирергә карар кылды. Үзбәк тә шуңа өметләнә бугай. Чәен йотып куйгач та, Котлы Тимергә карамый, дәвам итте:

– Яшермим, сиңа ачуым бар иде. Мин бу хакта Баялун хатынга да әйттем. Ул сине якларга кереште. Менә хәзер яшә инде, Баялунның үлеменә үзеңне гаепле санап...

– Алай димә, бөек ханым. Барысы да тәкъдиргә язылган...

– Килешәм, шулайдыр. Ләкин тәкъдир шулай хәл кылды ки, Баялун хатын белән сүзгә кергән килеш бәхилләштек. – Хан авыр сулап куйды. – Арабыз ерагайды, Котлы Тимер. Гаеп кайсыбыздадыр – шайтан белсен. Үзең бу нисбәттән ни әйтерсең? Мине нахак гаеп белән сиңа салкынайды дип саныйсыңмы?

– Сине гаепләргә ниятем юк, бөек ханым. Килешәм, мин таррак фикер йөртәмдер, син исә тәхет биеклегеннән киңрәк күрәсең. Әмма мин синең карарларга каршы төшәргә теләмәдем, бары тик үз фикеремне генә белдердем...

– Кызганыч ки, халык арасында инде синең фикерең ханныкыннан да үтемлерәк дигән сүзләр таралган. Чәйханәгә кергәч, ишеттең бит теге ак сакаллы картны.

– Бер бәндә гайбәте ул әле ил фикере түгел.

– Ил аерым бәндәләрдән тора, Котлы Тимер. Сине миңа тиңли башлаганнар, алай гына да түгел, өстәрәк тә тора дип сөйлиләр икән, биредә уйланырга урын бар. Әллә, чыннан да, мин артык йомшак, әллә син артыгын кыланып ташлагансың.

– Синең хакимлекне шик астына куярлык бер генә гамәл дә кылмадым, сөекле ханым. Мин синең тугры хезмәтчең, үз урынымны белеп йөрергә тырышам...

– Күктә кайвакыт берьюлы ай белән кояш очраша. Моны кешеләр һәрвакыт начар фалдыр дип юрый. Урда күгендә бер генә кояш булырга мөмкин, бәкләр-бәге Котлы Тимер. Без синең белән дәүләтебезнең иминлеге өчен күп көч түктек, канны да шактый агызырга туры килде. Олысларга тәхеткә хакы булмаган кешеләрне, шундагы ыруларның хөрмәтле һәм булдыклы әмир-бәкләрен билгеләдек, үзебезнең Чыңгыз нәселенә караганнарын кылычтан үткәрдек. Икебезнең ахмаклыгы аркасында ирешелгәннәр юкка чыкмасын иде. Безгә берәр төрле карарга килеп, бүтән арабызга гайбәтләр кертмәслек итәргә кирәк. Синең нинди фикерләрең бар?

– Бөек ханым, мин бу турыда шактый уйланып йөрдем. Урын өстендә ятканда, Баялун хатын белән дә киңәшләштем, ул мине ишетте һәм хуплады кебек. Минем синең ярдәмчең, терәгең булып каласым килә. Тик Сарай – бик кырыс урын, биредә сак кыланырга кирәк. Күзләр дә, колаклар да шактый. Сәясәт белән шөгыльләнеп тә шактый алҗыдым кебек. Хәер, ул мәсьәләдә синнән дә остарак кеше юк, сине өйрәтергә кирәкми,

зирәк ханым. Әгәр рөхсәтең булса, мин, кире Үргәнечкә кайтып, Хәрәзем олысында гына хакимлек итәр идем...

Котлы Тимер ханның күзләреннән үк аңлады – Үзбәк аңардан нәкъ шушы тәкъдимне көткән иде. Тик яхшысынмады, бәкләр-бәгенең карарын хуплавын күрсәтмәде. Киресенчә, аны әлеге уйдан кайтарырга да маташкан булып кыланды.

– Юк, син миңа янәшәмдә, мөддәбирем, киңәшчем буларак бик кирәк, Котлы Тимер! – диде ул, бер үк вакытта өстеннән авыр таш төшкәнлеген җаны-тәне белән тоеп. – Без бергә хакимлеккә килдек, соңгы сулышка кадәр бергә булыйк.

– Җылы сүзең өчен рәхмәт, бөек ханым! Ләкин мин карарымнан кайтмас идем. Үргәнечтә, башлап та, азагына җиткерелмәгән бихисап эшем калды. Исән чакта, аларны тәмамларга исәбем.

– Алай икән... Яхшы, Котлы Тимер, бу фикергә килгәнче, яхшылап уйлагансыңдыр, ул яктан син бик төпле кеше. Синең ихтыярыңа каршы төшә алмыйм. Шулай да, бер үтенечем бар. Үз тирәбездә яңа гайбәтләргә урын калдырмыйк. Дошманнар болар талашкан икән дип шатланмасын. Хәрәземгә кайтып китүеңне бераз соңрак, төрле имеш-мимешләр тынгач игълан итәрбез.

– Баш өсте, бөек ханым, син ничек әйтсәң, шулай булыр!

**7**

Ширван җирләрендәге яудан Мисыр солтаны Әл-МәликӘн-Насыйр шактый отты һәм Урда ханына бурычлы икәнлеген онытмады. Үзбәк хан яудан кайткач, озак та үтми, Сарайга Мисырдан Сәйфетдин Үтәҗи әмир җитәкчелегендәге олы илчелек килеп төште.

Солтанның бүләкләре күз явын алырлык иде. Гадәттә, мондый очрашуларда йокымсыраган кыяфәт чыгарырга тырышкан Үзбәк тә тыелып кала алмады, затлы парчаларны, аллы-гөлле келәмнәрне, асылташлар белән мулдан бизәлгән кылыч-хәнҗәрләрне – барысын да күздән кичерде. Илчесе аша солтан җибәргән хатта исә ханның җанын эретерлек мактау, рәхмәт сүзләре язылган иде.

– Бөек солтаныбыз Әл-МәликӘн-Насыйр миңа тагын бер бик мәртәбәле һәм шул ук вакытта нәзакәтле бурыч йөкләде, – диде Сәйфетдин әмир, хатны укып бетергәч. Ул бүлмәдәгеләрнең барысын да бик серле кыяфәт белән күзләп чыкты, хан гаиләсенә аеруча игътибар белән карап торды. – Мисырның кодрәтле хакиме Сарайның үзенә тиңдәш ханы белән туганлашырга тели!

Җыелган җәмәгать «аһ!» итте. Гадәттә бик тыныч халәтен саклаган Исабәк тә мондый көтелмәгән сүзләргә гаҗәпләнүен яшерә алмады. Нәзифә хатын исә янәшәсендәге кызы Иткөҗекнең кулын кысып тотты. Үзбәк хан бүләкләр кабул иткәндәге шатлыгының бер мизгелдә таралуын тойды. Шунда ук күз алдына рус олысына кияүгә бирелеп харап ителгән бертуганы Көнчәага килеп басты. Йөрәгендәге яралары әле җөйләнмәгән, зур бәладә үзен генә гаепле тойганга, алардан кан саркый... Тик илчегә сер бирергә ярамый, Үзбәк чак кына сизелерлек итеп елмайды.

– Бу минем өчен зур дәрәҗә булыр иде, мөхтәрәм Сәйфетдин Үтәҗи.

Солтанның минем олы ырумнан тәгаен бер чибәр кызны аласы киләме, әллә инде килен сайлауны сиңа йөкләдеме?

– Бөек хан, синең кызың Иткөҗекнең матурлыгы һәм акылы хакында бөтен дөнья буйлап риваятьләр йөри. Кодрәтле солтаныбыз нәкъ менә аңа ярәшергә җибәрде. – Илче, елмаеп, билен бөкте.

Үзбәк ханның йөзенә көенү чаткылары чыкты, ул хәтта учы белән тезенә дә сугып куйды.

– Кирәк бит, ә?! – диде ул, һәм, үкенечен раслагандай, тирән итеп сулыш алып куйды. – Иткөҗек кызымны мин бик кадерләп, саклап үстердем. Чыннан да, аның гүзәллеге җырларга салырлык, тәрбия-әхлагы исә һәркемгә дә мәгълүм. Тик... Кызым ярәшелгән инде, Сәйфетдин Үтәҗи.

Бүлмәгә янә гаҗәпләнү иңде, беркем дә, шул исәптән Иткөҗек үзе дә берни дә аңламыйлар иде. Кызны ярәшүне һәркайсы беренче тапкыр ишетте.

– Гадел һәм зирәк Әл-Мәлик Ән-Насыйр солтан мине, һичшиксез, аңлар. Динебездә вәгъдә – иман, диелгән. Вәгъдәне дә, иманны да бозарга хакым юк. Хан сүзе бер була.

Сәйфетдин илче бу тамашага ни дип тә әйтергә белмәде. Хан исә бер башлап җибәргән сәер уенын туктатырга уйламый да иде.

– Зыян юк, минем ыруымда Иткөҗеккә тиңдәш, аннан да чибәррәк һәм иплерәк кызлар җитәрлек. Бер атнадан соң мин сиңа үземнең карарымны җиткерермен. Мисыр дәүләтенең бөек солтаны теләге – минем өчен кадерле йөкләмә. Шул ук вакытта, Сәйфетдин илче... – Үзбәк хан, зур сер әйткәндәй, илчегә генә сөйләгән төсле кыланды, авызының бер читен кул аркасы белән каплады. – Безнең мөселман кануннары килен өчен калым таләп итә. Ханнар арасындагы алыш-бирешнең дәрәҗәсен төшерергә ярамый. Шуңа күрә мин калым хакын алтмыш мең динарга тиңләр идем.

Сәйфетдин Үтәҗи, бу санны ишеткәч, чак кына кычкырып җибәрмәде.

– Бөек хан, минем үзем белән бу кадәрле акчам юк, – диде ул, агарынып китеп.

– Зыян юк, бер өлешен түләсәң, калганын киленне озата барган әмирләрем алып кайтыр. Аннан соң, булачак никах хөрмәтенә, минем ыруга караган һәм Урданың иң дәрәҗәле хатыннары өчен мәҗлес корасы. Анысы зур түгел, кунаклар саны меңнән артмас дип уйлыйм...

Үзенең шулай тиз арада четерекле мәсьәләне хәл итүеннән чиксез канәгать хан тәхетендә җәелебрәк утырды.

Сәйфетдин Үтәҗи илче сакал бөртекләренең тамырлары чемердәп куйганлыгын тойды. Аркасыннан шабыр тир ага иде. Әл-Мәлик Ән-Насыйр солтан аны нәкъ менә Иткөҗек ханбикәне хатынлыкка сорарга җибәрде бит! Аның ярәшелгән икәнлеген шайтан белсен! Әмерен үтәмәгән өчен башын кисмәсме?! Икенче яктан, Үзбәк ханның тәкъдимен кире какса, бу Урда хакиме йортына әйтеп бетергесез хурлык булачак. Ул, вак кына бер илче, хан нәселендә Мисыр солтанына тиң икенче кыз барлыгына шик белдергән, имеш! Моның өчен хәзер үк башыңны кисәрләр, бусаганы атлап чыгарга өлгермәссең! Үзе белән хан әйткән кадәрле акча юк, ләкин Урдада һәрвакыт бик теләп һәм аннан соң артыгы белән кайтаруны шарт итеп куючы бәндәләр табыла. Хәзер үк кабергә кергәнче, Үзбәк хан шартлары буенча уйнау хәерлерәк булыр.

– Яхшы, бөек хан, синең шушындый катлаулы хәлдә дә зирәк карар кабул итүең мине сокландырды, – дип, бишкә бөгелде Сәйфетдин Үтәҗи. – Барысын да син теләгәнчә оештырырмын, ике бөек хакимне туганлаштыру өчен кылган хезмәтләремне Аллаһы Тәгалә үзе кабул итеп, әҗер-савапларын бирә күрсен!

Илче чыгып киткәч, Үзбәк хан бүгенгә очрашулар тәмам икәнлеген белдерде. Гаилә әгъзалары, бигрәк тә кызы Иткөҗек аның белән сөйләшергә талпынса да, үз якларында көтәргә кушты. Янәшәсендә бары тик Исабәкне генә калдырды.

Һәммә кеше таралышкач, Үзбәкнең төс-кыяфәте янә үзгәрде, ул, элеккеге җилле егет халәтеннән кырыс ир хәленә кайтты.

– Исабәк, син минем ышанычлы кешем дә, якын дустым да, – диде ул, бүлмәдә артык колаклар калмаганлыкка инангач. – Мине дөрес аңла – кызымны чит җирләрдәге бер белмәгән кешегә бирә алмыйм. Хәтта ул солтан булса да. Сеңлем Көнчәаганы рус олысына кияүгә озатып карадым, моның ни белән беткәнен син яхшы хәтерлисең. Аның үлеменә гаепле дип, көн саен үземне битәрлим. Икенче шундый югалтуны минем акылым да, йөрәгем дә күтәрә алмас...

– Аңлыйм, сөекле ханым, – дип, чак кына башын иде янәшәсендәге Исабәк. Ханга сораулары күп булса да, берсен дә әйтергә кыюлыгы җитмәде.

– Шуңа күрә, Исабәк, кызымны ярәшергә килгән кеше син булачаксың!

Исабәк, әллә ялгыш ишеттемме дип, тынсыз калды, аннан тәхет каршына, ханның аяк астына егылды.

– Бөек ханым, төшемме бу, әллә өнемме? Мин моңа хыялланырга да җөрьәт иткән кеше түгел бит...

– Торып бас, Исабәк, барысы да өндә. Кызым янәшәмдә һәм ышанычлы кулларда булыр. Мисыр солтаны илчесен озаткач, шартын китереп, гөрләтеп никах үткәрербез. Ә хәзер башкасын уйлап бетерәсе бар. Иткөҗек урынына Мисырга кемне җибәрәсе? Чибәр дә, акыллы да, минем ырудан да... Тагын берәр шундый кыз бармы бездә?

– Рөхсәт итсәң, бөек ханым, минем бер тәкъдимемне тыңла. Төкәтҗү әмирнең күз явын алырлык кызы Толымбай буйга җитеп үсте. Холкы да ипле, төс-кыяфәткә дә бик чибәр. Әгәр аны Мисыр солтанына хатынлыкка җибәрсәк, ул да канәгать калыр, синең дә дәрәҗәң сакланыр.

– Төкәтҗү минем ырудан бик ерак тора бит...

– Без барыбыз да – бертуган, сөекле ханым. Толымбайны күргәч, Мисыр солтаны аның җиде ата-бабасын сораштырып тормас, моңа иманым камил.

– Сүзең хак булыр дип өметләник, Исабәк. Иртәгә үк Төкәтҗүне гаиләсе белән минем яныма чакырт, әлбәттә, Толымбайны да онытмасыннар.

Ярдәмчесе белән саубуллашкач, Үзбәк хан хансарайның тар аралыклары аша хатын-кызлар ягына юнәлде. Аңа Мостафа әвнух юл күрсәтеп бара иде.

Беренче эш итеп, Үзбәк хан Нәзифә бүлмәсенең бусагасын атлап керде. Олы хатыны югалып калган кыяфәттә каршылады аны.

– Нәзифә, нигә синең болай йөзең качкан? – дип, хан, аның янәшәсенә

килеп, битенә төшкән чәчләрен сыпырды. Хатынының елаганлыгы күренеп тора, күз төпләре юеш, шешенгән.

– Үзбәк, мин синең хатының бит, – диде ул, янә еларга җитешеп. – Кызыбызга синең кадәрле дәрәҗәдә минем дә хакым бар. Аның язмышын син хан буларак түгел, ә минем ирем һәм аның әтисе рәвешендә хәл итәргә тиеш. Кызыбызны сорарга килгәннәр икән, ник мин бу хәбәрне барча җәмәгать белән бергә киңәшмәдә генә ишеттем?

Үзбәк хан көрсенеп куйды.

– Нәзифә, тыңла әле сүземне. Минем һәрбер карарым – хан боерыгы. Тәхеткә утырган көннән бирле мин үз-үземә хуҗа түгелмен. Барысын да дәүләт мәнфәгатен кайгыртып хәл итәргә тиешмен...

– Тәхет дип, үзеңне шулай югалтырга ярыймы?! Хакимлек сине нык үзгәртте, күреп-сизеп торам. Мине үз тарафыңа дәшмәвең белән дә күптән килештем. Ләкин мин сиңа тәүге улыңны һәм кызыңны бүләк иткән кеше! Хатын-кызны шулай мәсхәрәләргә ярыймыни?! Бер нәрсә булса, дәүләт өчен дисең дә авызымны ябасың. Үз тирәңә бары тик һәр сүзеңә килешеп, баш кагып торучыларны гына җыеп бетердең...

Үзбәкнең ачуы куба башлады, Нәзифәгә кайтарып әйтерлек, аңа килеп туган хәлне аңлатырлык сүзләр табылмады.

– Иткөҗек минем нәибем Исабәккә кияүгә чыгачак. Бу карарымнан ваз кичмәячәкмен!

Нәзифә, моны ишеткәч, тыела алмый үксеп үк елап җибәрде:

– Исабәк нәибкә?!... Хан кызын яраныңа икенче хатын итеп бирәсеңме?!.

Бәгыре кинәт таштай каткан Үзбәккә Нәзифә бөтенләй ят, килбәтсез хатын төсле тоелды. Үзенең аны яратып өйләнә алуына шаккатты. Салкын, хәлгә кермәс, аны аңламас бәндә белән ничек итеп ике бала үстерде ул?!

– Мин кызымны беркайчан да кыерсытмадым. Һәм алга таба да кадерләп саклармын. Ә син, Нәзифә... Никахтан соң Тимербәк янына Хәрәземгә китәрсең, әйберләреңне җыя тор!

Үзбәк җан ачысы белән елаудан бөгелеп үк төшкән хатынына арты белән борылды да бүлмәдән чыгып китте. Бүтән аның Нәзифәне күрәсе килми иде...

Иткөҗек әтисен бик тыныч халәттә кабул итте. Аның тарафына кергәч тә, Үзбәк хан әле генә булган сөйләшүне онытып елмаерга тырышты. Зур күзләре белән үзенә тутырып караган кызы янәшәсенә килде, утырырга чакырды.

– Бу дөньяда синнән дә якынрак һәм кадерлерәк башка хатын-кыз юктыр, Иткөҗек, – диде ул, баласының кечкенә кулын учына алып. – Капылт әйтелгән карарым өчен гафу ит, ләкин аны мин синең бәхетең өчен ирештерергә мәҗбүр булдым. Мин сине югалтсам, йөрәгем кайгыдан ярылачак. Апаң Көнчәаганы уйлаган саен бәгырем телгәләнә. Күңелемә якын икенче кешене чит-ятларга чыгарып җибәрә алмыйм...

Иткөҗек әтисенең куенына сыенды.

– Сөекле ханым, мин сине бик яхшы аңлыйм. Синең миңа карата мәхәббәтеңне тоеп яшим. Ни әйтсәң, шуңа күнәргә әзермен. Бер дә борчылма...

Үзбәк хан эченнән генә Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтен ирештерде. Кызы аны яклый, бусы – иң мөһиме.

– Исабәк – син аны бик яхшы беләсең, шулай бит?

– Беләм, сөекле ханым...

– Озакламый син аның хатыны булырсың. Ул сине рәнҗетмәс, бөтен гозерләреңне дә үтәр. Корылтайда урыннарыгыз янәшә, минем янымда ук... Син бу тәкъдимгә ризамы?

– Риза, сөекле ханым, барысы да син дигәнчә булыр. – Иткөҗекнең тавышы төссез, аның шатланамы, әллә көенәме икәнлеген һичничек аңларлык түгел. Тик Үзбәк хан кызының сүзләрендә ачу да, үпкә дә тоймады.

– Рәхмәт, кызым, – дип пышылдады Үзбәк хан, кинәт күңеле йомшарып китеп. Иткөҗекне маңгаеннан сак кына үбеп алды. – Янәшәмдә мине аңлаучы кешеләр бетеп бара төсле иде, син миңа яшәү көче бирдең. Бу гамәлеңне мәңге онытмам...

**8**

Төкәтҗү әмир көтелмәгән җирдән ишелеп төшкән бәхеткә чиксез шатлыгын яшермәде. Кирәк бит, уйламаган да иде, ә монда хан үзе тәхет каршына чакыра, диванга әмир итеп кертергә җыена, ә инде аның кызын Мисыр солтанына кияүгә бирү... Бусын иң татлы хыялларында да күз алдына китергәне юк иде. Әл-Мәлик Ән-Насыйр калымны да мулдан чыгарып салырга риза икән!

Толымбай исә, чыннан да, Исабәк әйткәнчә, бик чибәр һәм акыллы кыз булып чыкты. Аны Мисырга җибәрергә кызганыч та булып китте Үзбәк ханга – тәнсакчылары белән уратылган көе йөреп, Урдадагы чибәркәйләрне дә күрә алмый бит ул! Тик сүзе әйтелгән, аны үзгәртер әмәл инде юк.

Бөтен шартларына туры китереп, Сәйфеддин илче Толымбайга ярәште, алтмыш мең динарның егерме меңен шунда ук түләп куйды. Аннан соң дәрәҗәле хатын-кызларны мең кешелек табынга чакырды – анысы илчегә җиде мең динарга төште.

Мисырга киленне су юлы буйлап илтәсе иттеләр. Моның өчен зур кораб әзерләнде. Ул, Азак шәһәреннән Азов диңгезе буйлап башта Кара, аннан Урта диңгезгә чыгарга тиеш иде. Юл ерак булгач, хәстәрен дә күрделәр. Константинополь императоры Андроник Икенчегә Үзбәк хан җылы эчтәлектәге хат һәм бүләкләр юллады. Беренче тукталышны кораб шунда ясарга тиеш иде.

Толымбай бикәне озатырга Урда илчесе Баянҗарны билгеләделәр. Аңа затлы нәселләргә караган Айтугла, Тукбуга, Мәнгыш, Тарҗы, Биктимер, Кортык әмирләр иярде. Барлык гамәлләр дә Коръәнгә нигезләнеп башкарылуын баш казый Бәдретдин белән Борһанетдин имам күзәтеп торырга тиеш иде. Корабка барлыгы ике йөздән артык аксөяк утырды. Моннан тыш, меңгә якын хезмәтче һәм җарияләр Толымбай кулына тапшырылды.

Корабның юлга кузгалуы көзге чорга туры килде, диңгез бу вакытта бик дуамал кылана. Бөтен кеше дә Мисырга исән-сау килеп җитә алмаса

да, күпчелеге 1320 елның язгы май иртәсендә Искәндәрия каласын күрү бәхетенә иреште.

Толымбайны зур ихтирам белән каршыладылар. Җиде ай дәвамында корабта йөзеп, коры җиргә баскач, бераз башы әйләнсә дә, Урдадан килгән килен шатлыгын яшермәде. Әл-МәликӘн-Насыйр солтанның яраннары һәм хәрәмдәге җарияләре шаккатмалы матур киемнәр кигәннәр. Әйтерсең, биредә дөньяда булган барча төсләр җыелган. Ак чалма ураган чем-кара тәнле кешеләрне күрү үзе генә дә ни тора?!

Озакламый кунакларны, кечерәк көймәләргә утыртып, Каһирәгә алып киттеләр. Борынгы мәгърур шәһәр биек таш диварлары, йөзләгән мәчетләреннән яңгырап торган азан аһәңе белән каршылады. Бик зур, шанлы кала иде Каһирә.

Урдадан килгән илчелекне Үзәк мәйданда махсус алар өчен корылган атлас тирмәләргә урнаштырдылар. Шунда өч көн көткәннән соң, кунакларны солтан сараена, Әл-Мәлик Ән-Насыйр хозурына чакырдылар.

Әл-Мәлик Ән-Насыйрның кабул итү бүлмәсе үзенең купшылыгы белән һәркемне телсез калдыра иде. Ак мәрмәрдән күтәрелгән биек диварлар алтын йөгертеп бизәлгән, зур тәрәзәләрдән кереп торган яктылык, шул диварларга кагылып, тирә-якны нурга күмә. Уртада, мәрмәр ташлардан корылган күтәртмәдә алтын-көмеш, асылташлардан җемелдәп торган тәхет урнашкан. Шул тәхеттә Мисыр солтаны утыра. Яше кырыктан узган, ир затының иң матур мәленә кергән чагы. Карашында усаллык белән бергә тәкәбберлек тә сизелә – бөтен кыяфәте белән ул үзенең нинди олы көчкә ия булуын күрсәтеп тора.

Баянҗар илченең Үзбәк ханнан сәламнәр җиткерүен ул ялкау гына тыңлады, затлы бүләкләрне хиссез генә күзеннән кичерде. Бары тик Толымбай турында сүз чыккач кына җанланып китте.

– Бөек солтан, без бирегә үзебез белән бергә Үзбәк хан җибәргән иң олы бүләкне дә алып килдек, – диде Баянҗар әмир. – Урдабызның иң чибәр, иң уңган кызы, Үзбәк ханның кан карендәше Толымбайны хатынлыкка кабул итсәң, безнең дәүләтебез өчен бу чиксез шатлык булыр иде.

– Толымбай дисеңме исемен? – Солтан бер мәлгә уйга калды. – Ул Үзбәк ханның кызымы?

– Ни кызганыч, Үзбәк ханыбызның кияүдә булмаган кызлары әлегә буй җитмәгән. Шуңа күрә ул бертуган кардәшенең кызы Толымбайны җибәрде. Толымбайга гүзәллек буенча тиңдәш кыз Урдада да, якын-тирә дәүләтләрдә дә юктыр.

Солтан Сәйфетдин Үтәҗигә текәлеп бакты. Тегесе аның карашыннан куырылып килде, башын түбән иде һәм чак кына ишетелерлек итеп лепердәргә кереште:

– Баянҗар илченең һәрбер сүзе хак, падишаһым-солтаным! Үзбәк ханның кызы Иткөҗек ярәшелгән булып чыкты. Шуннан соң Урда хакиме бертуганының кызы Толымбайны тәкъдим итте. Мин башта карышып караган идем, аннан соң, ул кызны үз күзләрем белән күргәч, аның чыннан да сиңа тиң хатын икәнлеген аңладым. Андый гүзәллекне ташлап калдыру зур гөнаһ булыр иде...

– Сәйфетдин Үтәҗигә ышанам, Урда илчесе. Минем хакка шундый зур

уңайсызлыклар кичереп, күңелемне күргәне өчен Үзбәк ханга миннән олы рәхмәт сүзләрен җиткер. Бу никахыбыз ике дәүләт арасындагы туганлыкны тагын да ныгытыр, дошманнарыбызга каршы бердәм көрәштә ярдәм итәр, иншалла! – Солтан урыныннан торып басты, аннан янәшәсендәге әмирләренә борылды. – Сәйфеддин Аргун әмир, сиңа никах мәҗлесен оештырырга әмер бирәм. Табыннар ризыктан сыгылып торсын, чакырылган кунакларга бүләкләрне кызганмый таратыгыз. Сиңа ярдәмгә Сәйфетдин Биктимер әмир белән Кәрим Әл-Дин казыйны бирәм. Ике атнадан да соңармый никах укылсын. Аңа кадәр тиешле хәстәрен күрегез!

Атап үтелгән әмирләр, «баш өсте, падишаһым-солтаным» дия-дия башларын түбән иделәр.

Ике көннән соң парча-ефәкләргә төренгән Толымбайны, алтын йөгертелгән атлас белән капланган арбага утыртып, Каһирәдән читтәрәк урнашкан зур сарайга алып киттеләр. Арбага җигүле атларның өзәңгесен ике яктан баһадир гәүдәле ике мәмлүк яугире тотып барды. Аларга Мисыр һәм Урда ягыннан аксөякләр, имамнар иярде. Ашыкмый гына атлап, җәмәгать никах мәҗлесе үтәсе сарайга юнәлде.

Барып җиткәч тә, Толымбай затлы бүлмәгә урнаштырылды, Урда казые Бәдретдин белән мәмлүкләр солтаны вәкиле Сәйфетдин исә, мәчеткә кереп, никахлашу шартлары язылган килешүне имзаладылар. Әл-МәликӘн-Насыйр сүзендә торды – Толымбайга өйләнгәне өчен Урда ягына казнадан алтмыш мең динар түлисе иде.

Никах мәҗлесе зурдан кубып үткәрелде. Кияү белән яшь киленнең беренче күрешүеннән соң алар, икәүләп, мәйданда корылган күтәртмәгә менделәр. Солтан белән солтанбикә каршыннан мәмлүкләрнең гаскәриләре төз рәтләр белән үтте. Һәрберсе берәмтекләп сайлап алынган чибәр егетләр, өсләрендәге киемнәре бәйрәмчә – Урда тарафыннан килгән аксөякләр бу тамашаны таң калып күзәтте. Биредә җәяүле яугирләр дә, атлылар да, ике тәгәрмәчле ачык арбага баскан сугышчылар да бар иде. Алар артыннан дөяләргә атланганнары чыкты. Иң азактан, җиргә баскан саен тирә-юньне дер селкетеп, дүрт фил күренде. Филләрнең маңгайлары асылташлар чигелгән япмалар белән ябылган, ике яктан тырпаеп торган казык тешләренә аллы-гөлле тасмалар уралган. Сыртларындагы арбаларда исә берничә сугышчы урын алган.

Ачык һавада корылган табыннар да мул иде – килен ягыннан кунаклар кайбер тәм-томнарны, җиләк-җимешләрне беренче тапкыр авыз итте. Азактан никахка чакырылган һәрбер кешегә чигүле халатлар, ефәк күлмәкләр таратылды.

Мондый купшы туйны Мисырда күргәннәре юк иде. Урда аксөякләре, солтанның юмартлыгыннан бик канәгать калып, көзен генә кайтыр юлга кузгалдылар. Алар китеп озак та үтмәде, мәхәббәт мәсьәләсендә артык осталык күрсәтә алмаган Толымбайны Әл-МәликӘн-Насыйр солтан талак әйтеп аерды һәм үзенең янәшәсендәге бер сәргаскәренә хатынлыкка бирде. Бу хакта хәбәрне алгач, Үзбәк хан бераз гарьләнсә дә, артык сүз куертып тормады. Йөрәге алдамаган – кызын солтанга кияүгә бирми калып, бик дөрес эшләгән. Мисыр солтанбикәсе булып берничә ай гына яшәп калган Толымбайның тарихы әнә шулай тәмамланды...

Мәмлүкләр солтаны бик үткен хәтерле булып чыкты. Моннан соң шактый еллар үткәч, Үзбәк хан, солтан белән туганлашырга теләп, Каһирәгә илчеләр җибәргәч, Әл-Мәлик Ән-Насыйр «Минем Урда ханына бирерлек кызларым юк, барысы да бик кечкенә әле», – дип, кырт кисте...

**9**

Кытай белгече Чан Ши белән Болгар остасы Алмыш сүзләрендә тордылар – яңа башкала – Сарай Әл-Җәдид билгеләнгән вакытка тулысы белән өлгерде. Бу хакта алар икәүләшеп, хан каршына килеп, үзләре хәбәр иттеләр.

– Әлбәттә, шәһәрнең алга таба үсәргә, төзелергә мөмкинлеге бар, ләкин аның төп корылмалары әзер, бөек хан, – диде Чан Ши елмайган килеш башын игән халәттә. – Синең барлык теләкләреңне дә үтәдек.

– Таштан, сары балчыктан һәм агачтан күтәрелгән биналар бик нык һәм мәһабәт килеп чыкты, падишаһым-солтаным, – дип куәтләде аны Алмыш оста. – Бигрәк тә синең хансараең матурлыгы таң калдырырлык. Андый купшы сарай бер генә хакимдә дә юктыр.

– Сүзләрегез җаныма бал да май булып ята, хөрмәтле осталар! Минем яраннарым үзләре шәһәргә барып, аларның дөреслегенә инангач, мулдан әҗерен алырсыз. Әгәр җаегыз булса, Урдада калуыгызны үтенәм. Минем Кырымда мәчет салу теләгем бар, Хаҗитархан тирәләрен дә сипләргә кирәк. Бездә сезнең өчен эш беркайчан да бетмәс.

– Әгәр бөек ханга файда китерә алсак, бу безнең өчен чиксез бәхет. – Чан Ши тагын да түбәнрәк иелә төште шикелле.

– Котлы Тимер, Исабәк! Сезгә Сарай әл-Җәдидкә күченү хәстәрен күрергә боерам! Хан исеменнән игълан таратыгыз – яңа кала сәүдә өчен төп урынга әверелер. Анда төзелгән бина-корылмаларны башта минем яраннарым һәм туганнарым арасында бүлегез. Аннан соң теләге булган нойоннарга, бәясен чамалап куеп, таратып чыгыгыз. Төрле олыслардан килгән илчеләр, бәкләр өчен аерым урамнар билгеләнсен. Минем гаскәрем башкалада, хансарайга якын урында урнашсын. Барлык бу гамәлләр үтәлгәннән соң, башкалага җан кереп, халык анда күченгәннән соң, мин дә гаиләм белән шунда юл алырмын. Сарай Әл-Җәдидкә беренче аяк баскан көнем зур бәйрәмгә әверелсен. Казаннар асып, барча гавамга җитәрлек ит пешерегез, кымызны кызганмагыз. Олы мәйданда имамнар күмәк намаз укысыннар, алгы рәткә хан үзе басар. Әлеге намаз яңа шәһәребезнең нигезенә багышланган дога булыр. Бу әмеремне Урданың һәрбер почмагына җиткерегез, чит дәүләтләрнең илчеләренә хәбәр итегез. Башкалабыз – Сарай Әл-Җәдид һәммә кешене тартып торучы, кунакчыл кала булып калыксын! Ханның сүзе тәмам.

Әзерлек эшләре шактый вакытны алды, ләкин Котлы Тимер белән Исабәк ашыкмады. Яңа шәһәргә күченергә теләк белдерүчеләр бик күп җыелды, алар арасыннан иң ышанычлыларын үзләре сайлап алдылар. Зәркәнчеләр, күнчеләр, балта осталары, сәүдәгәрләр, алтын куллы башка һөнәр вәкилләре дә, хан белән бергә байлык чыганагы да, Сарай Әл-

Җәдидкә авышасын аңлап, үзләренә иң кулай йорт-корылмаларны алып калырга ашыкты. Төзелеш чыгымнарын күтәрмәсә дә, казнага барыбер саллы гына күләмдә акча керде.

Котлы Тимер мәдрәсәне һәм китапханәне гыйльми яктан тулыландыру хәстәрен күрде. Хәрәземнән дин белгечләрен, укымышлы галимнәрне чакыртты. Мәдрәсәгә дәрәҗәле әмирләрнең улларын сайлап алдылар. Китапханәгә исә басмалар агыла торды. Алар төрле телләрдә, төрле фәннәр хакында иде. Яңа башкалада хәтта йолдызларны өйрәнүче корылма да торгызылды.

Ханның гаиләсе белән бергә Сарай Әл-Җәдидкә килүен җомга көнгә билгеләделәр. Үзбәк үзе иң шәп атына атланды. Аның артындагы зур арбага улы Тәнибәк, кызы Сөенбикә һәм өченче тапкыр корсакка узган Тайдула утырды. Аларны берничә олауда ярдәмчеләре озата килә. Аннан ары Үрдүҗә бара, аның янәшәсендә өч кызы. Ханның җарияләре, ярдәмчеләре, бавырчылары төялгән арбалар исә йөздән дә артып китте. Ниһаять, әлеге озын кәрван юлга кузгалды. Ике яктан аны хан нүкәрләре озата китте. Алар хәрби киемнәрдән, атлары да махсус саклану япмаларына төрелгән.

Сарай Әл-Җәдидерактан ук күренде. Калкулыкта урнашып, ул, әйтерсен, тирә-юньгә нур сирпеп тора иде. Күпсанлы биналар, мәчет манаралары, чиркәү гөмбәзләре. Үзбәк ханның теләген искә алып, шәһәрне саклау өчен кирмән күтәрмәделәр. Бу – һәркем өчен ачык, кунакчыл кала булырга тиеш. Бер чите белән далага, икенче ягы белән Актүбәнең биек ярына терәлеп тора. Яр буенда күпсанлы кораблар шәйләнә. Моны күзәткән ханның күңеле шатланып куйды, тәне чемердәп киткәнне тойды.

Шәһәрдән аларны каршыларга Чан Ши белән Алмыш, аларга ияргән күпсанлы әмирләр чыкты. Чан Ши, иярдә йөрергә күнекмәсә дә, атка атланган иде. Мәзәк кыяфәт иде аңарда. Күрәсең, бәйрәм хөрмәтенә, иң матур киемнәрен кигән. Монголларның хәрби аты өстендә ул чәчәкле-чачаклы, аллы-гөлле киемнәр үзенә күрә бер көлке иде. Моңа Кытай остасының баш түбәсенә җыелган чәчләренә аркылы-торкылы тыгып куелган ике озын таякны да өстәгәч, бөтенләй сәер манзарага тап буласың. Шулай да, хан, Чан Шиның бик белемле оста икәнлеген истә тотып, аны мыскылларга җөрьәт итмәде.

– Бөек ханым, синең әмер белән төзелгән шәһәргә кешеләр җыйдык, ләкин ул, син булмагач, салкын һәм җансыз. Бары син генә аңа яшәү көче өрә аласың, үзеңнең яңа өеңә рәхим ит!

– Рәхмәт, Чан Ши оста! Сиңа да, Алмыш ага, Ходай исәнлек бирсен. Әле шәһәргә кереп җитмәс борын ук аның мәгърурлыгы күренеп тора. Аллаһы боерса, бик җанлы, кайнап торган кала булыр бу!

Хатыннарын һәм яраннарын хансарайга озатырга кушып, Үзбәк, атка атланган көе, шәһәр белән танышырга китте. Ул чиркәүле рус тыкрыгында булды, кызыл төсләргә төренгән, түбәләренә аждаһа сыннары менеп кунаклаган Кытай урамнарын үтте, үзенә генә хас йокымсырау халәтенә чумган көнчыгыш өлешен карады. Сарай Әл-Җәдидтә һәммәсенә дә урын табылган иде. Менә купшы тауарларын урамга ук чыгарып тезеп куйган Генуя сәүдәгәрләре, аннан ары чаялыгы

белән дан казанган яһүдләр, көн эшләнмәләренә тиңнәре булмаган Болгар осталары, Хәрәзем тарафыннан ук күченгән зәркәнчеләр, тагын әллә кемнәр!

Барган шәпкә Чан Ши белән Алмыш ага аңа Сарай Әл-Җәдиднең күзгә күренмәгән яклары турында сөйләде. Теләгән кешеләр өчен җәмәгать мунчалары да корылган икән. Эчә торган су исә һәрбер бинага махсус арыклар буенча китерелә. Башкаланың берничә почмагында шактый гына зур күлләр дә бар – аларга су үзлеге белән Актүбәдән агып керә, табигый рәвештә яңартылып тора.

Башкаланың йөзек кашы – Алтынташ. Аны күргәч, Үзбәк хан янә чиксез горурлык хисен кичерде. Ап-ак мәрмәр таштан төзелгән төп бина өстенә зур гөмбәз корылган, аны алтынга буяганнар. Гөмбәз өстендә исә зур кыйгач ай балкып тора.

– Сөбханалла! – дип кенә әйтә алды хаким. Аннан, бераз уйланып торгач, карарын җиткерде: – Хансарайны һәммә кеше Алтынташ дип атап йөртсен, бөек мәмләкәтнең үзәге шушында булыр.

– Баш өсте, бөек ханым! – диде Котлы Тимер. – Падишаһым-солтаным, син кыска гына вакыт эчендә Урдабызны алтын иттең, Ходай үзеңә алга таба да исәнлек һәм дәрман бирсен!

Хансарай каршындагы олы мәйдан халык белән тулган иде. Бер читтәрәк казаннар асылган, аларның буы борыннарны кытыклый. Ләкин Үзбәк ханның башында тамак кайгысы юк иде. Йөрәге чиксез шатлыктан ярылыр дәрәҗәгә җитте. Бу – аның куллары белән күтәрелгән шәһәр бит! Үзеннән соң мәңгегә калачак, аның төсе булып җир йөзендә сакланачак! Димәк, Үзбәкне кан елгалары агызган кеше түгел, ә булдыклы, дәүләтне үстергән хаким итеп хәтерләрләр, рәхмәт һәм мактау сүзләре белән искә алырлар. Хакимлекнең бөтен мәгънәсе дә шунда түгелмени?!

Атыннан төшеп, Үзбәк хан мәйданда үзен көтеп торган дин әһелләре янына юнәлде. Бирегә төрле олыслардан дәрәҗәле имамнар җыелган. Хан һәрберсе белән кул биреп күреште. Җомга намазын Бәдретдин казый алып барырга тиеш иде.

Ниһаять, Сарай Әл-Җәдидтәге барча манаралардан берьюлы азан тавышы яңгырады. Мәйдандагы ир-атлар сафланып басты. Күмәк җомга намазына керештеләр.

Үзбәк хан, күзләрен йомып, Аллаһыга мөрәҗәгать итте: «Йа Ходам! Минем башыма җибәргән күпсанлы сынауларыңны намус белән узарга ярдәм итүең өчен сиңа рәхмәтлемен! Әгәр мин бу дөньяда нәрсәгә дә булса ирешкәнмен икән – бары тик сиңа гына бурычлымын. Әгәр минем гөнаһларым җыелган икән – барысы да үземнең гаеп белән кылынган. Алдагы көннәремдә миңа сабырлык, зирәклек, акыл бир. Мине канкоешлардан, кешеләрне нахакка рәнҗетүдән аралап тор. Үземә, якыннарыма исәнлек бир. Балаларыма кул күтәрүдән саклап кал. Хакимлек белән вакыт-вакыт шашынып, төзәтеп булмаслык ялгышлык кылуыма юл куйма. Тәнемдә җаным барында дәүләтемнең һәрбер почмагында, сине олылап, мәчет-мәдрәсәләр торгызырмын. Үзеңнең рәхмәтеңнән генә ташлама, Йа Рабби бер Ходаем!»

Намаздан соң күпчелек халык казаннар янына ашыкты, бавырчылар

һәркемгә ризык таратырга кереште. Әмма Үзбәк хан табынга утырмады, үзенең даими гаскәре белән танышырга теләде.

Башкалада әлеге гаскәрнең ике йөз мең нүкәрдән торган егерме төмәне урнашкан иде. Алар, күнегүләр өчен көйләнгән махсус мәйданга тулы хәрби әзерлектә тезелеп басып, сабыр гына ханның килүен көтәләр. Хакимнәре каршыларына чыккач та, төмәнбашлары артыннан, һәммәсе дә хан каршында тез чүкте. Әйтерсең, бер анадан туган төсле бер үк дәрәҗәдә төз, нык беләкле бу егетләрне күреп, ханның күңеле булды.

– Торып басыгыз, минем ышанычлы нүкәрләрем! Сез – хан гаскәре генә түгел, сез – Аллаһы Тәгалә гаскәре. Безнең дәүләткә хезмәт итеп, сез изге динебезне саклыйсыз һәм киңрәк таратасыз. Изге бурычыгызны тоеп яшәгез! Безнең Урдабыз – көчле, горур мәмләкәт. Безнең нүкәрләребез дөньяның төрле кыйтгаларында булып, дошманнарны дер селкеткән баһадирлар. Бөтен дөнья безнең белән санлашып, бездән куркып яши. Биредә басып торган һәрбер яугирнең монда олы өлеше бар. Мин, сезнең бөек ханыгыз, вәгъдә бирәм – дәүләт үзегезне беркайчан да авыр хәлдә калдырмас, өстегез бөтен, тамагыгыз тук булыр. Яу югында хәрби осталыгыгызны чарлагыз. Безгә нүкәрләр генә түгел, зирәк сәргаскәрләр дә бик кирәк. Мин сезнең белән горурланам, нүкәрләрем!

«Орра!» тавышы бөтен тирә-якны дер селкетте. Үзбәк хан исә, Түләк-Тимер һәм Кара-Булат сәргаскәрләр озатуында гаскәренең нинди шартларда яшәүләре белән танышырга юнәлде.

Ял бүлмәләре иркен һәм якты иде. Берничә урында бавырчылар ризык хәстәрен күреп ята. Атлар өчен бик зур мәйдан бүлеп бирелгән, аларны тәрбияләп торырга аерым кешеләр куелган.

– Гаскәргә егетләрне билгеле бер калып буенча гына сайлап алабыз, – диде Түләк-Тимер. – Бирегә төрле олыслардан төрле милләт вәкилләре җыелган. Аларны бергә яшәтергә, хәрби йөрешләрдә бер үк төмәннәргә куярга тырышабыз. Иңгә-иң сугышканда, туганлык тойгысы нык ярдәм итә ул.

– Гаиләдән тартып алынып, бирегә китертүгә каршы чыгучылар юкмы?

– Юк, бөек ханым. Алар гади гаиләләрдән бит, барысы да ачлы-туклы тормышта яшәгән. Биредә исә бар нәрсә дә әзер, киендерәләр, ашаталар, акчасы да түләнә.

– Хәрби кирәк-яраклар белән ничегрәк?

– Синең әмерең белән нүкәрләрне казна хисабына баштанаяк киендердек һәм коралландырдык, – дип сүзгә кушылды Кара-Булат. – Кораллар төрле олысларда эшләнә, чит дәүләтләрдә ясалганнары да бар. Корал җитештерүне безнең вәкилләр күзәтүе астында гына башкаралар, шуңа күрә сыйфатына тел-теш тидерерлек түгел.

Бер читтәрәк ханга күрсәтер өчен хәрби кирәк-яраклар да әзерләп куелган иде.

– Нүкәрләрне дошманнарның укларыннан саклау өчен берничә төрле кыяк кулланабыз. Беренче төре – әйбәтләп киптерелгән тире кисәкләреннән

тегелгән. Ике тире арасына ат ялы куелган, әгәр ук тирене тишә калса, шул ялга буталып, көчен югалтачак. Җиңел кыяк үзебезнең укчылар өчен җайлы, ул ирекле хәрәкәтләнергә мөмкинлек бирә, атта утырган килеш артка кисәк кенә борылып та атып җибәрергә була. Аннан ары тимер белән ныгытылган кыяклар. Алары инде авыррак, әмма саклау көче зуррак. Атларга дип эшләнгән саклану япмалары да бар.

– Җәяләр, уклар җитәрлекме?

– Җитәрлек, бөек ханым. – Бер җәяне алып, Кара-Булат ханга сузды.

Хан, кызыксынып, аны өйрәнергә кереште. Очлары мөгезләр белән матурлап эшләнгән, кояшта шартлап киптерелгән сеңер исә зеңгелдәп тора.

– Яле, бер угыңны бир, – диде Үзбәк хан. Җәяне тарту өчен махсус ясалган нефрит балдакны ул һәрвакыт үзе белән йөртә иде, бармагын саклар өчен шуны киде. Укны җәягә салып, бар булган көченә тартып, атып җибәрде. Ук, очына куелган тишекле сөяге белән сызгырып, очып китте. – Санасыннар, ничә адымга очкан икән.

Бер меңбашы шунда ук ук артыннан адымнарын саный-саный китеп тә барды.

– Әйбәт җәя бу, тәтесе дә шәп эшләнгән. Тик сеңер тәтеләрнең бер начар ягы бар – яңгыр астында калсаң, шәлперәеп төшәләр, юньләп тартылмыйлар, – диде Үзбәк хан, коралны кулында әйләндергәләп. – Укның сызгыруы да бик файдалы. Ногай олысында яуда вакытта берьюлы берничә дистә мең ук очып китә, аланнарның атлары, котлары чыгып, хуҗаларын җиргә ташлап калдыралар иде...

Яшь чакларын искә төшерүдән ханның күңеле йомшарып китте. Башкалага күченү – олы бәйрәм. Ни кызганыч, бу шатлыкны әнисе күрә алмады, Баялун хатынга да иркен биналарда картлыгын каршылау насыйп булмады. Икесе дә тар гына гүр ияләре...

Ул арада тыны кысылган меңбашы да әйләнеп кайтты, кулына ул хан атып җибәргән укны тоткан иде.

– Биш йөз утыз алты адым, бөек ханым, – диде ул, еш-еш сулаган көе хакимгә теге укны сузып.

Түләк-Тимер сызгырып ук куйды:

– Машалла, мондый ераклыкка атарлык баһадирлар безнең нукәрләр арасында бармак белән генә санарлык, бөек ханым!

– Димәк, көчем бар әле... Насыйп булса, гаскәрне ияртеп, яуга да барырбыз, иншалла!

Үзбәк хан җиңел һәм авыр уклар белән танышты, дошманның тәненә кадалып, кире чыкканда, эчке әзгъзаларын да актарып ала торган ыргаклы сөңгеләрне карады, берничә төрле кылычны кызыксынып өйрәнде. Гаскәре хәстәрлекле иде – дошман кирмәнен җимерә торган авыр җайланмалар, зур кашыкка салып, ерак араларга түгәрәк ташлар яисә ут төртелгән салам түмгәкләре ташлый торган җиһазлар да бар. Аларын Кытай якларыннан ясатып кайтарганнар. Күрелгәннән канәгать калып, хан, ниһаять, Алтынташка юнәлде.

– Мондый зур гаскәрне янәшәдә тоту бер яктан ышанычлы булса, икенче яктан куркыныч та, – диде ул янәшәсендә атка атланган көе баручы

Котлы Тимергә. – Нукәрләр хәрби сәфәрләрдән кайтып кермәскә тиеш. Үзең әйтәсең бит – көнбатыштан безне яман көчләр кысрыкларга маташа. Ә мине сакларга үземнең шәхси кәшигем[4] җитәр – ул бер төмәнгә тула, аны туганым, ышанычлы кешем Чолхан җитәкли. Чолханның кәшиген Алтынташ эченә урнаштырыгыз, нукәрләренә түләү гади гаскәргә караганда бермәбер артыграк булсын...

– Аңладым, бөек ханым, – диде Котлы Тимер.

Кичке якта Алтынташта олы мәҗлес оештырылды. Аңа гаиләләре белән бергә бик күп әмирләр чакырылды. Ханның табыны мул, кымыз-эчемлекләр елга төсле акты. Үзбәк үзе дә нык арыганлыгы өстенә шактый гына хәмер эчте.

– Исабәк, – диде ул, думбрачылар бераз тынып калгач. – Нагатай әмирне күрәсеңме? Бигрәк картайган.

– Авыр чирдән интегә, бөек ханым! Шуның нәтиҗәсе.

– Беләм лә мин аның чирле икәнлеген! Сүзем ул хакта түгел. Янәшәсендә нинди чибәркәй ул?

Исабәк хан күрсәткән якка карады. Кыз, чыннан да, бик чибәр иде. Үзенә тәхет ягыннан игътибарны сизенеп, ул кызарып чыкты, оялып, йөзен яшерде.

– Көбәк ул, Нагатайның кызы.

– Кияүдәме?

– Юк дип беләм, яшь әле ул.

– Яшь, ләкин җитлеккән... Иртәгә үк Нагатай әмиргә яучылар җибәр, мин аның кызына өйләнәчәкмен.

– Ихтыярың, бөек ханым!

Янәшәдә утырган Тайдула, бу сүзләрне ишеткәч, шартлар дәрәҗәгә җитте, әмма түзде. Үзбәккә шелтә белдерергә хакы юклыгын яхшы белә. Әлегә кадәр аңа көндәш булырдай бер генә хатын бар – Нәзифә, чөнки аның улы Тимербәк – тәхеткә турыдан-туры хаклы кеше. Үрдүҗәдән зыян юк – ул бер-бер артлы кызлар гына таба. Әгәр Көбәк, Үзбәккә кияүгә чыгып, малай алып кайтса, тагын бер көндәш арта дигән сүз. Җитмәсә, үзенең дә карынында икенче егет озакламый дөньяга килергә тора. Тимербәк тиз үсеп җитәр, сизми дә калырсың. Ә тәхет, әнә, берәү генә...

**10**

Табын таралгач, Үзбәк хансарайның кунаклар кабул итү бүлмәсендә Котлы Тимер белән икәүдән-икәү генә калды.

– Адым-адым юл була, тамчы-тамчы күл була, Котлы Тимер! Сарай Әл-Җәдидне төзи башлау турында әмер чыгаргач, син моны Урда казнасы күтәрә алуга шик белдергән идең кебек, – диде хан, бәкләр-бәгенә кымыз салып.

– Шик түгел, бөек ханым, дәүләтебезнең иминлеге өчен борчылу гына иде ул...

– Хәзер шулай дисең инде. Ә башкалабыз бик матур килеп чыккан, күз явын алырлык!

[4] Кәшиг – ханның шәхси гвардиясе.

– Синең тырышлыгың нәтиҗәсе, падишаһым-солтаным...

Үзбәк усал елмаеп куйды:

– Берәр көнне базарга чыгып сораштырырга булыр әле, халык та синең фикердәме икән?

Котлы Тимер эсселе-суыклы булып китте. Моннан берничә ай элек булган күңелсез вакыйгалар капылт кына исенә төште. Аннан, фикерен туплап, ханга мөрәҗәгать итте:

– Бөек ханым, синең белән күптән сүз башларга җөрьәт итми йөрим. Без бу хакта сөйләшкән дә идек инде. Син миңа Хәрәземгә кайтырга рөхсәт бир. Дәүләт эшләре мине ялыктырды. Күрәсең, синең кебек киң колачлы зирәклек миңа бирелмәгәндер.

– Аңлыйм сине, Котлы Тимер, – диде Үзбәк, хафага төшкән кыяфәт белән. – Ләкин миңа синнән башка бик авыр булачак. Дөрес карар кабул итәмме-юкмы дип баш ватканда, ярдәмгә килүче син. Нишләрмен мин алга таба?

– Ялгышлардан куркырга кирәкми, бөек ханым. Кем берни дә эшләми – шул ялгышмый. Ә син башлыча дөрес һәм уйланылган карарлар иясе. Аның әҗере дә бары тик сиңа гына тиешле.

Җавабы күптән әзер торса да, Үзбәк уйланып калган төсле итте.

– Ярый, аңладым сине, Котлы Тимер! Әгәр күңелең Үргәнечкә тарта икән, шулай булсын. Тик син һәрвакыт миңа кирәк чакта яныма йөгереп килергә әзер тор. Мин сине киңәшчем дәрәҗәсендә күрергә телим, бәкләр-бәге вазифасы да калыр.

– Алланың рәхмәте яусын сиңа, гадел ханым! Минем тугрылыкка ышанып яши аласың, мин һәрвакыт ярдәм кулын сузарга әзермен!

Үзбәк ханның дөньясы ачылып киткән төсле булды. Моңарчы үзен биртәрләгән авыр уйлар юкка чыкты. Котлы Тимер белән дусларча, сүзгә керми аерылышу аның өчен бик мөһим иде. Алар әле тагын хәтсез генә табында икәүләшеп кенә утырдылар, яшьлек елларын, Үргәнеч чорларын исләренә төшерделәр. Бу инде хаким белән мөддәбир әңгәмәсе түгел, ике дусның җылы гәпләшүе иде.

Кара төндә үз бүлмәсенә кайтып ятканда, Үзбәк күзенә йокы кермәгәнлеген аңлады. Бу көннең кичерешләре артык күп булды, йөрәге тынычлана алмый, башында әле бер, әле икенче уй әйләнә.

– Мостафа! – дип дәште ул әвнухны. Тегесе озак көттермәде.

– Баш өсте, галиҗәнап падишаһым-солтаным, синең мескен колың әмереңне үтәргә әзер, – дия-дия ятагы каршында баш иде.

– Миңа бирегә шәраб белән җиләк-җимеш китерт, аннан соң Тайдула хатынны чакырт.

– Чакыртам да, вакыт соң бит, бөек ханым...

– Телеңне кыскартканчы кушканны үтәргә ашык, Ходай бәндәсе! – дип җикеренде Үзбәк, һәм әвнух шул мизгелдә үк юкка да чыкты.

Тайдуласы аның чакыртуын, әйтерсең, көтеп кенә торган. Вакытның соң булуына да карамастан, рәхәтләнеп елмаеп, ул хан янына узды. Үзбәк торып утырды, учы белән янәшәсенә суккалап утырырга дәште. Тайдула ханның шактый кәефле икәнлеген болай да белә, шуңа барлык теләкләрен карышмый үтәде.

Үзбәк аны назлап үбеп алды, бу үбешү, әйтерсең, аларның беренче очрашуларындагы кайнарлыкны саклаган иде. Иренең тагын бер хатын алырга теләвен белсә дә, Тайдуланың күңеле шунда ук эреп китте. Башка хатыннар вакытлыча мавыгу гына, Көбәк белән дә шул ук хәл кабатланачак. Юкса, балалары туып та, хатынлыкка алынмаган җарияләр хәрәмдә азмыни? Әйе, сабыйлары балда-майда йөзә, аларга ханбикә хөрмәте күрсәтелә. Әмма җарияләрне бар дип тә белүче юк, хан аларны рәсми хатыны дип игълан итми, диванга чакыртмый. Әлегә бу дәрәҗәгә ия ике генә нәфис зат бар – берсе Тайдула, икенчесе Үрдүҗә. Нәзифәне хәзер исәпләмәскә дә мөмкин, ире күптән аны улы Тимербәк янына Хәрәземдәге Яңа шәһәргә сөрде.

– Кендек әбисе Мәүлидә карчык безнең тагын бер улыбыз булачак, диде. – Тайдула, Үзбәкнең кайнар кулын алып, күлмәге астына, күпереп торган корсагына куйды. – Синең шикелле үк дуамал холыклы бала булырга охшаган, төннәр буе тибенеп чыга. Менә, бармагың белән тотып кара, бусы аның аягы.

Үзбәк кулын, кинәт кайнар әйбергә кагылып пешергән сыман, тартып алды.

– Нишләвең бу, сөекле ханым?!

– Соң, аягын тотып, берәр төрле зыян китерсәм?!

– Һии, сөекле ханым, минем карынымда ул алтын сарайда төсле. Аны әнисе саклый, бернинди зыян да килмәячәк, курыкма! Әтисенең назлы кагылуы аңа дөньяга аваз салганчы ук ышаныч бирер иде...

Үзбәк янә кулын хатынының корсагына куйды. Ул, чыннан да, улының аяк бармакларын тойган төсле булды.

– Иртәгә Нагатай әмиргә яучылар җибәрергә җыенам, – диде ул, хатыны әлеге яңалыкны үзеннән ишетергә тиешлеге хакында кинәт кенә карар итеп. – Аның кызы Көбәкне хатынлыкка алырга телим. Синең моңа кәефең китмәсен иде...

Тайдуланың бер дә исе китмәвен күреп, Үзбәк гаҗәпкә калды.

– Юк, падишаһым-солтаным, син нәрсә?! Мине генә өзелеп яратуыңны беләм һәм тоям. Төннәрен мин һәрвакыт синең яныңда. Караңгы күктә йолдызлар күп җемелди, ләкин Җиргә иң якыны һәм иң яктысы бер генә. Мин үземне әнә шул ай рәвешендә хис итеп яшим. Синең миңа булган мәхәббәтең, хөрмәтең өчен рәхмәтем чиксез. Көбәкне сеңлем төсле каршылармын, бер дә борчылма...

– Озакламый Котлы Тимерне кире Хәрәземгә озатырга ниятлим, бусын да белеп тор.

– Сөекле ханым! Гафу ит, көмәнле булуым комачаулый, синең каршыңда тезләнә алмыйм! – Тайдуланың әле генә ишетелгән яңалыктан шатлыгы эченә сыймый иде. Ул, ханның тагын бер хатынга ярәшү хафасын да онытып, җилкенеп китте. – Синең хакимлегеңне үз шәүләсе белән бик озак каплап яшәде ул. Күптән озатырга вакыт иде!

Үзбәк Тайдуланың болай кискен әйтеп ташлавын өнәп бетермәде.

– Тайдула, телеңне тый! – диде ул, кинәт кырысланып. – Мин Котлы Тимер белән озын юл үттем, ул тоташ сикәлтәләрдән генә тора иде. Әгәр аның тарафыннан берәр төрле кыек сүз ычкынган яисә ялгыш гамәл


кылынган икән, ул, һичшиксез, ханның ярлыкавына лаек кеше. Минем тәхеткә утыруымда да аның хезмәте зур...

– Гафу ит, бөек ханым, мин сирәк очракларда гына сиңа каршы дәшәм. – Тайдула алай да Урда хакиме белән сүзгә керергә җөрьәт итте. Ни гаҗәп, Үзбәк моңа карышмады, киресенчә, хатынының сүзләре аңа ошый кебек тоелды. Тайдула кыюлыгын җыя төште. – Үзбәкне Урдага Тогърулҗа белән Әрибах бүләк итте. Хан дәрәҗәсенә ул үз көче һәм акылы ярдәмендә иреште. Аллаһы Тәгалә биргән дәрәҗәңне беркем белән дә бүлешмә, синнән ары моңа лаеклы кеше җир йөзендә юктыр. Башка беркемгә дә бу хакта әйтмә, син үзеңне үзең күтәргән бөек хаким! Бүген без атлап кергән башкала – синең теләгең белән калкып чыккан шәһәр түгелмени? Син аның һәрбер ташын тотып карап, һәрбер почмагын аякларың белән йөреп чыгып төзеттең бит. Нигә моннан ояласың? Котлы Тимер – шушы төзелешнең арты хәерле булмас дип әйткән беренче яраның иде. Ширван белән Аррангa барганда, сиңа каршы төшүче, артыңнан сүз йөртүче дә ул. Андый кешеләрне ерак тотарга кирәк, асыл кошым минем. Ул синең күңелеңне үстерми, киресенчә, басымчак итә, аска гына өстери. Шуңа Котлы Тимердән котылуың хәерлегә генә.

Үзбәк Тайдулага бу хакта янә сүз куертып тормаска боерды. Шулай да, хатынының әлеге нотыгына ул чынлап торып мохтаҗ икәнлектән оялып куйды. Бер яктан күңеле Котлы Тимерне нахакка рәнҗетте дип битәрләсә, икенче яктан бәкләр-бәгенең үзен гаепле итеп калдыру, аның гамәлләреннән кер табу теләге зур иде. Тайдула аңа нәкъ менә шул, караңгы, яман ягын үсендерергә, үзен Котлы Тимердән хаклырак, яхшырак булуына инандырырга булышты...

Икенче көнне үк Үзбәк хан, диван әһелләрен җыеп, үзенең карарын игълан итте. Бәкләр-бәге Котлы Тимер, мөддәбирлектән азат ителеп, Хәрәзем олысына кайта. Моннан ары Үзбәк хакимиятендә мөддәбир вазифасы булмаячак. Аның урынына диван әһелләре өстендә торучы вәзир билгеләнә. Урданың бөек вәзире итеп Үзбәк хан Исабәкне сайлады. Акылы белән артык шаккатырмаса да, Исабәк тугры дус һәм каршы дәшмәүче киңәшче иде. Ә Котлы Тимер исә, тәхет янындагы тормышы сәхифәсен ябып, күңеленә илһам бирә торган җиргә – Хәрәземгә кайтып китте...

*(Ахыры киләсе санда)*



Вазыйх
Фатыйхов

# ӨМЕТЛӘР ЧИШЕЛМИ ТӨЙНӘЛӘ...

## Кышкы авыл

Карлы-бәсле авыл. Малай-шалай,
Боз өстендә алка тибәләр.
Язылмаган дәфтәр битләредәй,
Агарынып ята түбәләр.

Морҗалардан чыккан ялкау төтен
Чорнала да елгыр буранга,
Мунчаларның тәмле исен төяп,
Ял итәргә кача урманга.

Яшел җәйне төргәк-төргәк итеп,
Элеп куйды икән кем анда? –
Кычытканнар, кипкән мәтрүшкәләр,
Калтырана салкын чоланда.

Язны чакырамы тәрәзәләр –
Чәчәк аткан бозлы пыяла.
Кабарынып, саклык белән генә
Томшык сузган бер кош оядан.

Ул күрсәгез иде сабыйларның
Ак келәмнән атлап барышын!
Чана җиккән җитез аргамаклар
Карга тими чаба узышып.

...Карап торсаң, бер әкият сыман
Кызык та соң авыл тормышы!

Вазыйх ФАТЫЙХОВ (1958) – *шагыйрь; «Тормыш – ормыш», «Яшерен сөю», «Язлар көтә күңел» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Балык Бистәсендә яши.*

## Хакыйкать мөнбәреннән

Татлы да син, ачы да син, тормыш –
Сөеп сыйпыйсың, тотып кыйныйсың.
Бик еш кына кәеф колы итеп,
Санга сукмыйча, уен уйныйсың.

Тулпар сыман утлап бәгъзе хисләр,
Ача күңел, серле, үзгә галәм.
Буталыплар бетә, һаман көтә,
Өмет белән яши, сулый адәм.

Гел үзгәрә кавем шатлыкларда,
Сагышлардан чама беткән чакта.
Көләселәр килми көлгән чакта,
Китәселәр килми киткән чакта,

Кеше кайгысыннан дәртләнгәндә –
– Бар бит әле бездә андыйлар да.
Хаста җаннар бар шул, ни кызганыч,
Бер гөнаһсыз дәһри сантыйлар да.

Мәхәббәттән гаеп табучы бар,
Фәхишәне үлеп мактаучы да.
Авыр бүген хакыйкатьне санлап,
Дөреслекне хаклап яклаучыга.

Кыйтмир, Бәдүх безне саклый сыман,
Афәтләрдән, Дәҗҗал тырнагыннан.
Изү ачып килә җилкенәсе,
Шуып чыгып золым юрганыннан.

Кычкырасы килә болдырлардан,
Гавамнарга чаклы аваз салып.
Чистарасы иде шау-шулардан,
Күңелдәге тузаннарны кагып.

...Җиргә иңдерәләр. Башын иеп,
Кабаланып бирәү урын эзли?
Түзеп торам, суларга да куркып,
Хисем тышауларын чак-чак өзми!?

Ә хисләрем сөенечләр эзли,
Һәр карыш җир изге, үз урыным.
Йөрәк тибә киңлекләрне кочып,
Бер көй кебек атлап барыр юлым.

## Ни булды соң сиңа, замана?

Кызганыч, аяныч замана
Чайкала ишкәксез көймәдә.
Дулкынга егыла хыяллар,
Өметләр чишелми төйнәлә.

Үтереш, урлашу, сугышлар –
Көн туа сагышлы хәбәрдә.
Күнегеп барабыз бугай без,
Ышанып булмастай хәлләргә.

Иртәгә ни булыр? – шул сорау.
Һәр төнне уята йокыдан.
Дөньяга чыгулар куркыныч,
Хәбәрләр – аяусыз, котырган.

Чарасыз аерды бүз язмыш,
Кавемне акка вә карага.
Ни белми уйларга башлар да,
Фикерләр тумыйча тарала?!

Төш сыман калды күк үткәннәр,
Йөрәк бит тоташтан ярада.
Әйт әле ни булды соң сиңа,
Ни булды соң сиңа, замана?

## Төрле чагым бар бит минем дә

Бар шатлыгым ярларыннан ташып,
Сыешмаган чагы күңелнең.
Мин дә сезнең кебек гап-гади җан,
Әүлия да, сер дә түгелмен.

Бар, шашынып, диварларга сеңеп,
Яшькә каләм манып язганым.
Кырау тиеп бар өшәнгән көе
Каршылаган көзем, язларым.

Елый-елый сагыш йотканым бар,
Өмет белән җилкән сипләгән.
Ышанычлы булды җилкәннәрем,
Куәт бирде йөрәк хисләргә.

Мин әүлия йә әллә кем түгел,
Гади генә язмыш баласы.
Бабайлардан калган олы дөнья
Бездән дә бит берчак каласы.

Яшиселәр килә матур итеп,
Һәрбер таңнан серле нур алып.
Нинди матур гомер кайтавазы –
Тыңла әле, язмыш, тын калып!
Яшик әле, яшик сокланып!

## Китек күңел

Таңнар ата бүген синсез генә,
Тавышыңны шундый юксынам.
Көн өстендә караңгылык тора,
Әйтерсең лә кояш юк сыман.
Кайтып барам туган нигеземә,
Каршы алмас инде әнием.
Тәрәзәдән әнкәй көтмәс инде,
Күңел елар күреп буш өем.
Капка тавышына сискәнмәсләр,
Ишегалды шыр буш каршылар.
Күзләремнән агар сагыш яше,
Җаннан тамар сусау, ярсулар.
Бикле йозак елап ачылыр да,
Юл күрсәтер, төртеп ишеккә.
«Кайттыгызмы, балакайлар?» сүзен,
Әйтерсең лә һаман ишетәм.
Саклык белән генә өйгә узам,
Ял итмиме әнкәй, янәсе.
Кабасында тора язган йоны,
Оекбашы белән энәсе.
Чәйнек тора өстәл өсләрендә,
Пары чыкмый борын очыннан.
Кайда икән көннәр: әнкәй белән
Көлеп, елап бергә узылган.
Түргә узам, сәгать текелдәвен
Ишетергә бөтен теләгем.
Ул да туктап калган, моңсу тынлык,
Сулкып-сулкып куя йөрәгем.
Сискәнепләр китәм, таныш тавыш –
Әнкәй телефоны шалтырый.
Кемдер һаман аны эзли бугай,
Ала алмыйм, кулым калтырый.
Түр башына иңәм, сабыр сорап,
Күтәрелә куллар догага.
– Раббым, – димен, –
җәннәт насыйп әйлә,
Әнкәемә, газиз Анама!
Икенче кат күтәрелә куллар –
Монысы инде кабер янында.
...Китек җаным атлый китәр юлга.
Сагындыра, шундый сагынам...


## Җитү

Була вакыт, тормыш җайсызлана,
Аяз хисең китә исереп.
Күңелләрдә бушлык хөкем сөрә,
Иртәнге уй кала искереп.

Кайный дөнья, утта актарыла,
Күзләр күрми, башлар әйләнә.
Көткәннәрең синнән читләшәләр,
Көтмәгәннәр килеп бәйләнә.
Җитми нидер, бүз җан тәнгә сыймый,
Нәрсә җитми, үзең белмисең?
Көлү түгел елыйсы да килми,
Аның елмайганын телисең.
Җитмәгәнне эзләп абынасың,
Җаның йөри әрнеп, авыртып.
Күлмәк якасыннан алгач дөнья:
 – Тукта, – дисең, – үзең сабыр тот!
Бар да җитә икән, бар да җитә:
Байлык җитә. Баскан урының
Тик бер нокта юкса. Вакыт китә,
Еракларга сузып толымын.
...Уйлар башка бүген, акыл бүтән:
Барысы да җитә, җитә икән!

## Мәдхия җыр

Тормыш буйлап күпме атласам да,
Һич арымыйм туры юлымда.
Мәдхия җыр язам чын күңелдән,
Ә ул җырым – сөю турында.
Ким дә түгел, түгел артык та ул,
Шактый гына язмыш сүтелгән.
Юлларыма чыкты мине сөйгән,
Өлешемә тиде – көтелгән!
Сабыр канатымда яши алдым,
Акыл белән кылдым гамәлем.
Нинди генә кыен хәлләрдән дә
Таба белдем чыгу әмәлен.
Ихлас сөйсәң, чаптар дилбегәсе
Түзүләрдән шартлап өзелә.
Тәртәләрне ватмас, җимермәскә,
Хисләремне тоттым тезгендә.
Сөю вәгъдәләрен саклау өчен,
Аңлый белү кирәк сүз хакын –
Йөрәгеңдә янсын ихлас учак,
Хисләреңдә дөрләт ут-ялкын!
Сөя белеп сөю – бер фәндер ул,
Чама белү – үзе мәртәбә!
Ашыксаң да авыз пешә кайчак,
Соң булу да мөмкин иртәгә.
Яратулар кирәк ихласлыкта,
Чын күңелдән коч син ярыңны!
Кабатлансын мизгел гомер булып –
Җылытсын ул һәрчак җаныңны!
Курыкмады җаным сынаулардан,
Максатыма хадим идем мин.
«Булдыралсаң, сөй көчлерәк мине,
Миннән көчле ярат», – дидем мин.
Бары шунда, бары парлы хистә
Сөю булып яна куш йөрәк.
Мәхәббәткә юлыктырса язмыш,
Бергә утын өстәү бик кирәк.
Пыскып яну – һич килешмәс халәт,
Сөю хисе – утлы чаптарлы.
Җилләрне дә узып йөгердем мин,
Сулышыма ялкын капмады.
Уйларым да булды тоташ ялкын,
Пеште, көйде якын торганнар.
Мине аңлар һәм дә үз күрерләр,
Янып-көеп гашыйк булганнар.
Меңнәр сөя, сөелә дә бүген,
Дәвам итә язмыш сынавы.
Йә, әйтегез әле, бу тормышта
Сөюдән дә тәмле хис бармы?!
Таңнар, кичләр, көннәр, минутлары,
Алып килсә сөю бәхете.
Кире кагар адәм алтыннарын,
Хәтта патшаларның тәхетен.
Тапламагыз, берүк таптамагыз,
Сөю хисе – ул бит гомерлек!
Күпме серләр аның сандыгында,
Бары икәү генә бүлерлек?!
Мәдхия җыр яздым чын күңелдән,
Ул җыр, әнә, сөю турында.
Яратыгыз һәм дә сөелегез,
Нокта куям шушы урында.



Рахман
Шәфигуллин

# ШӘП АТТЫҢ, ГАЛИМУЛЛА!*

ХИКӘЯ

*Фронтовик, Сабан туйлары*
*батыры булган әтием*
*Шәфигуллин Галимулла истәлеге*

Без үскәндә, авыл баласы барыбер бәхетлерәк иде! Тормышыбыз урамда, табигать кочагында үтте. Кышын тимераякта шуу, шартаяк сугу, дисеңме, чаңгыда элдерү, окоплар казып, сугышлы уйнау! Нечкә билле март җилләре карны эретә башлау белән тояклы мал-туарны тау итәкләрендә көтү. Монда инде карта сугу, учакта бәрәңге пешерү, җылы яклардан очып килгән кыр казларын, торналарны күзәтү. Беренче майда исә күршедән күршегә йөреп, төрле төсләргә буялган йомырка, тәм-том җыю бәйрәме үзе ни тора! Укуларны имин генә төгәлләгәч, каен бөреләре өлгерә. Аның тәменә әллә кайлардан бал кортлары да очып килә. Алмагачлар чәчәкләрен коеп, бер айлап узгач, колхозның алмалары чия зурлыгына җитә. Әче булса да, яратып ашыйбыз үзен. Тора-бара елгаларда кәҗә сакаллары, төрле кузгалаклар, кукы өлгерә. Аннан безне куандырып, җиләкләр бөреләнә... Нинди генә уен булмасын ул, кул көрәше һәм бил алышу белән төгәлләнә иде.

Июнь азагында бәрәңге араларын ярганда, Сабан туйлары гөрли. Аңа булдыра алган һәрбер кеше әзерләнә. Эх, тизрәк үсеп җитәсе иде дә мәйданнарга чыгып, бил алышасы иде. Күрсеннәр иде кемнең кемлеген! Ләкин моңа ераграк, үсәсе дә үсәсе әле. 1959 ел. Яңа гына ун яшь тулды. Әни Хәсбиҗамал ападан миңа сары төстә чалбар тектерде. Абыйга яңа күлмәк алгач, аныкы миңа таман булып калды. Бездә Сабан туе бик матур уза. Миңа ат чабышлары, көрәш бик ошый. Ә менә дустым Ризван

* «Мәйдан – батырлар өчен!» конкурсында катнашкан әсәр.

Рахман ШӘФИГУЛЛИН (1949) – *журналист, язучы; «Йозак» исемле китап авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

уеннарны хуш күрә. Ул апалары Нурҗиһан, Хәмидә, күрше кызлары Нурзия, Нуриянең җыр-биюләрен карарга ярата. Соңыннан эти-әнисенә аларның иң оста биюче, җырчы икәннәрен сөйләргә тотына – тыңла гына. Аның әтисенә дә көрәш ни почём, ул күңелле уеннарга мөкиббән.

Әтием оста көрәшче булганлыктан, үземне беләә башлаганнан алып, аның бил алышканын күзәтеп үстем. Беләкләрем әле сыек булса да, яшьтәшләрем белән бил алышкалыйбыз. Бу, әлбәттә, чын көрәштән ерак, әмма күңелне күтәрергә менә дигән чара.

Әти әйтә: «Улым, татарга бу җирдә көрәшсез булмый ул, һәрдаим аңа әзер торырга тиеш. Җиңә алмасаң да, бирелмәскә, нык булырга кирәк. Үзем дә авырлыклар күрдем, бил бөксәм дә, рухым сынмады, сез дә шундый булсагыз иде».

Ятим үсеп, сугыш ачыларын татыган әтиемнең көче ташып торса да, күңеле чиста иде. Чиста көрәште, намуслы яшәде. Бәләкәй генә өй эчендә Сабан туйларында җиңү яулаганы өчен бирелгән бүләкләре дә хәттин ашкан иде. Әни җаен табып әйтә:

– Җитте, Галимулла, көрәшәсен көрәштең. Биш бала атасына тукталырга вакыт, болай да төннәрен сызланасың, – ди.

Аның сүзләре үзенең нәтиҗәсен бирде бугай. Быел ул мәйданга чыкмаска ниятләде. Әти безнең урта буйдан бер сөямгә өстәрәк. Төгәл генә әйткәндә, 177–180 сантиметр чамасы. Нык гәүдәле, киң җилкәле ир-ат иде. Үзе тыштан салмак күренсә дә, бил алышканда, ут уйнатучы елгыр кешегә әйләнә. Күтәреп алган көндәшенең кайсы якка очасы билгеле түгел, ул моны җаена китереп башкара иде. Ул көрәшкәндә, таякка таянып йөрүче карт-коры килеп: «Чиста салдың, Галимулла! Рәхмәт», – диләр иде. Ул беркайчан да аяк чалу яки башка хәрәмләшүгә бармады.

Батыр калучы сиксән-туксан килодан ким булмаска тиешлеген чамалап үстем. Нинди генә оста булсаң да, 60–70 кг авырлык белән тәкә алу, ай-һай, икеле. Андыйларның күпчелеге шул батырларга ярдәм, теләктәшлек итүчеләр иде инде. Алар үзләренең гаярьлеген шулай булса да, канәгатьләндерә иделәр. Ул чагында авырлык үлчәме буенча бил алышулар кертелмәгән иде әле.

Көрәштә төрле ысуллар кулланыла. Ә менә көндәшен күтәреп алып (ул «суплекс» дип атала), баш аркан ату иң матуры һәм чиста көрәш дип саналды. Бу чакларда мәйдан халкы аягүрә басып, җиңүчене сәламләде. «Молодец, чиста атты, булдырды!» – диләр иде. Вакыт-вакыт чәкәләшеп алган очраклары да була.

Бил алышканда хәрәмләшүне халык яратмады, андыйларны мәйданнан куып ук чыгару да исемдә. Хәзерге вакытта көрәш ул һөнәргә әйләнде инде. Спортчылар көне-төне күнегүләр үтә, кирәген ашый, ял итә. Элек көрәшкә теләсә кем керде, үзенең көчен сынап карады. Авылда аның мөмкинлеге дә юк иде. Бер хезмәт көненә ике йөз грамм ашлык, ике тиен акча бирелгәндә, нинди ул махсус шартлар...

Батырга традиция-гадәт буенча тәкә, аңа өстәп, матур сөлге, күн итеге яки сәгать, тегү машинасы, сөт аерту сепараторы бирелде. Ә батырның даны югары иде. Әйтик, сөйләшкәндә: «Ул бит Күки, Ямаш, Балтач, Күгәрчен батыры», – дип әйтүләре ни тора!

Шулай итеп, быел әти көрәшмәскә карар кылды. Колхоз эше, гаилә мәшәкатьләре белән тормыш үз көенә дәвам итте. Әйткәнемчә, безнең өйдә генә түгел, авылларда да халык бәйрәм рухы белән яңа көнне каршылады. Кояш батканнан алып таң атканга кадәр урамнарда гармун тавышы, җыр тынмады.

Сабан туе... җыен... мәйдан... Изелгән, әмма сынмаган халкыбызның бердәнбер бәйрәме, ничектер милләтнең үзбилгеләү, үзенең барлыгын күрсәтә торган чара да иде. Шуңа күрә аны матур итеп, кунак өстәлләре әзерләп үткәрү йоласы дәвам итте. Әйткәнемчә, бәйрәмгә һәр гаилә үзенчә әзерләнде. Кемнеңдер малаен өйләндерәсе, кемнеңдер кызын кияүгә бирәсе бар. Безнең дә дәү абый армиядән кайтты, алма апа да җитеп килә... Абыйга – коңгырт төстәге костюм-чалбар (парочка), апага акка зәңгәр түгәрәк төшкән күлмәк, ак башмак алынды. Яшүсмер ике абыйга күлмәкләр тектерелде.

Кесә чыгымнарына кемгә биш, кемгә өч сум бирелде. Килгән кунакларны сыйлау өчен ачы бал коелды. Каз мае белән коймак пешерергә он агартылды. Ашка кар базында тозлаган ит, кыекта каклаган каз әзер. Мин, баллыны, әчене, тозлыны, төчене яраткан үсмер буларак, бәйрәмдә туйганчы тозлы кыяр, кәбестә, балык ашарга, квас эчәргә план кордым. Аларны алып, түрүш Мәксүтләренә керергә дигән карарны дустым Ризван да хуплады.

Сабан туе алдыннан яулык җыючыларга бирү өчен көмеш калай белән бизәлгән олы сандыктан әнинең Ямаштан алып килгән матур сөлгесе чыкты. Акка кызыл белән киртле-киртле бизәкләр төшерелгән Сабантуй сөлгесе, көя даруы исе бетсен дип, керләр киптерә торган бауга эленде. Җил искән саен җилфердәп бәйрәмне якынайткан кебек тоелды. Әти белән әни кунаклар исемлеген барлый. Уфадан әтинең яшьлек дусты Нурмөхәммәт ага гаиләсе белән кайтачак, Балтачтан Рәшидә апа, Габделхак, Ильяс абыйлар, Бөкәштән сеңлесе Гыйзелбанат апа белән Гаяз җизни, Березняктан – әтинең туганнан туганы Минҗиһан апа белән Дәян җизни. Өйләнгәнлектән, армиягә соңарып киткән Гариф абыйның да кайтуы ихтимал... Саный китсәң, күп инде. Очраклы керүчеләре дә булмый калмас... Уптым алганда, егермегә тула, үзебезгә урын җитмәве дә ихтимал.

– Кунакларны басып сыйларбыз, алай күңеллерәк тә, – дип, әни безне тынычландыра.

Өстәвенә, яңа чалбар кесәсендәге яшел өчлек һәм җыелган тиеннәр җанга тынгы бирми. Таш кибеткә төшеп, конфет-прәннек алуым да бар...

Әллә инде көрәш осталары күп булган, әллә тирә-юнь он тарттырырга безгә йөргәнгә, Тимерлекне Тегермәнлек тә дип йөртәләр. Гадәттә, бәйрәм атнасы дүшәмбедән, яулык җыюдан башлана. Хат ташучы Илгизә апа әнә телеграмма да китерде. Молотов (Пермь) – Казан парахуты белән Дәян җизниләр кайта, ди. Аларны Балык Бистәсенә пристаньга барып каршыларга кирәк. Ара – егерме чакрым. Әти әче таңнан ат җигеп, шунда китте. Көтү кайтканда, алар авылда иделәр инде. Төп йортлары әле исән, анда минем кендек әбием, җизнинең әбисе Хәдичәбикә яши. Ул олы, нык гәүдәле. Дәян җизни аның күчермәсе. Биредә зур бакча. Анда шомырт, алма, кура җиләге үсә. Ишегаллары яшел чирәм белән капланган. Ике

бәтие белән зур мөгезле кәҗә шундагы яшел үлән белән туклана, койма арасыннан агач яфракларын авыз итүдән дә тайчынмый. Кунаклар ялларын шунда үткәрәчәк. Дәян җизни Сабан туе батырына бүләккә без белмәгән, колак ишетмәгән мотопила алып кайткан.

– Адарындым. Хәер булсын, җәме, – дип, бу могҗизаны эшләтеп тә карады. Әллә ничә ел яткан имән чурбаннарны «эх» дигәнче кисте дә атты. Минҗиһан апа, әтинең туганнан туган сеңлесе (әтиләре бертуган). Икесе дә сугышта һәлак булгач, аларның гаиләләрен бабабыз Хәмзин Вәли үз ярдәменә алган. Дәян җизнинең дә әтисе, Садыйков Фәләх безнең чыбык очы туган. Җизни мәктәптә укыган чагында чирләп чукракланган. Кешенең иреннәренә карап, иркен сөйләшә. «Җәме» сүзләрдән җөмлә оештыра. Укымаган китабы, гәҗите юк, ул белмәгән хәбәр юк. Ул оста ташчы: сыйфатлы мичләр чыгара, йортлар төзи. Сәламәтлеге көнләшерлек! Тән төзелеше, мускуллары нәкъ Гераклныкы инде. Әйтүләренчә, кулына эләктең икән, ычкынам, димә.

– Бәхет эзләп, читкә киткәч, авылны нык сагынам, – ди. Төннәрен төшкә кереп җәфалый. Ял вакытын сәгатьләп саный икән, Сабан туйларында ул һәрчак ике потлы герне күтәреп, рекорд куя. Хөсәен Равилен җиңеп, беренчелекне алгач та, ике герне бергә сөлге белән бәйләп, 20-30 мәртәбә күтәрә. Аңа җеннәре ярдәм итә торгандыр, диләр. Дәян җизни көрәшеп тә караган. Ләкин көче барның җае юк дигәндәй, ул көндәшен күтәреп алуын ала, ә менә кукрәгендәге «йөкне» урынына куя белми гаҗизләнә. Көрәшеп, тәкә алу аның балачактан килгән олы хыялы икән.

Иртәгесен җиңелчә чәй аларның алма бакчасында оештырыла. Патефоннан Гөлсем Сөләйманова, Галия Гафиятуллина, Рәшит Ваһапов, Фәхри Насретдинов җырлары агыла... Күчтәнәчләрне авыз иткәннән соң, Дәян җизни әтигә:

– Абый, чукраклыгым аркасында күп нәрсә югалттым... Кеше кебек армиягә бара алмадым, гармун тарта алмыйм, җырны белмим. Бәләкәйдән көрәшергә омтылуым барып чыкмады... Җәме... Быел соң булса да, уң булсын дип, көрәшеп карыйсы килә. Өйрәтсәң, җиңәрмен бәлки, җәме...

«Җәме» – аның сүз җилеме. Ул аны еш куллана. Бүләккә «Молния» дигән кесә сәгате һәм яшел эшләпә дә эләккәч, этигә ризалык бирергә туры килә.

Үзенең сәләтен раслау өчен утлыкта яшел печән ашаучы биянең астына кереп, аны күтәрмәкче була. Әнисе Хәдичәбикә бердәнбер улының бу кыланмышларына түзә алмый:

– Моны җеннәре котырта бугай, туктатыйк, йә имгәнер, – ди. Кичә төнлә кайткан Гариф абый да биредә, ул хәлне аңлап, җизнәсен – Дәянны якларга керешә. Зәңгәр погонлы кителен, андагы значок-билгеләрне төзәтеп:

– Гәүдәм бәләкәй дип уйламагыз, бездән дә кое-что чыга, кирәк икән бил алышырга мин дә чыгам. Егылсам егылырмын, җизнине поддержать итәрмен, – ди. Сарытауда авиация частенда хезмәт итеп, старшина дәрәҗәсенә ирешкән Гариф ротада ничек итеп тәртип ясаганын, кирәк чагында әзмәвердәй егетләрне акылга өйрәтүен тәфсилләп сөйли. (Сүзләре белән ул үзенең даһилеген расламакчы, янәсе). Кем белә, бәлки дөрес тәдер, әмма ялтыравыклы хром итек, ярымйоннан тегелгән галәфи чалбар,

гимнастёрка кигән старшинаның мәйданга чыгып, көндәшләрен җиңәрлек көче юк иде шул. Ул акылы, белеме белән кояш астындагы җылы урын өчен көрәшергә яратылган, тик шулай да Дәян җизнине көрәшкә әзерләгәндә, әти аны да файдаланырга булды.

Чамасын белеп, «Зәм-зәм» йотып куйгач, туганнар Рәшит Ваһаповның җырлавына кушыла.

...Кистем пар каен,
Сагынам көн саен...

Безнең мөгезсез кызыл сыерга, аның бозавына, сарыкларга, каз, тавыкларга көннең, бәйрәмнең һич кенә дә аермасы юк. Аларга фәкать ашарга, рәхәтләнеп су эчәргә, җылыда ял итәргә булсын. Нигәдер, ашыйсылары килеп, кояш чыгу белән мөгрәргә, кыткылдарга тотыналар. Шунлыктан йорт хуҗалары иртә таңнан аякта. Сыер савып, ярты сәгатьләп узгач, көтү куар чак җитә. Бераздан чарт-чорт чыбыркы шартлаган тавышка, сөт, сарык йоны исе чыгарып, көтү кузгала. Алар югары очка, аннан балчыклы, сулы, коры елгаларга юл тота. Биредә аларны Байтирәк, Сул таулардан челтерәп аккан чишмә сулары, тәмле үләннәр көтә. Маллар кузгалу белән, бригадир Хәйретдин йорттан-йортка кереп, халыкны эшкә чакыра. Кичә генә кунак кайткан иде дип әйтеп кара син аңа! Тавык чүпләп бетермәслек колхоз эшен кем башкарыр? Монда бит терлекләре дә йөзләгән, иген басулары да меңәрләгән гектар, пар җирләренә тирес чыгару, фермаларны төзекләндерү, уракка техниканы әзерләү... Әтинең абруе зур, аның җәе-кышы гел колхоз эшендә. Әтисез печән, салам эскерте сала белүче юк. Ул эшне оештыра белә, кичкә кадәр чүмәлә өстендә була. Сәнәкләр белән ыргытылган печән-саламны урнаштырып, таптап тора. Матур эскертләргә яңгыр да үтми, давыл да очырмый. Аннан соң ул бәрәңге, чөгендер ташу өчен пләтән-кәрзиннәр үрә. Алар ат арбасына урнаштырыла һәм зур күләмдә йөк ташырга булыша. Тагын карама агачыннан матур, нык дугалар бөгә. Өстәвенә, малларны дәвалый торган сәләте дә бар. Бригадир кунаклар кайтуын белсә дә, хәл-әхвәл белешергә безгә керә. Җитез хәрәкәтле, җиңел гәүдәле Хәертдин үз кеше, тормышны аңлый, кеше хәленә дә керә белә.

Бүген төнлә Сабан туйлары батыры, утны-суны кичкән фронтовикның йокысы йокы булмады. Аңа ничек тә гер күтәрүче, мич чыгаручы Дәяннан көрәшче «ясарга» кирәк иде. Сүзне әйтмә, әйтсәң – кайтма, дигәндәй, ир сүзе бер булыр, ди халык. Бүген ул аңа татар көрәшенең иң үтемлесен – билдән кысып алып, көндәшен күтәрү һәм егып салу алымын өйрәтәчәк. Чукрак кешегә аңлату авыр, шуңа күрә ярдәмгә ул чыбык очыбыз – тулы, нык гәүдәле Рәшитне дә чакырды. Ул тракторда эшли, Сабан туйларында көрәшеп, шактый тәҗрибә туплаган кеше. Авырлыгы центнерга якынлаша. Көрәшкәндә, билен төрле якка уйнатып, аны күтәреп алганда, сөлге калак сөякләренә кадәр күтәрелә дә, көндәше берни эшләми кала. Андыйларны егып кара син!

Күнегүләр иртәнге аштан соң берәр сәгать үткәч башланды. Әти әүвәл Гариф абый белән көрәшә. Һәр адымын аңлаешлы итеп күрсәтә. Хәлиткеч

адым ясар алдыннан көндәшенең хәрәкәтләрен, буй-сыннарын, гадәтләрен чамаларга кирәк. Менә көндәше дә сөлгесен кысып күтәрмәкче була, көче җитми, берара туктап кала. Шушы мизгелдә ул күтәрелә һәм баш аркан җиргә ава. Күп очракта батырлар вакытны сузмый. Чыгу белән һөҗүмгә күчә. Көндәшен суырып ала да, аның аяклары җирдән аерыла-аерылмас атып та бәрә. Егу өчен батырның куллары да, эче дә ярдәмгә килә. Рычаглар хәрәкәткә килеп, авырлык тигезлеген югалткан кеше җиңелү ачысын татый. Тагын бер үтемле алым: бу юлы һөҗүм итүче юан корсаклы көндәшен әйләндерә башлый. Әйтик, бәләкәй урында хәрәкәт сәгать йөрешенә каршы якка эшләнә, бер мизгелдә кире якка кискен борылыш ясала һәм көндәше күтәрелеп, җиргә атыла... Киң җилкәле, калын билле көрәшчеләр белән бил алышу гаять авыр. Монда инде сөлге бер кул белән бил уртасында, икенчесе белән касыктан урала. Каты, көчле куллы көрәшче көндәшен егып сала... Әти боларны да җизнигә төшендерде. Бер, ике, өч, дүрт, биш көн күнегүләр дәвам итте. Рәшит абыйның билләре кызарып чыкты. Ләкин ул түзде, сер бирмәде. Дәян җизни көрәшнең күтәреп алу һәм ике якка да көндәшен егу – ыргыту ысулын чамалый башлады. Соңгы көнне әти Дәян җизни белән үзе көрәшеп карарга булды. Бирелергә тиеш булса да, Сабан туйлары батыры Галимулла көндәшен чиста җиңүгә иреште.

– Ачуланма, Дәян, бирешмәү канга сеңгән инде ул. Үземне мәҗбүр итә алмыйм. Батыр калырга синең мөмкинлек бар, – диде ул.

Мәйданда чукрак көрәшчегә старшина Гариф, Габделхак абыйлар күз-колак булачак. Рәшит абый көрәшергә чит авылга китәчәген әйтте. Чөнки ул Дәянны сыртына салырлык түгел иде.

...Бәйрәм алдыннан авылга Чистай, Казан, тагын әллә кайлардан кунаклар кайтты. Автобуслар булмаганлыктан, халык су юлы белән кирәк җиргә бара. Йөз чакрым ераклыктагы башкалага бару бер җәфа. Балык Бистәсендәге пристаньга көчкә килеп җитәсең дә кичкырын парахутка утырып, Казанга барасың. Иртәнге алтыларда шәһәр юлчыларны каршылый. Элек бабайлар Казанга ат белән көнен барып кайткан дип сөйлиләр. Пристаньда халык һәрчак күп, бередән Әстерхан, Мәскәү, Пермь, Уфага утырып китәләр. Су йорты ике катлы, беренчесендә чыгу-керү, парахут көтү урыны, ә өстә зур ашханә. Монда тәмле ашлар, кабымлыклар дәрьясы. Парахутлар пристаньга кайвакыт икешәр-өчәр туктала. Аннан чыккан пассажирлар бер чакрым үрне җәяү үтә. Йөкләрне күтәреп, өскә менеп җиткәч, кемгә нәрсә эләгә инде. Рыбныйга сөт китерүче тракторга да, йөк автомобиленә эләгү дә зур бәхет. Күки, Балтач, Ямаш авылларына күп вакытта бездән җәяү кайталар. Гариф абый да кырык мәшәкатьләр белән кайтып җиткән туган өй бусагасына. Багажы да саллы булган, күрәсең, кулларым тәмам рәттән чыкты, ди. Үзенчә бүләге дә юк түгел. Бала-чагага төрле значоклар, әтигә лётчиклар кия торган зәңгәр күлмәк, әнигә ул вакытта дефицит саналган исле сабын һәм тегү энәләре... Тимерлектә бәйрәм рухы, һәр йортта таба ризыклары, көтү чыкмаганлыктан малларны ашатырга чабылган үлән исе. Малай-шалай чабышка атларны әзерли.

Иртәнге сигезләр тирәсе. Авылның урта мәчете агачларыннан сипләнгән

клуб янында инде бер атна сөлгеләр җилферди. Яулык җыю өчен клуб мөдире фронтовик Газиз абый җаваплы. Ул бирелгән һәр бүләкне язып барачак. Кәрҗиннәрдә көрәшчеләр арганда хәл алу өчен йомырка урын ала. Алар чаян Вакыйфы җиккән атлы арбага салына. Бер урамда биеп тора торган кара турыга атланган Мәүлә Хәннаны сафларның тигезлеген тәэмин итә. Акылга зәгыйфь Әхәт белән Мәлик өйләреннән үк муеннарына матур ситса яулыклар асканнар. Гомумән, быел да бәйрәмдә матур җырлар тынып тормаячак. Яулык җыюга стартны авыл советы рәисе Низам Галәветдинов бирә:

– Райком секретаре иптәш Вафин үзе килеп карыйм, диде, зинһар, йөзгә кызыллык китермәгез... Аллага тапшырдык, егетләр, – ди.

Хәер-фатиха бирелде.

Гармун тавышына яулык җыючыларның армия сафларына озатканда җырлана торган:

«Алмагачы чәчәк ата
Майның унбишләрендә,
Берсе китә, берсе кайта
Берсе комиссиядә», –

җыры яңгырый.

Солдат хезмәтенә инде китеп беттеләр, дембельләр исә кайта гына башлады, төркем арасында хәрби киемдәгеләре дә күзгә чалына.

Бүләк биргән хуҗаларга «Рәхмәт, рәхмәт, рәхмәт!» сүзләре яңгырый. Кайбер йортларның ишегалларында бәләкәй булса да, табын корылган. Анда тәмле чәй, коймак, кабартма урын алган. Теләүчеләргә ачы балы да куела. Шулай күңел ачып, төшке ашка яулык җыючылар югары очка менеп җитә. Гармунчылар да, алышына-алышына уйнап, чират сары бөдрә чәчле Зөлме Галләметдиненә җитә. Ул әтисеннән калган кыңгыраулы тальянда үзебезнең авыл көен уйный. Аңа бәрхет тавышлы Сәвәри кушыла:

Һаваларда очкан аккошларның
Каурый очларыннан чык тама.
Аталардан калган яшь ир бала
Күкрәк көче белән мал таба.

Ятимлектә үскән Сафиулланың үз җыры:

Кулъяулыгың бүләк булсын,
Матур итеп чиккәне.
Бил алышмый аңлау авыр
Кемнәр дошман икәнен...

Яшьләр чәй Мәннәне кызы Гөлчирәдән чиккән сөлге алгач, дәррәү «Рәхмәт!» кычкырып, урта урамга борыла. Монда аларны буйга җиткән кыз-кыркын каршылый. Тиз арада түгәрәк хасил була. Яшьләр тузан туздырып бии башлый. Эх! Нинди матур чак! Яулык җыючыларның җыр-биюләре кичке уенга барып тоташа. Бу тамаша озак дәвам итә.

Иртәгесен авыл уртасындагы мәйданда Сабан туе башлана. Гадәт

буенча бүген дә хуҗалык рәисе Гариф ага Шәйхиев, халыкны бәйрәм белән котлап, алдынгыларга бүләкләр тапшырды. Безнең күрше сыер савучы Зәйтүнә Мөнирова күлмәклек ситса, тракторчы Рәшит Касыймов – күн итек, комбайнчы Сабирҗан Фәйзрахманов самавыр алды.

Бәйрәмне клуб мөдире Газиз абый оста алып бара. Сабан туе төрле уеннар белән башлана да балалар, яшүсмерләр көрәшенә кереп китә. Аның эчке мәйданы барлык кешеләрне сыйдырып бетерә алмый. Тышкы өлешендә дә җыр, бию, күңел ачу. Әнә Бызгый Габдерахманы нәкъ цирк артисты, диярсең: мәтәлчек атып, кулларына баса, өстә калган аяклары белән бию хәрәкәтләре ясый. Минниша абый быел да колхозның кәҗә тәкәсен уфалла арбасына җигеп килгән. Аның дугасына, тәртәләренә матур яулыклар элгән. Бала-чага тәкәгә конфет-прәннек, чикләвек ашата. Ат чишмәсе янында күрше авыллардан килгән руслар тозлы кыяр, кәбестә, алма, салкын квас сата.

Төштән соң – ат чабышы. Аргамакларга старт биш чакрымдагы авылда бирелә.

Сабан туенда катнашучыларның күпчелеге бермәлне атларны каршыларга чаба. Әнә беренче булып соры төстәге ат элдерә. Аның артыннан кара туры алмачуар юыртып килә.

Малкайларның һәрберсенә мәйданга чакырып, бүләкләр тапшыралар. Иң артта килгәненә карт кызлар, ирсез хатыннар, әби-чәбиләр, адарынган хәер бүләген башын аска игән атның муенына бәйлиләр...


Ат чабышыннан соң көрәшне өлкәннәр башлый. Бил алышучылар саны күплеген истә тотып, аларны ике әйләнештә көрәштерергә булалар. Беренче, икенче һәм өченче урыннарны яулаганнар тәкә өчен көрәшәчәк икән. Ягъни алты ир-атның берсе тәкә алачак! Дәян җизнигә эти биргән «дәрес» бик үтемле булып чыкты. Ул күтәреп алган кеше җиргә очты. Чиста көрәште. Аның батыр булып калачагына өмет туды. Солдат хезмәтеннән әле кичә генә кайткан Брахау Камил Сабан туенда бил алышыр дип кем уйлаган? Ул бәйрәмгә солдат батырлыгын дәлилләүче билгеләр таккан гимнастёркасын президиум өстәленә куеп, сырлы майкадан һәм галәфи чалбардан чыгып басты. Әле өч ел элек кенә чандыр гәүдәле кара чутырны танып та булмый. Ул мускуллар, ул буй-сын, дисеңме! Менә ул авыл пәһлеваны, Сабан туе батыры. Армиядә чакта десантчы булган, кул сугышы, көрәш серләренә дә өйрәнгән икән... Икенче әйләнештә ул көндәшләрен урды гына. Тәкә өчен пәһлеван Камил белән тимер куллы чукрак Дәян мәйдан уртасына чыгып бастылар. Сабан туе гөрли. Берәүләр Камил, икенчеләре Дәян яклы. Кем җиңәр дә кем батыр калыр? Әти бер урында тора алмый, нык борчыла. Ни әйтсәң дә, Камил абый да, Дәян җизни дә батыр булырга хаклы... Ике потлы герләрне күккә чөйгән, хәзерге вакытта җиңү тәмен тойган чукрак көрәшчене туктату мөмкин түгел иде инде. Дәян җизни беренче минуттан ук көрәшне кыска тотарга булды бугай. Камилнең хәлен сынап тормады, һөҗүмгә күчте. Көндәшен күтәреп алды да чөеп үк җибәрде. Тегесе егылмады, дүртаяклап яшел хәтфә өстендә калды. Тагын Дәян күтәреп алды, Камил кабат бирешмәде. Ярты сәгатьләп бил алышкач, сөлгеләре икесенең дә

билләренә ныклап бәйләнде. Бу кысуга пәһлеванның аяклары күтәрелә башлаганда сөлге түзмәде, тавышсыз гына өзелде. Мәйдан гөрли. Инде кич җиткән. Җиңүче билгеле түгел. Ике көрәшченең билләренә яңа сөлгеләр бәйләнде. Әйтерсең, Камил солдат бу мизгелне көткән, ул бу юлы үзе һөҗүмгә күчте. Дәян җизнине үзенә тартып китерде дә көндәшен җибәргәндәй итте. Тагын тартты, тагын җибәрде һәм Дәян җизнине җиргә матур гына «ябыштырды». Сабан туенда катнашучы ир-атлар ике батырны бер-бер артлы күтәреп, күккә чөйде. Үзләренең шатлыгын, соклануын җиткерделәр...

Камилнең кайтасын кем белгән. Ул булмаса, батыр булып чукрак көрәшче калган булыр иде, әлбәттә. Моны Дәян үзе дә, халык та яхшы аңлады. Ул инде максатына иреште. Күңеле тынычланды, инде бүтән көрәшкә чыкмады. Шушы ук елның көзендә бәлагә тарып, солдат Камил үлемнән чак кына исән калды. Бүтән көрәшмәде. Гомер буе комбайнчы булып эшләде.

Әти читтән генә Дәян җизнинең һәр хәрәкәтен күзәтте һәм кабатлап барды. Аның өчен куанды, янды, көйде. Ул инде уянган дәртен тыярлык түгел иде. Иртәгесен, иптәшкә диптер инде, мине ат арбасына утыртты да Котлы Бөкәшкә, Кызыл Йолдыз район Сабан туена киттек. Тяб.Чаллы, Бирдебәк, Кыерлы авыл батырларын, үзенә генә хас алым белән баш арканча очырып, батыр калды. Аңа бүләк итеп кыңгыраулы тальян гармун һәм бик зур тәкә бирелде. Тәкәне ул Тимерлектә батыр каласы Дәян җизнигә олылап тапшырды.

...Милләтебездә батырлар җитәрлек. Сабан туйларында көрәшүчеләр саны арта гына. Мин үзем дә үсеп буйга җиткәч, грек-рим көрәше белән шөгыльләндем. Әтинең алымын кулланып, чемпион булып калдым. Беренче спорт разрядына лаек булдым. Сабан туйларында бил алыштым, ләкин 1959 елда көрәшкән әтием, Дәян җизни, Камил солдат көрәше әле дә күз алдымнан китми. Әйе, татарга көрәшсез яшәү мөмкин түгел. Бу безнең канга сеңгән!



*Ирина Шәрәфәтдин кызы Узденова – карачай шагыйре, Карачай-Черкес Республикасының халык шагыйре, күпсанлы китаплар авторы. Шигырьләрен рус телендә яза. Журнал укучыларына шагыйрәнең берничә шигырен тәкъдим итәбез.*

Ирина
Узденова

# МИН ТАУ ГӨЛЕ, ТАШНЫ ТИШЕП ШЫТАМ...

## Мөәзингә

Базар мәйданы өстендә
Җырлы сүрәләр вәзен
Яңгырата бар тарафка,
Азан укысаң, мөәзин.

Сихерләнеп, Ай нурлана
Син сүрәләр укысаң.
Синең тавыш җиде кат күк
Капусын ача сыман.

Синең аһәңдә тәм-томнар,
Хушбуйларның хуш исе.
Тавышыңның йомшаклыгы
Аккош мамыгы төсле.

Кышын да ул бәрхет кебек,
Җәйләрен – атлас сыман.
Бар гаугалар кала тынып,
Синең саф тавышыңнан.

Иманга килә бар тараф
Син дога укыганда.
Язмышларны буйсындырган
Көчләр бар бу догаңда.

Кояштан иртә торасың,
Соң ятып, син йокыңнан.
Кешеләр килеп көч ала
Синең йөрәк утыннан:

«Аллаһының барлыгын һәм
Берлеген танып, иман
Китерегез! Аллаһ сезне
Ярлыкар үзе аннан!..»

## Фәрештәм

Кара төндә, йә бер якты көндә
Сукмак эзләп йөрсәм гарештән,
Кабахәтләр тырнагына мине
Син ташлама, берүк, Фәрештәм.

Мин, бәлагә тарган бәндәләргә
Ярдәм итәм дигән минутта,
Буш кул белән үзем торып калсам,
Син, Фәрештәм, мине онытма.

Мин алданып матур хыялларга,
Атласам да упкын читеннән,
Ишетмәсәм, «Сак бул!» дигәннәрен,
Син, Фәрештәм, ваз кичмә миннән.

Мин башкалар өчен җан атканда,
Йөрәгемне биреп аларга,
Үзем җансыз торып калганда да,
Син, Фәрештәм, тырыш аңларга.

Сүткән чакта тормыш йомгагын мин,
Алтын җебен аның кыскартсам,
Кичермичә гайбәт һәм яланы –
Гаепләмә мине һичкайчан.

Әгәр дә мин гаделсезлек күреп,
Еш бәхәскә керсәм тормышта,
Син, Фәрештәм, мине ачуланма,
Кичерә күр мине, орышма.

## Кыямәт сүрәсе

*Бисмилләһир-рахманир-рахим*

О кыямәт көне! Җәза, афәт көне!
Сизәсеңме, җиһан, курку-тетрәнүне?

Нәзберек җан күчәр төнге күбәләккә,
Таулар калыр торып мамык кебек кенә.

Кылган изгелекләр сираттан юл ачар,
Кылган яманлыклар җәза булып басар.

Ничек әйтеп бирим бер-ике сүз белән?
Тәмуг уты яман  бөтен афәтләрдән.

## Тау чәчәге

Мин тау гөле, ташны тишеп шытам.
Бүләк өчен мине сатмыйлар.
Үскән җирем – таш өеме минем,
Мине җилдән таулар саклыйлар.

Тамырымны сугара тик комнар,
Кояш мине иркәли таңда.
Торган саен мин буй җитмәс булып,
Охшап калам үзем шул тауга!

Тау баласы, йоклап китәр өчен
Мин ябынам йолдыз юрганын.
Мине өзәр өчен ир-егетләр
Үрмәләргә тиеш югары.

Ташкын сулар сыный ныклыгымны,
Керфекләрем туңа бозланып.
Шундый кыска миңа язган гомер,
Сизми калам аның узганын.

Таш өстендә үскән нәфис чәчәк,
Ераклардан балкып торам мин,
Тау түбәсен яулый алган кыю
Каһарманга бүләк сыман мин.

## Ярчык

Тимер ярчык йөрәк янында,
Хатирәсе узган сугышның.
Дәвалап та булмый, ташлап та,
Юлдашы ул узган тормышның.

Кем сукыр, кем кулсыз, кем аксак,
Кем күптән билгесез кабердә.
Шуларның берсе син идең бит,
Син исән, яшисең хәзер дә.

Тимер ярчык йөрәк янында.
Яуда син төрлесен күрдең күп.
Син сугышта кылган батырлык
Өчен ул бирелгән орден күк.


**Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре.*

# НИЧЕКЛӘР ГЕНӘ САГЫНДЫРА ӘЛЕ ҮТКӘННӘР...

## БАШКОРТСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ ӘНГАМ АТНАБАЕВНЫҢ ТУУЫНА – 95 ЕЛ

*Әнгам Атнабаев – һичшиксез поэтик сүз остасы. Ул телнең шул кадәр кадерен белә, үзенең әсәрләрендә бер генә кирәкмәгән сүз дә ычкындырмас, кирәклесен әйтмичә калдырмас иде... Чөнки ул үзенең бөтен шигырьләрен дә ювелирлар кебек җентекле эшкәртә, халык әйтмешли, коеп куя торган иде.*

Нәҗип Асанбаев



Туган-үскән йортымның моңсу тәрәзәләренә сабыр гына күз сирпим дә, каршыма килә кебек үткәннәр, югыйсә чәчләр дә бит агарып беткәннәр. Кыл кебек нечкә күңелемнең ак пәрдәсен сак кына ачам да, анда аксыл плащын кигән, олпат гәүдәле, кара мыекларына кырау төшкән, уйчан карашлы, әдәбият дөньясын шаулаткан әдипне – Әнгам Атнабайны шәйлим. Нишләптер, аны якын итеп, авылча гына Әнгам абый диясем килә. Ничектер, ул миңа күптән очрашмаган кардәшемне, нәкъ мәрхүм әткәм кебек 1928 елгы, туганнан да якынрак кешене хәтерләтә. Елар чакта сине елмайта, йөрәгеңә кереп, күңел яраңны ягымлы сүзләр белән дәвалый белә иде ул. Ә инде аерылышкач, аны оныта алмыйча изаланасың. Их, андый эчкерсез, саф күңелле кешеләр күбрәк булсын иде дә бит бу дөньяларда! Мондый изге җанны ничекләр инде онытасың?!.. Кайчандыр «үткәннәргә кайтыр юлым юк», дип язган иде Әнгам ага. Шулай да үткәннәргә бер кайтам әле синең хакка.

### Шагыйрьнең эзләре калган авылым урамнарында

«Тыңлачы, замандаш, йөрәк тибешемне!» исемле автобиографик повестема керми калган, әмма минем өчен бик тә кадерле мизгелләр бар. Ул да булса, бөек шәхесләрнең туган авылым Кыңгыр-Мәнәвезгә (Бишбүләк районы) килүе.

1966 ел иде ул. Безгә – дүрт йөздән артык йортлы татар авылына Әнгам Атнабаев белән якташым Таһир Ахунҗановның (Таһировның) килеп төшүе (моңа кадәр тере әдип күрмәгән гади авыл халкына) берникадәр гаҗәп тә, шулай ук сөенечле, онытылмас вакыйга да булды. Дөрес, «Кызыл таң» гәзитенең мөхәррире Таһир Исмәгыйль улы моңа кадәр бездә булган икән. Башкортстан партия өлкә комитетының матбугат бүлегендә эшләгәндә, безгә килеп, «Каганович исемендәге колхозда» дигән зур репортаж да язган *(«Кызыл таң», 1953 ел, 4 июль,)*. Ул гәзитнең кисемтәсен үзе биреп

калдырган иде. Аны бүген дә кадерләп саклыйм. Бу юлы Таһир ага Атнабайның үзе белән килгән. Булачак халык шагыйре Әнгам Атнабаевның ялкынлы чыгышы шыгрым тулы иске клуб стеналарына гына сыеша алмыйча яңгыраган иде. Бигрәк тә «Кара икмәк» шигыре авыл кешесен сискәндереп, уйлар диңгезенә чумдыры:

*Әнкәй миңа кара икмәк чәйнәп,*
*Имезлеккә салып биргән дә*
*Үзе киткән урак урырга...*
*Елаганмын, ләкин чыдаганмын—*
*Икмәк белән була торырга...*

Хәзер ятимсерәп калган басу-кырларга бу шигырь мәдхия, гимн булып яңгырый сыман. Заманында безнең «Победа» колхозы КПСС Үзәк Комитетының Кызыл байрагына лаек булган миллионер хуҗалык иде. Кызганыч, бу хакта яшьләр дә, хәтта бүгенге укытучылар да белми. Таһир ага Ахунҗанов Әнгам Атнабаевны бу татар авылына очраклы гына алып килмәгән иде. Ул чакта клуб залында Бәләбәй төбәгенә караган хуҗалыклар арасында бердәнбер 3 тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, фронтовик, күренекле «Победа» колхозы рәисе, искиткеч тыйнак ил агасы Габдулла Кадыйр улы Фәритов та утыра иде...

Залда урнашкан тынлыкны бозып, фронтовик Таһир ага үзе белән алып килгән тальянын кулына алып, авыл, урам көйләрен сыздырды. Ихлас йөрәктән чыккан көйләр гүя Кыңгыр-Мәнәвез авылына кире әйләнеп кайтмаган 455 яугирне искә алу аккорды булып яңгырады. Бу минутларда сугыштан кайтмаган әткәсен уйлап, бәгырьләре телгәләнеп утырган Әнгам ага да түзә алмады. Ул акрын гына галанка (калай белән тышланган) мич янына килде дә халыкка күренмәскә тырышып кына иелә биреп, «Беломорканал»ын пыскытты. Шагыйрь абый безгә – алдагы рәттәге малайларга нәрсәдер ымлады. Таһир ага халык белән аралашканда, ул классташым, уку отличнигы, яшь хәбәрче Хәниф Латыйпов (мәрхүм инде) белән минем янга килде дә: «Сез дә шигырь тыңларга килдегезмени?» – дип сорады. «Әйе, шагыйрь абый, без бит районның «Якты юл» гәзитенә бәләкәй генә мәкаләләр дә җибәреп торабыз», – дидек. «Үскәнсез инде, юлыгыз да якты булыр, пажалый», – диде Әнгам абый, аркабыздан сөеп. Аның көрәктәй кул җылысы бүген дә күңелләрне җылытып тора сыман...

Әнгам Атнабаев кебек ятимлектә, «нужа калачын кимереп» үскән, тормыш төбеннән күтәрелгән гади авыл малайларына сугыштан соң туган буын өчен эти урынына калырга туры килде. Бу Атнабайның әсәрләрендә ачык чагыла. Шуңадыр да аның рифмага салынган, йөрәк каны, җан авазы белән язылган шигырьләре әлеге кичәгә килгән һәммә кешенең игътибарын җәлеп итте. Бигрәк тә «Без – егерме сигезенчеләр!»:

*...Сугыш безне колаклардан тартып,*
*Вакытыннан иртә өлгертте:*
*Кичтән егет итеп йоклатты да*
*Таң атуга инде ир итте.*

Шагыйрь шигырен укып бетерүгә зал торып басып, гөр килеп кул чапты. Алкышларны туктатып булмый гына бит! Клуб тутырып килгән укытучыларга, савымчыларга, терлекчеләргә, механизаторларга карап, рәхмәтен белдереп, Әнгам ага болай диде: «Әллә бик ошап киттеме? Төн уртасы бит инде, кайберләрегезнең сәгать 5тән торып эшкә барасы бардыр». «Шагыйрьләр безгә көн саен килми, сыерларны без җырлап савабыз аны», – диде арадан берәү. Ә клубның тәрәзәләрен нәкышләнгән тылсымлы кышкы бизәкләр сарган иде...

## Күрдемне дә күрдек, «Кызыл таң»да күрештек без...

Университетның беренче курсын тәмамлагач, төркемдәшләрем белән миңа 1976 елның җәендә гүзәл табигатьле Тәтешле якларында фольклор экспедициясендә булырга туры килде. Максатыбыз – фольклор галиме Риф Мөхәммәтҗанов җитәкчелегендә Сараштыбаш, Күрдем авылларындагы әби-бабайлардан татар халкының авыз иҗатын җыю иде. Шулай итеп, без булачак халык шагыйре Әнгам Атнабаевның туган якларында булдык, ул йөргән сукмаклардан үттек. Хәтта аның туган йортында куна да калдык. Әнисе Мәрзия ападан «интервью» алдык, Әнгам, Мәгъдән абыйлар, Зинира апалар һәм башка туганнары кайчандыр туган йорт тәрәзәләреннән шушы якты дөньяга бакканнар бит инде дип, шул рухны тоярга тырыштык. Әнгам абый йөргән урманнарда җиләк ашадык, ул эчкән җиде күзле изге «Хәзрәт» чишмәсенең шифалы суын авыз иттек, шагыйрь сулаган һаваны суладык, аның туган мәктәбендә булдык. Хәтта Казаннан килгән Татарстанның халык артисткасы Флүрә Сөләймsymbolанованың концертында булып, аңа ялан чәчәкләре бүләк итү бәхете дә елмайган иде миңа...

Әнгам ага белән икенче тапкыр мин университетта укыганда, 1977 елның февралендә «Акчарлаклар» әдәби-иҗат түгәрәге оештырган шигърият кичәсендә очраштым. Безнең өчен күренекле шагыйрь белән күзгә-күз карап очрашу олы мәртәбә иде. Ул башта безнең «Акчарлаклар» стена газетендә чыккан иҗат җимешләре белән танышты. Аннан соң татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, профессор Габделхәй Әхәтов, түгәрәк җитәкчесе, профессор Әхәт Нигъмәтуллинның кыска чыгышларыннан соң төрле курс студентлары Люция Халикова, Фәнирә Исмәгыйлова, Рәзинә Мөхиярова, Юнир Бәширов, Рәфыйга-Рәиф Закировлар, Розалия Нәбиуллина һәм башкалар үзләренең шигырьләрен укыдылар. Үз чиратында, олуг шагыйребез, остазыбыз үзенең фәһемле киңәшләрен бирде, кайбер шигырьләрне матбугатка да тәкъдим итте.

Әлбәттә, яраткан әдибебез Әнгам Атнабаев «күчтәнәч»сез килмәгән иде. Аның «Без малайлар идек», «Кешегә ни җитми?», «Таңнарда гармун уйнадың», «Капка төбендә» һәм башка шигырьләрен кинәнеп, ораторларча укуы һәркемнең күңеленә хуш килде. Кичәнең ахырында шагыйрь студентларга автографлы җыентыкларын бүләк итте. «Еллардан җырлар кала» исемле китабына: «Әнвәр! Сөйгәнеңнән сөелеп һәм поэзияне сөендереп, озак яшә. Ә.Атнабай. 15.02.77», – дип язган иде. Моннан 45 ел элек бирелгән китапны бүген дә халык шагыйренең күңел һәм кул җылысы итеп саклыйм.

Мин студент елларында да, аңа кадәр дә – җәмгысы 50 елдан артык «Кызыл таң» белән тыгыз иҗади элемтәдә тордым. Дистә елдан артык анда бүлек мөдире, үз хәбәрчеләр җитәкчесе булып эшләдем. Стажёрлык практикасын да биредә үттем, «Кызыл таң» газетендә очерк жанры» дигән темага диплом эше яклады. Стажёр вакытта миңа мәдәният һәм сәнгать бүлегендә эшләргә туры килде. Бүлек мөдире, шагыйрь, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фәрит Габдерәхимов мине колактан тартып үстерде. Гадәттә, бу бүлекне каләм тибрәтүчеләр – шагыйрьләр, язучылар, артистлар, мәдәният хезмәткәрләре үз итә. Берсендә эш сәгате тәмамланыр алдыннан: «Җитәр инде сезгә, егетләр, батырга да ял кирәк», – дип, мыек астыннан елмаеп кына, Әнгам Атнабай килеп керде. «Кызыл таң»ның соңгы санына күз йөгертеп чыккач, ул: «Әнвәр туган, син яшьрәк кеше, бар әле, юл аша чыгып кер», – дип, яшел кәгазь өчлек сузды. Мин инде тыңлаучан солдат кебек тиз генә кибеткә барып килгәч, илһамланып, янә үз эшемә керештем. Аның уңай энергетикасы тәэсир иткәндерме, эштән соң калып, шактый гына язып ташлаганмын.

...Әнгам абыйның икенче керүендә кабинетта үзем генә нәрсәдер сызгалап утыра идем, ул миңа сүз катты: «Син Бишбүләк егете бит әле. Дипломат Кәрим Хәкимов, патриот-шагыйрь Фатих Кәрим төбәгеннән. Киләчәктә аларны да онытма, – диде

өлкән каләмдәшем. – Заманында «Коммуна», «Кызыл таң»ның мөхәррирләре булган Мөхәммәт Бикбулатов белән Таһир Ахунҗанов та синең якташларың булып чыга бит әле. Каләмең шомара төшкәч, иҗатыңны аларга, гомумән, шәхесләр тормышына юнәлтергә тырыш. Алар синең күңел күзләреңне тагы да ныграк ачар», – дигән иде ул. Шул елларда «Һәнәк» журналында мөхәррир урынбасары булып эшләп йөргән Әнгам абыйның, шулай ук Таһир аганың да киңәшләрен колагыма киртләп куйдым. Гомер дәвамында шактый гына шәхесләр – әдәби геройларым китапларымда лаеклы урын алдылар, әдипләрнең традицияләрен кулымнан килгән кадәр дәвам иттердем...

## Атнабайны Ахунҗанов «Кызыл таң»га ничек «кодалаган»?

36 ел буена Таһир Исмәгыйль улы белән аралашу дәверендә ул миңа күп кенә рухи кыйммәтләр хакында сөйләп калдырды. Хәтер сандыгымда хәйран гына җәүһәрләр саклана. Әлегә шуларның берсен генә тәкъдим итмәкчемен.

«1964 елның башында мине «Кызыл таң»ның баш мөхәррире итеп расладылар. Гәзитнең эчтәлеген баету, аның йөзен үзгәртү, халыкка якынайту изге максатларымның берсе булды. Иң зур өметем – язучыларда, өлкән журналистларда иде. Яңа вазифамның беренче көнендә кич белән Әнгам Атнабаевның фатирына киттем: ул күптән түгел «Кызыл таң»нан «хезмәт дисциплинасын бозган өчен» (эшкә соңлап йөргән өчен) чыгарылган иде. Әлеге дә баягы шул «законлы» булсын дип җибәргәннәр инде: хезмәткәрләр эшкә вакытында йөрсен. Минемчә, язучының редакциягә иртәнге тугызда килеп утыруының һич хаҗәте юк: ул өендә дә гәзиткә эшли ләса, аның эше дә, ашы да шул бит! Килдем, Сәвия ханым әзерләгән чәйне эчтек, мин аптырабрак калган хуҗага йомышымны әйттем: «Редакциягә кайт, гәзитне бергәләп күтәрик». Озак кына уйланып торганнан соң: «Кайтам, тик бер шарт белән, – диде Әнгам. – Үзеңне монда күп тотмаслар, киткәндә, мине «по собственному желанию» чыгарып китәсең. Мин башка кешегә буйсынып эшләргә теләмим... Соңыннан шулай иттек тә: кадрлар буенча минем беренче приказым Атнабаевны эшкә алу хакында, соңгысы аны үз теләге белән редакциядә эштән бушату турында булды. Дәвам итеп, тагын берничә сүз әйтим: мин командировкаларга күбрәк Атнабаев белән йөрдем. Баш мөхәррирнең аны үзенә артык якынайтуын хупламаучылар да булды, ләкин бергә йөрдек, аның белән эшләве күңелле, нәтиҗәле иде. Район-шәһәрләрдә «Кызыл таң» көннәре, халык белән очрашулар шулкадәр күңелле үтә иде ки, кешеләр соңыннан озак җибәрми торалар иде».

Сөекле татар шагыйребез турында әйтер-язар фәһемле сүзләр биниһая, тик журнал бите генә гармун күрекләре кебек сузылмый. Шулай да тагын берничә детальгә генә тукталмыйча булмас. «Кызыл таң»да эшләгәндә, миңа Атнабайның 70 яшьлек юбилеенда катнашу бәхете тиде. Юбилярны котларга Башкортстанның ул вакыттагы Президенты Мортаза Рәхимов, Татарстанның күренекле шагыйрьләре, якташларыбыз Илдар Юзеев, Роберт Миңнуллин килгәннәр иде. Биредә Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Башкортстанның халык шагыйренең әнисе – 94 яшьлек Мәрзия апаның, туганнары арасында РФнең халык артисты Зинира Атнабаеваның булуы үзе бер могҗиза иде. Танылган драматург Әнгам Атнабаевның «Шоңкар», «Игезәкләр», «Ана хөкеме», «Ул кайтты», «Хушыгыз, хыялларым!» һәм башка пьесаларыннан өзекләр күрсәтелде. Әлбәттә, шагыйрьнең «Җиз кыңгырау моңнары», «Әнкәй, синең куллар», «Дусларыңны онытма», «Галия белән Заһир» дуэты, «Яшьлегемә кайтып барам», «Танып буе» һәм башка җырлары яңгырады. Дистәләгән җыентыклар авторы буларак, Әнгам ага тәнәфестә үзенең китапларына автографлар язып, яраткан укучыларына бүләк итте. Билгеле, Атнабайны Татарстанда да бик хөрмәт итәләр. Аның 90 еллыгына багышланган искиткеч кичәнең филармониядә зур дәрәҗәдә оештырылуы һәм телевизион каналларда

түкми-чәчми төрле төбәкләрдә күрсәтелүе олы мәртәбә иде. Анда танылган артистлар Рәшит Сабиров, Филүс Каһиров һәм башкаларның әдипнең онытылмас әсәрләрен сәхнәгә чыгарулары, кичәгә әдипнең уллары Салават белән Азаматның чакырылуы да бик сөенечле мизгел булды.

## «Тарихлардан укып ятларлар әле...»

Әнгам ага халыкчан итеп язды. Татар поэзиясенең алтын баганасы, әдәбиятыбызның йөзек кашы иде, дисәк тә, фәстерү булмастыр, мөгаен.«Түш кесәгә салып йөртәсе бар үзебезнең туган туфракны», «Кеше үзенең бөек икәнлеген каян белер иде, үлмәсә» – болар һәммәсе күптән канатлы сүзләргә әверелде инде.

Моңсу кара күзләрдә яраткан шагыйребез белән хушлашкан идек. Гомер кояшы сүнсә дә, аның якты эзләре туган туфрагын җылытып тора. Ә якташлары исә аңа кадер-хөрмәт күрсәтеп яши. Иң мөһиме – бүгенге көндә дә күренекле шагыйрь һәм актриса туган йортның учагы сүнмәгән. Иске Күрдемдә аның бертуган энесе, районның танылган шәхесе, Әнгам Атнабаев исемендәге премия лауреаты, хезмәт ветераны, мактаулы имам Мәгъдән Касыйм улы Атнабаев яши. 2022 елда юбилеен зурлап үткәрделәр. Атнабаевларның нәсел шәҗәрәсен төзегән кеше ул. Әнгам ага заманында аңа этисен алыштырган. Туганлык җепләрен өзмичә, Мәгъдән ага, истәлекләрне яңартып, туганнарының исемнәрен мәңгеләштерү эшләрендә актив катнаша. Иске Күрдем авылындагы җиде күзле Хәзрәт чишмәсе янында күрше-тирә район һәм төбәкләрнең имам-хатыйбларын чакырып, җыен үткәрү, аларга кадер-хөрмәт күрсәтү, мәктәптә очрашуларда булу – һәммәсе дә савaплы гамәл.

Шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү йөзеннән дә туган авылында шактый гына эшләр башкарылган: Иске Күрдем мәктәбе алдында Әнгам Атнабаевка бюст куелган, шунда ук музее бар, Иске Күрдем, Югары Тәтешле авылларында, Яңавыл шәһәрендә урамнар аның исемен йөртә. 2003 елда Әнгам Атнабаев исемендәге район премиясе булдыру да бик күркәм гамәл. Әйткәндәй, күренекле әдибебезнең исемен мәңгеләштерү максатында район, урындагы хакимиятләр шактый кадер-хөрмәт күрсәткән. Моңа һәркем сөенә генә. Танылган галим, филология фәннәре докторы, профессор, Әнгам Атнабаев исемендәге премия лауреаты Рәиф Кадыйм улы Әмиров «Безнең Атнабай» исемле китапның төзүчесе буларак, искиткеч зур эш алып барды. Әлеге көндә ул китапның икенче кисәген әзерләүдә актив эшли. Халык шагыйре үзенә күптән әдәби һәйкәл куйган иде, ә аның ихтирамлы, изге күңелле якташлары Әнгам Атнабаевка Югары Тәтешледә чын һәйкәл куярга җыена. Район халкы иганәче Камил Ибәтуллинга чиксез рәхмәтле. Менә шундый мәрхәмәтле, милли рухлы ир-егетләрнең күркәм гамәле шагыйрьнең «мин бу дөньяны матурларга тудым» дигән сүзләренә тәңгәл киләдер, мөгаен...

**Әнвәр СӨЛӘЙМАНОВ,**
*Фатих Кәрим, Динис Бүләков исемендәге премияләр лауреаты,*
*ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре.*





Фатих Хөсни Хәсән Туфан белән
Тукай клубында. 1974 ел.




Шагыйрә Гөлзадә Бәйрәмова.
Бу көннәрдә ул юбилеен
билгеләп үтә.

## Авылдаш әдипләр







Мамадыш районының Түбән Ушмы авылы тумалары – язучы Локман Закир (сулда), галим, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хуҗи Мәхмүтов (уртада) һәм Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров (уңда).

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*



*1977 елның февралендә Тукай клубында Әдәби ел йомгаклары җыелышында «Казан утлары» журналы «Почёт билгесе» ордены белән бүләкләнә. Орденны КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Мирзаһит Вәлиев «Казан утлары» журналының ул вакыттагы баш редакторы Зәки Нуриға тапшыра. Рәсемнәрдә тантанадан күренешләр.*







*Сәхифәне* **Рөстәм НӘБИУЛЛИН** *әзерләде,*
*фотолар автор архивыннан алынды.*

# «ҮТКӘН БЕЛӘН БҮГЕНГЕ АРАСЫНДА КҮПЕР КОРМАК МӘСЬӘЛӘСЕ БУ...»

*Моңа кадәр тормышлары һәм эшчәнлекләре укучы игътибарына тәкъдим ителгән галимнәр барысы да – Татарстаннан читтә яшәүче, әмма мин белгән, аралашкан шәхесләр булып, алар сурәте шәхси мөнәсәбәтләрнең дә бер чагылышы булды. Бу язма багышланган галимә – алай түгел. Дөрес, мин аны шәхсән күрдем: Әнкара шәһәрендә 2011 елның 10–12 октябрь көннәрендә узган «Идел-Урал тарихы» дигән фәнни симпозиумда булды ул. Зыялылыгы йөзенә чыккан, үз бәясен белүе күренеп торган бу горур ханым белән Ильяс Камалов таныштырды, шул ук көнне ул чыгарган китап – төрки халыкларның кытай теленнән тәрҗемә ителгән чыганаклардагы борынгы тарихын туплаган басманы күрсәтеп, аның Төркия фән галәмендә хуплап кабул ителгәнен әйтте...*

*Инде менә Төрек тарих корумы (академиясе) аның 80 еллыгына багышлап «Яшәгән тарих» сериясендә төшергән 2 сәгатьлек документаль фильмны карау насыйп булды. Аннан алган тәэсирләр кулга каләм алырга мәҗбүр итте дияргә дә ярый торгандыр. Бу язмада шәхси тәэссоратларымны – ул үзе фильмда сөйләгән истәлекләр һәм Алп Демиркаяның мәгълүматлары тулыландырды. Әлеге материал уртак хезмәтебез булып чыкты.*

Аны татар укучысына таныту өчен сәбәпләр зурдан. Бердән, ул – олы галимә, фикер иясе, төрки халыклар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә гомерен багышлаган шәркыятьче. Икенчедән – инкыйлаблар давылында илдән читтә аерылып калган күренекле нәселнең дәвамчысы. Өченчедән – без танып бетермәгән, әмма белергә һәм ихтирам итәргә, татарларның да билгесез ерак тарихын ачкан, бүгенгегә китереп җиткергән хезмәтләрен татар дөньясында фәнни әйләнешкә кертергә лаеклы фән йолдызы...

Ул – Төркиянең күренекле галимәсе, Төрек тарих корумының академигы, профессор Исәнбикә Туган. Мәшһүр сәясәтче һәм дәүләт эшлеклесе, философия фәннәре докторы, профессор, Башкорт милли-азатлык хәрәкәте җитәкчесе Әхмәтзәки Вәлиди (1890 – 1970) кызы. Әтисенең: «Кешеләр (инсаннар) һәм халыклар-дәүләтләр арасында төрлелекләр бар. Шуларны аңласаң – галим булырсың», – дигән сүзләренең үзенең тормыш девизына әйләнүен әйтә! Әлеге төрлелеккә төшенү «үткән белән бүгенге арасында күпер корырга» ярдәм итте дип белдерә!

Башкортстан автономиясенә нигез салучы Зәки Вәлиди, аның килеп чыгышы, тамырлары, хезмәтләре турында Татарстанда да, күрше республикада да мәгълүмат бар, күп. Ленин һәм Сталин белән дә, Ататөрк белән дә хезмәттәшлек иткән сәясәтче Вәлиди шәхесенә һәм эшчәнлегенә тукталмастан, бер фактка гына игътибар юнәлтергә кирәк табам: XX йөз башы татар вакытлы матбугаты белән таныш, иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтне өйрәнгән кешеләр аның үз дәвере татар дөньясында билгеле фикер иясе икәнлегеннән хәбәрдар. 1908 елны 18 яшендә туган авылы – Башкортстанның хәзерге Ишембай районына кергән Көзән авылыннан Казанга килеп, «Касыймия» мәдрәсәсенә урнашкан егет тиз арада биредә милләт ваемы белән янып яшәгән яшьләр арасында кай-

наша башлый. Әтисе Әхмәтша мәдрәсәсендә гарәпчә һәм әнисе Өммелхәяттан фарсыча камил үзләштереп, Казанга килгән Зәки мәдрәсәдә үзе дә төркиләр тарихын һәм гарәп әдәбияты тарихын укыта, вакытлы матбугатта актив языша. Үз фикерле, үз сүзле, хакыйкать дип санаган кыйммәтләр өчен ахыргача көрәшә торган Әхмәтзәкинең язмалары татар дөньясында күп кенә бәхәсләргә сәбәп була. Мәркәзебездә ул үзенең галимлек омтылышына юл ача: 1912 елда Казанның «Милләт» типографиясендә «Төрк вә татар тарихы» исемле беренче зур фәнни хезмәте басыла.




Зәки Вәлиди Казан университетында тарих һәм тел белеме буенча лекцияләргә йөри, фәнни эшләргә сәләтле, кызыксынучан егет университет каршында эшләгән Археология, этнография һәм тарих җәмгыятенә кабул ителә. 1913 елны исә, әлеге җәмгыятьнең әгъзасы буларак, Төркестанга өч айлык этнографик экспедициягә китә. Биредә алган тәэссоратлар, күргән һәм язуын күчереп алган ташъязмалар, табылган сирәк кульязмалар һәм сүзлекләр аның киләчәк тикшеренүләренең нигезенә ята. 1914 елны ул кабат бу җирләргә килә, галим Төркестанны төрки халыкларның тарихи ватаны дип кабул итә һәм кавемдәшләре тудырган бөек тарихны һәм асыл мирасны өйрәнүгә гомерен багышларга уйлый. Хәтта 1917 ел инкыйлабыннан соң иң йогынтылы сәясәтчеләрнең берсенә әйләнгәч тә, Вәлиди фән белән шөгыльләнүен читкә куймый. Хәтта Төркестанда төркиләрнең бөек мәмләкәтен тергезү омтылышы да ясый...


1923 елны илне һәм олы сәясәтне ташлап киткәч тә, Вәлиди фән юлын дәвам итә. Ул 1932 елны Вена университетына укырга керә, философия факультетын тәмамлап, «Ибн-Фадлан юлъязмалары» турында диссертация яклый. 1935 елдан Бонн һәм Геттинген университетларында укыта, 1938 елны Төркиягә әйләнеп кайта һәм Истанбул университетына профессор булып урнаша. Ул – 400ләп фәнни хезмәт, 30 монография авторы. Урта гасырлар төрки-татар истәлекләренә багышланган фундаменталь хезмәтләр арасында бүген дә Зәки Вәлиди карашларына сылтамаларсыз язылганын табып булмас.

Исәнбикә Туган менә шушы бөек шәркыятьче-галим һәм румын татарларыннан Нәҗмия (Назмия) ханым гаиләсендә, 1940 елның 8 декабрендә Истанбулда дөньяга килә. Ул үзен дүрт кабилә каны кушылган гаилә дәвамчысы дип атый: әтисе ягыннан – башкорт һәм типтәр, әнисе ягыннан – нугай һәм Кырым татары. Үзе сөйләвенчә, Кайсери һәм Конья шәһәрләрендә мәктәптә укый, 1954 елны 3 ай Һамбургта белем ала, 1964 елда Истанбул университетының әдәбият факультетындагы тарих бүлеген тәмамлый. Студент вакытта ук «Сөләймания», «Айя-Суфия» китапханәләрендә эшләүне хуп күрә. Шунда Караханыйлар дәүләте тарихы белән кызыксынып китә һәм фәндә каләм сыный.

Әлбәттә, Зәки Вәлиди гаиләсендә үсеп, фән юлын сайламау гаҗәп булыр иде! Исәнбикә ханым үзе дә фәнгә килү юлындагы иң беренче этәргеч – гаиләсе булуын ассызыклый. Гаять интеллектуаль мохиттә, әтисенең бай китапханәсендәге китаплар арасында үсү, шәрык тарихыннан әтисе сөйләгән берсеннән-берсе гүзәл мавыктыргыч хикәятләр, Вәлидиләрнең кунакчыл өендә өзелми торган мосафир бөек шәхесләр...




*Исәнбикә Туган. «Дала җәмгыятьләренең сыгылмалылыгы һәм чикләнгәнлеге: Кәрәит ханлыгы һәм Чыңгыз хан». 1998 ел.*




*Исәнбикә Туган, Гөлнара Кара, Җаһидә Байсал. «Борынгы Тан (Чиу Тан-шу) тарихы: Кытай чыганакларында төркиләр». 2006 ел.*

Әйтик, үзләрендә 6 ай яшәгән Муса Яруллаһ Бигине Зәки Вәлиди үзенең бөек укытучысы дип атый. Исәнбикә сүзләренчә, әтисе башка бер кешене дә укытучысы дип олыламаган! Яки Габделкадыйр Инан (Фәтхелкадыйр Мостафа улы Сөләйманов) – шулай ук Башкортстанда үсеп, Төркиядә шәркыятьче булып танылган олы галим. Исәнбикә ханым әйтүенчә, Әхмәтзәки белән Габделкадыйр фән мәйданында еш кына фикер төрлелегеннән бәрелешәләр, әмма бу аларга чын дуслар булып калырга комачауламый!


Математиканы яраткан, телләр өйрәнүгә сәләте һәм кызыксынуы көчле булган кызына әтисе һөнәр сайлауда ирек куя! «Нәрсә телисең – өйрән, тарихка соңрак әйләнеп кайтырсың», – ди ул.

Чыннан да, әдәбият факультетында уку – телне романнар аша өйрәнү – кешеләр холкын һәм хисләрен, вөҗдан шикелле асыл кыйммәтләрне, шәхесләрне һәм дәүләтләрне хәрәкәт иттергән бөек көчләрне аңларга ярдәм итә. Студент вакытта ук Исәнбикә, инглиз һәм алман телләреннән тыш, фарсы һәм рус, кытай телен үзләштерә, әмма фәндә үз юлын билгели алмый. Бәлки, төрки тарих белән тирәнтен шөгыльләнә башлаганда, әтисенең гаять югары галимлек абруе, Төркия гуманитар гыйлемнәре өлкәсендә киң кулланылыштагы хезмәтләре сукмагының башка булырга тиешлеген искәртеп torгандыр. Бәлки, әтисенең төркиләрнең чын тарихын ачыклау өчен кытай чыганакларын кайтару кирәк дип кабатлавы үз ролен үтәгәндер. Кинәт кенә кыз ул вакытта Кытай составындагы Тайбейга (Тайвань) китеп бара, биредәге милли университетта 1964 – 1966 елларда кытай телен камилләштерә, магистрлык диссертациясен яклый.

Әлеге адымны ясаганда, аны беренче булып әтисе хуплый: «Башка мәмләкәтләр, башка инсаннар хәятын күрү – яңа юллар, офыклар ача; башта шуларны күзәт, шуларны аңла», – ди ул үткен фикерле, якты карашлы кызына. Чыннан да, яңа юл ачыла, галимәнең: «Тайбейдан соң кытай-монгол тарихыннан аерылмадым», – дигән сүзләре шул хакта сөйли. Бу урында, алгарак китеп, тагын бер мисал китерергә мөмкин. Галимәнең әле генә инглиз телендә дөнья күргән ике зур язмасы – «Чыңгыз ханга кадәрге Монголия» *(Mongolia before Chinggis Khan. 2022)*, «Бик борынгы Монгол дәүләте» *(The Early Mongol State. 2022)* хезмәтләре икесе дә монголларның ерак тарихына багышланган.


Истанбул университетына укытырга кайтып, биредә докторлык диссертациясе әзерләргә керешә ул. Әмма белем, караш киңлеге җитмәгән кебек тоела: Гарвардка китеп, анда 1973 елны фәлсәфә докторы дәрәҗәсенә ирешә (1995 елдан – профессор). Биредә ул үзенең гыйльми күзаллауларына иң зур йогынты ясаган остазларын – Фрэнсис Крейзны һәм Джозеф Флэтчерны очрата. Бу йогынтыны ул – документларда кешеләр (инсаннар) язмышын күрергә өйрәтү дип билгели. Әлеге күзаллау аны төркиләр сәнгатен, икътисадын, дәүләтләр оешу тарихын, динне, ышану һәм борынгы күзаллауларны, әдәбият һәм фольклорны, архитектураны бербөтен итеп өйрәнүгә этәрә.

Фәндә бу ысулны «көнитеш тарихы» яки «тарихи антропология» дип йөртәләр. XX гасырның икенче яртысында Европа илләрендә (Франция, Алмания, Англия) мәйданга чыккан, Ф.Бродель, «Анналлар мәктәбе» (Ж.Ле. Гофф, Р.Шартье) вәкилләренең аерым хезмәтләре белән танылган бу методология бер халык, урын, дәүләт тарихын иҗтимагый, икътисади, географик, этнографик, социологик, хокукый һәм мәдәни яссылыклар үремтәсендә, көнкүреш киңлегендә, детальләрдә, сурәтләрдә тергезергә, реконструкцияләргә мөмкинлек бирә. Үз чиратында, билгеле бер тарихи чорның психологик атмосферасын, фикри-гакълый халәтен, кешеләрнең яки халыкларның менталитетын, шул вакытта хөкем сөргән кичерешләр-омтылышларны аңлау, тою, теге яки бу вакыйгаларның эчке сәбәпләрен билгеләү ягыннан мондый язу рәвешенә тиңнәр юк. Фәндә шушы нигез методологияне сайлап, И.Туган гомере буе шуңа тугрылыклы кала.




*«Худуд әл-галәм: Исәнбикә Туганга бүләк». 2011 ел.*

Гомер юлына күз салганда, иң беренче чиратта, ул – мөгаллим, укытучы. 1985–1992 елларда Исәнбикә Туган АКШ (Кембридж, Вашингтон, Бостон, Тафтс университетлары) һәм Әнкарадагы (Хаҗәттәпә, Урта Көнчыгыш техник университетлары) төрле уку йортларында Урта Азия, Урта Көнчыгыш, Кытай тарихыннан белем бирә. Бүгенге көнгә кадәр аның бу эштән аерылганы юк.





*Исәнбикә Туган. «Төркиядә Кытай турында уйланулар». 2013 ел.*

Үзе дә бер үк вакытта галим һәм укучы булудан гомер буе тукталмый. Гарвард университетындагы Джон Кинг Фэрбэнк исемендәге Кытай фәнни-тикшеренү үзәгендә һәм Урта Көнчыгыш фәнни-тикшеренү үзәгендә, Вашингтон университетының Ислам җәмгыятьләрен һәм цивилизацияләрен өйрәнү үзәгендә гыйльми хезмәткәр булып эшли. Бу елларда галимә Принстон университеты профессоры, Якын Көнчыгышны өйрәнү мәсьәләләре буенча зур белгеч Мартин Диксон, Калифорния университеты профессоры Франс Шульман (икесе дә З.Вәлидинең укучылары) белән хезмәттәшлек итә. Иран һәм Үзәк Азия мәдәнияте, Сефевиләр тарихы буенча зур белгеч Диксон да, Шульман да – тарихи антропология тарафдарлары; сәяси, мәдәни, икътисадый мөнәсәбәтләрне бергә карыйлар.

И.Туган ике ел (1980–1982) Суданда гыйльми эш белән шөгыльләнә. Судан аны яңа бер сукмакка – шәрык дөньясында хатыннар мәсьәләсен өйрәнүгә китерә.

10 телне камил белүе, шулай ук госманлы, чагатай, борынгы монгол, кытай язма телләрен үзләштерүе аңа гомере буе төрле илләрнең архивларындагы чыганаклар белән эшләргә мөмкинлек бирә. Текстолог буларак, ул үзе өчен фарсы һәм кытай телләрен белүнең гаять мөһим икәнлеген искәртергә ярата.




*Исәнбикә Туган. «Тарих һәм матур әдәбият». 2022 ел.*

Оештыручы-җитәкче булуы 1984 елда Урта Көнчыгыш техник университетында тарих бүлеген оештырганда ачык күренә.

1990 еллар – аның кытай архив документлары белән актив шөгыльләнә башлау дәвере. Галимә кытай чыганаклары ярдәмендә – төркиләр тарихын һәм тормышын, сугышларны һәм дәүләтләр төзелүне, ирләр һәм хатыннар, хөкемдарлар һәм халык фаҗигаләрен һәм ышануларын, үзе әйтмешли, «Азиянең олы мәдәниятен» ачыклый. Галимәнең бу хакта беренче басылып чыккан монографиясе инглиз телендә, «Дала җәмгыятьләренең сыгылмалылыгы һәм чикләнгәнлеге: Кәрәит ханлыгы һәм Чыңгыз хан» (Flexibility and limitation in steppe formations: the Kerait Khanate and Chinggis Khan / *by Isenbike Togan.1998*) дип атала. Галимә китапта монголларның кытайлар белән чиктәш яшәгән күчмән дәүләте, андагы тормыш-көнкүреш, Тогрул ханны Тимучинның алмаштыруы турында «көнитеш тарихы» мәйданыннан торып сөйли.

Гомумән, фән дөньясында Исәнбикә Туганның төп фәнни хезмәтләре Урта Азия, Монголия һәм Кытайда яшәгән төрки халыклар тарихына, Урта гасырларда ыруара һәм дәүләти мөнәсәбәтләргә, Бөек Ефәк юлындагы халыкларның сәүдә, мәдәниятара бәйләнешләренә карый дип санала. Шунысы кызык: Исәнбикә ханым әтисе шөгыльләнгән теманы – Шәркый Төркестан белән бәйле мәсьәләләрне дә читкә куймый. 1990 елларда аның Эчке Азия кануннарының Госманлы җирендә ничек кулланылуы, яки Шәркый Төркестанда ислам дине, Олугбәк заманында шәригать һәм дин кануннары буенча бәхәсләргә багышланган бер төркем фәнни хезмәтләр яза. 1991 елны инглиз телендә дөнья күргән «Эчке Азия кануннары күзлегеннән Госманлы тарихы» *(Ottoman history by inner Asian norms)* дигән хезмәтендә галимә борынгы төрек империясенең үткән хәятын шәрык мөселман илләре тормышы белән чагыштырып, уртак һәм аермалы якларны билгели. 1996 елны ул тикшеренү объекты итеп Үзәк Азиядәге үзгәрешләрне сайлый: «Үзәк Азия һәм аның чик буйларында яңа геосәясәт» *(The New Geopolitics of Central Asia and Its Borderlands)*. Аның ЮНЕСКО каршындагы Күчмәннәр цивилизацияләрен өйрәнүче Халыкара институтның (Монголия) һәм Үзәк Азия халыкара институтының (Үзбәкстан) киңәшчеләр берлегенә сайлануын бу юнәлештә зур белгеч икәнлеген һәм гыйльми уңышларын тану дип бәяләргә кирәк.

XX-XXI гасырлар чигендә ул монгол яулары дәверендә төрки халыклар тарихы белән шөгыльләнүен дәвам итә. Бөек Ефәк юлында дини, мәдәни, фәнни (космологик) фикерләр алмашу турында кызыклы хезмәтләр яза. Бу елларда галимә Урта гасырларны өйрәнү фәнендә методология мәсьәләләренә дә кагыла. Әмма иң зур хезмәте – 2006 елны Әнкарада басылып чыккан «Борынгы Тан (Чиу Тан-шу) тарихы: Кытай чыганакларында төркиләр» (Гөлнара Кара һәм Җаһидә Байсал белән хезмәттәшлектә) *(Çin Kaynaklarında Türkler: Eski Tang Tarihi (Chiu T'ang-shu). / İsenbike TOGAN, Gülnar KARA, Cahide BAYSAL. 2006)*. Анда төркиләр тарихына караган Кытай архивларындагы чыганак-материаллар туплап бирелгән.

Архив чыганаклары белән янәшә, галимә төрки күчмәннәр тормышындагы төрле мәсьәләләргә кагылышлы фәнни мәкаләләр бастырып килә. Мисалга, 2015 елны ул инглиз телендә «Күчмәннәрдә иҗтимагый-сәяси терминология. Кытайда Тан дәверендә Булуо терминының кулланылышын күзәтү» *(The Use of Sociopolitical Terminology for Nomads An Excursion into the Term Buluo in Tang China)* дигән тема белән чыгыш ясый. 2017 елны ясак җыю тәртибенә багышланган язмасы да *(Tribute and Tribute Missions Revisited)* галимнәр арасында зур кызыксыну уята.

Галимә кытай тарихы белән бүгенге төрек һәм төрки мәдәниятләр арасында охшашлыкларны (образлар, темалар, сюжетлар, символлар...) эзли. Әйтик, Күлтәгин язмалары бүгенге Анадолу культурасында сакланганмы? Ерак үткән белән бүгенге арасында күпер шул рәвешле корыла. И.Туган 2008 елда Госманлы империясе тарихы буенча эзләнүләрен дөньяга чыгара. Бу юлда ул үзенең остазы дип Гарвард

университетының мәшһүр профессоры, безнең эраның мең еллыгына кадәр Иран һәм Үзәк Азия тарихы һәм мәдәнияте белгече Ричард Нельсон Фрайны саный. 2011 елга тиклем төрек телендә язылган мәкаләләрен туплап, галимә 2022 елны «Тарих һәм матур әдәбият» *(Tarih ve Kurgu)* дигән җыентык та нәшер итә.

2013 елда галимә «Төркиядә Кытай турында уйланулар» исеме белән (Сәлчук Исенбел, Алтай Атлы белән хезмәттәшлектә) монография нәшер итә *(Türkiye'de Çin'i Düşünmek. / Selçuk ESENBEL, İsenbike TOGAN, Altay ATLI. 2013)*. Монда инде ике олы борынгы җәмгыятьләрнең тарихына тулы килеш, бербөтен барыш итеп реконструкция ясала, тарихи фактларны аңлату юлы белән – төркиләр һәм кытайлар, утрак һәм күчмән тормышлар, дәүләтләр төзелеше-тәртибе һәм мәдәни аң тергезелә.

Яңа унъеллык галимәне яңа сукмакка юнәлтә: 2018 елдан ул борынгы госманлы теле буенча семинарлар башлап җибәрә. Бер үк вакытта Стивен Хамфрисның Көньяк-Көнбатыш Азия һәм Төньяк Америка буенча хезмәтләре аңа историография белән шөгыльләнүгә илһам бирә. И.Туган төркият фәненең историографиясен өч тармакка бүлеп эшли: Тарикатьләр тарихы; Хатыннар роле турындагы хезмәтләр; Кабиләләр тарихы.

Бу елларда ул, үз гаиләсенең узганы белән якыннан кызыксынып, әтисенең тарихчылыгын аңлаткан хезмәтләр яза. Бер үк вакытта бик күп укучыларына да яңа сукмаклар салырга ярдәм итә. Шуңа күрә XX гасыр ахыры, XXI гасыр башы дәверен ул «укучылы елларым» дип атый. Аның җитәкчелегендә әзерләнгән диссертацияләр арасында Шәйбани хан һәм үзбәк сәяси берләшмәләре (1500-1510) төзелүгә багышланган *(Nurten KILIÇ, 1999)*, XIII-XVI гасырларда Үзәк Азия һәм Анадолуда хатын-кыз һәм ир-ат статусына караганы да *(Nilgün DALKESEN, 2007)*, Алаш-Урда хәркәте турындагысы да *(Yunus Emre GÜRBÜZ, 2007)* бар. Алар Исәнбикә ханымның төрки халыкларның урта гасырлар тарихын өйрәнә торган фәнни мәктәп булдыруы турында сөйлиләр. Шулай ук укучыларының суфичылык карашларын һәм әдәбиятын *(Elif BİLGİN, 1996)*, XI-XVI гасырларда Анадолуда мәдрәсәләр оешу һәм аларның архитектурасы *(Mehmet SAĞLAM, 2000*), Госманлы дәүләте һәм Идел-Урал буендагы дәүләтләрдә зыялыларның яшәеше *(Selim KARAHASANOĞLU, 2004)*, Монгол, фарсы һәм кытай чыганакларында Чыңгыз хан образы *(Burcu KARAARSLAN, 2022)*, казакъ, үзбәк милли үзаңы формалашу мәсьәләләре һ.б. темалар булу галимәнең фәнни офыклары гаять киң булуын дәлилли. Укучылары, хезмәттәшләре аның 70 яшьлек юбилеена багышлап 2011 елда чыгарган «Худуд әл-галәм: Исәнбикә Туганга бүләк» *(Hudûdü'l-Âlem: İsenbike Togan'a Armağan)*) китабы да шуңа бер дәлил булып килә.

Бүген әнисе белән иңгә-иң торып, кызы Сара да тарих һәм этнография өлкәсендә эшли, Англиядә университетта укыта. Димәк, фәнни дәвамчанлык өзелмәгән!

Шул ук сүзне Зәки Вәлидинең улы, Исәнбикәнең энесе Сүбидәйгә карата да кабатларга мөмкин. Ул һөнәр итеп икътисад өлкәсен сайлаган була. Философия докторы (1972), профессор (1986), Әнкараның Билкәнт университетында укыта, Халыкара икътисад һәм идарә итү үзәгенең директоры. Әмма ул да әтисе кызыксынган темаларны читкә куймый. Мәсәлән, 2015 елны Н.Ш. Нәфыйков инглиз теленнән тәрҗемә итеп аның «Бөек Ефәк юлы: үткәне һәм хәзергесе» дигән язмасын Татарстан укучысына да ирештерде. Аның кызы Амра, улы Аслы, оныгы Дениз да яңа дөньялар ачарлар әле!

Исәнбикә Туган турындагы бу язма – аны танытуда беренче адым, хезмәтләренең безгә килеп ирешүенә этәргеч булыр дип ышанам. Чөнки гыйлем дөньясы – уртак мәйдан, анда бергәләп хәрәкәт иткәндә генә уңышка ирешергә мөмкин. Галимә үзе дә фән юлын болай дип бәяли: «Гыйлемне гаиләдә өйрәндем; китаплардан өйрәндем; фикерле олылардан өйрәндем. Фән ялгыз эшләнми, хәятта башкарыла...»

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
**Алп ДЕМИРКАЯ**

*Түбән Кама шәһәрендә 50 елдан артык бай тарихы булган «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе эшләп килә. Әдәби берләшмә танылган язучылар Разил Вәлиев, Фәннүр Сафин, Әхмәт Гадел, Зөлфәт Хәким, Эдуард Мостафиннарның иҗади бишеге булып торды. Шулай ук Фәтхулла Абдуллин, Мизхәт Хәбибуллин, Мөхәммәт Шәйхи, Мөслах Таҗи, Рифкать Имаев кебек язучыларыбыз да беренче адымнарын «Кама таңнары» әдәби берләшмәсеннән башладылар. Үткән 50 ел эчендә әдәби берләшмәдә 200 дән артык автор каләм тибрәткән, 24 авторыбыз Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, журналистлар тагын да күбрәк. Түбән Кама әдәби берләшмәсе шагыйрьләре үзләренең әдәби альманахын чыгару бәхетенә ирештеләр һәм ул традиция бүген дә дәвам итә. Әдәби берләшмә әгъзалары шигырьләр, хикәяләр язу белән генә чикләнмиләр, мәктәпләрдә, көллиятләрдә, югары уку йортларында укучылар, студентлар белән очрашулар, әдәби музыкаль кичәләр үткәрәләр. Мәгариф, мәдәният идарәләре, китапханәчеләр, балалар бакчалары тәрбиячеләре белән берлектә «Хәтер сагында», «Әдәбият корабы», «Мәрхәмәтлелек», «Серле каләм» проекты кысаларында киләчәк буында телебезгә мәхәббәт тәрбиялиләр. Телебезне, милләтебезне киләчәккә илтү өчен әдәбият өлкәсендә яшь талантларны барлау, аларга беренче адымнарын ясарга ярдәм итү дә безнең бурычыбыз булып тора.*

**Рәсимә НӘБИУЛЛИНА,**
*«Кама таңнары» әдәби берләшмәсе җитәкчесе*

## Яраттым

Зәңгәр күкне ялгыз иңләгәндә,
Сыкраса да сынган канатым,
Каршы барып искән салкын җилгә,
Мин тормышны өзелеп яраттым.

Кара төннәр үтмәс кебек иде,
Алсу таңнар көтеп зар аттым.
Сыгылмадым көчле давылларга,
Мин яшәүне артык яраттым.

Гөлләремне кырау суккан чакта,
Мин язларны күбрәк яраттым.
Бу тормыштан инде ваз кичкәндә,
Яраларны бәйләр пар таптым.

Сарылганда җанга ялган, гайбәт,
Көлүләрем белән тараттым.
Якын дуслар мине саткан чакта,
Дошманнарны күбрәк яраттым.

Упкын кырыенда әнкәм теле,
Илем, денем диеп җан атам.
Бар халыклар җирдә тату яшик,
Мин, кешеләр, сезне яратам.

**Рәсимә НӘБИУЛЛИНА**

## Силәле бишек

Үзәкләрем өзелә гел
Моңлы җыр ишеткәндә.
Мин дә тибрәлгән бер бала
Силәле бишекләрдә.

Әнкәй көйләре, күрәсең,
Сеңеп калган күңелгә.
Бишек җырлары колакта
Чыңлый кебек бүген дә.

Барыгыз да шундыймы соң,
Мин генә микән тиле?
Давыл булып дулый кайчак
Җанда сагыну җиле.

Яланаяк мин дә чаптым
Авылым урамында.
Тик хәзер адашып йөрим
Уйларым урманында.

Күңелләрем урап кайта
Туган як болыннарын.
Назлы җилләре шаярып
Тарата толымнарым.

Ә хисләрем, рәшә булып,
Йөгерә миннән алдан.
Үткәрергә бу халәтне
Сабырлык алыйм кайдан?

Нигә якын бу туган як?
Бардыр ул берәр сере.
Туган җирләреннән киткән
Мин бит меңнәрнең бере.

Уйлар ташкыны җирсетеп
Уята һаман таңда.
Силәле бишек көйләрен
Кузгатып минем җанда.

**Фәнүзә САБИРОВА**

## Безнең күңел

Безнең күңел нигә моңлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән?
Ни буласын алдан сизенә,
Урын тапмый кайчак үзенә.

Безнең күңел нигә җырлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән?
Сүтелә дә йомгак, үрелә,
Алып кайта хәтер иленә.

Безнең күңел нигә җырлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән?
Тартыла да чыңлап өзелә,
Өмет чаткылары сүрелә.

Безнең күңел нигә нечкә икән,
Безнең күңел назлы, иркә микән?
Күзләрен язларга төренә,
Сагыну-сагышларга күмелә.

Безнең күңел нигә моңлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән?
Сөю канатында яшәтә,
Күпме сине күтеп яшәп тә.

**Рушания ГАББАСОВА**

## Шулдыр бәхет...

Шулдыр бәхет – алтын көзгә без керәбез,
Җиһанның бар матурлыгын без күрәбез.
Яз кайтыгыз, туган яктан киткән кошлар,
Каршыларбыз, әле без бар, әле без бар.

Шулдыр бәхет – алда күтәр көнебез бар,
Кеше иткән иманыбыз, телебез бар.
Дөнья күрер өчен күңел күзебез бар,
Без яшибез, әле без бар, әле без бар.

Шулдыр бәхет – оныкларны без сөябез,
Ата-баба каберенә баш иябез.
Анлык кына чамабыз бар, хәлебез бар,
Бу дөньяда әле без бар, әле без бар.

Шулдыр бәхет – безнең зиһен чуалмаган,
Шулдыр бәхет, әле хәтер югалмаган.
Җырыбыз бар, күпме әйтер сүзебез бар,
Әле без бар, әле без бар, әле без бар.

**Никифор ТУКМАЧЁВ**

## Онытмагыз сугыш ятимнәрен

Сугыштан соң үтте күпме еллар.
Ә яралар сызлый һаман да.
Кем аңлар соң сугыш ятимнәрен,
Яшибез соң кайсы заманда?

Туганбызмы әллә без вакытсыз,
Таңнарында канлы елларның?
Баласы без, Ватаным дип, утлы
Яуга кергән солдат улларның.

Әти сүзен әйтәлмыйча үскән
Без бәхетсез буын булдыкмы?
Иңебезгә сагыш йөген салып
Яшәр өчен җиргә тудыкмы?

Җавап эзлим, ләкин таба алмыйм,
Без нишләп соң читкә кагылган?
Кияр-кимәс, туяр-туймас ашап
Үскәнгәме сабый чагыннан?

Әнкәйләрнең горурлыгы булдык,
Илгә хезмәт иттек һәрчакта.
Яшен булып яшьнәп яшәдек без,
Егылмадык, арып талсак та.

Җанда сүнми, яна өмет уты,
Ерагайса да еллар арасы.
Без калырбыз мәңге тарихларда
Булып һәрчак солдат баласы.

**Гөлчирә ИБӘТУЛЛИНА**

## Саубуллашу

Саубуллашу көен эзли җилләр,
Сак кагылып тоҗым-кылларга.
Яшел уҗым калтыранып куя,
Төренәсе килеп юрганга.

Кайтып киләм таныш сукмаклардан,
Сагынам дию генә аз булыр...
...Аяз күктә сәйлән чылбырыдай
Өзелеп үтте киек каз юлы.

Нигә болай күңелемне айкый,
Нигә теләә казлар тавышы?..
Әллә җанга уелганга микән
Яшәлмәгән еллар сагышы?!

**Асия САФИНА**

## Кышкы авыл иртәсе

Туган авыл. Салкын. Кышкы иртә.
Кояш күтәрелә соң гына.
Кыш кышларга калган кошчык, туңып,
Оясында утыра тын гына.

Карлар мулдан булган, ахрысы,
Капка читләренә өйгәннәр.
Мин язармын, менә рәсем итеп
Төшерсәләр икән бүтәннәр.

Ап-ак җиһан, ак-ак юлдан атлыйм,
Әй яратам кышның шул мәлен!

Иңнәреңә алып япсаң иде
Агачларның мамык ак шәлен.

Яр буйлары тигезләнеп беткән
Чана-чаңгы шуып, күрәсең.
Соңрак кабат бер үтәрмен әле,
Ул халәтне килә күрәсем.

Зәңгәр күктә йөзә ак болытлар,
Һәммәсе дә, гүя, танышым.
Шул корабка ут(ы)рып хыялымда
Балачакка кайтып барышым.

**Мөнҗия ХӘЛИМОВА**

## Хәтер юлы

Ерак юлны якын итеп һәр ел
Сәфәр кылам төньяк башкалага.
Бу сугышта һәлак булганнарны
Миндәй искә ала башкалар да.

Вагон тәрәзеннән карап барам
Юл буенда ауган агачларга.
Охшаш алар шушы сазлыкларда
Хәбәрсез югалган солдатларга.

Мәңге яшел чыршы-наратлары,
Шаһитлары сугыш елларының.
Барлык серен чишми әле алар:
Монда нинди мәхшәр булганлыгын.

Көмештәй саф Волхов сулары да
Шифа бирми күңел ярасына.
Хәтәрлеген канлы сугышларның
Хәтерләтә Любань каласы да.

Мәрҗән булып солдат каберләре
Тезелгәннәр Ватан киңлегендә.
Ленинград бoжрасында гына
Санала ул бик күп меңнәр белән.

Каменкада хәрбиләр зираты.
Күп татарның монда соңгы юлы.
Илен саклап башын салган батыр
Исән яшәсен дип кызы, улы.
Каберләрдә яткан батырларга
Дәвам итсен һәрчак хәтер юлы.

**Нурулла ГАПТУЛЛИН**

## Мәхәббәт һәм табигать

Җептәй сузган кояш нурын җиргә,
Күккә кунып сайрый тургаем.
Зәңгәр күлнең бәллүр көзгесенә
Алыштырмас яшьлек тугаен.

Керфек очларыңнан сөю тама,
Шыткан чәчкә сыман күңелең.
Моң дулкыны тия ярларына
Биләп алган бәхет күгенең.

Киптерми лә сөю тамырларын
Чык тамчысы иңгән су булып.
Мәхәббәтем олы табигатьтә
Чишмә сыман агар моң булып.

**Гөлшат СОЛТАНГУЛОВА**

*Камил Мотыйгыйның тууына – 140 ел*

# ИРЕК ХИСЛӘРЕ ҖЫРЧЫСЫ



XX йөзнең беренче яртысында татар халкының иҗтимагый һәм мәдәни тормышында үзенчәлекле эз калдырган, татарча беренче басма газета һәм журналларның нашире-мөхәррире, популяр җырчы-артист Камил Мотыйгыйның (1883–1941) тууына – 140 ел.

Татарстан радиосы архивында әдипкә кагылышлы берничә язма саклана. Соңгысы – 2021 елга карый. Күренекле артистыбыз һәм язучы Хәлим Җәләй гомеренең соңгы көннәрендә студиягә килеп, Нияз Акмалның «Камил Мотыйгый» исемле поэмасын укып яздырды. Режиссёр Рамил Һидиятулла аны моноспектакль итеп эшләде. Бу язмада шагыйрьнең Камил Мотыйгыйга кагылышлы гаҗәеп кызыклы фикерләре белән беррәттән, мәрхүм Хәлим Җәләйнең тавышы-төсе дә саклана.

Журнал укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган аудиоязма исә Камил Мотыйгыйны җырчы буларак ача. Моннан беркадәр элек танылган журналист Раил Садри тарих фәннәре кандидаты Лилия Габдрафикова белән XX гасыр башы татар музыкасы тарихына бәйле тапшыру әзерләгән иде. Аның шактый өлеше нәкъ менә Камил Мотыйгый иҗатына багышлана.

Узган гасыр башында граммофон дигән могҗиза безнең халыкка да килеп җитә. Кемнәргәдер патефон тәлинкәләре сатып, акча эшләү мөмкинлеге ачыла. Франциянең «Пате» тавыш яздыру фирмасы Россиядә үзенең филиалын булдыра һәм анда эшләүче елгыр егетләр пластинкалар әзерләп сату белән шөгыльләнә башлыйлар. Әлбәттә, җыр-моңга хирыс татар халкы да аларның игътибарыннан читтә калмый. 1904–1912 елларда әлеге фирма тарафыннан дистәләгән татар җырчыларының чыгышлары язып алына. Язмаларның төп нөсхәләре хәзерге вакытта Франция Милли китапханәсендә саклана, һәм аларны китапханәнең сайтына кереп тыңлап була. Камил Мотыйгыйның җырлары да тапшыру өчен нәкъ менә шушы сайттан күчереп алынды.

Әлбәттә, без Камил Мотыйгыйны Коръәнне иң югары камиллектә укучы дин эшлеклесе, язучы, педагог, Габдулла Тукай әсәрләрен пропагандалаучы, «Фикер» газетасы, «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» журналларының нашире буларак та беләбез.

Татар кешесе өчен профессиональ җырчы сыйфатында сәхнәгә менү бик җиңел генә бирелмәгән, билгеле. Баштарак Мотыйгый таныш-белешләре оештырган хосусый җыеннарда, әдәбият-музыка кичәләрендә генә чыгышлар ясый. Аның түләүле беренче рәсми концерты 1909 елның 16 июлендә Сембер шәһәрендәге приказчиклар клубында уза. Репертуарында – татар халык җырлары, Тукай шигырьләренә җырлана торган көйләр, үзенең импровизацияләре h.б. инкыйлабкача сигез ел эчендә Камил Мотыйгый Россиянең татарлар яши торган бөтен төбәкләрен йөреп чыга диярлек. Матбугатта аның концертлары турында хәбәрләр, рецензияләр басыла, аерым бәяләмәләрдә «моңнар патшасы», «татар Шаляпины» кебек чагыштырулар да яңгырый.

Камил Мотыйгый, замандашлары Фәттах Латыйпов, Фатима Мохтарова белән беррәттән, беренче профессиональ башкаручылар буларак, татар музыка сәнгате тарихында, һичшиксез, тәкъдир ителергә хаклы. Чөнки алар – беренчеләр, татар эстрада сәнгатенә тәү башлап юл ячучылар.

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп,*
*тапшыруны тыңлый аласыз.*

# КАҺАРМАННАРНЫ КҮТӘРГӘН ЭЗТАБАР



Язучы, журналист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Шаһинур Мостафинның (1948–2020) тууына – 75 ел. Ул әдәбият сөючеләргә шагыйрь, публицист, документаль проза өлкәсендә эшләүче каләм иясе буларак таныш. Һәм, әлбәттә инде, Шаһинур Мостафин турында сүз чыкканда, аның каһарман милләттәшләребезнең исемнәрен халыкка кайтару, мәңгеләштерү юлында алып барган фидакарь хезмәте күз алдына килеп баса. Тыңлаучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителә торган аудиоязмада әдипнең нәкъ әнә шул юнәлештәге эшчәнлеге турында сүз бара.

Ул үзенең остазлары Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин, Самат Шакир, Шамил Рәкыйпов юнәлеш биргән үтә авыр, әмма бик тә игелекле, изге шөгыльне уңышлы төстә дәвам иттерде. Ш.Мостафин җитәкчелегендәге «Хәтер яктысы» экспедициясе әгъзалары хәрби архивларда кат-кат эшләп, Балтыйк буе һәм Кавказ республикаларында, Волгоград, Донецк, Кировоград, Орёл, Ленинград, Львов, Мәскәү, Псков өлкәләрендә, Карелиядә һәм Германиядә булып, Бөек Ватан сугышының моңарчы билгесез булган батырлары турында бай мәгълүматлар туплап кайттылар. 2000 елда, Бөек Җиңүнең 55 еллыгы уңаеннан, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән «Батырлар китабы» — «Книга Героев»ның баш консультанты, кереш сүз авторы һәм мөхәррире дә булды Шаһинур Мостафин. Җиңүнең 60 еллыгын исә ул «Хәтер яктысы» (2004) дигән документаль-публицистик язмалар китабы белән каршылый – әлеге энциклопедик басмада Бөек Ватан сугышының моңарчы «хәбәрсез югалды» дип саналган яисә аз билгеле булган каһарманнары турында тәфсилләп сөйләнелә.

Әйе, без үз халкыбыз белән горурланырга, башкалар алдында үз халкыбызны олыларга кирәк чакларда һәрвакыт батыр милләттәшләребезнең исемнәрен атыйбыз. Шулар ярдәмендә үзебезнең кем булуыбызны, кемнәр нәселеннән икәнебезне күрсәтәбез. Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Александр Матросов, Пётр Гаврилов, Газинур Гафиятуллин һәм тагын йөзләгән, меңләгән каһарман милләттәшләребез – безнең горурлыгыбыз. Ләкин батырларның исемнәрен байрак итеп күтәрү өчен әле синең үзеңнән дә батырлык таләп ителә. Әйтик, ничәмә ничә еллар дәвамында Рейхстаг гөмбәзенә беренче булып Җиңү байрагы кадаган татар кешесе Гази Заһитов турындагы дөреслек әллә ничә кат йозаклар белән бикләп куелган иде. Әнә шундый каршылыкларга, киртәләргә карамастан, Гази Заһитовның батырлыгын дөньяга тарату өчен чын мәгънәсендә көрәш алып баручы шәхесләребез булды. Шуларның берсе эзтабар язучы Шаһинур Мостафин иде. Ул бу хакта күп тапкырлар республика һәм Россия матбугатында язып чыкты, радио, телевидение аша чыгышлар ясады. Әнә шундый чыгышларының берсен хәзер сезгә кабатлап тыңлатасыбыз килә. Ул 2019 елның 9 Май көнендә беренче тапкыр эфирга чыкты.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

## ҖАНИСӘП

Росстат җанисәп нәтиҗәләрен игълан итте. Саннардан күренгәнчә, Россиядә татарлар 596 980 кешегә кимегән. 2010 елгы җанисәптә 5310649 кеше милләтен татар дип күрсәткән булса, 2020 елгысында (пандемия сәбәпле 2021 елда үткәрелде) – 4713669. Татарлар саны кимү сәбәбен халык санын алуның ковид зәхмәте котырган чорга туры килүе, милләттәшләребезнең бер өлешенең җанисәптә катнаша алмавы, теркәүчеләрнең һәр кешегә барып җитү мөмкинлеге булмавы, Россиядә 16,6 миллион кешенең милләтен күрсәтмәве белән аңлаталар. Россиядә татарлар санының 5,5 миллионнан да ким булмавы турында фараз бар.

## «ТАТМЕДИА» ХИСАП ТОТТЫ

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «ТАТМЕДИА» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының коллегия утырышы булып узды. Узган елгы эшләргә хисап белән агентлык җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев чыкты. 2022 елның эш нәтиҗәләре куанычлы. Редакцияләрнең көн саен чыгара торган яңалыкларның уртача саны – 3 мең тирәсе. Республиканың әйдәп бара торган массакүләм мәгълүмат чаралары социаль челтәрләрендә язылучыларның гомуми саны – 7,5 миллион. Бу 2021 елгы күрсәткеч белән чагыштырганда, 25 процентка күбрәк. Утырышта «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директоры, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов, Россия китап чыгаручылар ассоциациясе президенты Константин Чеченев, «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире Радик Сабиров, Чаллы шәһәре мэриясенең пресс-сәркатибе Римма Мөхәммәтҗанова һ.б. чыгыш ясады. Чарада Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров катнашты, узган елгы эшкә бәя бирде һәм киләчәккә бурычлар куйды. Утырышта бер төркем журналистларга, хезмәткәрләргә дәүләт һәм хөкүмәт бүләкләре тапшырылды. Редакциябезнең журналны битләргә салучы дизайнеры Элеонора Җамалиева ТР Министрлар Кабинетының Рәхмәт хатына лаек булды. Котлыйбыз!

## ОЧРАШУЛАР

Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев җитәкчелегендәге делегация – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасары, берлекнең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, язучы, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рафис Корбан, Идел буе федераль округының милли оешмалар җитәкчеләре Удмуртия Республикасының Ижау шәһәренә барып кайттылар. Алар Г.Тукай исемендәге 6 нчы гимназиядә, Х.Фәезханов исемендәге лицейда, М.Җәлил исемендәге китапханәдә булдылар, укучылар, укытучылар, китап сөючеләр, Удмуртиядә яшәп иҗат итүче татар язучылары белән очраштылар.

* * *

Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев эш сәфәре белән Рязань өлкәсендә булды. Аның белән бергә Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, язучы Хәбир Ибраһим да бардылар. Алар Касыйм шәһәрендә Казан ханбикәсе Сөембикә һәйкәленә чәчәкләр салды, татар җәмәгатьчелеге белән очрашты, XV гасыр архитектура истәлеге – Хан мәчетендә булды.

* * *

Уфада Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Башкортстан Республикасында яшәп иҗат итүче татар язучылары белән очрашты. Әлеге чара татар һәм башкорт әдәбиятлары классигы Мәҗит Гафури һәйкәленә чәчәкләр салу белән башланып китте. Очрашуда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Марс Тукаев, Татарстан Республикасының Башкортстан Республикасындагы даими вәкиле Йосыф Якубов, Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстан Республикасындагы вәкиле Альфред Дәүләтшин, язучылар Факил Сафин, Рафис Корбан, Булат Ибраһимов катнашты.

## КИТАПНЫҢ ГЕРОЕ – ИСӘНБӘТ

Тинчурин театрында «Җыен» фондының «Шәхесләребез» сериясеннән татар әдәбияты классигы, Татарстанның халык язучысы,

драматург, шагыйрь, тел-әдәбият галиме, фольклорчы Нәкый Исәнбәткә багышлап чыгарылган китабын (төзүчесе – Миләүшә Хәбетдинова) тәкъдим итү булды. Анда Татарстанның халык шагыйрьләре Разил Вәлиев, Рәдиф Гаташ, язучы Рафис Корбан, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Әзһәр Шакиров, галимнәр Марсель Бакиров, Әлфәт Закирҗанов, Илнур Миргалиев, Фәнзилә Җәүһәрова, ТР Дәүләт Советы депутаты Рамил Төхфәтуллин, Тинчурин театры директоры Фәнис Мөсәгыйтов, баш режиссёры Туфан Имаметдинов һ.б. чыгыш ясадылар. Китап бәйрәмендә Йолдыз Исәнбәтнең «Татар-информ»ның баш мөхәррире Рәмис Латыйповка биргән соңгы интервьюсыннан өзек тәкъдим ителде, Н.Исәнбәтнең шигырьләре, әсәрләреннән өзекләр яңгырады. Тинчурин театрының камера оркестры чыгышы да бәйрәмгә ямь өстәде. Чараны Тинчурин театры артисты Резеда Сәлахова алып барды.

## МУЗЕЙ-САЛОН АЧЫЛДЫ

Балык Бистәсе районы Балтач (Юлсубино) авылындагы Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин исемендәге мәктәп кунаклар кабул итте. Монда Равил Фәйзуллинның музей-салоны ачылды. Заманча эшләнгән бу музейда язучының эш өстәле, язу машинкасы, култамгалы китаплары, фоторәсемнәр, документлар, көндәлекләре, тәүге шигъри юллары урын алган. Бер стенд Балык Бистәсеннән чыккан әдәбият-сәнгать әһелләренә багышланган.

Музей-салон ачу тантанасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, ТР Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкарма директоры Нурия Һашимова, Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, Балык Бистәсе районы башлыгы Радик Ислямов, Татарстан мөфтиятенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Айгиз Баймөхәммәтов, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев, галим Харис Мусин һ.б. чыгыш ясады.

## ЮБИЛЕЙЛАР

Язучы, әдәби тәнкыйтьче, мөхәррир, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Җамал Вәлиди исемендәге әдәби премия лауреаты Мансур Вәли-Барҗылыга (Мансур Вәлиев) 75 яшь тулды. Татарстан Язучылар берлегендә аны олуг юбилее белән котладылар. Тәбрикләү сүзләрен ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкарма директоры Нурия Һашимова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасарлары Илсөяр Иксанова, Рифат Җамал, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат һ.б. каләмдәшләре ирештерделәр.

***

Казандагы Муса Җәлил музей-фатирында язучы-эзтабар, шагыйрь, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Шаһинур Мостафинның тууына 75 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булды.

Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, язучының туганнары, якташлары, иҗатташ дуслары катнашты.

## ШӘЙХИ МАННУР ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Тууына 118 ел тулу уңаеннан Мамадыш районында Шәйхи Маннур премияләрен тапшырдылар. Быел бу бүләккә «Кирмән нигезе» китабы өчен Фәнил Гыйләҗев белән «Җиремнең чәчәкләре» романы өчен Гыйлемхан Дәүләтшин лаек булды. Әлеге чара шәһәр үзәгендәге Ш.Маннур бюстына чәчәкләр салу белән башланды. Лауреатларга бүләкләрне Мамадыш Үзәк китапханәсендә район башлыгы Анатолий Иванов тапшырды. Әлеге чарада Татарстанның халык шагыйре, Ш.Маннурның мирас комиссиясе рәисе Зиннур Мансуров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасарлары Рифат Җамал, Факил Сафин, язучы Ринат Мөхәммәдиев, җирле каләм әһелләре катнашты. Алар шулай ук Олыяз лицее укучылары белән очрашты, Толбай авылында Ш.Маннурның каберен зиярәт кылды, әдипнең үзе төзеткән китапханәдәге музеенда булды.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Ф.ГИМАЛТДИНОВА «Хан Орды Узбек»,
рассказ Р.ШАФИГУЛЛИНА «Даёшь, Галимулла!»; поэма А.ГАЯЗОВА;
стихи Р.АЙМЕТА, В.ФАТИХОВА.
«Драматургия»: драма И.ЗАЙНИЕВА «Вишнёвая гора».
«Литература родственных народов»: стихи И.УЗДЕНОВОЙ в переводе Р.КУРБАНА.
«Юбилеи»: статья А.СУЛЕЙМАНОВА, посвящённая 95-летию А.Атнабаева.
«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ, А.ДЕМИРКАЯ.
«Литературные объединения»: стихи Р.НАБИУЛЛИНОЙ, Ф.САБИРОВОЙ,
Р.ГАББАСОВА, Н.ТУКМАЧЁВА, Г.ИБАТУЛИНОЙ, А.САФИНОЙ, М.ХАЛИМОВОЙ,
Н.ГАПТУЛЛИНА, Г.СУЛТАНГУЛОВОЙ.
«Бесценные голоса»: статья к 140-летию К.Мутыги и статья к 75-летию
Ш.Мустафина. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Тайницкая башня Казанского Кремля. Фото И.АБРАМОВОЙ;
писательница Алина Хабибуллина.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by F.GIMALTDINOV «Khan Uzbek of the Horde», story by
R.SHAFIGULLIN «Give it, Galimulla!»; poems by R.AYMET, V.FATIKHOV; poem by
A.GAYAZOV.
«Dramaturgy»: drama by I.ZAINIEV «Cherry Mountain».
«Literature of Kindred Peoples»: poems by I.UZDENOVA, translated by R.KURBAN.
«Anniversaries»: article by A.SULEIMANOV dedicated to the 95th anniversary of A.Atnabaev.
«Science»: article by D.ZAGIDULLINA, ALP.DEMIRKAYA.
«Literary Associations»: poems by R.NABIULLINA, F.SABIROVA, R.GABBASOV,
N.TUKMACHEV, G.IBATULINA, A.SAFINA, M.KHALIMOVA, N.GAPTULLIN,
G.SULTANGULOVA.
«Priceless Voices»: article on the 140th anniversary of K.Mutigi and an article on the 75th
anniversary of Sh.Mustafin. The rubric is led by N.AKMAL.
From the archive of the magazine.
Diary of social and cultural life.
On our covers: Tainitskaya Tower of the Kazan Kremlin. Photo by I.Abramova;
writer Alina Khabibullina.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан Кремленең Нур-Али манарасы.
*И.Абрамова фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* яшь язучыларның «Иделем акчарлагы» бәйгесенең
Гран-при иясе, Шәриф Камал исемендәге әдәби премия лауреаты
Алинә Хәбибуллина.